# казан утлары

11
НОЯБРЬ-1970

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
КЫРЫК ТУГЫЗЫНЧЫ ЕЛ ЧЫГА

11

НОЯБРЬ
1970

## БУ САНДА:

РОМАН, ПОВЕСТЬ, ХИКӘЯ, СКЕТЧ, ШИГЫРЬЛӘР

Н. ДӘҮЛИ. Рәхмәт сезгә, хатын-кызлар! Айга карап уйланганда. Дусларыма. Шигырьләр . . 3
Ш. РӘКЫЙПОВ. Таңнар һаман матурмы! Повесть . . . . . . . . . . . . . 7
С. КУДАШ. Ленин белән киңәш итәмен... Кышкы тылсым. Сагыну. Китәләр... Онытма. Юк, эзләмим. Кил әле... Шигырьләр. . . . . . 28
Ф. ХӨСНИ. Өзелгән җыр. Хикәя. . . . . . 32
Ә. ИСХАК. Төрле ел шигырьләре. Югалтудан соң. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . 47
Н. ФӘТТАХ. Әтил суы ака торур. Роман . . . . 53
З. МӘҖИТОВ. Йөрәкне син... Илдә тормыш... Ниең бар күңелеңдә... Бу ни хикмәт... Кояш кына... Сугылма, җил... Шигырьләр . . . . . 93
Ф. ШИҺАПОВА. Шундый бер моң... Соң аңладым... Шигырьләр . . . . . . . . . . . . 95
М. СИРАҖИ. Сукыр. Йолдызлы төн... Пар эз. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . 96
С. КАЛЬМЕТОВ. Китап сатучы. Скетч . . . . . 97
Р. ӘХМӘТҖАНОВ. Шагыйрьләр. Баш сөяген касә итеп... Күз. Күгемне ятим калдырып... Еракеракларндан. Карт монологы. Артта — үлем, алда — тормыш... Куркыныч булса да. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . . 100

ЗАМАНДАШЛАРЫБЫЗ

Т. СӘГЫЙТОВ. Тормыштагы эзләр . . . . . . . . 104

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Г. ХАЛИТ. Керәшчә әдип портреты . . . . . . 109

ЯЗУЧЫ АРХИВЫННАН

Г. ХУҖИЕВ. Салават күпере . . . . . . . . . 116

ГАЛИМНЕҢ ИҖАТ ПОРТРЕТЫ

М. МӘҺДИЕВ. Профессор Мөхәммәт Гайнуллин һәм татар филологиясе . . . . . . . . . 123

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ТӘРҖЕМӘ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Г. ХАНТЕМИРОВА. Тәрҗемәдә милли үзенчәлекләрне саклау . . . . . . . . . . . . . 128

КЫЗЫКЛЫ БИОГРАФИЯЛӘР

Р. ГАРӘФЕТДИНОВ. Өч революция бәркете . . 134
В. ИСХАКОВ. Алтмыш дүртенче кавалер . . . . 147

СӘНГАТЬ КЕШЕЛӘРЕ

И. ВӘЛИТОВА. Җырдай матур гомер . . . . . 157

БАТЫРЛАР КИТАБЫНА

Революция баһадирлары . . . . . . . . . . 164

ИСТӘЛЕКЛӘР, ЯЗМАЛАР

Ф. ХӘМИДУЛЛИН. 1918—1919 елларда Казанда культура хәрәкәте . . . . . . . . . . 169

АЛАР БЕЗДӘ БУЛГАННАР

В. КЛИМЕНТОВСКИЙ. Университетның беренче студентлары . . . . . . . . . . . . . . 175

Бәләкәй рецензияләр . . . . . . . . . . . 180

ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ...

Р. ИСАЕВ. Алма бабай. Үз башына төшсә. Хикәяләр . . . . . . . . . . . . . . . . 184
И. ТУКТАР. Җөмләләр . . . . . . . . . . 188

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

Редакциягә килгән
кульязмалар
кире кайтарылмый

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: җаваплы редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52, бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*

Баш редактор: Зәки Нури.
Редколлегия: Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова, Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Газиз Мөхәммәтшин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.

Производствога бирелде 10/VIII-1970 ел. Басарга кул куелды 23/IX-1970 ел. ПФ 09094. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 80246 экз. Заказ С-450. Бәясе 50 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан. Бауман урамы, йорт 19. 1970 ел.

## Нәби Дәүли

### Рәхмәт сезгә, хатын-кызлар!

Мин уйласам узган тормышымны,
Күз алдыма килә елларым,
Рәхмәт сезгә, рәхмәт, хатын-кызлар,
Сезнең белән —
Мин бәхетсез кеше булмадым.

Ятимлектә калган көннәремдә,
Ялгызлыкта анам булдыгыз.
Елаганда мине юаттыгыз,
Баштан сыйпап,
Иркәләде җылы кулыгыз.

Ерак иде алда өметләрем,
Юлларымда озата килдегез.
Рәхмәт сезгә, рәхмәт, хатын-кызлар,
Кайгыларны
Сез йөземә карап белдегез.

Өстемдә юк иде затлы кием,
Юка иде «шиблет» аякта.
Мин үземне бөек итеп сиздем,
Сезнең күзләр
Бер елмаеп миңа караса.

Ямьсез идем, керпе чәчле идем,
Ә сез мине: «Матур!» дидегез.
Рәхмәт сезгә, рәхмәт, хатын-кызлар,
Йөрәк белән:
«Ямьле бул!» — дип акыл бирдегез.

Мин дөньяны әле белми идем,
Тубыклардан иде зур диңгез.
Кире беткән усал малай идем,
Ә сез миңа:
«Син акыллы егет!» — дидегез.

Мин ышандым сезнең шул сүзләргә,
Теләкләрне сезнең акладым.

Рәхмәт сезгә, рәхмәт, хатын-кызлар,
Хәзер инде —
Соңгы сүзне әйтер чакларым.

Янып-көеп йөрдем бу дөньяда,
Узып кайттым утлы юл аша.
Кайгы белән әле яшәп була,
Мөмкин түгел
Сезнең сөю җирдә булмаса.

Еллар узды, мин дә кеше булдым,
Шул көнемне сагынып көттегез.
Рәхмәт сезгә, рәхмәт, хатын-кызлар,
Сез бит мине
Акыллы һәм матур иттегез.

## Айга карап уйланганда

Ай!
Гомер буе сиңа гашыйк булдым,
Серле идең ничә гасырлар.
Кичә генә әле җир кешеләре
Сиңа барып аяк бастылар.
Кемгә шатлык, ләкин минем өчен
Бу хәбәрләр кайгы шикелле.
Шул минутта минем сөйгән ярым
Ят кулларга калды шикелле.
Ай!
Карый идем төнлә синең йөзгә,
Зөһрә кызны искә төшереп.
Тора иде ул кыз йолдызларга
Чиләгеннән сулар эчереп.
Ай!
Мин яраттым сине сафлык өчен,
Ялгыз чакта күңел юаттым.
Яктылыгың өчен кара төндә,
Ераклыгың өчен яраттым.
Минем инде йөрәк ярсып тибә,
Калдым кебек ялгыз дөньяда.
Сине яклап бүген сүз әйтергә
Хак бирелгән җирдә миңа да.
Ай!
Гомер буе сиңа гашыйк булдым,
Серле идең ничә гасырлар.
Кичә генә әле җир кешеләре
Сиңа барып аяк бастылар.
Яшәделәр бары ярты тәүлек,
«Чадра» белән каплап йөзләрен.
Саф тәнеңдә тимер башмакларның
Калдырдылар салкын эзләрен.
Космонавтлар таза, яшь егетләр,
Батырлар да алар, уңганнар.
Батырлар да... ләкин йөрәкләрен
Тимер белән каплап куйганнар.

Ай!
Ә син, беләм, беләм,— теләр идең
Ялан куллар кочып алганын.
Сизәр идең менә шул чагында
Йөрәкләрнең ничек янганын.
Тояр идең кеше җылылыгын,
Белер идең кайнар хисләрен.
Күрер идең бәлки таш өстендә
Тәүге гөлләр ничек үскәнен.
Алар...
Алар сиңа нәрсә китерделәр?
Ефәк байрак бүләк иттеләр.
Ә үзләре синең таш энҗене
Илләренә алып киттеләр.
Китте алар, ә син карап калдың,
Гаҗәпләнеп мондый хәлләргә.
Җирдә бәлки, бәлки бер мин генә
Моңлы идем шушы көннәрдә.
Әйтерсең лә, Зөһрә күкрәгеннән
Гәүһәрләрен өзеп алдылар.
Ул матурның зәңгәр чиләгеннән
Җир өстенә чыклар тамдылар...
Космонавтлар җиргә очып кайтты,
Төн йокымнан кинәт уяндым.
Кемгә шатлык, кемгә кайгы кебек,
Авыр сулап тагын уйландым.
Космонавтлар ята карантинда
Йозак салган бина эчендә.
Рәсемнәре дөнья экранында,
Гәүдәләре үлчәү өстендә.
Кан бирәләр алар анализга,
Чәчләрен дә йолкып бирәләр.
Доктор карый, ләкин үзе курка,
Кулларында нейлон бияләй.
Ай ташлары бикле тартмаларда,
Камерада гүя тоткыннар.
Ә кешеләрдән ташка микроб керсә,
Ул чагында нишләр докторлар?
Ай!
Күрәсеңме, дустым, җирдә сине
Рентгеннарга куеп күзлиләр.
Америка Кушма Штатлары
Курка-курка микроб эзлиләр.
Ай!
Мин оялам хәзер синең өчен,
Кимсетәләр кебек җанымны:
Бер кабат та әле үбелмәгән,
Гомер буе сөйгән ярымны.
Минем өчен бәлки онытылмаслык —
Бу хурлыклы авыр минутлар...
Штатларның әле үз йортында
Агрессия дигән микроб бар.
Ә ул микроб кыра авылларны,
Шәһәрләрне калдыра исемсез.
Балаларны яндыра бишекләрдә,
Кешелекне калдыра кешесез.

Ай!
Син белеп тор менә шушы хакта,
Барып җитсен сиңа уйларым.
Синең тәнгә кемнәр кагылса да,
Юып килсен башта кулларын.
Җирдә әле ал да, гөл дә түгел,
Яман чирләр җирне йөдәтә.
Бар микроблар — кеше төсле алар —
Фашист дигән исем йөретә.
Бар тираннар, әле бар хунталар —
Богау ясый, сала төрмәләр.
Алар айны бары бер кечкенә
Концлагерь итеп күрәләр.
Ай!
Син белеп тор менә шушы хакта,
Язмышыңа сизгер кара син.
Ул микроблар синдә таралмасын,
Әзер булсын синең карантин!

## Дусларыма

Бер вакытта миңа илле тулды,
Дус-ишләрем котлап килделәр;
— Кеше гомере илле генә түгел,
Алтмыштан да арта! — диделәр.
Без күтәрдек тулы бокалларны
Әйтә, әйтә бәйрәм тостларын.
— Озын гомер миңа теләдегез
Чын йөрәктән, якын дусларым!

Бүген миңа инде алтмыш тулды,
Дус-ишләрем кабат килделәр.
— Кеше гомере алтмыш кына түгел,
Җитмештән дә арта! — диделәр.
Без күтәрдек тулы бокалларны,
Әйтә-әйтә шатлык тостларын.
— Озын гомер миңа кирәк түгел,
Булмаганда якын дусларым.

Миңа инде җитмеш яшь тулганда,
Дус-ишләрем, тагын килегез:
— Кеше гомере җитмеш кенә түгел,
Сиксәннән дә арта! — диегез.
Күтәрербез тулы бокалларны,
Әйтә-әйтә шатлык тостларын.
Язмыш миңа озын гомер бирсә,
Бергә яшик, якын дусларым.

## Шамил Рәкыйпов

# ТАҢНАР ҺАМАН МАТУРМЫ?

*Укучыларыбыз язучы Шамил Рәкыйповны матбугатта уңай бәя алган «Геройлар эзеннән», «Чәчәкләр сөйли белә» һәм «Кайда син, Жан?» исемле китаплары буенча беләләр.*

*Үткән ел журналыбызның бер санында аның «Егерме алтының берсе» исемле очеркы басылып чыккан иде. Анда халкыбызның беренче Советлар Союзы Герое Гыйльфан Әбүбәкер улы Батыршинның 1938 елда Хасан күле районында илебез чикләрен бозып кергән япон илбасарларына каршы сугыштагы батырлыклары сурәтләнде. Бу бәрелешләрдә Гыйльфан, дошманны кыйнау белән бергә, яралы тугыз иптәшен су аркылы алып чыгып коткарып кала.*

*Автор геройның язмышы белән ахырынача кызыксына: архивлардан эзләнә, Батыршинны якыннан белгән күп кешеләр белән очраша. Һәм шулай итеп, «Таңнар һаман матурмы?» исемле документаль яңа повесть туа. Әсәрдә шулай ук украин халкының батыр улы, Гыйльфан Батыршинның дусты, Советлар Союзы Герое Иван Давидович Чернопяткога да киң урын бирелә. Яңа әсәр асылда шушы аерылмас ике дус турында. Аларның язмышлары гаҗәеп кызыклы: икесе бер елда туалар, бергә укыйлар, шахтада бергә эшлиләр, бергә үк Армия сафларына алынып, бер үк заставада хезмәт итәләр һәм 1938 елда япон илбасарларына каршы күрсәткән батырлыклары өчен бер үк указ белән икесе дә Советлар Союзы Герое исеменә лаек булалар. Аннары — Хәрби академиядә бергә, Бөек Ватан сугышы башланган көннәрдә чик буенда бергә, Җиңү көнендә бергә. Каһарманнарның 1946 елда һәлак булулары да бергә була...*

*Хәзер аерылмас ике дусның якты истәлеген мәңгеләштереп, ике ак лайнер океаннарны гизә. Аларның берсе «Гыйльфан Батыршин» исемле, икенчесе — «Иван Чернопятко».*

*Укучыларыбызга шул әсәрдән кайбер өзекләр тәкъдим итәбез.*

### Диңгез белән сөйләшү



Кичә миңа балыкчы карт гаҗәеп бер әкият сөйләде. Шуның тәэсиреннән айный алмыйча керфек какмый төн үткәрдем, таң аттырдым.

Менә мин кабат таш кыялы диңгез ярында басып торам. Уйланам, күңелемнән генә диңгезгә өн салам.

Тузгак яллы чал дулкыннар бер-берләрен ашыктырып миңа таба тәгәриләр, авыр ыңгырашып үзара пышылдашалар да, бәйдән ычкынгандай ярсып, кинәт ярга ташланалар. Күкрәген киереп торган таш кыяның ачулы дулкыннарга һич исе китми: ул аларны җиңел генә этеп җибәрә шикелле, дулкыннар күккә сикерәләр, һавага

су тамчылары чәчеп, күбекләнеп бер мәлгә тынып калалар, аннары кинәт исләренә килгән төсле, ашыга-ашыга үзләренең бишегенә — дингез эченә йөгерәләр. Аларга саф-саф тезелеп килгән яңа зур дулкыннар очрый. Болары — гайрәтлеләр, җинелгәннәр белән сөйләшеп торырга да гарьләнәләр шикелле. Алар ашыгалар, кабаланалар. Күккә кабат су баганалары ыргый, күктән кабат шарлавыклар ага, җилләнеп-җилләнеп яңгыр сибәли. Бу юлы барысы бетте, ишелде сыман. Ләкин таш кыя су туфаны астыннан берни булмагандай калкып чыга, иңнәрен җәеп, бетмәс көчен, арткан дәрманын күрсәтә. Гайрәтләнүләре бушка китүен сизгән дулкыннар, күбекле итәкләрен җыя-җыя, дингезгә шылалар. Аларны тагын да гайрәтлерәкләре каршылый. Тик барыбер таш кыя кымшанмый. Ул элеккечә мәгърур басып тора бирә...

Дингез, дингез! Нигә болай ярсыйсың, котырасың син?! Әле кичә генә ягымлы, мәрхәмәтле идең бит. Әллә сереңне бүтән берәүгә сөйләгәне өчен балыкчы картка хәтерең калдымы? Рәнҗемә, үпкәләмә син аңа! Ул сөйләгән әкиятне калебемә мәңгегә бикләдем мин!

...Икесе ике бишектә үсеп, газиз әнкәләренә икесе ике телдә «әни» дип эндәшсәләр дә, бу ике сабый бер-беренә ике тамчы су кебек охшаган булган. Йөрәкләрендә мәңге сүнмәслек нур балкыган. Кара көчләрне көйдергән, дусны-якынны җылыткан, сөендергән бу нур. Бер төптән үсеп чыккан ике имән кебек, аларны беркем дә бер-берсеннән аера алмаган.

Җир асты патшасының бердәнбер чибәр кызы нишләп кенә карамаган бу ике дусны үз тозагына эләктерү өчен! Дөм караңгы патшалыгында адаштырып, кайтыр юлларын бикләгән, ашарга-эчәргә бирмәгән. Барыбер җиңә алмагач, хәзинәләре белән дә кызыктырмакчы булып караган. Җем-җем итеп торган затлы таҗын-калфагын, алтын алкаларын, беләзек, балдакларын, чулпыларын, сандык-сандык алтын тәңкәләрен күрсәткән. Бу байлыкларга хуҗа булырга теләп, егетләр үзара сугыша башларлар дип көткән, көтә-көтә арып беткән.

Егетләрнең байлыкка исләре китмәгән, алар җир куенына елышканнар, гап-гади кара ташларны тәннәре белән җылытканнар, кайнар тирләре белән сугарганнар. Шуңа күрә бу ташлар җир өстенә чыгуга ахактай ялкынланып янып киткәннәр, кешеләрне бәхетле иткәннәр.

Үзләрен бик зурга санаган капкорсакларның мондый хәлгә эчләре пошкан, һәммәсе бу бәхетле илгә берәр төрле этлек эшләргә маташкан. Алар коткысына бирелгән илбасарлар бу якка уклар ата башлагач, аерылмас ике дус сөңге-кылычын кайрап акбүз атларга атланып чыгып киткәннәр, күз ачып йомганчы ил чикләренә килеп җиткәннәр. Күкрәк киереп дошманга каршы торганнар, каты дауда явыз илбасарларны кырганнар... Боларның йөрәк кылларына чиертүче дә табылган берәздән. Алар су кызыдай бер гүзәлгә гашыйк булганнар. Барысы көтә, ниһаять, дуслык бетә, дип өмет итә. Ләкин... Чын дуслар арасында барыбер дау чыкмый. Чибәр кыз, аптырап, күккә очып китә.

Көнләшүдән кара көйгән явыз көчләр бергә җыелып киңәшәләр, кабат мәкер һәм хәйләне эшкә җигәләр. Бу ике дусның күккә менеп чибәр кызны эзләп кайткан чаклары була. Давыл куба, яшен яшьни. Дуслар утырган көмеш очкыч түзми — җимерелә һәм таш шикелле аска, упкынга атыла...

Кашыңны җыерма, йөзеңне чытма, чал дингез: ике дус турындагы бу гаҗәеп кыйсса әкияткә бик охшаса да, әкият түгел, булган хәл бу, булган хәл!

Моннан егерме дүрт ел элек, таш кыялы шушы ярларга җитәрәк, бер җитез очкыч ни сәбәпледер һәлакәткә очраган иде. Хәтерлисеңме, дингез, бу фаҗигане? Ул чакта да бүгенгедәй давыллы, куркыныч идең син. Ярсыган дулкыннарың канаты каерылган җитез очкычны комсызланып үз кочакларына суырып алдылар, тирән упкының аларга

билгесез кабер булды. Беләсенме: кемнәрне күмдең син үзеңнең төпсез упкынына? Бер-берсенә ике тамчы су кебек охшаган, суга батырып та аерырга мөмкин булмаган Гыйльфан белән Иван ята бит анда!

Аларның җансыз гәүдәләрен мәңгелек тынлык сакланган тирән упкынына суырып алдың да фаҗигале һәлакәт турында кешеләргә бер сүз дә сөйләргә теләмисең. Юкка! Алар барыбер безнең күңелләрдә яшиләр...

Мин кояш чыккан якка карап торам. Очкыч чама белән әнә шул тирәләрдә су төбенә чумган, япон башкисәрләрен хөкем итеп Токиодан кайта торган пәһлеван йөрәкле ике батырның гомере әнә шунда өзелгән.

Диңгез һаман ярсый, һаман котыра.

Тынычлан, чал диңгез, сөйлә гомерләре мәңгелек гүзәл җырга тиң ике ир-егетнең батыр үлеме турында, житкер безгә аларның соңгы сүзләрен, теләкләрен...

Үлгәннәр эндәшмиләр...

Алар өчен хәзер тереләр сөйләргә, алар эшен тереләр дәвам итәргә тиеш.

Мин Гыйльфанның балачагына, яшьлегенә юнәләм. Батырларның матур эзләре буйлап юл алам.

## Беренче тукталыш

Поезд Голубовка станциясенә вакытыннан иртәрәк килеп житте. Берничә кеше вагоннан төшеп калдык. Алар шунда яшәүчеләр иде булса кирәк, станциягә кереп тә тормастан, төрлесе-төрле сукмакны сайлап, эреп югалгандай юкка чыктылар.

Мин ашыкмадым. Көпчәкләр җырын тыңлап, моңаеп калган тимер юлдан уңгарак каерып, калкулыкка күтәрелдем. Таң атып килә иде. Каршымда искиткеч гүзәл күренеш: җир өстенә өрсәң таралып китәргә торган җиңелчә күксел томан төшкән, диңгез эчендәге кечкенә утрауларны хәтерләткән, Мисыр пирамидалары шикелле терриконнарда дистәләрчә утлар җемелди, кәпәчен кыңгыр салган, озын зифа буйлы спортчы егетләргә бик охшаган шахта коперлары менә-менә туп куарга йөгереп китәрләр сыман. Чыннан да, әнә каршыдагы шахтадан ниндидер карамчык тәгәрәп чыкты түгелме? Әйе, ул терриконга таба бара, текә дип тормый, һаман өскә, терриконның түбәсенә күтәрелә... Беләм, бу карамчык — җир куеныннан чыккан вагонетка; ул тар тимер юл буйлап менәр-менәр дә, махсус җайланмага кереп, әйләнеп капланыр һәм ташкүмер юлдашы булган каты тау токымнары бер-берсен этә-төртә аска таба тәгәрәрләр. Әнә шулай булды да! Унда да, сулда да, берәрәк тә, арырак та шундый ук хәл күзгә чалына. Кешеләр күренми. Таулар тын тора, таулар гүя йокыга талганнар. Алар, ниндидер тылсымлы көч ихтыярына буйсынып, йокылы-уяулы, һаман бер үк хәрәкәтләрне кабатлыйлар кебек.

Ара-тирә паровоз кычкырткан, дөбердәтеп әйбер бушаткан тавышлар ишетелә.

Һавага әчкелтем күкерт исе таралган. Миллион еллар җир куенында яткан кайбер тау токымнары өскә чыккач үзлекләреннән пыскый-яна башлыйлар икән. Терриконнар шуңа төтенли...

Бу — Донбасс! Россиянең йөрәген көчлерәк типтергән, берәүләрне мәңгегә аерган, икенчеләрне кавыштырган, һәр карыш җире тир һәм кан белән сугарылган атаклы Донбасс бу!..

Кировскийның шәһәр дип йөртелә башлавына әле өч кенә ел. (Элек ул Голубовка рудниги тирәсенә салынган берничә казарма, эреле-ваклы мескен алачыклардан, землянкалардан торган ярлы бер поселок булган.) Шахтерлар иәкъ шәһәр уртасындагы киң мәйданга Сергей

Мироновыч Кировның мәһабәт һәйкәлен куйганнар, мәйдан тирәли өчәр-дүртәр катлы таш йортлар, культура, көнкүреш учреждениеләре житкергәннәр.

Яңа урамнарның берсе халкыбызның беренче Советлар Союзы Герое Гыйльфан Батыршин исемендә. Ул шулай ук Кировскийның да беренче герое. Шәһәрдәге пионер оешмасы аның исемендә.

Геройны яшьли үк белгән кешеләр шактый икән бирелә. Иң сөенечлесе шул булды: ул яшәгән йорт үзгәрешсез саклана, аны тәрбияләп үстергән абзасы Хәлиулла һәм җиңгәсе Шәмгелҗәннан Гобәйдуллиннар исән-сау икән әле.

Партизан урамында егерме икенче йортның капкасын шакыйм. Чылбырда эт үрсәләнә. Илле биш-алтмыш яшьләр тирәсе бер агай аны тиз генә тынычландырып, бикләвечне ача.

— Ә... сез Гыйльфан турында язучы,— ди ул һәм, елмаеп, күрешергә кулын суза.— Мин Габдулла Гобәйдуллин булам. Хәлиулланың олы улы. Гыйльфан белән бергә үстек. Ул гына, мәрхүм...— Габдулла агайның шат чырагена хәсрәт күләгәсе үрмәли, җыерчыклар тирәнәяләр.

Бераздан өйгә керәбез. Ап-ак чөй сакаллы Хәлиулла бабай һәм аның гомер юлдашы Шәмгелҗәннан әби башта аптырап калдылар, аннары, күзләрен яшьләндереп, өс-баш киемнәремне чишендерергә, туган як хәбәрләрен сорашырга керештеләр.

СССР чик буе гаскәрләре музеенда саклана торган бер рәсми кәгазьдә (ул 1938 елда язылган) Гыйльфан Батыршин әнисе белән бертуган абзасы Хәлиулланы һәм җиңгәсе Шәмгелҗәннанны чиксез хөрмәт итүен, алар тәрбиясендә үсүен белдерә. Шуларның һәммәсен хуҗалардан сорашам.

Хәлиулла абзый сүзне еракдан башлады. Донбасска ул 1910 елда хәзерге Биектау районының Ямәширмә авылыннан килгән. Һәм 1938 елга чаклы җир астында эшләгән. Забойда күмер чапкан, җигелеп чана тарткан, штректа ат куган (коногон), әртилщик (бригадир) булган. Күп кешеләрне күмер чабу һөнәренә өйрәткән.

Алты баланы берүзе эшләп туйдырса да, сеңелесе Фатыйманы һәм аның улы кечкенә Гыйльфанны үз канаты астына сыендырган.

Хәлиулла абзый, аякларын бөкләп түр башына менеп утырган килеш, ашыкмыйча гына сөйли. Тыны кысылганда, тоныклана башлаган күзләрен йомып, туктап кала. Туксан яшь уен түгел шул. Әлегә чаклы карт бирешмәгән. Гыйльфан утырткан алмагачларның төбен йомшартканда тирләп азрак салкын тидергәнгә генә кәефсезрәк икән бүген. Гыйльфан салган мунчаның ләүкәсенә менеп чабынса, бу чир үтәчәк тә китәчәк...

## Кочаклашып күрешү

Җигүле ат җай гына баш чайкап, баш чайкаган саен муенына асылган кечкенә кыңгыравын шылтырата-шылтырата, үз көенә атлап бара. Вакыт-вакыт башын борып кешнәп ала: артта калган колынын чакыра. Арбага җиде-сигез яшьлек бер малай һәм сөйкемле чырайлы ир уртасы кеше утырган. Икесе дә бәйрәмчә киенгән: башларында өрйәңа салам эшләпә, өсләрендә чиккән якалы ак күлмәк, билләрендә кара чуклы ефәк билбау, аякларында ялтыравык итекләр.

Ир кеше, поселокның аргы башында күренеп торган часовнялы зиратка таба төртеп күрсәтә-күрсәтә, малайга нәрсәдер сөйли. Атасының сөйләгәне соң дәрәҗәдә тәэсир иткәнгәдер, ахры, малайның иреннәре дерелди, ул менә-менә елап җибәрер төсле.

Моны атасы да сизеп ала һәм улын кочаклый башлый.

— Син зур инде, улым. Синең белән хәзер барысын уртага салып,

ирләрчә сөйләшеп була. Әниең искә төшсә күңел дигәнең минем дә нечкәрә нечкәрүен... Тик ир кеше еламаска, нык булырга тиеш.

— Мин еламыйм, әти. Әнине генә кызганам. Әни исән булса, кунакка бергә килер идек. Тәмле бөккәнне аңа да кисеп бирер идек.

— Без аның өлешен зиратка илтербез... Менә килеп тә життек. Монысы инде Хәлиулла абыең ташпулаты була. Борыл әйдә, малкай...

Ат туктый. Өлкән Чернопятко арбадан житез генә сикереп төшә һәм капкадан башын чыгарып бу якка караган түбәтәйле малайга эндәшә: «Капканны ач, улым. Давид дәдәң сезгә кунакка килде»,— ди.

Төсе унган яшькелт күлмәген билдән берни белән бумаган, киндер ыштанлы, ялан аяклы ябык малай тиз-тиз бастырыкны этәрә, чалшаеп торган капканы оста гына жырлатып ачып жибәрә. Үзе капка артына поса.

Ишек алдына керәләр. Нигәдер тып-тын.

Иван, гаҗәпләнүеннән авызын ачып, үзе төсле кара чутыр малайга карап тора. Менә малай баягыча ук жырлатып капканы япты, хужа әзрәк сабыр ит әле дип куып жибәргән яшь колынга күз кырые белән генә сөеп карап алды да ат тугарышырга килде. Оста итеп тартып аркалык каешын чиште, камыт бавын ычкындырды.

— Синең жир жиләге ашаганың бармы? Яки гөмбә бөккәне? — дип сорады аңардан Давид.

— Жиләк ашаганым бар. Ә гөмбә — юк,— диде малай, моңсу гына.

— Яхшы. То-есть, яхшы түгел бу. Но бүген без жиләкне дә, гөмбә бөккәнен дә туйганчы ашап карарбыз.

Давид, шулай сөйләнә-сөйләнә, атны тәртә арасыннан чыгарып, тезгенне арбага бәйләп куйды, арбадагы ямь-яшел печәнне күпертте дә малайга кабат:

— Исемең ничек әле синең? — дип эндәште. Күзләрендә кызыксыну, ягымлылык чагылды.

— Гыйльфан...

— Давай хәзер танышыйк, Гыйльфан.— Ул уч төбе шомарган сөяк кебек ялтырап торган кулын Гыйльфанга сузды.— Давид Чернопятко. Ә арба артында күн итек башы белән жир казып торган бу егет Иван Чернопятко булыр. Кил, улым, бире. Шап иттереп күреш яшьтәшең белән. Менә шушы ут егет инде синең белән имезлек суыручы!

Юк, Иван арба артыннан да чыкмады, кулын Гыйльфан кулына шап иттереп сугып күрешмәде дә. Нигәдер оялып, аска карап тора бирде. Әтисе аның иңбашыннан тотып, Гыйльфанга таба этәргәч тә, абзарга керергә теләмәгән кәжә кебек, киреләнеп аяк терәп торды.

— Моңысы инде килешми, бөтенләй килешми, Иванушка,— диде Давид дәдә.— Гыйльфан, кайда соң хужалар? Нигә тавыш-тын юк? Йоклыйлармы әллә?

— Йокламыйлар. Түбән очка киттеләр. Ат суйган жиргә.— Гыйльфан кабат моңаеп аска карады.

— Нигә суялар ул атны?

— Мал дохтыры Радион дәдә әйткән, барыбер терелмәс, дигән.

— Ә син нигә бармадың?

— Өй сакларга калдым,— диде малай.— Атны жәллим. Суйганны карап тора алмыйм...

— Аңлашыла...— дип, Давид Гыйльфанның жилкәсенә кулын салды.— Аңлашыла, браток. Скрипка кылы кебек нечкә күңелле икәнсең... Ну, әйдәгез, күчтәначләрне өйгә кертик.

Иванны, әйтерсең, алмаштырып куйдылар. Табигать биргән эчкерсез юмартлыгы оялчанлыгын жиңде. Сикереп арбага менде, хуш исле дымлы печәнне актарып ташлады, алкалары салынып торган шома яфраклы себеркеләрне читкә этәрде. Астан өсте алъяпкыч белән тартып бәйләнгән козау һәм бәләкәй бер төенчек килеп чыкты.

— Монысында гөмбә бөккәне, монысында җиләк,— диде Иван. Әйтеп кенә калмады, козауның эченә тыгылып, күрүгә авыздан сулар китерә торган, алсуланып пешкән бер уч җиләкне Гыйльфанга алып та бирде.

Гыйльфан ризыктан баш тарта торганнардан түгел. Аннары — мондый тәмле нәрсәләр аңа еш эләкми иде. Кунак килсә, шундые килсен икән аның! Ичмаса, авыз тутырып ашап калып була. Бәлки әле Иван тагын берәр уч җиләк бирер? Әтисе елмаеп кына тора ич. Шундый әтиең булса икән...

Барысының да әтисе үз янында. Күрше малайларының да, менә бу Иванның да. Әнә ничаклы җиләккә хуҗа ул. Әтисе белән атка утырып барып, урманнан җыйганнардыр. Кара син тагын өстендәге киемнәрен! Күн итеге дә елык-елык итә! Ә Гыйльфанга тишек калош та эләкми әле. Чөнки алар күбәү. Узган кыш әнә калын олтанлы солдат ботинкасын Кәлимулла белән алмаш-тилмәш киделәр. Ярый әле: берсе иртән, икенчесе төштән соң укыды. Мондый чиккән якалы ак күлмәкләр Гыйльфанның төшенә дә кергәне юк. Дөрес, Шәмгөлҗәннан җиңгәсе малайларның күлмәк-ыштанын еш юып алмаштыра. Шулай да, иске иске инде ул. Коймага-фәләнгә менсәң, черт итә дә шәрә тәнең ачылып китә...

Давид дәдә сүзендә тора торган кеше икән. Туйганчы җиләк ашатырмын дип юри әйтәме дисәң, өйгә кергәч, козаудан зур бер җамаяк тутырып алды да бирде. Икәү утырып ашагыз, диде. Иван, тук бәти төсле, җиләкләрне этеп-төртеп, чемченеп кенә утырды. Ә Гыйльфан состы гына.

Үпкә-бавыр, эчәк-карын салынган табак-савытларын күтәреп, көтүе белән чебен ияртеп өй хуҗалары кайтып кергәндә, Гыйльфан кунак малай белән дуслашып уенчык әйберләр алмашкан, аларның үзләрендә ике көн торачакларын, зиратка әнисе каберен төзәтергә барачакларын белгән, озата барырга үзе дә чакырылган, кыскасы, аның күңеле тәмам түгәрәкләнгән иде.

Давид дәдә белән Хәлиулла абзый туганнарча кочаклашып күрештеләр. Шәмгөлҗәннан җиңгәләре авызын яулык чите белән каплап, тартынып кына исәнләште. Хәлне иренең күз карашыннан аңлап, ураза вакыты булганга көпә-көндез төтен чыгарудан гаять дәрәҗәдә шомланып, ләкин ире ихтыярыннан уза алмыйча авыр көрсенеп, самовар куярга, мич кабызырга чыгып китте. Сабыр холыклы, басынкы хатын иде ул. Аның уенча, дөньяда Хәлиулладан башка ир юк, яшәү юк, аның кодрәте җитмәгән нәрсә юк. Ире суламый тор дип әйтә икән, ул моңа да сүзсез күнә, карышмый. Вакыт-вакыт күңелендә иренә карата ризасызлык туа тууын, бигрәк тә дин-шәригать мәсьәләләрендә килешә алмыйлар иде. Хәлиулла абзый үзе ураза тотмый, балаларны да тоттырмый, гает, бәйрәмнәрдә өйгә мулла чакырмый, сәдака бирми. Телгәтешкә керәм дип тә курыкмый. Менә бүген дә шул ук хәл...

Кар базыннан май, корт, бавырсак кебек нәрсәләр чыкты, өй түбәсеннән бөкләме белән казылык төште. Хәлиулла абзый, түбәтәен кыңгыр салып, мыек астыннан гына канәгать елмая-елмая, үткен пычак белән казылык телде. Гыйльфан белән Иванны чакырып алып, мае сыгылып торган ике зур кисәкне кулларына тоттырды.

— Ягез әле үлчәшегез, кайсыгыз зуррак икән? — дип малайларны янәшә бастырды.

Иван Гыйльфаннан калкурак иде. Гыйльфанның кунак малайдан кечкенә күренәсе килмәде, ахры, аяк очларына басып, дусты белән тигезләште. Олылар, Гыйльфанның бу хәйләсен күреп, шаркылдап көлешеп куйдылар.

Хәлиулла абзый малайларны кочагына алды: «Әле кайчан гына сәкедә имезлек суырып яткан идегез. Инде менә янәшә басып казылык

кимерәсез! — диде.— Үтә гомерләр! Ярый, бәхетегез бар, заманнар яхшырды»,— диде.

Малайлар, тамак туйдырып, ишегалдына чыгып киттеләр. Көн кичкә таба авышкач, эссе басыла төшкән иде. Качышлы уйный башладылар. Хәлиулла абзыйның уллары Габдулла, Хәбибулла, Кәлимулла, хәтта ике яшьлек Шамил дә уйнады. Көчдәгечә хәрәмләшмәделәр, кычкырышмадылар. Һәммәсе кунак малайга хөрмәт күрсәтергә, аңа ярарга тырышты.

## Гыйльфанның бишенче кыйссасы

— Өй белән мунча арасындагы беседкага игътибар иттегезме?

Ул хәзер әнә искергән инде... Заманында бик матур иде. Бәлки үзебез ясаганга шулай матур күренгәндер!.. Ни генә булмасын, анда ял итәргә, ә җәй көннәрендә тәмләп кенә чәй эчеп утырырга ярата идек без. Кемнең нәрсә эшләргә тиешлеге шунда ачыклана, хәбәрләрнең зурысы шунда сөйләнә. Ямаширмәдән кайтып төшкәч, Рәхиләне ярата башлавымны да Чернопяткога шунда әйттем мин.

Хәл белергә килгән иде. Мин аны тизрәк беседкага сөйрәдем. Авызым колакка җиткән, бер минут тик тора алмыйм.

Дөньялар матураеп китте! Ә Иванга аңа нәрсә? Үзе дә кызлар кебек оялчан егет, аска караган да кызарынып тик тора.

— Әгәр Рәхиләне күрсәң, ихластыр әгәр, син дә гашыйк булыр идең! — дидем мин аңа.

— Белмим... Белмим,— диде ул.

— Аның каравы безгә хәзер нәрсә эшләргә кирәген мин беләм: шахтага эшкә керәбез. К чорту техникумың! Миңа акча кирәк...

— Ярар, синеңчә булсын, Гыйльфан. Бергә дек бергә,— диде Иван.— Бераз эшләгәч, күз күрер тагы...

Роговларга киттек. Көн эссе. Бакчалардагы агачлар суга сусап, сәлберәешеп утыралар. Күләгәдәге тавыкларның канатлары салынып төшкән, авызларын ачканнар. Урамда җан әсәре юк, өйләрнең тәрәзә капкачлары ябылган, капкачсызлары эчтән томаланган.

Ванька Рогов, майка-трусиктан килеш, койкасында Лисичанск тау техникумына керү өчен имтиханнарга хәзерләнеп ята иде. Егет башаягы белән китапларга чумган.

— Ахмаклар сез! — диде ул эшкә керергә йөрүебезне белгәч.— Патриотлык күрсәтәсез?! Барыгыз, чумыгыз муеннан пычракка. Гәзиткә язып чыксыннар үзегезне: күмер фронты баһадирларына алмашка килә, дисеннәр. Әх, сез! — Ул, борынын җыерып, төкереп куйды, урынына сузылып ятты. Тимер койканың пружиналары зарланган сыман шыгырдашып алдылар.

Без Роговтан көлдек кенә. Мәхәббәтне аңлыймыни ул? Аннары, Рогов әйткәнчә, гәзиткә язып чыксалар да, эчебезне тишмәс иде. Шаккатарлык эшләрне — тайгада яңа шәһәрләр салуны, заводлар коруны, каналлар сузуны — могезлеләр түгел, безнең кебек яшьләр башкара ич. Алардан кай җиребез ким?!

Ил күмер сорый, яшьләрне шахтага чакыра. Барабыз! Безнең урын шахтада.

Шул хакта Хәлиулла абзыйга әйттек. Ул урмәле гөлләр белән чорналган беседкада тирләп-пешеп чәй эчеп утыра иде. Муенын сөлге белән сөртә-сөртә:

— Һай, әттәгенәсе! Әйтергә кирәк, башыгыз йомры икән сезнең, оланнар! Төтенегез туры чыга: дөрес карарга килгәнсез,— диде.— Как раз шахтерлар хәзерли торган училище сыман нәрсә ачарга торабыз.

Син, Иван, калкурак, отбойщиклыкка язып. Ә син, Гыйльфан, зирәгрәк, электрослесарь бул. Машина килә шахтага, балалар, машина!

— Юк, Хәлиулла абзый, без аерылмыйбыз. Без гел бергә,— Иван шулай диде дә, бу кыюлыгы өчен уңайсызланып, кысладай кызарды.

— Гел бергә?! — Хәлиулла абзыйның хәйләкәр кысык күзләре зур булып ачылды.— Әйтергә кирәк, монысы да хикмәтле сүз.— Ул урыныннан кузгалып куйды, сакалсыз ияген сыпырды, мыекларын төзәтте.— Хикмәтле сүз... Гел бергә. Шәп уйлагансыз, ирләрчә! Шәмгөлҗәннан, ишетәсеңме: гел бергә! — дип дәвам итте ул.— Амин! Хәерле сәгатьтә! Гел, мәңге бергә булсагыз иде.— Абзыем, кәефе килеп, кеткелдәп көлеп куйды, кәләпүшен төзәтте һәм: — Яса әле, хатын, чәеңне куе гына итеп. Сыйла әле үзләрен вәринҗәң белән! — диде.

Ул, безне ике ягына утыртып, илгә һәрвакыт чын күңелдән хезмәт итәргә кирәклеге, халыкның шундый кешеләрне генә ихтирам итүе турында аталарча ягымлылык белән озаклап сөйләде.

Без электрослесарьлар хәзерли торган группага язылдык. Ике айга якын укып, җир астында эшли торган механизмнар белән танышып йөрдек. Ниһаять, көннәрдән бер көнне безгә өр-яңа ап-ак брезент киемнәр бирделәр. Киендек. Онга төшкән тараканнарга охшап калганбыз. Бер-беребезне таный алмыйбыз. Ләкин йөрәкләр ашкынып тибә. Тизрәк, тизрәк аска! Әлегә кадәр бары тик ишетеп кенә белгән серле дөньяга! Әллә кайдан Хәлиулла абзый килеп чыкты. Мин малайларга: «Беләсезме, бу кем? Бу — минем абзыем!» — дип пышылдадым. Бер карышка үсеп киткәндәй булдым. Ә абзыем мине бар дип тә белми.

— Шахта ул, энекәйләрем,— диде Хәлиулла абзый, кыштыр-кыштыр иң алдан атлап,— кәпрәеп өскә карап йөрүчеләрне яратмый. Борын чөйдеңме — маңгаеңны тишәсең. Шахта ул үзенә баш игәнне ярата, тәртип ярата. Аста шырпы сызу, тәмәке тарту кебек азгынлыкларны бүгеннән гомергә онытыгыз...

Хәлиулла абзый безне лампповойга ияртеп китте. Кечкенә тәрәзәгә чиратка бастык. Килеп җитүгә, үз фамилияңне әйтәсең дә лампа кабул итеп аласың. Алар җемелдәп янып тора. Икенче тәрәзәдә сиңа калай кисәге — номер тоттыралар. Аннары, чын шахтерларча лампаңны селки-селки, шахта йорты аркылы үтәсең. Тәрәзә пыялаларына, стеналарга күмер тузаны утырган, аяк асты кап-кара.

Шахтаның төп бинасы якынрак килгән саен шомлырак күренә. Өстә бертуктаусыз зур корыч көпчәкләр выжлап әйләнә, көпчәкләрдән, сыгылмалы тирбәлеп, корыч арканнар йөгерә. Арканнар бетми дә бетми. Әйтерсең, кемдер бик зур көнҗәләдән җеп эрли.

Малай чакта без бирегә еш килә идек. Ләкин безне якын җибәрмиләр, куалар иде. Бер тапкыр Ванька Рогов белән бәхәсләшеп, шахтага төшәргә булдым. Ствол төбендә торучы хатын мине агач арасына поскан җирдән күреп алып, вагонеткадан сөйрәп чыгармаса, төшеп киткән дә булыр идем, бәлки.

Менә инде мин качып-посып түгел, кесәгә номер тыгып шахтага төшәм.

Җир куеныннан күмер чыга, эреле-ваклы кисәкләр чык бөртекләре кунгандай җемелдиләр. Яньчелгән, тутык баскан вагонеткалар тәмам алҗып беткәннәр сыман...

Нигәдер әни күз алдына килә. Аның кайдадыр якында гына моңаеп, үзәкләрне өзәрлек итеп кубыз уйнавын ишетәм төсле. Балачактан ук таныш «Шахта» көе якты дөнья белән бәхилләшүем турында искәртә кебек. Элеккеге шахтер җыры хәтеремдә яңара.

...Көн дә төшәм шахтага
Өч йөз сажинга кадәр.
Доганнан ташлама, энкәй,
Күмелеп калсам әгәр...

Китегез, китегез, дим, карангы уйлар, куркытмагыз, шомландырмагыз күңелемне! Шахтага төшкән һәр кеше аста күмелеп калса, Каф тавы кадәрле әнә теге террикон җирдә калка алыр идемени?!

Клеть көтеп торабыз. Откатчица кызлар, безнең якка карап, безне үчекләп, юри моңлы җыр сузалар шикелле.

Клеть менеп житте. Тимер зыңгылдады. Кызлар күмер белән тулы юеш вагонетканы тартып алдылар. Без тамчы тамып торган салкын клетька кереп тулдык. Ствол янындагы апа рәттән дүрт тапкыр сигнал тоткасын тарттты. Клеть азрак күтәрелде, тирбәнде һәм без баштанаяк төпсез карангыга чумдык. Лампаларыбызның яктысы тычкан күзе чаклы гына. Астан жил дулата, өстән шыбырдап салкын янгыр ява. Клеть вакыт-вакыт кинәт ычкынып киткәндәй була, тән чымыр-чымыр итә, бугазга төер тыгыла. Аякны тимер идәнгә терисең, кулыңдагы лампаңны катырак кысасың. Үз-үзеңә: «Җебемә, егет, чын шахтер бул!» — дисең.

Сирәк-сирәк утлар күренеп кала, стволдан ычкынып киткән таш кисәкләре, корыч ныгытмаларга бәрелеп, бик яман чыңлыйлар, вентиляторлар гүли, насослар гөжли.

Ниһаять, клеть дынк итеп җиргә бәрелә, ишек ачылып, дөньялар яктырып китә. Без, жиңел сулап, ярыйсы гына иркен штрекка чыгабыз. Идән такта, түшәмдә бүрәнәләр, як-якта баганалар. Шахта! Исәнме, карт шахта!

Безне Хәлиулла абзый иярте китте. Ул елларда шахтада хәзерге кебек электровозлар юк иде. Нәкъ теге жырда жырланганча: санщик забойдан чана сөйри, вагонеткаларны ат тарта. Төпсез караңгыда алда әледән-әле әче сызгыру янгырый. Бу — коногон шулай хәбәр бирә, юлдан читкә чыгып, стойкалар арасына посарга куша. Юкса күмер белән тулы, дулап килгән авыр вагонеткаларның сине канлы калҗага әверелдереп узулары ихтимал.

Лампаң белән юлны яктыртып барасың да барасың. Кабер тынлыгы. Бары тик тып-тып тамчы гына тама. Аяклар суда лач-лоч атлыйлар. Борынга әчкелтем ис килеп бәрелә...

Без шул шахтада эшли башладык. Яуга хәзерләнүче баһадир сыман кат-кат киенәсең, лампаңны биленә асып, коралларыңны иңеңә күтәрәсең дә — әйдә жир асты патшалыгына! Гөрләп-гүләп, еракта җемелдәгән утлары белән кызыктырып каршы ала сине карт шахта. Дымлы әчкелтем һавасы да күңеленә якын булып китә.

Без, электрослесарьлар, үзебез турыдан-туры күмер чапмыйбыз. Ләкин жир өстенә чыгарылган һәр тонна ягулыкта безнең өлеш зур. Әйтик, бурильщик кулындагы электр боравы минут саен кәҗәләнә башласа, ай-һай, смена нормасы үтәлер идеме икән? Ә ни өчен забойщик сиңа ярты чакрымнан сәлам бирә? Чөнки син һава вентильләрен тиешенчә караштырмасаң, фыркылдап-мыркылдап торган отбой чүкече белән бер вагонетка күмер чапканчы аның җан тирләре чыгачак! Чүкеч дулап, ярсып эшләсә, күмер ташкындай агыла — порожнягыңны гына өлгерт!

Мин еш кына забойга керәм дә кулыма отбой чүкече алам. Резин көпшәләрдәге кысылган һава кайсы ягы беләндер авызлыкланган ярсу атны хәтерләтә. Бу күндәм тулпар, сабырсызланып бер урында бии-бии, әмер көтә кебек. Азрак кына кагылдың исә, китәчәк, китәчәк... Менә без икәү моннан миллион еллар элек шаулаган абагалар карурманына барып керәбез. Ярсу атым-тулпарым пошкыра, тояклары белән таптана, киң күкрәге белән урманны ерып бара... Абагаларның ниндие генә юк монда: алтын сыман төслесе дә, кызгылты да, шәмәхәсе дә. Кояш шулай бизәгән аларны. Әссе. Аяк астыннан бакылдап озынча авызлы, үткен тешле эре-эре сәер кошлар очып китә, тирә-якта симез гәүдәле кәлтә сыман җанварлар утлап йөри... Болар — тирләп-

пешеп күмер кискәндә күңел күзе күргән хыяллар гына, әлбәттә. Чынлыкта ташкүмер, җемелдәп торса да, каты бәгырьле, салкын ул. Әнә ничек забойга сузылып яткан! Торып китәргә һич ашыкмый, үз бәясен белеп, чыбылдыклы ятагыннан горур гына кузгала ул. Отбой чүкече аны ашыктыра, куа... Күмер кантар-кантар булып кителеп төшә. Киртләч арты киртләч ватыла. Һәр киртләчтә тоник ут яктысында шәмәхә, чия, кызыл нурлар уйный. Күмер катламы, чыннан да, утырмага килгән кунак кызы кук, энҗеле күлмәкләрен кыштырдата-кыштырдата, мут күзләреннән ут чәчә-чәчә биергә төшә сыман... Нинди егет күңеле түзсен моңа?! Тәмам сихерләнеп эшлисең дә эшлисең. Забойдан җемелдәп, уйнап торган күмер кисәкләре коелалар да коелалар. Сокланыгыч күренеш!

Чү! Түбә шытырдый! Эчең жу итеп китә. Әгәр... Баш өстендә табигать үзе генә бизмәнгә сала алган таш тавы. Аны сагызлы нарат баганалар иңнәрендә күтәреп торалар. Кайчакларда бу баганаларның җегәре җитми... Шахтер бу хакта уйламый. Янында үзең төсле иптәшләрең булганда бәла-каза куркыныч түгел ул. Җир асты һавасын сулап, һәрвакыт иптәшләре ярдәмен тоеп эшләргә күнеккән егеткә җир өсте бик шау-шулы, киң юллар исә аңа чын-чынлап тар булып тоела...

## Гыйльфанның унынчы кыйссасы

Японнарны чик буеннан куып чыгаргач, заставаны рәтләргә керештек. Миңа үлгән иптәшләрне җирләргә куштылар. Бу хәл күңелгә гаять авыр тәэсир итте. Әле кичә генә синең янда уйнап-көлеп йөргән дусларың бүген юк инде... Алма кебек сөйгән ярларның керфекләре яшькә чыланды, курешү көннәрен сәгатьләп санап, зарыгып кавышу көткән яшь хатыннар тол калды, әти сүзен өйрәнеп кенә килгән алсу яңаклы балалар ятим калды. Боларның барысына бер төркем япон империалистлары сәбәпче. Коноэ Фумимаро, Итагаки Сейсиро, Мамору Сигемицу һәм тагын шулар ише ун-унбиш ерткыч эше бу. Тотасы иде үзләрен, бастырасы иде утлы табага кылган җинаятьләре өчен! Япониядә безнең ил белән тату яшәргә теләүче акыллы кешеләр дә күп. Ләкин аларга якты көн юк, аларны Сугамо дип аталган таш капчыкта черетәләр. Биклисе иде менә шунда ул Фумимароларның үзләрен, интексеннәр иде шунда кояш яктысын күрмичә, татысыннар иде азатлыкның тәмен!

Әнә шундый ярсулы тойгылар кичердем мин полкташ иптәшләремне җирләгәндә. Пулеметчы Елецев аеруча кызганыч булды. Каберенә чәчәкләр илтеп салдым. Кайчандыр Донбасста Хәбибулла каберенә шулай чәчәкләр китергән идем мин. Моңсуланып, бик озак уйланып торган идем.

Мин әле генә атымны кыргыч белән кырып, юып чистарттым да, тезгенен аягына бәйләп, утларга җибәрдем. Дутый (мин заставада да үз атыма шулай эндәшә идем), койрыгы белән чебен куа-куа, үлән ашап йөри. Анда-санда снаряд актарып ташлаган базларны, танклар шакмаклап узган юлларны исәпкә алмаганда, тирә-юньнең күзгә матурлыгына тел-теш тидерерлек түгел иде. Ат яратып ашый торган тукранбашлар, үрмәле эт эчәкләре, казаяклар купшыланып чәчәк атып утыра, алар тирәсендә гөжләп төклетуралар оча, әллә кайда үлән араларында чикерткәләр чырылдый, әйтерсең, монда канлы бәрелешләр бөтенләй булмаган. Хасан күле ягына колак салам. Тынлык. Сугыш шау-шуыннан куркып еракларга очып киткән кыр үрдәкләре үз ояларына кайтмаганнар әле. Кайтырлар алар, әлбәттә, кайтырлар.

Талгын җил Хомуку авылы ягыннан быргы, барабан тавышларын алып килә. Бу — японнарның хәрби оркестры. Анда император өчен

һәлак булганнарны соңгы юлга озаталар. Анда үлекләрнең сөякләре сыкраныррлык итеп зәһәр нотыклар сөйләнә, йодрык селки-селки янаулар кабатланып тора. Җеназаны кабахәт планнарны тормышка ашыру чарасы итеп файдаланудан да мәкерлерәк нәрсә булырмы тагын?!

Тәндәге җәрәхәт сызлый, контузия аркасында башым чатнап авырта. Хәлем шундыйрак дип бер кәлимә сүз әйткән булсам, минем үземне дә Иван янына госпитальгә озатырлар иде. Сиздермәдем. Заставада ул көннәрдә кеше житешми иде. Нарядка да бардым, хуҗалык эшләрен дә үтәдем. Шулай тынгысыз, эни әйтмешли, йорт җанлы булганыбыз өчен безнең халыкны аеруча яраталар бит.

Рәхиләдән хат юкка ике ай. Алтмыш көн бит ул! Миңа пышылдыйпышылдый: «Мин барыбер синеке булырмын. Син онытсаң да, синеке булырмын!» — дигән иде бит ул үзе. Ышанырлык итеп әйткән иде. Кызлар вәгъдәсе таңда төшкән чык суы кебек икән шул: ялтырап кояш чыга да эзсез югала... Гарьләнеп, ярсып Рәхиләгә хат язып җибәрдем. Берничә көн үткәч тагын яздым, тагын яшеннәр яшьнәттем. Җавап килмәгәч, ачудан: «Мин монда Марусяга өйләндем, бу минем сиңа соңгы хатым» дип, төзәтә алмаслык җүләрлек эшләдем. Ни хикмәттер, әрнеп, сыкрап язган хатларым Рәхиләгә барып ирешмәгән, ә менә соңгысын алган ул...

Минем отделение элек-электән хуҗалык эшләре белән мәшгуль булганлыктан, японнар тудырган мәшәкать күбесенчә безнең җилкәгә төште. Заставаны сакларга калган чик сакчылары, без самурайлар белән сугышкан арада, атлар абзарын сүтеп, баррикада сыман нәрсә ясаганнар. Малкайларны ачык һавада тотып булмый бит — кулга балта, пычкы алдык. Аннары складларны рәтләдек. Шулай итеп шактый вакыт үтеп китте. Сентябрь керде. Көз Приморьеда җилле, давыллы була. Бигрәк тә төннәр яман. Салкын. Яңгыр ява башласа, чиләкләп коя. Корыга китсә, ком бураны күтәрелеп, әбиеңә сәлам әйттерә. Тайфун котырган чакларда күк йөзе күренми. Тешне тешкә тидерер хәл юк — ком чытырдый, күзне, борынны әчеттерә. Чәч төбенә хәтле шул каһәр төшкән ком утыра.

Ләкин, тайфун котыра дип, кул кушырып утырып булмый. Чик буе бу. Андый чакларда үтә сизгер булырга кирәк. Нарядларны көчәйтәбез, ешрак алмашабыз. Кораллар тәртиптә, үзебез чишенмичә үк йоклыйбыз. Авыр, ләкин бирешмибез.

— Син, Батыршин, сәламәт түгел бит,— ди беркөнне парторг Иван Мошляк, минем койка янына килеп утырып.

— Контузия үтеп бара инде, иптәш лейтенант,— дим мин.

— Нәрсә борчый, сөйлә. Иванны сагынасыңмы, әллә нечкә билдән хат юкка йокы алмыймы? — ди.

— Икесе дә бар, ләкин ничего,— дим, сер бирергә теләмичә.

Рәхиләдән бик озак хат килмәве, шуның хәсрәтеннән өзгәләнеп кыйналуым турында иптәшләрдән берәрсе лейтенантка чишеп өлгергән, күрәсең. Уйлап-уйлап тордым да бернәрсә дә яшермичә барысын сөйләп бирдем. Тиңсенмичә борынын чөйгән булса, андый кыз өчен төн йокыларын калдырырга не стоит, ди лейтенант. Янәсе, Рәхилә миңа үзе ялыначак әле. Эреләнүе, масаюы өчен әй үкенәчәк, әй үкенәчәк әле. Имеш, Батыршинны бөтен ил хөрмәт итәчәк. Имеш, Батыршинның батырлыгын газитка язачаклар...

Герой исеме бирергә тәкъдим ителүчеләр арасында минем фамилия дә барлыгын белеп торганга шулай юаткан икән ул мине. Үзе капчык төбен селкеп тә бетерми — хәрби сер саклый. Мин бу мактауга унайсызланып, кызарып утырдым. Күңеле китек чакта сабый балаларны үзем дә шулай юата идем ич. Дөрес, үткән атнада майор Алексеев үзәктән килгән бер корреспондентны ни өчендер минем катка җибәргән иде җибәрүен. Самурайлар белән сугышу күренешләрен хәтерләтеп

теңкәне кортты. Мин аңа иптәшләр турында сөйлим, ул үзем турында сораша. Үзем турында тәки әллә ни сөйләмәдем. Хәзер моңа үкенеп бетә алмыйм: Рәхиләнең йөрәген җилкетү өчен генә булса да сөйлисем калган икән, билләһи! Газетаны укып, иреннәрен тешләгән булыр иде. Нинди форсат кулдан ычкынды бит! Хәерле булсын инде.

Икенче тапкыр очрашуда лейтенант:

— Хәлең бик авырмы? — ди, һаман нәрсәдер төпченә биреп.

— Авыр шул, ләкин түзәрлек,— дим.

— Сагышка бирелергә ярамый, туганкай! — ди бу, үзе дә уйга чумып. Аннары иңбашыма сугып куя:— Түз, озакламый барысы әйбәтләнер, ышан миңа! — ди.

Түзәргә тек түзәргә! Службамны әйбәт үтим. Буш вакытларымда ат абзарына Дутый янына барам. Чистартам, кыргычлыйм, йөртергә алып чыгам. Моң-зарымны сөйлим. Колакларын кайчы кебек очландырып тыңлап тора. Күзләрендә сагыш. Сөйләп җибәрер иде — белми. Аерылышуыбызны сизгән икән, бичара малкай.

Мин аның җырларын тарый-тарый:

> — Сагыну көйләренә шаулый микән
> Хасан күлләренең камышы?
> Ниләр генә күрми, нигә генә түзми
> Ир-егеткәй белән ат башы...—

дип акрын гына җырлап та җибәргәлим...

— Бая полк партия оешмасы секретаре лейтенант Мошляк турында сүз кузгаткан идем бит... Аның соравы буенчадыр инде, тиздән миңа минометчылар хәзерли торган курска китәргә боерык килде. Бер төркем иптәшләр Хабаровскига киттек. Яхшы минометчы булу өчен котелогыңны, ягъни башыңны эшләтергә кирәк. Дөрес һәм тиз исәпли белмәсәң, цельгә тидергәнче үзеңне чүкеп кәтлит ясаячаклар. Яңа һөнәрне тештырнагым белән ябышып үзләштерәм. Элек күңел биреп укуның файдасы тиде. Полигонда көне буе минометтан атабыз, маневрлар ясыйбыз, чигенәбез, һөҗүмгә күчәбез. Ә кич артиллерия складына кайтып авабыз. Шунда төн кунабыз. Эт салкыны. Сикереп торып, тыпырдап җылынасың. Тешләр тешкә тими. Азрак суык алдырганмын. Ләкин лазарет турында авыз да ачмыйм. Курсны бетерәм дә вәссәлам! Тәки отличнога тапшырдым. Юлга азык-төлек алып, Хабаровск вокзалына юнәлдек. Егерме җиденче октябрьга билетлар алдык. Вокзал тирәсендә айкалабыз. Иван янына госпитальгә сугылып чыгарга исәп тотам. Үткән атнада гына озакламыйча кайтарып җибәрерләр инде, хәлем әйбәт, дип язган иде ул. Бәлки, бергә үк кайтырга туры килмәсме, ә, дим. Иптәшләр көләләр, янәсе, лучше кызлар янына барырга кирәк. Юк, дим, кызлар — башка статья, дуслык — башка.

> Бергә тудык, бергә үстек,
> Бергәдер безнең әҗәл,—

дип тагын шаяртып такмаклап алам. Һәм гомерлек дустым Иван өчен җаным да җәл түгеллеген әйтәм.

— Җаныңны түгел, җаныкаеңны да бирмәс идең әле! — ди иптәшләрнең берсе, күзләрен мутландырып.

— Әгәр дустымның аның белән бәхетле буласын белсәмме? Валлаһи менә, бирер идем! — дим, бер дә икеләнмичә.

Уйлар, уйлар... Рәхилә күз алдына килә. Казанда яшәгәндә иртән йокыдан уянып чаршау эченнән балкып чыккан бәхетле Хафизә исемә төшә. Рәхиләнең йөзе дә шулай балкып тора. Имеш, ул чаршау эчендә Иван белән йоклаган. Көнләшү корты күңелне кимерә башлый. Әһә, дим, Иванга кечкенә кульяулыкны тикмәгә генә бирмәгән икән Рәхилә. Минем кульяулык штабтан кайтмады, ә Иван түш кесәсендә саклый. Әнә Иван татарча ватып-сындырып:

Тал бөгелә, тал бөгелә,
Тал бөгелә икән ул.
Җан яраткан, күңел тарткан
Яр бер генә икән ул! —

дип такмаклый. Үзем өйрәткән җыр. Хәзер ул шуны минем Рәхиләмә җырлый, имеш...

Ух!.. Нишләргә?! Ләкин мин дуамал тойгыма дуларга ирек бирмим. Әгәр бер-берсен яратышсалар, читкә китәрмен, дим. Җаны теләгән — елан ите ашаган дип, киң күңелле булырга тырышам. Шулай да әлегә бу хәлгә дучар булмавыма шөкер итәм.

Казандагы туганнар турында уйланам. Әнвәр, Абдулла нишли икән? Әминә зур кыз булгандыр инде. Кабат Рәхилә искә төшә... Тәмам җелеккә үтте бу кыз!

Каударланып, кызу-кызу атлап вокзал алдын үлчи башладым. Иптәшләрем «Правда» газетасы куела торган витринага ябырылдылар.

— Хасан күле вакыйгалары турында язганнар!

— Указ чыккан, егетләр! — диләр.

Алар кинәт мине сырып алалар.

— Бүген синнән тиеш, Гыйльфан, иртәгә Иванны кашындырырбыз! — диләр.— Чыннан да, сез аның белән әкияттәге кебек һич аерылмас ике дус икәнсез! — диләр.

— С какой стати миннән тиеш әле? — дим мин.— Кемнәрдер орден, медаль ала, ә мин кунак итәргә тиешме?.. Акылыгыз алтын икән! — дим мин, кәефем кырылып.

— Син нәрсә карунланасың? Герой кеше юмарт булырга тиеш! — диләр тегеләр.

— Нинди герой? Кем герой? — дим мин, һичнәрсә аңламыйча.

— Син — герой! Дустың Иван Чернопятко белән икегез дә герой! — диләр иптәшләрем һәм авызымны ачып торуымнан бу хода бәндәсендә берниндн кылану юклыгын аңлап, мине витрина янына сөйрәп китерәләр. Илаһым! Күзләрем ялгыш күрәме әллә? Указда безнең Посьет чик буе отряды начальнигы полковник Кузьма Евдокимович Гребенниктан соң икенче булып ук минем фамилиям язылган!..

Тукта, герой булырлык ни эш күрсәттем соң әле мин? Хәрби антыма турылыклы хәлдә кулымнан килгәнне генә ич...

Ә Иван? Аңа мәнә герой исемен бик дөрес биргәннәр. Киң күңелле, тыйнак украин дустым, син бу шөһрәткә чын мәгънәсендә лаек! Савыктыңмы инде, яраларың төзәлдеме? Син, бәлки, заставага кайтып та җиткәнсеңдер инде?

Шаулы үткәннәр, кинодагы төсле, бер-бер артлы күз алдыннан узды. Бер сәкегә янәшә ятып имезлек суыргандыз, бергә уйнап үстек, бергә укыдык, авырлыкларны бергә кичердек, җир астында бергә күмелеп калдык, үлемне дә, дошманны да бергә җиңдек... Гел бергә! Әни шаяртып әйткәнчә, мөгаен, бергәдер безнең әҗәл дә! Шулай була икән, булсын! Ләкин әле безнең яшисе бар, яшисе!

Донбасста шахтер дуслар, Хәлиулла абзый, Шәмгелҗәннан апа, Казанда әти, әни, Гайшә апа, энекәшләр ничек шатланганнардыр! Үз якыннарыңның ышанычын аклап, аларга рәхәтлек бирә алуны тою шулай ук рәхәт икән ул, шайтан алгыры!

Владивостокка шалтыратып, Иван белән сөйләштек. Ул бүген госпитальдән чыга, бездән өч кенә сәгатькә соңрак заставага кайта. Димәк, бүген очрашачакбыз. Кара инде, чын мәгънәсендә сагынылган икән ләбаса!

Безне кочак җәеп каршыладылар. Өлгкәнчы тәбрикләделәр, инаданҗептән генә чыккан өр-яңа киемнәр бирделәр. Ә кичке якта митинг

булды, котлау телеграммалары укылды, аннары — банкет. Аеруча тантаналы бәйрәмнәрдә гадәткә кергәнчә, ашханәдә командирларыбыз хатыннары аш-су тараттылар, кыстый-кыстый сыйладылар...

Сәгать уннарда, мул табынны олылаган кебек, нур өстенә нур өстәп, Владивостоктан Иван Чернопятко кайтып төште. Егетебез тазарган, тагын да матурайган. Иван безне, без аны тәбрикләдек. Сөйләшеп сүз, җырлашып җыр бетмәде. Эх, ул чаклар!

Казармада безнең койкалар янәшә генә. Донбассны искә алдык. Шахтадагы дуслар, кунакка кайтырга чакырып, телеграмма биргәннәр. Казаннан да шундый ук телеграмма бар. Кая кайтасың! Иртәгә без Мәскәүгә китәргә тиеш. Анда хәрби академиягә укырга керү турында да сүз булачак. Нишләргә? Шахтер профессиясен алыштырып үзеңне гомергә хәрби хезмәткә багышларгамы?

Икенче көнне Мәскәү — Владивосток поездына утырып, башкалага юл тоттык. Ул чакта поездлар акрын йөри иде әле. Күтәренке күңел белән көн үткәне сизелми дә калды. Ничаклы юл йөреп, Мәскәүгә Кремльгә баргандагы кебек якты истәлеклесе беркайчан да булмады, ихластыр әгәр, булмады.

Иван белән без бер купеда. Новосибирскины үткәч, Кузьма Евдокимович Гребенник безне үз купесына чакырып алды. Кәефебезне сорашты һәм: «Бүләкләнүчеләр исеменнән Кремльдә җавап сүзе әйтергә туры килер. Икегезнең берегез сөйләр. Кайсыгыз кыюрак?» — дип икебезне дә аптырашта калдырды.

Иван мин сөйләр ди, мин аны тәкъдим иттем. Ахырда Иван кулайрак булыр дип аңа туктaлдык. Ул бит миннән буйга зуррак. Төз, чибәр, мәһабәт. Яңгыравык табыш белән сөйләп җибәрсә... Менә ул безнең чик сакчылары нинди дисеннәр!

Радио: «Безнең поезд Ватаныбыз башкаласы Мәскәүгә якынлаша!» дигәч, бөтен тән чымырдап, эсселе-суыклы булып китте. Киң Идел агышын хәтерләтеп, мәһабәт төстәге «Ватан турында җыр» яңгырый башлагач, үзебез дә сизмәстән, төз басып сүзсез калдык. Ихластыр, гаҗәеп кадерле минутлар иде бу безнең өчен.

Казан вокзалына якынлаштык. Перрон тулы халык! Тынлы оркестр. Почет каравылы. Байраклар, транспарантлар, портретлар, лозунглар... Сәламләү сүзләре, тәбрикләр... Аннары, җиңел машиналарга утырып, мотоциклчылар артыннан Кремльгә таба юнәлдек. Декабрь салкыннары булуга карамастан, урамнарга ике яклап халык тезелеп тора. Кул болгыйлар, сәламлиләр... Бу тантана, бу шатлыклы авазлар төштә генә түгелме, дип уйлыйм. Уянып китәрмен дә, сабый чакта күрелгән матур төш кебек, барысы юкка чыгар, бүленер төсле тоела. Шикләнеп Иванга карыйм. Юк, төш түгел, өн бу! Әнә дустым ничек шатлана, бит алмалары алсуланып янып тора, авызы колак, күзләре көлә. Өстендәге өр-яңа шинель, шлем, портупеялары бик тә килешә икән үзенә. Бу яңа хәрби киемнәр миңа да шулай килешәме икән?

Аяз күктән учлап-учлап сипкәндәй ярма ява. Ярма түгел, рәхмәт ява бу. Һәрхәлдә, миңа шулай тоела. Машинадан төшеп, яннан йөгерәсем килә. Әй, дөнья, без бу — кичәге гади малайлар, шахтер кисәкләре килә. Әйе, бу чаклы кадер-хөрмәт күрсәтерлек батырлыгыбыз да булмады безнең. Әмма булыр. Бөтен тормыш юлыбыз белән, кешеләргә булган яхшы мөнәсәбәтебез белән чын батырлыкның нәкъ үзен күрсәтербез әле без!

Дүртенче декабрьда безне Кремльдә Михаил Иванович Калинин кабул итте.

Билгеләнгән сәгатькә Зур Георгиевский залга юнәлдек. Мәрмәр баскычка киң кызыл келәм җәелгән. Ул баскычның ак шома култыксалары, мин сиңа әйтим, ялт итеп тора. Стенаның уң ягына алтын рамлы зур картина эленгән. Анда ниндидер канлы сугыш сурәтләнә.

Мин бу картинаны дикъкатьләп тамаша кыла алмадым. Берсеннән-берсе тәти уенчыкларга кызыгып, тәкатьсез калган сабый шикелле тиз-тиз ары карадым, бире карадым — карап туя алмадым.

Иван янымда гына иде, җиңемнән тартып исемә китерде. Түшәмдә очып йөргән фәрештә рәсемнәрен авыз ачып карарга килмәгән монда. Мөһимрәк эш бар, янәсе...

Бил каешымны рәтләп, гимнастеркамны сыпырып куйдым. Чернопятко белән янәшә төз басып, кызыл келәм җәелгән баскыч буйлап өскә күтәрелдек. Менә ул атаклы зал! Сугышларда зур батырлык күрсәткән баһадирлар хөрмәтенә салынган бу зиннәтле бинаның каһарманнарга мәңгелек һәйкәл икәнлеген ишетеп белә идем инде мин. Рус дәүләтенең шанлы бүләге булган Георгий тәресе күбесенчә биредә тапшырылган. Ахырдан каһарманнарның исемнәрен мәрмәр стенага алтын хәрефләр белән язганнар.

Залга аяк бастык. Идәннәр көзгедәй, ап-ак стеналар сөт белән югандай, түшәмнәр таң калырлык нәфис бизәкле меңнәрчә нечкә нәкыш белән тулы. Алтын, көмеш, ука, энҗе... Бу матурлыкларны сөйләп кенә аңлатып булмый, аны үз күзләрең белән күрергә, күреп сокланырга, шаккатарга кирәк! Ә син анда булдыңмы? Яхшы, яхшы... Димәк, андагы мәңгелек җемелдәүләрдә минем күзләрдән түгелгән шатлыклы нурларны да күргәнсеңдер син. Ул залда бар алар, бар. Күрдеңме, таныдыңмы? Түшәмнән асылынып төшкән, тәлгәш-тәлгәш укмашкан энҗе шәмнәрдә, идәннән түшәмгә хәтле сузылган бик күп исемнәрнең мәрмәргә уелган алтын хәрефләрендә бик-бик озак сакланырлар алар!

Залның уң ягындагы шома ак стенасында күңелгә ифрат якын сүзләрне укып ничаклы сөенгән идем мин. Мең дә сигез йөз кырык биренче елда Казан гарнизон батальоны Георгий тәресе кавалеры булган икән ләбаса. Йөз дә җитмеш сигезенче тәртип номеры куелган алтын язма әнә шул хакта сөйли. Горурланып озак карап тордым аңа. Бабаларыбыз мич башында йокы симертеп ятмаган! Шулай дим дә язманы Чернопяткога күрсәтәм. Ул да кызыксынып карый.

Бер заман ян ишекләр ачылып китте һәм безгә таныш булмаган бер төркем кешеләр арасында Михаил Иванович Калинин күренде. Кара костюм, галстуклы ак күлмәк кигән. Елмая-елмая килә. Сөйкемле, мөлаем карт. Без, берникди боерыксыз төз басып, тын калдык. Михаил Иванович һәммәбез белән күрешеп чыкты. Аннары секретарь хезмәтләрен үтәүче Хасан күле батырларын бүләкләү турындагы Указны укыды. Ә Михаил Иванович бүләкләнүчеләрнең кулларын кысып орденнар, герой кенәгәләрен тапшырды. Китте алкышлар, китте тәбрикләүләр...

Чернопятко мине стеналардагы рәсемнәрне карарга алып китә. Барлык кунаклар хәзергә шуның белән мәшгуль. Канатлы фәрештәләр, ярым шәрә чибәр кызлар, тәвәккәл чырайлы пәйгамбәрләр... Менә рәсемдә шул пәйгамбәрләрнең берсен каны уйнап торган сылу кыз үз катына чакыра. Пәйгамбәр, гөнаһка батуыннан куркып, читкә тартылган...

Мин, бу күренешне озак тамаша кылырга уңайсызланып, карашымны янәшәдәге рәсемнәргә күчердем. Безобразие! Кунакларның күбесе пәйгамбәрне азындырырга теләгән кыз янына тукталган. Арада хәтта безгә таныш булмаган бер сакалбай да бар. Чибәр генә яшь ханымны култыклаган ул.

— Пәйгамбәр кебек беркатлы түгел бу! — дим Чернопяткога, пышылдап кына.

— Төньяк боз океаны баһадиры академик Отто Юльевич Шмидт ич бу! — ди Чернопятко.— «Челюскин» бозваткычы, Папанинчылар дрейфы, Котып... Хәтерлисеңме?

— Тере фәрештә турында да бер-ике авыз белешмә бирсәң, рәхмәт әйтер идем үзенә,— дим, Иванның ханымга игътибар итмәвенә гарьләнеп.

— Монысын инде үзенә тапшырам, — ди Чернопятко.— Бу мәсьәләдә синең колач киңрәк.

— Ачуымны китерсәң, валлаһи әгәр, танышмый калмам! Шмидтның үз кызы түгелме икән ул? Бик яшь күренә,— дим.

— Бәхетеңне сынап кара,— диде Чернопятко.

Без табын янына Зорин фамилияле язучы белән янәшә утырдык. Чибәр туташ (мин аны Отто Юльевичның кияүгә чыкмаган кызы дип уйлап, күңелемнән инанган идем инде) һәм сакалбай аз гына түгәрәк, безгә каршы якка туры килделәр. Минем муен, үземнән сорап та тормыйча, һаман шул якка борыла. Кыз бик мөлаем, бик итагатьле һәм азрак моңсу иде. Чем-кара күзле, тарткан җәядәй кыйгач кашлы, озын толымлы. Йөзе ак, чиста. Килешле матур борын, сәнгать остасы ясап куйгандай кечкенә авыз, тыйнак кына елмайганда күренеп киткән энҗедәй ак тешләр, чыннан да, магнит кебек күзгә күренмәс көчкә ия иделәр шул.

Мин түзмәдем, Зориннан бу фәрештә-кыз турында сораштым.

— Юк, Отто Юльевичның кызы да, хатыны да түгел ул,— диде Зорин.— Маргарита Ивановна Михайлова. Минем сеңелкәшнең ахирәт дусты. Теләсәгез, таныштыра алам.— Зорин шулай диде дә елмаеп куйды.

— Телибез! — дидек без Иван белән беравыздан, ярым пышылдап.

Мәҗлеснең яме бермә-бер артты, күңелләр хушлыгына чик-чама юк иде. Тостлар әйтелде, бокаллар чыңлады.

Банкеттан соң гына таралыштык. Мин киенү бүлмәсендәге кунаклар арасыннан Маргаританы табарга тырыштым.

Ул күренмәде.

Икенче көнне дә, өченче көнне дә очрашырга туры килмәде безгә. Аннары, Татарстан хөкүмәте чакыруы буенча, Казанга кайтып киттек. Гаять шатланып һәм бер үк вакытта нигәдер моңсуланып аяк бастым мин туган җир туфрагына. Шатлыкларымның сәбәбе билгеле: хөкүмәт, партия вәкилләре, якташлар, туганнар зур хөрмәт күрсәтеп, ачык чырай белән каршылый. Әнә перрон тулы халык, байраклар, мактау сүзләре язылган транспарантлар, чәчәкләр, музыка...

Аз гына моңсуланырга да урын юк шикелле югыйсә. Ләкин сәламәт тәнгә энә очы кадәр генә шырпы кереп өзлексез сыкраткандай, йөрәкнең бер чите әллә нишләп әрнеп, сулкылдап тора. Ник? Белмим.

Әти-әни янына бардым. Гайшә апа, Кәлимулла абзый, Әнвәр, Абдулла, Ибраһим, Сафиулла, Хафизә һәм иң яраткан сеңелем Әминә дә шунда. Ул үскән, чибәрләнгән...

Әни яшәреп киткән, йөзе саф, балкып тора. Җаны тыныч булгач, хатын-кызга дөнья мәшәкате берни түгел икән ул.

Әти картая төшкән. Мыек җибәргән, калынайган. Кочаклашып күрештек. Ул ирләрчә нык итеп аркамнан кагып куйды.

— Молодец, улым. Батыршиннар нәселенең чынлап та батыр икәнлеген бөтен Рәсәйгә күрсәттең! — диде ул.

Әти безнең — аз сүзле кеше. Әйтсә, берәгәйле әйтә, әйтмәсә, сүзен авызыннан келәшчә белән дә тартып ала алмыйсың. Менә ул, тагын бер кат аркамнан какты да, үз эшен беткәнгә санап, мине әнигә таба этәрде. Әни шатлыгыннан елап ук җибәрде.

Кунакка йөрү яхшы булса да, туйдыра икән. Кая гына чакырмадылар безне! Балалар бакчасына хәтле барырга туры килде. Көн саен бишәр-алтышар очрашу. Һәрберсендә бер үк нәрсәне сөйләргә кирәк: японнар ил чиген боздылар, без аларны пыр туздырып куып чыгардык. Нык сугышырга туры килде. Шулай гомуми гына башлап, тирән-

тә кермичә котылмакчы булам. Ләкин кая ул! Сорауларны биреп кенә торалар...

Ямаширмәгә кайту хәтергә нык уелып калган. Басу капкасы төбендә ипи-тоз белән каршыладылар. Сабан туендагы шикелле олысы-кечесе килгән. Туп-туры клубка юнәлдек. Клуб бәйрәмчә бизәлгән. Монда сәгать ярымлап сөйләттеләр. «Син туган йортыңа кайттың, иркенләп сөйлә!» — диләр.

Аннары туган-тумача, дус-иш үз өенә чакырып, кунак итә башлады. Бармасаң, үпкәлиләр...

Председатель агай, тимер табанлы җинел чанага шәп ат җиктереп, колхоз утарын күрсәтеп йөрде. Сабан, тырма, чәчкечләрне карап бетергәч, терлек абзарларына киттек. Мин атлар белән кызыксындым. Ул елларда Кызыл Армиягә җибәрү өчен һәр колхозда ат асрыйлар иде. «Кайда сезнең андый атларыгыз?» дим.

Биредә дә, бездәге кебек үк, һәр атның исеме, яше, нәселе, асыл сыйфатлары фанер кисәгенә язып ишеккә кадакланган. «Карлыгач» кушаматлы чем-кара яшь ат янына җиткәч, председатель ишекне ачты. Кесәсеннән ипи сыныгы алып атка каптырды, теге кызларча нәзакәтлелек белән иреннәрен кыймылдаткан арада башына йөгән кигезде. Колаклары уйнап тора, күзләрендә ут җемелди иде бу малкайның. Сыраклары матур, нечкә, күкрәге киң. Бер заман гармун чыңнарыннан да уздырып янгыратып кешнәп җибәрде.

— «Карлыгач»ның синең белән танышуы бу, Гыйльфан! — диде председатель.— Без аны сиңа дип үстердек. Идарә исеменнән военкомнан атны Ерак Көнчыгышка сиңа җибәрүләрен сораячакбыз. Мә, туган, кабул итеп ал. Ил чикләрен саклауда ышанычлы ярдәмчең булсын ул.

Хәрби академиягә укырга калачагым хәл ителгән булса да, рәхмәт әйтеп атны алдым. Кашка маңгаен сыйпап сөйдем, муенын кашыдым. Ат, ипи сорап, түм-түгәрәк иреннәрен култык астыма төртте, тынып калды.

— Бу теге вакытта сез Апакайга кунакка барганда җигелгән атның тае бит, Гыйльфан энекәш,— диде ат караучы, зур сер әйткәндәй пышылдап.

Бәлки, ул байларны сугә-сугә юлда камыт төзәткән олаучы агай үзе булгандыр? Сорарга кыюлыгым җитмәде.

Күңелемне матур хатирәләр биләп алды.

Малай чакта узган юллар буйлап Апакайга киттек. Үшнә калын боз астында йокымсырый. Әрәмәләр, таллыклар гүя ак мамык юрган ябынганнар. Балык тотып, үчак ягып яткан җирләр, сез кайда соң? Үшнәгә аркылы ауган агач янында елга текә борыла иде, уң як ярда инкүлек, инкүлектә таллар үсеп тора иде... Шунда без Харис абый Һадиевның хикәятен тыңладык, шунда Рәхиләнең аягы җәрәхәтләнде. Менә ич, менә ич ул җир!

Мин чанадан сикереп төшәм, тирән карга бата-бата Үшнә ярына киләм, истәлекле үткәннәргә кайтып, туктап, тирә-юньгә карап торам.

Кокушкинодагы Бланк утарын элеккеге чактагыча иткәннәр иде инде. Монда хәзер юлбашчыбыз Владимир Ильич Ленинның балачагын һәм үсмер елларын, революцион эшчәнлеген сурәтләгән музей ачканнар. Ильичка Кокушкино крестьяннары язган һәм Харис абый Үшнә буенда безгә яттан укыган хатның фотокопиясен күреп аеруча дулкынландым мин.

Кокушкинога килеп Галимҗаннарга керми китү гафу ителмәслек хәл булыр иде. Алар үзләре дә хәстәрләнеп торганнар икән. Ислам агай белән Нәгыймә апа бер дә үзгәрмәгәннәр төсле. Әүвәлге кебек тиктормас җаннар, шат күңеллеләр. Балалары үсеп буй җиткән. Галимҗанны танырлык та түгел, ул киләсе елга каралырга барырга тиеш икән инде. Симез каз ите салып пешерелгән карабодай бәлеше белән сыйланып,

баллап, бавырсак салып чәй эчкәч, Нәгыймә апа кызыклы хатирәләрне яңартып, сакланып кына Рәхиләне искә алды. Гариплэнгән каз бәбкәләрен иске кәрзингә утыртып Үшнәгә йөртүен — кызның гаҗәп нечкә күңелле, миһербанлы булуын, аягы авыртып яткандагы түземлелеген һәм тагын әллә нинди уңганлыкларын сөйләде. Сизеп торам: ул шулай кактырып-суктырып безнең ике араны ачыкларга тели. Берсе герой, икенчесе менә-менә очучы булырга тора. Мондый пар килгәннәрне көндез кулына шәм тотып эзләсәң дә таба алмассың, янәсе.

Мин эндәшмим, миңа бу хакта сөйләшү җайсыз. Гүя Рәхилә түрдәге караватта чаршау эчендә ята. Тик ул элеккеге кебек балаларча беркатлы, самими түгел, аңа ниндидер чит рух сеңгән, гүя аны алыштырып киткәннәр. Шушы хәлгә төшкәне өчен, үзен тырышып саклмаган өчен рәнҗеп, үпкәләп ята кебек, өзелгән чәчкәдәй сула баруының фаҗигасен аңлап ышыккарак поса, кача, киреләнә кебек.

Без Галимҗан белән өйалдына чыгабыз. Менә биреге утырып токмачлы аш ашаган идек. Рәхилә менә шушы ишек янагына сөялеп карап калган иде. Ә менә биредә... Җитте! Һәрнәрсәнең чамасы булырга тиеш! Мин үз-үземне тирги башлыйм, җебемәскә өндим. Кызлар үзләре үк: үпкән-кочкан — җилгә очкан, дип әйтәләр ич. Димәк, ни дип адым саен шул кызны уйларга?! Кирәкми! Барысы күптән җилгә очкан, күптән!

Галимҗанга карап елмаям. Елмаюым өтек чыга. Чәчләремне артка таба сыпырам, бил каешымны иплэп, гимнастеркамны төзәтәм. Гадәти халәтемә кайтам.

— Я, Галимҗан, капитан булу уеңнан кире кайтмадыңмы әле? — дим.

Галимҗан комачтай кызара, кулларын кая куярга аптырап артка яшерә һәм оялып кына: «Капитан булу өчен бик күп укырга кирәк икән бит, Гыйльфан абый! — ди.— Шулай да флотка эләгеп булса, карап карарбыз әле»,— ди.

Мин аңа армия тормышының кешене чыныктыруы, үстерүе турында сөйлим.

Галимҗан, йорттагы малларга печән салып йөргән абыйсы ишетмәсен өчен тавышын баса төшеп, миңа сорау арты сорау яудыра. Яшь кызылармеецларга кайчан кием бирәләр, ант кабул иткәнче кораллардан атарга өйрәтәләрме, төнлә сакта торганда йокы килеп интектермиме, буш вакытта нәрсә эшләргә мөмкин һәм башкалар, һәм башкалар...

Ислам абзый, ишек төбендә сөйләнә-сөйләнә, киез итекләрен кага иде.

— Вәт, агай, дөньялар нишләде, элек солдатка китүне кабергә керү белән тиң күрәләр иде. Хәзерге яшьләр үзләре атлыгып тора,— дип безне өйгә чакырды һәм кабат өстәл янына утырышкач: — Син, Гыйльфан, безнең Галимҗанны тәмам исәрләндерәсең инде. Хәерлегә булсын,— диде.

Ул каш астыннан гына энесенә карап куйды, аның тирән җыерчыклар белән буразналанган, үткен пәке белән шома итеп кырынганга ялтырап торган тулы йөзенә борчылу билгеләре чыкты. Ислам абзый стаканнарга бал сала-сала дәвам итте: — Дөньясы тыныч булса, бер хәл иде. Болгана бит, болгана. Бер якта япон, икенче якта герман. Котырган этләр кебек ди ул мәмләкәтләрнең иң зур янараллары.

Мин аны тынычландырырга ашыктым. Ишеткән-белгәнне сөйләдем. Ил-йорт иминлеге өчен дарыны һәрвакыт коры тотарга һәм Галимҗан кебек егетләрнең һәрвакыт әзер булырга тиешлеген әйттем. Мине бүтән иптәшләр дә куәтләделәр. Сүз иярә сүз чыгып куйгач, без бирeдәге ат-тун, аларның сбруй-арбасы белән кызыксындык. Ислам абзый без

теге чакта Апакайга килгәндә юлда өзелгән камыт бавын исенә төшереп булса кирәк:

— Безнең камыт баулары нык. Армиягә китәргә тиешле атларның сбруена кулак каешын якын да китермәбез! — диде, аннары, тамак кыргалап: — Әзерлек турында бик дөрес әйтәсез, оланнар,— дип өстәде.

Әңгәмә әнә шулай үзеннән-үзе оеша. Мәҗбүриятсез сөйләшеп утырасың, ятсыну-читсенү калмый. Җаның рәхәтләнә.

Ә шәһәрдә эш башкачарак. Аягүрә басып, нотык тотарга кирәк. Ә андый эшкә маһир түгел мин. Язу машиналары заводына баргач, нәкъ шулай булды. Агай-эне клубка җыелган. Күбесен таныйм. Менә мастер Апанаев, Меркулов, җыю цехы слесарьлары Хәйдәров, Петров, Маликовлар. Сәхнәдән очып төшеп кулларын кысасы, үзләре белән бергәләп «за компанию» тәмәке көйрәтәсем килә. Юк, трибуна артында сөйлә, матур сүзләр эзлә. Үз-үзеңне тотышың тел-теш тидерерлек булмасын. Герой бит, башкача ярамый... Кичәге эшче иптәшең өчен син һаман син бит. Ул шул ук станокның шпинделен басып тимер тишә, кискеч кайрый, тискида иги, чүкеч белән сөйләшә, ашханәгә керә, душта коена. Сине ул үз янәшәсендә тоя. Аның белән югарыдан торып сөйләшү-аңлашу барып чыкмый, килешми. Кызыл җәймәле өстәл янында унбиш-егерме минут сайрагач — түзмәдем, аска төштем. Залдагылар урыннарыннан торып урап алдылар. Китте күрешү, китте иңбашка кагыш.

Бер заман, күземә генә шулай күренәме дисәм, алдымда теп-тере җирән чәч — Рюрик басып тора. Уңайсызлана-уңайсызлана гына килеп күреште. Бөтенләй үзгәргән бу.

— Завод егетләренә рәхмәт, алып калдылар,— ди Рюрик.— Синең тискида эшлим,— ди.

Башта мин һичнәрсә аңламый тордым. Завком председателе Кадыйр агай мәсьәләне аңлатып бирде. Теге чакта сабан туе көнне паркта булган хәлдән соң завод комсомоллары Рюрикны үз җаваплылыкларына алганнар. Тозлап-борычлап сөйләшкәннәр егет белән. Ышанганнар үзенә. Һәм Рюрикны минем тискида эшләргә беркеткәннәр. Үзеңне бөгеп салган кешене һаман күз алдында тоту уен түгел. Тискига деталь кыстырганда шахтер кулларының көчен исенә төшерә икән. Гарьләнә, тискины чүкеч белән төя. Тора-бара гадәтләнә тагы.

Рюрик, үткәннәр өчен рәнҗемәвен белдерергә теләп: «Беләсезме, Гыйльфан Әбүбәкерович, сезгә Герой исеме бирелгәч, эшчеләр исеменнән заводтан истәлек бүләк хәзерләү тәкъдимен беренче булып үзем кузгаттым. Кузгатып кына калмадым, кара савыты панелендәге җиз юлбарысны да үзем игәп ясадым,— диде.

Мин, рәхмәт әйтеп, Рюрикның кулын кыстым. Ислам ага әйтмешли, вәт дөньялар нишли бит ул. Тар басмада туры килеп, акны-караны күрми маңгайга маңгай сөзешәләр. Зур казанда кайный башлагач, күзләре ачылып китә, туганлашалар.

Эшчеләр кара савытын нинди̇рәк итеп ясау турында шактый баш ватканнар икән. Чик сакчысына тапшырыласы бүләк, ул нәрсә сөйләргә тиеш, аңа нинди сурәт төшерергә? Тукай ярдәмгә килә боларга. Аның: «Без сугышта юлбарыстан көчлебез»,— дигән шигъри юлларын хәтерләп, кара савытына юлбарыс сынын әмәлләп куярга булалар. Аны Рюрик үз теләге белән эштән соң калып игәп ясаган.

— Ә теге кыз белән ара ничек? — дим мин егеткә.

— Полный расчет! Ташладым мин ул кикимораны,— диде Рюрик.— Ә сезнең ара ничек, Гыйльфан Әбүбәкерович?

Мин аның үз сүзләре белән үк җавап кайтарам: «Полный расчет! Ташлады ул сылу мин кикимораны!» — дим.

Рюрик ышанмый.

Мин үзем дә ышанмыйм. Һаман нидер көтәм. Ул юк та юк... Өйдә Хафизә вакыт-вакыт нәрсәдер әйтергә тели шикелле. Ләкин җае чыкмый, бүлдерәләр. Күзләрен мөлдерәтеп, читтән карап тора, авыр сулап китеп бара. Бәлки, миңа гына шулай тоеладыр? Бәлки, аның берничә әйтер сүзе юктыр?..

Мин ялгышмаганмын. Барыбыз бергәләп «Эшче» театрында үткәреләсе шагыйрьләр кичәсенә баргач, киленкәйнең теле чишелде.

— Нигә Марусяңны алып кайтмадың? Күрсәтерлек түгелме әллә? — диде ул, картларны утыртып, без өчәү фойега чыккач.

— Икенче кайтуымда күрерсез,— дидем мин, үҗәтләнеп.— Ә кайчан безгә кызыл саплы пәкеләр әләгер икән? Очучы җизни туй йоласын бозарга телиме әллә югыйсә?!

— Бозмас, бозмас,— диде Хафизә, кара коелып.— Һәр кешене дә үзең төсле күрмә.

Безнең арада менә шундый чәкәләшү булып алды:

— Күрмим шул әле менә. Үзе дә юк, җылы сүзе дә юк. Бәлки ул җизнигә җизни дип әйтергә дә ярамыйдыр?

— Җаны теләгән — алтмыштагыга чыккан.

— Алтмыштагы озак яшәми ич ул!

— Аз булсын — тәмле булсын, кечкенә булсын — ямьле булсын!

— Матур дамыни әле ул җизни?

— Матур. Теләсәң, карточкасын күрсәтермен.

Хатынын култыклап, безнең сүзгә кушылмыйча, тып-тыныч атлаган Сафиулланың сабыр савыты ташыды:

— Син, Анфиса, безнең нервларда уйнама, яме. Рәхилә анда үзенә очучыныммы, кочучыныммы тапкан икән, әйдә, рәхәтен күрсен. Абыйга без дә Рәхиләдән кимне тапмабыз! — диде.

Буфетка кереп сыра эчтек, конфетлар алдык. Кабат фойега чыктык. Сөйләшергә сүз табылмады. Бәхеткә, безнең янга артистлар, әдипләр, журналистлар җыелды. Мин гомеремдә беренче тапкыр күренекле кешеләр белән таныштым. Атаклы Сәйдәшне, виртуоз Туишевны, мәһабәт Камалны, артисткалардан Сульва, Кайбицкая, Ильскаяны, язучылардан Таҗи Гыйззәтне, Гадел Кутуйны, Фатих Кәримне, Әхмәт Фәйзине, Сибгат Хәкимне, тагын әллә кемнәрне, әллә кемнәрне күрдем.

Кичә башланды. Биредә дә мине зур кызыксыну белән тыңладылар. Шылт иткән тавыш юк. Ник берәү селкенсен. Сөйләп бетергәч, шаулатып кул чаптылар. Кыш көне кайдан тапканнардыр, сабый күзләре кебек зәп-зәңгәр чәчәкләр сиптеләр, «Бис! Әфарин гайрәтеңә, Батыршин!» дип кычкырдылар. Сораулар белән күмделәр.

Аннары әдипләр, җырчылар, биючеләр сүз алды. Фәйзулла Туишев берсеннән-берсе кечкенәрәк кыңгыраулы гармуннарын селтәнә-селтәнә, йөрәкне җилкетеп Дим, Сакмар буйларына алып китте, кара урманга ияртеп керде. Хәтта «Донбасс» көен дә уйнады ул. Голубовканы искә төшердем, төтенләп яткан терриконнарны, кызыл флагы җилдә җилфердәгән шахта коперларын күз алдына китердем.

Кичәне алып баручы ыспай егет: «Батыршин маршы». Беренче каһарманыбызга бүләк итеп язылды. Беренче тапкыр башкарыла!» — дигәч, башым әйләнеп китте, эсселәдем.

Шагыйрьләр яңа шигырьләрен укыдылар. Арадан бер яшь шагыйрьне күңелгә аеруча якын иттем. Мөлаем, тыныч тавыш белән укылган шигырьләре әллә ничек моңлы да, дәртле дә аның. Гүя ул минем кичерешләрне белеп алган да хәзер шул хакта сөйли. Мин шулай уйчанландым, мин шулай юллардан күз алмый аны көтәм, мин шулай ул укыган мәктәп буйларыннан моңсу гына карап үтәм, мин шулай иптәшләре белән шау-гөр килеп ул күренер дип өмет итәм!

Өйгә кайткач, бер кызык хәл булды. Бергәләп, тәмләп чәй эчеп утырганда әни миңа: «Бер шигыренең ахырын русча шәрекләгән ак

чырайлы егетне танымыйсыңмы? Аны моңарчы кайда очратуыңны беләсеңме?» — диде.

Әни җанланып китә, битләре алсулана, күзләрендә нур уйный башлый. Тавышыннан да, үзеннән дә ягымлылык бөркелеп тора.

Мин аның соравына сәерсенеп:

— Белмим шул, миңа ул егет кайда очрасын икән соң? — дим.

— Ямәширмәдән Апакайга барганда камыт бавы өзелеп юлда тукталган идекме? Шунда әтиең яраткан җырның сүзләрен бер егет бәйнәбәйнә язып алган идеме? Шул егет бүген шигырь укыды бит инде каршында, Гыйльфан! — диде әни, минем аптырап карап торуыма кәефе килеп.

Телефон чыбыгына кунган карлыгачлар кебек өстәл янына тезелеп утырган Әнвәр, Абдулла, Ибраһим һәм Сафиулла, хәтта кечкенә Әминә дә бу вакыйганы «кичәге кебек» хәтерләүләрен әйттеләр.

Әти мыегын сыпырып, елмаеп безгә карап утырды. Нәрсә әйтсен соң ул? Аның башында зур бер больницаның хуҗалык эшләре. Бүтән нәрсәдә һич гаме юк.

Берничә көннән соң мин Донбасска юнәлдем. Бирәдә дә бик әйбәт кабул иттеләр. Җыелышлар, очрашу кичәләре, мәҗлесләр... Хәлиулла абзыйның шатлыгы икеләтә арткан иде: аңа почетлы шахтер исеме биргәннәр, шуның өстенә мин кайтып төштем. Өйдә гөр килеп зур мәҗлес үткәрдек, күңел ачтык. Балачак дустым Иван Рогов кубыз уйнавымны, җырлавымны үтенде. Ахырдан, тәмам күңеле нечкәреп, елап ук җибәрде. Абыйсы — безгә зур булышлыклар күрсәткән Александр Александрович бик каты чирләп киткән икән... Терелүенә ышаныч аз, ди. Бу хәл, дөресен әйтергә кирәк, авыр тәэсир итте. Күршең үлек күмү хәстәре белән йөргәндә туй үткәрү килешмәгән кебек, без дә бирәдә озак кунак булып ятуны кулай күрмичә, Чернопятко белән икебез дә Мәскәүгә кайттык. Безне Михаил Васильевич Фрунзе исемендәге Хәрби академиягә укырга алдылар.

*(Ахыры бар.)*

## Сәйфи Кудаш

### Ленин белән киңәш итәмен...

Уйларым төйнәлеп төерләнсә,
Икеләнсә әгәр исәбем,
Акыл сорап шуларны чишәргә
Ленин белән киңәш итәмен.

Белми калсам тирән кичүләрнең
Үткелләре кайда икәнен,
Йөкләремне чылатмый кичәргә
Ленин белән киңәш итәмен.

Торып калсам җирдә япа-ялгыз
Җиткерәлми таңын кичәнең,
Булмас өчен тагын шундый гамьсез
Ленин белән киңәш итәмен.

Юлга чыксам аңа киңәш итеп,
Кулга тотып аның чырагын,
Гомер юлының гасырлар куерткан
Караңгысын ярып чыгамын...

### Кышкы тылсым

Күзләп талганчы күзләрем
Мин урман, таудан эзләдем —
Кышның сихри матурлыгын,
Кочакларга сыймаслыгын,
Уйлар сынын җуймаслыгын,
Күреп күзләр туймаслыгын...

Кыш тылсымлы тынын өреп,
Үз ямен энҗегә төреп,
Сыйдыргач кар бөртегенә,
Җилбәзәктәй җемелдәтеп,
Кундырган да куйган икән
Аны синең керфегеңә...

## Сагыну

Йөрәктә сүнмәс ут яндырып,
Юлга карап күзләр талдырып,
Читкә ташлап барлык эшеңне —
Кочак җәеп каршы барасың,
Вокзалларга төшеп аласың
Бик сагынып көткән кешеңне.

Сагынганмын икән шул чаклы,
«Яз» исемле назлы кунакны,
Көтмәдем Өфегә житкәнен,
Биш ел күрешмәгән яр сыман,
Йоматауга бардым каршылап,
Сагынуларның чыгып чикләрен!

## Китәләр...

Әйтерсең лә, борсаланып,
Бер-берәнә башын салып,
Тузан тузгып куйлар чаба.
Агыйделнең өстен каплап,
Бер-берсен этеп, таптап,
Эркелешеп бозлар ага...

Җилләр белән айкалышып,
Силләр белән чайкалышып,
Ярдан ашып карлар китә.
Әйтерсең лә, яздан качып,
Ишекләрен тулы ачып
Йөрәкләрдән зарлар китә...

## Онытма

Талчыкканчы алга омтыл
Сәләтләрең бар чагында.
Җан чыкканчы таңга томрыл
Канатларың пар чагында.
Сәләтләрнең кәмүе бар,
Канатларның талуы бар,
Онытма!

Җилгән чакта җирәннәрең,
Сөргән чакта тәрәннәрең,—
Актарып иң тирәннәрен
Күтәр уйның чирәмнәрен.
Җирәннәрнең аксавы бар,
Тәрәннәрнең какшавы бар,
Онытма!
Уй җилкәнең тузмас борын,
Җилләр җилеп узмас борын —
Ярып хыял дәрьяларын
Йөзеп калсын корабларың.
Җилкәннәрнең тузуы бар,
Җилнең җилеп узуы бар,
Онытма!

## Юк, эзләмим

Үтәмен дә гомер елларының
Салкынын, чуагын, буранын,
Каш өстенә куеп кулларымны
Юлларымны карап торамын.

Уйламагыз:
эзли икән бу, дип,
Озын юлда югалтканнарын.
Юк, эзләмим.
Беләм кабат атмый
Бер балкып югалган таңнарың...

Тик аякны яза басмас өчен,
Маякларны хата какмас өчен —
Көчләремне барлап аламын.
Уйларымны чарлап аламын.

Аумал юлда авып ятмас өчен,
Баткакларда таеп батмас өчен —
Сызганып аламын җиңемне,
Билбаулап аламын билемне,
Биштәрләп аламын иңемне...

## Кил әле...

*Мәгъфүрәгә*

Гомер сөргәч тәүге тапкыр гына
Алдан белеп булмый серләрен.
Кайнар каның ничек, кайда тына,
Ничек йома күзен көннәрең?

Алтын көзнең көне чуак чакта
Якынрак утыр, кил әле,
Ширбәтләрнең йөрәк төпләрендә
Калган куесын салып бир әле!

Өсләренә таулар үскән саен
Чишмәләрнең арта җырлары.
Бетми икән сүзе гашыйкларның
Үскән саен гомер еллары...

Мактанырлык хәлләрем юк минем,
Оҗмахларга кертә алмадым.
Тик шулай да сине бу дөньяның
Тәмугларына да салмадым.

Ничек кенә сакланып бассаң да
Тормыш юлының баткакларына,
Чәчрәгәнен сизми дә каласың
Пычраклары балакларыңа.

Мөлдерәмә тулган булсалар да
Үзләрендә изге теләкләр,
Саранрак әле иркәләүгә,
Җылылыкка безнең йөрәкләр...

Җырдагыдай чәчәкләрне өзеп,
Тезеп куялмадым юлыңа.
Тик шулай да әрем бәйләмнәрен
Тоттырмадым бер дә кулыңа.

Әйтә алмыйм, йөздердем дип сине
Шатлык шәраплары эчендә,
Кайгыларның калын болытлары
Булды күбрәк синең өстеңдә.

Бик теләдем сине утыртмаска
Бер дә өрелмәгән урынга.
Инде хәзер үзем ояламын
Әйтергә бу уем турында...

Биралмадым үрелеп кенә тотып
Күктә чыңрап очкан торнаны.
Тик шулай да кулыңдагы тургай
Һичбер вакыт җырдан тынмады.

Кер югандай чайкап Акманайда
Айкалдырып кочкыл камышын,
Чайкар идем синең сафлыгыңда
Бик күп сылуларның намусын...

Кичер мине, атласларга төреп,
Алтыннарга мана алмадым.
Нишләтим соң, кайчан күргәнең бар,
Алтынны алтынга манганын?!

Утыр әле якынрак килеп,
Сөйләшик бер чишелеп, сүтелеп.
— «Әйтер сүзне әйтә алмадым!» — дип,
Азактан йөрмәссең үкенеп...

1970

## Фатих Хөсни

# ӨЗЕЛГӘН ҖЫР

хикәя

## I



Миләүшә — Талиповлар гаиләсендә бердәнбер кыз, ди
мәк-ки, бик тә кадерле гөл булып үсте. Дөрес, Талипо
ларның кайчандыр бер малайлары да булган, ләки
ике яшьлек чагында ук, үпкә шешүдән, үлеп киткән. Б
аянычлы югалту өчен ир белән хатын арасында әледә
әле сүз дә килеп чыга: ире Харис, әлбәттә, нәзакәтл
генә итеп, баланы карап йөртмәүдә хатыны Сәрияне битәрләп куйгалы
ә хатыны Сәрия исә, артык нәзакәтләп тормыйча, ирен төшеп калганлык
та, өйне җитәрлек кайгыртмауда, хәтта доцент исеме күтәреп йөре
башка фән эшлекләләре файдалана торган махсус поликлиникадан д
файдалана алмавы белән тегенең авызын томалый иде. Әти белән ән
арасында әллә нидә бер иртәнге йомшак җил кебек сирпелеп уза торга
мондый вак-төяк әйткәләшүләргә бер дә исе китмичә, яшьләй үлгән эне
сен дә тамчы да искә төшермичә, бердәнбер иркә кыз Миләүшә үсә бирд
Менә ул буй җиткән кыз, яше егерме икедә, студентка, соңгы курст
өлгерәсе алмалары өлгергән, инәдән-җептән генә һәм иң соңгы мод
буенча киенә, кирәк-яракка, ягъни карманный расходларга дип кесән
дә буш тотмый. Әнисенең эчтән генә сызып йөрүенә караганда, юньлерә
бер кеше табылса, ай-һай ла, укып әллә ни эш чыгарырдай күренмәгә
бу расходлы күсәкне тотып кияүгә озатканда да бик вакыт иде кана д
син көткәндә аның кирәкле кешесе аяк астында аунап ятамы соң! Ә Сәри
ханымның борын күтәренке, җил-яңгыр тидерми иркәләп үстергән чәчә
тәй кызын озын чәченнән бүтән кызыгырлык җире булмаган «буш кеса
ләр»гә тагып җибәрәсе килми. Ә кызның үзенә килгәндә, бераз җи
яграк ул, аңа кияү булды ни дә, булмады ни, хәер, күктән бик чибәр д
бик акыллы да, бик бай да, бик дәрәҗәле дә берәр даһи егет атылып төш
сә, ул аны шундук кочагына эләктереп алудан качмас иде. Хәзергә эл
андый хикмәтле эш күренмәгәч, дөньясы һәм үзе түгәрәкләнгән тук кы
яшьлеген кая куярга белмәгәнлектән, килешсез зур башлы, курсташ
ларының сүзләренә караганда, теләсә кайсы укытучы-профессорын га
лошка утыртырлык табигый сәләте булган физмат малаен котырты
йөртә һәм, кайбер башлангыч бөреләренә караганда, Миләүшә — ча

кыз — бу уенны алып та барыр кебек. Моны, курка-шикләнә генә дигәндәй, әни кеше белә, әти кешене мондый нечкә эшләрдә катнаштырып тору, хәер, килешмәгән дә булыр иде. Гомумән, әйтергә кирәк, доцент Талипов кызы турында кайгыртуның авыр башын хатыны җилкәсенәрәк аудару ягын карый. Матди яктан мохтаҗлыкта тотмагач, кызының филфакны уңышлы гына бетереп килүен белеп торгач һәм шуның да өстенә тагын — нур өстенә нур дигәндәй — туташның, бик алай сәмруг кош очыртып алып китәрдәй булмаса да, буе-сыны, төсе-битенең һәм үткенлегенең кем алдында да йөзгә кызыллык китерерлек түгеллеген, хәтта кайвакытларда, әлбәттә, ганләдә — чәй янында, әтисе бакчасына да таш ыргытырлык, әти-әнисен консерватизмда, искечәрәк уйлауда гаепләргә җитәрлек чаялыгы да булгач, башкасына тыгылып торуы кирәкмәстер дип уйлый. Инде бер сүзсез калуны җайсыз тапса, аз гына юмор кыстырып, шулай да бердәнбер иркә «элита»ның хәтерен калдырырга һич теләмичә, йомшак кына итеп авыз эченнән мыгырдана:

— Кем белеп бетергән бу прогресс заманынныкын, без, әнисе, бәлки чынлап та Фәтхулла хәзрәт хөкемендәрәк калган кешеләрбездер, илле ел йоклаганнан соң, илаһның бирмеш бер көндә яңадан уянып, яңа дөньяны бик үк танып җитми торган катмыш бәндәләрбездер. Ләкин... менә бу (ул хәйләкәрләрчә кызына таба ымлап куя мондый вакытларда) яңача уйлый торган чибәр туташларның да, канатланып, өй түбәсеннән өй түбәсенә очып йөргәннәре күренми әлегә. Шул без йөргән гөнаһлы җирдә үк йөриләр, шул консерватив фикерле әтиләре тапкан акчага тырнакларын буяталар.

— О, бусы слишком, әти! Кызының маникюрщага түли торган акчасын да исәпләп торасың, имеш. Кажется, синең Фәтхулла хәзрәтең андый ук реализмга барып җитмәгән кебек, минем белүемчә.

Шулай диде дә кыз, ясаган чәен дә эчмичә, утырган урыныннан дәррәү сикереп торды, урындыгын игътибарсыз гына читкәрәк этәреп, әтисенең юри ачуын китерергә теләгәндәй, иңбашларын сикерткәләп, җилкәсенә чук-чук салынып төшкән буяулы чәч толгашларен кулы белән бер җилпеп, кая ашыкканлыгын һәм кайчан кайтачагын бер сүз белән дә әйтмичә, тырт-пырт чыгып та китте. Мондый «фокуслары» өчен ул чибәр туташны, әлеге шул буяулы чәч толгашлареннан тотып алып, йөзен кыйблага борыпмы-бормыйчамы дигәндәй, әти кулы белән бераз селкеткәләп алганда да артык булмас иде, югыйсә. Кая инде ул, мөмкинме бердәнбер кызны, җитмәсә тагын шундый чая-үткен кызны алай рәнҗетергә? Ә менә кызны яклап, аның чал чәчле әтисенә ташланырга мөмкин, хәтта йөрәкнең ярсуы ук басылып китәчәк.

— Син дә шул бер теленә хуҗа була белмәдең,— дип, кабынып иренә ташланды Сәрия ханым, кызы ишектән чыгып китүгә,— кулыннан килсә әгәр, оятыннан курыкмасаң, общежитиега ук куып чыгарыр идең.

Шулай да сүз талашка ук барып җитмәде, чөнки кызларын икесе дә яраталар һәм шул ярату аркасында икесе дә бердәй мөкиббәннәр иде.

— Нишләп куып чыгарырга, канат-каурыйлары шундый ипле утырган кош, вакыты җиткәч, болай да очып китәр дип уйлыйм, әнисе,— дип, хатынын тынычландырырга ашыкты Талипов,— әнисенә охшаса, тем более... Әнисе әнә ВУЗда да укымаган, ә шулай да егетнең урта бармак кебеген кулга төшергән бит...

## II

Ир белән хатын үзара теләсә ничек кытыклашсыннар — анысы алар эше. Ә Миләүшәгә килсәк, дөресен әйтик: иркәлек аркасында шытып килә торган кайбер җилбәзәк якларын — үзен артык һавалы тотуын, бизәнергә яратуын, бер эшне дә тирәнтен уйлап җиткермичә, җиңел эшләнә торган эш дип каравын һәм, чынлап та, нинди генә эшкә тотынса да, артык

көч сарыф итмичә, үтә җиңел ерып чыгуын исәпкә алмаганда, кызыйның кайберәүләр белән кылычка-кылыч килерлек дәрманнары да юк түгел: ул — табигый талантка ия, әле генә әйтелеп үтелгәнчә, нәрсәгә генә тотынмасын, җиңел һәм пөхтә итеп башкарып чыга. Егерме ике яшькә җитсә дә, чыгып бетмәгән һәм якын арада гына чыгып бетәрдәй дә күренмәгән мөлаем сабыйлыгы бар, кешеләргә — бөтенесенә бертигез дәрәҗәдә — ышанып карый, укый торган предметларын белә, бер вакытта да конспект төзеп мәшәкатьләнми, имтиханга хәзерләнәм дип аулак бакчаларга чыгып, чәчен йолкый-йолкый цитата ятлап утырмый һәм үзе дә сәләтле кешеләрне әллә кайдан танып ала. Ярата һәм, озак уйлап тормыйча, үзен шушындыйлар кочагына башы-аягы белән атып бәрергә әзер...

Мондый дуамаллыкның кайчакларда аянычлы нәтиҗәләргә китерү мөмкинлеге турында ул хәтта уйлап та тормый, гомумән, аның өчен бу дөньяда бернинди дә аянычлы хәлләр юк, булуы мөмкин дә түгел, булса да ул кайбер мокыт бәндәләрнең уңмаганлыклары аркасында гынадыр. Тулаем, дөнья матур, Миләүшәнең күп акча китерә торган доцент әтисе һәм кызы ни әйтсә шуны эшләргә әзер торучы киң күңелле, бик тә бала җанлы мәрхәмәтле әнисе бар. Аннары тагын бик күп, бик күп дуслары бар — кызлардан да, малайлардан да. Һәм алар барысы да Миләүшәдән биһушлар. «Синең сөйкемле сөягең бар, колдунья», «Сиңа ни кисән — шул килешә!», «Син бик тә, бик тә бәхетле булырга тиеш, Миля!» дип колак төбендә безелдәп торалар. Шунын өстенә, шуларның барысы өстенә ул җилбәзәк кызның бүтәннәргә бик алай тәтеми торган тылсымлы бер өстенлеге бар: аны кояш ярата. Җәй көннәрендә туристлык походларыннан йөреп кайтканда кара-кучкыллы һәм җимешле Кавказ, әйтерсең, аның битенә, беләкләренә, тәненә бөтенләйгә-бөтенләйгә йогып кайта.

Әйткәнебезчә, аның кызлардан да, малайлардан да бик күп, бик күп танышлары бар, ул алар белән ничектер башын артка ташлап, берсенә дә игътибар итмәгәндәй, челтерәп аккан чишмәдәй көлә-көлә, шул ук вакытта аларга ышанып, ни өчен ышанганлыгын үзе дә белештермичә, яшел яфракларга шыбырдап коелган иртәнге яңгыр кебек, шаулап та, пышылдап та сөйләшә ала. Һәм әнә шул бик күп дуслары арасында тагын берсе бар — бер малай бар, дөресрәге, малайлыктан чыккан, егет үк булып җитмәгән, дәү башлы, киң маңгайлы, маңгаена караганда, чак кына Альберт Эйнштейнга да охшаган, ләкин хәзер әле Эйнштейн үк булып җитмәгән, Миләүшә җүләр башның алдан ук чыгарып куйган хөкеменә караганда, әлбәттә, барып җитәчәк дәү башлы, киң маңгайлы, сөйләшергә яратмый һәм сөйләшә белми дә торган берсе бар. Сәйяр атлы. Сәйяр Солтанов дигән йомыкый гына бер малай. Ни хикмәттер менә, бөтен кеше белән, хәтта эти-әнисе белән дә чатылдатып сөйләшә ала торган безнең ул чая Миләүшәбез әнә шул малай белән сөйләшүдән башта озак кына куркып йөрде.

### III

Ни өчен алай куркып йөрүенең сәбәпләрен тикшереп тормыйк — ни өчен генә булмас егермедән узган, ләкин әлегә кияүсез калу сагышына ук батмаган кызларныкы! Без аларны бөтен нечкәлекләре белән кайдан белеп бетерик! Ә менә язмышның бер көнендә — бәлки бу урында адәм балаларын иләсләндерә торган язны гаепләргәдер — курку качты. Туры мәгънәсендә дә, читләтебрәк әйткәндә дә. Гадәттә, мондый озатып куюлар чыгарылыш кичәләреннән соң, имтиханнар биреп, өстән тау төшкән чакларда гына була торган иде. Ә өстендә тау барын гомумән бик алай сизми торган, фәннәрдән җиңел баручы дәү башлы, аз сүзле Сәйяр ул кичне үзен әллә ничек сәеррәк бер хәлдә тойды. Гомердә булмаган хәл: аның тора торгач кызлар белән сөйләшеп карыйсы килеп куйды. Нинди

да булса атап әйтеп була торган бер кыз белән түгел — ходавәндә, атап әйтергә мөмкин булган һәм яшертен сер итеп күңел түрендә очыртып йөрткән ул сихри җыр турында, күңелне гел алгысытып, гел яктыртып, гел яхшылыкка өндәп торучы ул фәрештә турында, гөнаһлы тәнне тибрәтеп, нинди дә булса сөю-сәгадәт сүзе кыстырырга мөмкинме! Әйе, әйе, шул ук институтта дәрес бирүче доцент Талиповның күз өстендәге каштай бердәнбер кадерле кызы бит ул. Өстеннән этиен искесеннән ук-маштырып теккән пиджак төшмичә һәм, кеше данына кызыгучы лыгырдык авызларның «Будущий Ландау» дип шапырынуларыннан һәм, яшертен генә мыскыллап, «бәләкәй белошвейканың дәү башлы малае» дип йөртүләреннән башка бернинди искитәрлек байлыгын юк чагында шундый чибәр, бөтен җире килгән кыз турында уйларга мөмкинме соң? Мөмкинме?

Хәлбуки, мөмкин икән! Бер кичне шулай комсомол җыелышыннан чыгып, нилектән болай икәнлеген үзе дә белмәстән, башын салыбрак кайтып килгәндә, Сәйяр-дәүбаш артыннан Миләүшә-житез күбәләк очып килеп җитте. Миләүшәләрнең Карл Маркс урамындагы квартираларына кадәр бергә кайттылар, көндәлек килде-китте сүзләрдән бүтән сүз кузгалмады. Миләүшәләрнең капка төбенә кайтып җиткәч һәм Миләүшә, шәһәр алгандай тантана белән, «Без, Сәйяр, менә шунда, икенче каттагы биш тәрәзәле квартирада торабыз, минем бүлмәмнең тәрәзәсе әнә чаттагысы!» дип белдергәннән соң, Сәйяр, эченнән генә җинел сулап, «Йа алла, телдән юк-бар сүз ычкынганчы котылам, ахры, бу кыздан!» дип шатланып куйган иде. Юк, котылырга юл куймады кызый, «Әле вакыт иртә, әйдә, мин сине озата барам, һаман кызларны гына озатырга дигән закон юк, кайвакытта кызлар үзләре егетләрне озатып куярга тиештер» дип, аңарга хас рәвештә, үҗәтләнеп, егеткә ияреп китте. Аз сүзле Сәйярның теле барыбер ачылмады! «Әйеме? Әйе!», «Шулаймы? Шулай»дан узмады. Сөйләшә алмавыннан, эчке дулкынлануыннан, теле көрмәкләнүдән ахырда ул үтә уңайсызланып, «Карагыз әле, Талипова, мин Товарищеское урамындагы общежитиега барам, йомышларым бар, нигә сезгә ул җәһәннәм астына барып йөрергә, кайтыгыз борылып!» дип кырыс кына әйтеп тә карады. Егет кырыс торган саен, кызның чытлыклыгы арта гына бара иде. Ниһаять, ул, егет күрсәтмәгән кыюлыкны күрсәтеп, Сәйярның култыгыннан ук алды. Беренче тойгы шул булды: икесе дә яналар, ялкынсыз яналар иде. Сүз аның саен рәтсезләнә генә барды. Хәер, сүз урынымы соң бичара «белошвейка малаена»: төнлә төшләрендә күреп, көндез очратканда тизрәк күзеннән ычкынырга тырышып ярата торган яшертен алиһәсе ич ул аның — алла мәңгелек итсен иде бу минутларны! — менә бит аның белән рәттән бара. Сүз дигәне тумаса да, рәттән бара, кызуы белән яндырып бара...

Ләкин мәңгелек итмәде алла бу минутларны. Хәрәкәткә бай һәм нык яктыртылган Вишневский урамыннан борылып, аулаграк Академический урамына бары тик кергәннәр генә иде — үз бәхетләреннән үзләре исергән безнең бу яшьләребез абайламый ук калдылар — алар каршына тузгак башлы, авызларыннан аракы исе аңкыган ике сантый килеп чыкты, бик үк сузып тормыйча, борыннары белән төртелгәндәй, каршыларына килеп бастылар. Боларның юлларын кистеләр һәм, әлбәттә, сүз тәмәке сораудан башланды. Шунда ук мыскылга күчеп:

— Тәмәке дә суыра белми торган авызың белән, син, пацан, бу чибәр кошны үбәргә алып барасың түгелме? — диде берсе.

— Юк, ул аны скандалсыз гына безнең кулга тапшыра,— диде икенчесе һәм кызны тупас кына үзенә тарта башлады. Менә кайда икән сөйләшә белми торган «белошвейка малае»ның чын мәхәббәтне сүзсез генә изһар итәр минутлары! Сәйяр, һични уйлап тормастан, уртага атылып керде һәм яшь арсландай ыргылып, теге нахалның яңагына кундырды. Шул арада, җәлт кенә борылып, Миләүшәгә тизрәк ычкынырга ымлады.

Кызның киткәнен абайлагач, бер үзе коры кул белән ике хулиганга каршы сугышка ташланды. Ә тегеләр коры куллы булмаганнар икән, кыскасы, мәхәббәтен тел белән әйтә алмаган Сәйяр Солтанов ул хис белән шаярырга ярамаганлыгын кызны беренче озатканда ук күрсәтте. Икенче көнне аны больницада яңагы телгәләнгән хәлдә таптылар.

## IV

Миләүшә Сәйяр янына больницага, көн саен ук булмаса да, әледәнәле килгәли йөрде. Килгән саен тәмле-татлы күчтәнәчләр китерә, ишеткән яңалыкларын җиткереп, ишетмәгәннәрен үзеннән чыгарып, ничек тә егетнең күңелен күтәрергә, юатырга тырыша, озаклап-озаклап утырып китә иде. Килгәне саен өстенә яңадан-яңа күлмәк, платье-костюм, билне кысып, башка урыннарны күпертеп күрсәтә торган мәкерле трикотаж киеп, авыруның хәлен белүдән дә бигрәк, үзен күрсәтә килгәндәй килә. Әлбәттә, чамасын белеп кенә иңбашларын да сикерткәләп куя, җиңелчә генә кытыклый торган берәр сүз әйтә, Сәйярның палатадаш иптәшләре алдында гадәттәге көмеш тавышы белән яңгыратып көлеп җибәрүдән дә тартынмый иде. Көлке урыны түгел икәнлеген абайлап алгандай итеп, оялып, кызарып та кала, Сәйярның күзләренә карап хәтсез генә сүзсез утыра. Каһәр төшкән вәсвәсә, боларның барысының да үзенә килешеп торганлыгын, бөтенесенең дә күзе аңарда икәнлеген, бу кыланышлары, болай кинәт кызарып тынып калулары белән Сәйярга әллә нихәтле куаныч, әчке горурлык һәм шул ук вакытта күңел тирәнлегендә баш калкытучы, көнчелек катнаш, яшертен пошаманлык алып килгәнлеген, әйтерсең лә, сизә.

— Кара әле, егет, син мондагы врачларның тәмле телләреннән бик эреп китмә,— ди ул, егетне әллә шаяртырга, әллә юатырга тырышып,— хәзерге медицина тәнгә ямау салырга бик оста, күрәм, килгәннән-килгәнгә шомарта баралар үзеңне. Кайдадыр, яңагыңдамы, авыз читендәрәк булса бигрәк тә шәп, Виктор Гюго хикәяләрендәгечә романтично чыга, кыскасы, истәлеккә кайдадыр берәр җөй калсын. Мин дә бит кеше, минем дә мактанасы килгән минутларым булыр.

Эндәшми Сәйяр, мөлдерәп карап тик ята Сәйяр. Ә күзләрендә әлеге шул хәтәр ялвару: «Уйнап әйтәсеңме син бу сүзләрне, уйлап әйтәсеңме? Уйлап әйтәсең икән, нигә кирәк Виктор Гюгоны кыстырырга? Күп белгәнлегеңне күрсәтер өченме?»

Ә үзенең җаны уч төбендә: «Китәргә җыена торгандыр, шуңа күрәдер болай теленә салынуы. Янәсе, «юата» һәм әледән-әле тирәнтен, әйтә алмый торган хәсрәте бар кеше сыман, уфылдап куя.

— Әллә һаман авыртамы? — дип сорый Миләүшә, бу юлы инде бик җитди кешегә әверелеп.

Җавап бирми Сәйяр, шул ук вакытта Миләүшәгә юкны-барны уйларга сәбәп тә калдырасы килми, ах алла, үзенең көеп ятуы да җиткән. Җавап урынында авыз чите белән генә елмая һәм кызга тагын бер томырылып карап куя. Һәм кинәт, пафоска һич бирелмичә, шул ук вакытта сүзне уенга алырга да юл калдырмаслык итеп, авыз эченнән пышылдап кына диярлек, теленә килгән строфаны әйтә:

> ...Бәлки, уйларсың бу кеше, бушка аһ ормый, диеп,
> Аһлары, фөрьятлары чынлап та урынлы, диеп.

Аннары, имтихан алучы доцент кебек, бу юлы инде көррәк тавыш белән сорый:

— Син филолог ич, Миля, йә, әйтеп кара: кем шигыреннән бу юллар?

— Әллә тагы? Үзем язган булсам, бәлки, хәтердә торыр иде,— дип, гадәтенчә уен-көлкегә борып, сорауны сүндермәкче була Миләүшә. Чынлыкта исә, аңа ничектер уңайсыз булып кала бу минутта. Математика

җенс кагылган кеше, «Будущий Ландау», әнә, ничек матур итеп, уйланып һәм моңланып, шигырь сөйли белә. Татар шагыйренең шигыре. Ә тарих-филология факультетында укучы, җитмәсә үзе дә филолог кызы Миләүшә Талипова ык-мыкка килеп төртелә. Хәлне ашыгыч рәвештә төзәтергә кирәк иде. Бу очракта Тукайны гаепләү иң ансат юл булып күренә Сәйярга:

— Булган бит Тукай дигән бер кеше дөньяда. Безнең ише башлары каткан студентларга эш ясап, әллә нихәтле шигырь язып калдырган. Аларның барын да ничек хәтердә тотмак кирәк. Ике юл шигырен әйттем, анда да икеме-өчме урында ялгыштым шикелле.

Ләкин кыз сүрән килеш калды, аны элеккечә җилкендерү мөмкин түгел иде хәзер. Шундук ул китәргә кузгалды һәм йомшак, ак кулын Сәйярның учына салганнан соң, шулай да егетнең кулын кысарга ашыкмыйча һәм гаять җитди итеп әйтте:

— Икенче килеп йөрмәм, Сәйяр. Тизрәк терелеп чыгу ягын кара. Антым шушы булсын: җиң сызганып Тукайны зубрить итәргә утырам. Оялттың син мине, будущий...

Шулай да гадәтенә хилафлык күрсәтмәде ул. Кырт кына борылды, башын бик тә текә тотып, көдрә чәч толгәшләрен җилфердәтеп, вак-вак кына атлап һәм, шул назлы-нәфис кыланышлары белән, болай да каршылыклы уйларга күмелгән бичара мәгъшукны тәмам исертеп диярлек, палатадан чыгып китте.

## V

Яшь тән тиз төзәлде, больницадан чыкканда Сәйярның яралары беткән, егет яхшы ук тазарган-шомарган, тик Миләүшәнең теге вакытта әйткән теләген искә алгандай, авыз читендә беленер-беленмәс кенә җөй эзе уелып калган иде. Миләүшә үзе теләгән бу «романтика» өчен тыштан куанган кебек күренсә дә, чынлыкта исә «романтикасыз» вакытта да әллә ни коеп куймаган бу егетне ул үтә очынып каршыламады. Дөресен әйткәндә, башлы-сәләтле булганы һәм курсташ студентлары арасында яхшы даны таралганы өчен «вакыт уздыру өчен ярар!» дип керешелгән мәзәк кенә. Шуның өчен чибәр кыз Миләүшә һавага сикереп торсынмы! Аның каравы, Сәйяр үзе авыз читендәге җөй турында ичмасам уйлап та бирми, Миләүшәсен бик-бик сагынып чыккан, ничек тә вакыт табып, кызны күрергә, аның янында булырга атлыгып тора, мәҗнүннәрчә гашыйк булганлыктан, кыздагы эчке үзгәрешләрне бөтенләй сизми. Җитмәсә тагын, больницада эшсез аунап ятканда башы әллә ниләр уйлап чыгарган, Миләүшәгә очынып-очынып әкәмәтләр сөйли: имештер, җирнең тарту көчен атмосферадагы һава хәрәкәтенең агышы белән дөрес бәйләнешкә куя белсәң, табигать капризларын, бөтенесен булмаса, күбесен авызлыкларга мөмкин булачак. Әлбәттә, бу ансат кына хәл ителә торган гипотеза түгел, ләкин, егетнең шашынып хыяллануына караганда, хәзерге атомный-электронный исәпләүләр, микромирларның табигатенә үтеп керү заманында, бүген булмаса иртәгә, кеше кодрәтеннән киләчәк эш, имеш! Ә Миләүшәгә ни — әллә керә колагына, әллә керми. Аның башында үз хыялы:

...Бер елдан булмаса, ун елдан булсын. Күпмени ул ун ел! Ун елдан Миләүшәгә нибары утыз тирәсе, ә аның дәү башы ул вакытта дөнья-күләм ачыш ясап, планетаны шаулаткан бер гений булса? Үзегез уйлап карагыз, дан ярата торган һәм, чибәрлеге сәбәпле, әтисе белән әнисенә бик кадерле бер кыз булуы аркасында, инде яхшы ук узына да башлаган Миләүшә егетнең ирен читендәге беленер-беленмәс җөйгә игътибар итеп торырга тиешме соң?

Һәм әнисен шушы юнәлештә алдан бераз әзерләгәннән соң, планының еракка юнәлтелгән очын хәзергә ачыктан-ачык әйтеп бетермәсә дә, ләкин

тел төбен сиздереп, ә этисен әзерләүне энисенең үзенә калдырып, көннәрдән бер көнне кыз, аллага тапшырыпмы, тапшырырга өлгермичә үкме, җөйле иренле егетне Карл Маркс урамындагы бик матур, бик җиһазлы квартираларына ук алып кайтты. Хыялый Сәйяр, мәгъшук Сәйяр анымоны уйлап тормады, өстендәге кием-салымына да игътибар итмәде, нәрсә бар, нидә йөргән — шул килеш китте дә барды. Чөнки дөньяның ялгансызлыгына ышанган: Миләүшә хәтле Миләүшә чакыргач, ничек инде ни дә булса уйлап, икеләнеп тормак кирәк. Миләүшәнен һәм өлешчә аның әнисенең эшне болай тиз тотуларынын, шулай ук, эчке бер сере бар иде: егет тә, кыз да институтны бетереп киләләр, менә диплом эшләрен тапшырырга да, амин, хуш, җаным, Болак буе. Өркеткәне бигрәк тә шунда: кая җибәрерләр бит әле? Кыскасы, җөйле ирен дип торырга түгел, өс-башына да күз йомарга булдылар — бөтен даһи кешеләр өс-башка игътибарсыз булганнар, дип ышандырды Миләүшә әнисен.

Бер мәсьәләдә кыз да, әнисе дә аерып булмаслык союзниклар иде: институтны бетереп, кая булса да җибәрергә өлгергәнче тизрәк «семья» дигән чикләвек кабыгы эченә кереп бикләнергә һәм, әлбәттә, Казанда калырга! Бөтен чаралар белән, кирәк икән, этиләре доцент Талиповнын барлы-юклы авторитетын да ходка җибәреп.

Егетне беренче мәртәбә өйгә китерү көткән эффектны бирмәде. Миләүшәсе алдында гына әтәчләнгән икән, кызнын этисе алдында кайда гипотезалар корып азаплану, кирәкле сүзен дә әйтергә уңайсызланып, түбән карап кына утырды. Күтәрелеп караса да әллә нидә бер Миләүшәсенә генә карап ала, анысы да: «Кая китереп куйдың син мине?» дип ялварып карау иде.

Вино салып алдына куйдылар, башта «Эчмим!» дип өздереп әйтеп ташлады, кыстап карадылар, эчмәде. Һәм кинәт, эчү-эчмәү мәсьәләсе бөтенләй онытылгач, ахрысы, таркалып калудан үзе дә сизмичә булса кирәк, бокалны дәррәү күтәреп эчеп җибәрде. Һич югы, Сәрия ханымнын зур тырышлыклар белән, әлбәттә, доцент Талипов акчасына алган импортный мебеле турында кызыксынып бирәр сүз кыстырсын икән!

Чәйдән соң Сәйяр, кинәт кыюлык җыеп, эти Талиповка шахмат тактасында ике мәртәбә «мат» куйды да, «Булмый сездән, доцент иптәш! Кылычка-кылыч килеп сугышырлык булмагач, вакыт әрәм итәргә кирәк түгел!» дигәндәй, кырт кына торды һәм китәргә җыенды.

— Бик мокыт нәрсә күренә синең бу мактаулы егетең,— диде әнисе, соңыннан Миләүшәне алгы якта үзен генә туры китереп. Аннары, кунак киткәч, шул кызу белән иреннән сорау алырга кереште:

— Иә, синдә нинди тәэсир калдырды «белошвейка малае»? Алла сакласын, көннәрдән бер көнне шул оешмаган гыйбат синең бердәнбер кызыныц кулын сораса?

— Син, әнисе, Тургенев романнарыннан качып чыккан гранддамаларча сөйлисең бүген.— Аннары, хатынын үпкәләтүдән шүрләп булса кирәк, сүзне бераз йомшартырга, уен-көлкегә борырга булды.— Ничек дип әйтим, адәм ат түгел, тешен карамадым. Ә менә шахмат тактасында миңа ике очко бирүенә караганда, башсыз егет түгел ул.

Сүзне хәзергә шуннан артык куертырга теләмәделәр, чөнки эш ул хәтле чаң сугу дәрәҗәсенә үк барып җитмәгән, әгәр шул якка китә калса... һәм егеттән чынлап та бәрәр гений чыгардай күренеп торса... Төкерергә авыз читендәге җөйгә һәм аның «белошвейка малае» булуына! Шулай да Миләүшә-ялкау артык баш ватмаска, һәрхәлдә, Сәйярга ошарга тырышудан гына Тукай шигырьләрен ятлауны артык дәвам иттермәскә булды.

## VI

Шулаен шулай да, әмма этисе әйткән сүз дә кызнын күңелендә нык утыра: «Шахмат тактасында миңа ике очко бирүенә караганда, башсыз

егет түгел ул!». Шулай диде бит әти кеше. Ә Миләүшә, бөтен җилбәзәклегенә дә карамастан, әтисе фикере белән нык исәпләшә, кыска гына шул сүзләрдән ул үзенә әллә нихәтле мәгънәләр чыгарып, «белошвейка малае»н тагын бер кат күңеленнән «гарше-көрсиләргә» менгезеп утыртырга, уенчак фантазиясе белән дөньякүләм танылган гениләрнең берсе ясап куярга өлгергән иде инде. Шуңарга тагын яңа хәбәр дә өстәлеп тора: чын булса әгәр, Сәйяр Солтановны аспирантурада калдырачаклар, имеш. Һәрхәлдә, ачык авыз булып торырга ярамый, чарасына керешергә кирәк. Сүзгә саран ул егетнең, тауга таба бер менә башласа, ярты юлда тукталып калмаячагына кыз чын ихластан ышанган һәм шөһрәт тавының башында, җитәкләп алып менгән пәйгамбәре гәрчә алай күзнең явын алырлык булмаса да, бергә аяк сузып утырып, түбәндә чуалучы вак кына адәм балаларын өстән тамаша кылу аны бик-бик кызыктыра иде. Шуларның барысын да искә алып, Миләүшә хәрәкәткә үк кереште. Иң элек Сәйяргә—бу юлы инде томанлы сүзләр белән сузып тормыйча—үзенең планнарын ачып салды. Ачык авыз булып торасы юк, институтны бетереп, төрлебезне төрле яры озатканчы, икебезнең язмышны бергә кушарга, ягъни, закон нигезендә ирле-хатынлы булып алырга. Шуннан соң карасыннар семьяга кагылып.

Болай үтә ачык әйтелгән тәкъдимне һич көтмәгән һәм тәкъдимнең шулай ачыклыгыннан хәтта бераз аптырабрак та калган Сәйяр шулай да сөенде. Һәм бер үк вакытта курка да калды. Ләкин ул чын-чынлап гашыйк иде һәм, шулай булarak, дөньяда нинди дә булса мәкер булыр дип уйламый да иде. Миләүшә дөрес әйттеме соң? Шундый чибәр, шундый уенчак күңелле, сөйкемле, тапкыр сүзле кешедә, укымышлы ата баласында, мондый житди мәсьәләдә шаяртып сөйләшү мөмкинме соң!

...Һәм алар бер дә бер көнне, Миләүшәнең кыздыруы, Сәйяр беркатлылыгының ышануы аркасында, әни кешенең кылын тартып карау нияте белән, бу юлы инде егет өенә килделәр. Сәйярнең әнисе Хәят ханым мондый хәбәрне каршылау өчен, әлбәттә, әзер түгел иде, башта бераз каушабрак калды. Өенең җыелмаган булуы өчен каушады, үзенең ялгызлыгы, фәкыйрьлеге өчен уңайсызланды. Ниһаять, малае ияртеп килгән кызның чибәрлегеннән өнен югалткандай булды. «Па хода, булса да булыр икән! Мина моңарчы күрсәткән газапларың өчен бер бүләгендер бу! Әллә моңарчы күрсәтеп өлгермәгән яңа газапларга әзерләвеңме?» дигән уй үтте аның күңеленнән.

Ләкин әш кешеләренә хас реалистик акыл шундук үзенекен итте — аның Сәйяры да төшеп калганнардан түгел ич! — бар булганы белән бу кадерле кунакны сыйлап җибәрергә ниятләп, табын әзерләргә керешә. Әнисен өзгәләнү катыш болай балкыган хәлдә һич күрмәгән Сәйяр, әллә юатырга, әллә аңарга ярарга тырышып:

— Каушама ул хәтле, әнкәй. Без узышлый гына кердек, хәзер китәбез,— дип караса да, Хәят ханымны алай тиз генә айнытырга мөмкин түгел иде инде. Улының кыздан күзен ала алмаганлыгын, эчке балкуын күреп тора ич, малае бәхетлегә ана да бәхетле, карасана, алар урамына да шундый бәйрәм килер көн булыр икән! Шик юк, әнә ул чибәр кыз да бәхетледер, аның Сәйярын яратадыр, шулай булмаса, өйгә үк басып кермәс, болай сөйкемле көлемсерәп тормас иде. Соң шушы хәтле зур шатлыкны бер утырып чәй дә эчмичә уздырып җибәрү мөмкинме?

Ул да түгел, кыз үзе дә, һич рияланып тормыйча, бу йортның әллә кайчангы үз кешесе кебек, уйный-көлә әйтеп ташлады:

— Эчмәсәң, син эчмәссең, Сәйяр, сине көчләгән кеше булмас. Ә минем тамак чатнап тора, Хәят апаның бер стакан кайнар чәен эчмичә китәр хәлем юк. Сөйләшә башлагач сүзе дә чыгар дип уйлыйм.

Хәйләкәр кыз, чегән кызы! Торышында, сөйкемле елмаюында, янгырап торган тавышында, сүзләрнең һәрберсен теш арасыннан сайлап-сайлап кына чыгаруында — бөтенесендә, бөтенесендә — бер үк вакытта са-

мимилек тә, үз итү дә бар сыман, шунда ук тагын «аналы-уллы икесе дә бер калып икән болар, егылып төштеләр бер күрү белән!» дип, чак кына мыскыллау да яшерелгән иде.

Табын янына утырып сөйләшә башлагач, чынлап та, сүз чыкты. Үз тормышларының кысанрак булуын сөйләп, бу сөйкемле кызны алдан ук кисәтеп куярга теләгән Хәят ханым, бер тел ачылгач, үзе белән генә чикләнеп калмыйча, Талиповлар ягына да үзенчә разведка ясарга маташып карады. Ләкин аның хәйләсе ак җеп белән тегелгән, ерактан урап йөри алмый, ике сүзнең берендә сүз тынлаучан Сәйяры белән мактанырга керешә һәм аның шушы тәүфыйклы улын күреп алган бу сөйкемле кыз өчен дә — киләчәктә үз кызы булып бу йортка киләчәк ул чибәр кыз өчен дә куанычы йөзенә, сүзләренә бәреп чыга иде.

Малае Сәйярның әледән-әле искәртүенә дә карамастан, Хәят ханым, үзе дә сизмәстән, чишелепме чишелде. Булган-хәл ителгән эшкә йомгак ясаган тон белән:

— Вакыт житкәч, бер бездән генә калмаган, ата-баба җоласы, алдыарты хәерле булсын, дияргә генә кала,— дип нәтиҗә ясарга да өлгерде һәм шундук тагын, соңыннан сүзгә урын калмасын, дигәндәй, квартираларының кысан булуыннан, үзенең кул эше белән генә шөгыльләнүеннән бераз зарлангалап та алды.

— Сәйярның бу зур башы белән киләчәктә квартирны гына, шәт, зурайтып булыр, хафаланмагыз юк өчен, Хәят апа,— дип, әллә Сәйярны мактыйсы килүдән, әллә үзенең дан яратуын сиздермичә тыелып кала алмаганлыктан, бер шаулап куйды Миләүшә...

Әлбәттә, бер утырып чәй эчү вакытында гына күп нәрсә сөйләшә алмадылар, әмма эшне озакка сузмыйча, Загска гариза биреп куярга кирәклеге турында ишарәләр ясалды.

Иң кызык аңлашу соңыннан, Сәйяр институтта эшләрен бетереп кайткач, әнисе белән улы арасында булды. Соңыннан барысын да кайта-кайта уйлаган ана, шатлыгын яшермичә, әмма күңел тирәнлегендә яткан хәвефне дә сиздерми кала алмыйча, әйтә куйды:

— Болай үзе яхшы ата баласы күренә ул Миләүшә дигәнең. Сүзгә өнгә дә ягымлы, бер карауда гына кеше күңелен белеп бетереп булмаса да...

— Ә мин бер генә күрмәгән Миләүшәне, әнкәй, юкка борчылма,— дип, әнисен тынычландырырга ашыкты Сәйяр һәм, артыгы белән гашыйк булганлыктан булса кирәк, үз сүзләренә бик нык ышанып, өстәде,— бәхетле булачакбыз без аның белән, күр дә тор менә, шушы дивана әйткән иде диярсең, бәхетле булачакбыз.

## VII

Дөньясын онытkan гашыйк кешеләрдә генә мөмкин бәхетле минутлар да, әлбәттә, булгалагандыр, әмма чын бәхеткә әле ерак, алар аны көтәләр генә иде. Икесенең дә ризалыгы белән һәм олыларның да ризалыгын алып, ә Сәйярның әнисе Хәят апага килгәндә, шундый абруйлы кешеләрнең коры кашык белән суырып йотарлык чибәр кызларын үзенә карата алган улы өчен аны башы күккә тиярдәй куандырып, Загска гариза биреп кайтканнан соң, әлеге чын бәхетне көтү тагын да дәртлерәк бер төскә керде. Ике якта да туйга хәзерлек эшләре башланды. Кыз әнисе Сәрия ханым, үз гаиләсенең баерак булуына таяныпмы, җөйче хатынның фәкыйрь бюджетын күздә тотыпмы, бер сөйләшү вакытында, үзе дә сизмәстән тавышына тәкәбберлек өне чыгарып:

— Сезгә, ялгыз тол хатынга авырга килердәй булса, туй дип көчәнү фарыз түгелдер, безнекенең җилкәсе калын, доцент кешегә акчаны санап

бирмиләр, берләнбер кызыбыз икән — жәл түгел, ике як авырлыгын да үзебез күтәрербез,— дип ычкындырып ташлаган иде, аның бу сүзләре егет әнисен яхшы ук рәнжетте. Ләкин Хәят ханым сабыр, үзен тота белә торган кеше иде.

— Ә минеке берләнбер түгелмени? — диде ул, җинелчә генә үпкәләгәндәй итеп,— кеше арасында, шәт, борынгылар жоласына тап төшермәбез, үз өлешебезгә тиешлене үзебез күтәрербез, туй мәҗлесе иң элек минем түремдә булырга тиеш,— диде аннары, катгый рәвештә өзеп.

Горурлык хисенә кагылганда әйтү ансат булса да, әмма элекке запасы булмаган, кул хезмәте һәм улының стипендия акчасы белән генә очын-очка ялгап килгән сыңар канатлы бу гаиләгә туй хәтле туйга әзерләнү, әлбәттә, җиңелгә төшмәячәк иде. Ләкин әйтелгән сүз, Хәят ханым ничек тә сер бирмәскә булды. Малае Сәйярның зурдан купмаска дип тукып торуына да карамастан — берләнбер улын өйләндергәндә зурдан купмаска мөмкинме соң! — әни кеше шулай да кеше арасында ким-хур булмаска, кыз ягы алдында сер сынатмаска, үз өендәге туй мәҗлесен жиренә җиткереп уздырырга, яшь киленгә, кодагый-кодаларга бүләк-санакларны биткә оят китермәслек итеп әзерләргә булды.

Һәм китте, китте фәкыйрь тол хатынның борчулы төннәре башланып. Көндез авыздан сүз чыгарырга ярамый, кирегә сукалаучылар бар, улы Сәйяр да борчылырга тотыныр аннары, ә әни кешенең, шундый бәхетле көннәрендә юкны-барны әйтеп, малаен борчыйсы килми иде. Инде дә әнигә нәрсә кала? «Шулай итсәм, ничек булыр икән?», «Болай иткәндә, бер жле килеп чыкмасмы?» дип төннәр буе йокы күрмичә исәпләп чыгарга кала.

Бурыч сорап кемнең булса да ишеген шакыганчы, иң элек үзенең иске сандыгын ачып карарга булды. Электә хәлле кешенең баласы булганлыктан, Хәятның үзен кияүгә йоласын җиткереп биргәннәр, сак хатынның егерме-утыз ел сакланган бирнә маллары әле булса исән-сау, ләкин заманы узган, модасы чыккан бу зиннәтле малларга хәзер кызыгучы булмаслыгын ул белеп тора иде. Күптән исенә төшеп тә, ләкин яшьлек хатирәсе буларак кулдан ычкындырасы килмәгән ике-өч зат нәрсәсе бар: берләнбер улы өчен кызганырга мөмкинме, ниһаять, сандык төбеннән аларны да тартып чыгарды. Нинди дә булса карарга килергә бик ашыкмастан, әле берсен, әле икенчесен кулына алып, озаклап карап торды. Болар: иренең әтиләре бүләк иткән энҗеле калфак белән муен энҗесе һәм Хәятның киявенә — Сәйярның әтисенә — Хәят ягы бүләк итеп китергән калын алтын балдак иде. Ничек кенә аңлатып бетермәк кирәк — аннары тагын тигезлектә узган бәхетле көннәрнең татлы серләрен аңлатып бетерү мөмкинме? Кирәкме? — Бик-бик газиз истәлекләр иде болар. Шулай да, ничек кенә газиз булсалар да, малае хакына ул аларны сатып җибәрергә әзер иде. Курка-ояла берничә кешегә тәкъдим ясап та, көткән бәһаны бирүче булмагач, тәмам гаҗизләнеп, ахырда энҗеле калфак белән энҗе муенсаны итәк астыннан гына шундый алу-сату эшләре белән йөрүче бер еврейга ярты бәясенә биреп җибәрде. Ә алтын балдакны сатмады, ире төсе белән шаяруны күңеле күтәрмәде. Ничек кенә булмасын, туйга дигән мая туплана башлаган иде инде. Шуның өстенә төннәр буе эшләргә туры килсә дә, һич авырсынмыйча башкарырга ашыгыч җөйләр алды. Сер сыярдай якыннарыннан һәм, әлбәттә, вакытында һич көттермичә түләргә антлар итә-итә, бурычка да алгалады. Барысын бергә җыйгач — әртил, дигәндәй, һәрхәлдә, туйны адәм көлкесенә калмыйча ерып чыгарлык сәрмая тупланды. Ничек? Кайдан? Нинди шартлар белән? Бу турыда әлегә Сәйяр берни дә белми, ул шулай белмәгән, кызыксынмаган, дөнья ыгы-зыгысы белән вакланмаган хәлдә бәхетлерәк, ул кавышу көннәрен көтү белән бәхетле, ул Миләүшәсенең шәүләсен күрү, аның тавышын ишетү белән бәхетле, ниһаять, ул шушындый көннәрдә — кояш һәм өмет белән тулган шушы җәй башы көннәрендә — башын югары тотып җирдә атлап

йөрүе белән бәхетле иде. Ә сизгер күңелле ана моны, әлбәттә, тоеп йөри, ул исә бердәнберенең бәхетле икәнлеген күрүдән бәхетле иде.

Шул ук вакытта дөнья көтелмәгән хәтәрлекләрдән дә имин түгел иде. Бер көнне институт коридорында Миләүшә Сәйярның үзен генә туры китереп, пышылдап кына, шулай да бик ишеттерерлек итеп, хәтта боергандай, өзеп кенә әйтте:

— Минем сине күрәсем бар, Сәйяр. Син бүген кич бушмы? — диде. Сорап торган була, соң инде Миләүшәсе дигәндә Сәйярның кайчан буш булмаганы бар! Очраштылар. Өйдә дә түгел, кинода да түгел, кеше күп йөри торган парктa-мазарда да түгел, аулаграк урын дип, Миләүшә Сәйярны Казанка тавындагы түгәрәк бакчага алып китте.

— Все течет, все меняется,— дип, ничектер табышмакка охшатыбрак, башлап китте Миләүшә, Казанка суына карап.

— Кем әйткән әле моны?

— Кем әйтсә дә к черту,— диде Миләүшә, тавышын күтәрә төшеп. Һәм паузадан соң төрпә генә кабынып һәм, шул ук вакытта мөмкин кадәр әдәп рамкасыннан да чыкмаска тырышып, янә ялгап китте:

— Кара әле, идеальный герой, миңа җиткерделәр: син аспирантурадан баш тартып, авылга укытучы булып китәргә йөрисең, имеш. Дөресме шул сүз?

— Болай бик стенага терәп сорагач, әйтмичә дә булмас: бәлки, дөрестер дә.

— Минем чынлыкны беләсем килә һәм синең үз авызыңнан.

— Минем бер вакытта да ялганламаганымны беләсең, Миләүшә. Ялган — миңа противопоказано. Шулай булгач, әйтсәм әйтим: әгәр дә фән юлыннан китәргә миндә нинди дә булса сәләт бар дип табалар икән... дөресрәге, мин үзем шулай табам икән, ул юл белән китәргә бер вакытта да соң түгел... аспирантурасына да, докторантурасына да. Без бит әле юлны башлыйбыз гына...

Сүз кинәт өзелде, икесе дә тынып, бер-берсенә карашып калдылар. Бигрәк тә Миләүшә, беренче кабат күргәндәй, Сәйярның күзләренә текәлеп калган иде.

— Күзләрең бик матур синең, болай матур булганынны әле бер вакытта да күргәнем юк иде,— дип, ярым пышылдап, Сәйярның авызына үрелде кыз. Үзе башлап үрелде, үзе башлап үбәргә кереште. Аннары дәррәү сикереп торды да ашыгып китәргә җыенды. Ләкин, әйтәсе төп сүзен әйтергә уңайсызланып, китә алмыйча таптаныбрак торды. Аннары, китә башлагач кире борылып, әйтте:

— Вот тебе будущий Ландау. Авыл мәктәбендә борын җелекләре кипмәгән малайларга әлифба өйрәтә.

Уртаклашу булдымы бу, әллә Сәйяр уйлаганны бөтенләй кире кагумы? Аера алмады Сәйяр. Аннары тагын, ник алай шашынып үпте ул бүген? Нәрсәгә юрарга икән моны?

## VIII

Бактың исә бөтенесенең нигезендә әлеге иркә кызның йөгәнләнмәгән фантазиясе эшләп чыгарган уен яткан икән! Бөтенесе әзерләнеп беткәч, җәйче Хәят муеннан бурычка батып булса да абруйлы кодалары алдында биткә кызыллык китермәслек итеп җыенгач, туйга килергә тиеш кунакларга хәбәр ителгәч, шул арада ана үзе, эченнән куанып йөрү белән генә чикләнеп кала алмыйча, улы Сәйярны да «Бәхетле булдың син, бала. Әтиеңнең вакытсыз вафат булуы өчен син гаепле түгел, сугыш гаепле, әмма шуннан соңгысында ходайга үпкәләр урыным юк, ач-ялангач булмадык, менә хәзер дә, әйтмәгәнебез булсын, нинди зат кешеләр белән аралашырга торабыз, берүк бер-берегезнең кадерен белеп, тормышыгызны ямьле итеп яши күрегез, балакаем!» дип, аналарча үгетләп-нәсихәтләп

торганда, күршеләр арасында да — кайсы бу тол хатынның шатлыгын уртаклашып, кайсы көнчелегеннән төрлечә юрап — сүз таралгач, кыскасы, туй тантанасы ишек төбенә килеп җиткәч, иртәгә-берсекөнгә туй дип торганда, Сәйяр почта ящигыннан адресы күрсәтелмәгән бер конверт алды. Әле ярый, почта ящигын әнисенә хәтле карап өлгерде, хат чынлап та сәеррәк иде шул... Почта белән килгән дип булмый, чөнки бер җирендә дә бер төрле дә элемтә органнары пичәте юк, аны кем булса да боларның ящигына кулдан ташлап киткән булырга тиеш. Почеркыннан Миләүшәнеке булырга тиеш икәнлеген чамаласа да, шундый җитди вакыйга — туй алдыннан кызның болай шаяруын Сәйяр башына сыйдыра алмый иде. Дөрес, соңгы вакытларда кыз ничектер серле рәвештә күзгә чалынмыйчарак йөри һәм егет моны кызның оялчанлыгыннан, күрше-күлән, туган-тумача, дус-иш арасында өйләнешү хәбәре таралганнан соң Агылый белән Тагылый булып күзгә ташланып йөрмәскә тырышуыннандыр дип үзен юата килде. Ай-һай ла! Шулай гына булсын икән. Хатны кулына алу белән, күңеле нидер сизенгәндәй, дерелдәп куйды ул һәм беравык конвертны ачмыйча торды. Ачса, анда ике төрле уйлауларга урын калдырмаслык итеп, ачык һәм кыска рәвештә түбәндәге сүзләр язылган иде: «Мин Загска биргән заявлениене кире алдым. Бернинди дә туй булмаячак. Авылга ияртеп алып китәргә иптәш кирәк булса, син инде андый кешене бүтән урыннардан эзлә. Миләүшә».

Юк, аптырап түгел, аптырау дигән төшенчә генә моны сыйдырмый, ачуланып та түгел — ачуланып кешене нишләтәсең, гарьләнеп тә түгел — әлегә кулы-аягы исән, аяк астында җир җимерелмәгән, җир ничек тә күтәреп торыр, шулай да нәрсә дип әйтергә дә, ничек уйларга да белмичә, бер мәл торыксыз калды Сәйяр. Башы эшләми, аягы атламый, теленә сүз килми — таш та таш, Сәйяр да таш. Югыйсә, барлы-юклы берничә минут, әнә шул конверт, әнә шул хат кисәге... коштай очынып йөргән кешене күз ачып йомганчы ташка әйләндерер икән. Беренче булып башына килгән дәһшәтле уй: кеше сүзеннән курку түгел, курсташ иптәшләреннән ишетелүе мөмкин булган мыскыллы ишарәләр дә түгел, үзенең зур башлы, сай акыллы булып, тиң түгел кыз артыннан хыялланып йөрүен кинәт аянычлы рәвештә төшенеп алудан да түгел, ниһаять, кызның шундый мәрхәмәтсез шаяртуыннан да түгел — Сәйяр әле моны Миләүшәнең гади бер шаяртуы гынадыр дип уйларга да әзер иде. Беренче булып җанны өшетеп үткән уй: «Әни! Әни бичара нишләр? Күпме өзгәләнеп, канатланып, бер үк вакытта хәсрәткә батып, йөз суы түгеп, кешедән уртак сөенеч сүзләре көткән көне ишек төбенә килеп җиткәч, менә кәрәм дигәндә, башына җимерелеп төшсенче! Күтәрә алырмы ул бу хурлыкны? Җөйче Хәят кына бит ул!»

Сәйяр, Талиповларга үзе барып ачыкламыйча, бу коточыргыч уенны әнисенә ничек тә сиздермәскә булды. Хатны кесәсенә яшереп, тизрәк өйдән чыгып китү ягын карады.

Каршылыклы уйларга баткан хәлдә, юлда очраган таныш-белешләренә күтәрелеп тә карамыйча, тизрәк Миләүшәнең үзен күрергә дип чапты ул. Әйе, әле ул чаба ала иде, әле аның күңелендә сүнәр-сүнмәс калган өмет уты бар иде, һич югы... һич югы, барып җиткәч ярсып бер кычкырыр кебек иде. Институтта очратса — институтта, өендә туры китерсә — өендә, кеше арасында икән — кеше арасында кычкырып әйтерлек сүзе — «Ник болай? Ник болай мәрхәмәтсез шаярту кирәк булды сиңа?» дигән соравы бар иде. Арлы-бирле буталып чаба торгач, бу соравын да онытты. Дөресрәге, ул сорауның тәүге энергиясе югалды. Кызны ул өендә, әнисе Сәрия ханым белән икәве генә чагында туры китерде. Өчесе дә бер-берсенә сүзсез генә карашып калдылар. Фаҗигале рәвештә кызык килеп чыкты бу очрашу: күпне әйтергә дип килгән Сәйяр ишектән атлау

белән бусага төбендә шып туктап калды. Сәрия ханым кулына кайнаган чәйнек тоткан килеш, чәйнеген кая куярга белмичә, кызына текәлде — аның иреннәре арасында әйтелмәгән сүзе бар барлыкка да, ләкин ул кызы башлаганны көтә иде. Ә Миләүшә исә, дөньяда берни дә булмаган һәм иртәгә-берсекөнгә берни дә көтелмәгән кебек, ап-ак тешләрен балкытып, авызын ерып көлеп тора иде.

Мондый каршылаудан инде бөтенләй югалып калган Сәйяр, сүзләрен теш арасыннан көч-хәл белән генә чыгарып, ярым пышылдау белән башлады:

— Мин ялгышмыймдыр, бу синдер ич, Миләүшә? — Аннары, бераз хәл алгач, инде ачыграк итеп, шулай да үпкә белдерергә һич ашыкмыйча, дәвам итте,— соң алай булгач... шундый исәбең булгач, Миләүшә җаным, кирәк иде. Берьюлы үтереп ташларга кирәк иде...

Ә тегесе һаман шул баскан урынында, һаман шул ерык авыз килеш кала бирде. Кала бирде һәм кинәт бөтен өй эчен шаулатып шаркылдап көлеп җибәрде — әгәр иблис дигәннәре кайчандыр булган булса, кеше бәхетсезлегеннән иблис кенә шулай каһкаһәләп көлә алгандыр.

— Мин юри туйны көттем. Юри шулай эшләдем, Сәйяр. Син мин көткәнне челпәрәмә китереп ватканда ярады ич. Янәсе, имеш, будущий Ландау... Фактта килеп чыкты авыл мөгаллиме...

— Кемне көтәр идең тагын җөйче Хәят малаеннан. Тот капчыгыңны,— бусын кызның әнисе әйтте, беренче сүзе һәм соңгы сүзе шул булды. Һәм иңбашларын уйнаткалап, зур тәкәбберлек белән, алгы якка үтте.

Үзен кимсеткәнгә әле, бәлки, түзә дә алган булыр иде Сәйяр, әле аның Миләүшәгә әйтер сүзләре бетмәгән, әле ялынып-ялварып, аягына егылып карарга иде исәбе, ләкин әнисен — ун еллар буена аны газап белән үстергән, «Туй! Туй!» дип очынып-көенеп йөргән әнисен кимсетеп әйткән сүз аны бөтенләй өнсез калдырды.

— Шулай, алайса,— диде ул, тавышын мөмкин хәтле тигез һәм нык тотарга тырышып. Ишеккә таба атлады. Ишеккә барып җиткәч, борылып карап тормастан, авыз эченнән мыгырданды,— мин аңа әйтермен. Ялгыш юлдан киткәнбез... син дә, малаең да диярмен.

Кемгә карата булды бу сүзләр? Һәм, гомумән, уйлап әйтелгән сүзләр булдымы?

. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Кичен Сәйяр өйгә кайтмады. Хәят ханым төн йокламыйча диярлек аны көтеп чыкты. Сәйяр кайтмады. Иртәгесен дә, аннан соң килгән төнне дә кайтмагач, тәмам аптыраган ана, килешү-килешмәү турында уйлап тормастан, Талиповларга үзе китте. Кем беләндер киңәшмичә-сөйләшмичә мөмкин түгел, ә ул — беркатлы ана — сүзне читкә чыгарганчы, булачак кодалар белән аңлашу дөресрәк булыр дип уйлый иде.

Талиповларның өчесе дә өйдә чак туры килде, ләкин кодагыйны көтеп торган минутлары түгел, гаиләнең үз эчендә яңарак кына буран булып узганга охшый иде. Кыз әле генә елап туктаган, аның күзләре кызарган, күтәрелеп ни дә булса әйтергә базмады, баш иеп кенә исәнләште дә, тизрәк үзенең бүлмәсенә кереп бикләнү ягын карады. Сәрия ханым шулай ук ничектер шиңебрәк калган иде. Монда азмы-күпме үзен тигез тотып тора алганы әти Талипов иде.

Хәер, кодагый булачак кешедән күңелсез хәбәр — егетнең юкка чыгу хәбәрен ишеткәч, анысының да төсенә бәреп чыкты, кызы кереп бикләнгән бүлмәнең ишеге төбенә барып, тавышын күтәрә төшеп кычкырганын абайламый ук калды.

— Ятма бикләнеп, бар әнә үзең качырган киявеңне үзең эзли чык.

Тиз генә өстен-башын киенде, тик шуннан соң гына күреп алгандай итеп, Хәят ханымга урын тәкъдим итте. Өлкән Талипов бу минутларда

шулай ук бик аптыраган-йончыган һәм, бер ук вакытта, өйдә үзенең баш кеше икәнлеген күрсәтергә маташуы белән чак кына көлке дә иде.

Чыгышлый кызы булмасаенең ишегенә тагын бер кагылмыйча тыелып кала алмады ул.

— Кеше арасында көлкегә каласың килмәсә, — диде, бу юлы инде йомшаграк, ләкин бик тә үткәрә торган итеп,— ике юл кала синә, кызый: яки кулыннан ычкындырган Сәйярыңны эзләп табып, аннан гафу үтену... яки туйга чакырылган кешеләргә берәм-берәм чабып, туйның барып чыкмаганлыгын, һич югы кичектерелүен аларның исләренә төшерү. Үзең пешергән кайнар шулпаны үзең чөмер, минем бүтән сүзем юк.

Һәм, әчке ярсудан булса кирәк, мондагылар белән исәнләшеп торуны да онытып, ишекне каты ябып чыгып китте.

## IX

Ләкин «шулпа» телне өтәрлек кайнар, авызга алгысыз тозлы булып чыкты, ни теләсә шулай кыланып өйрәнгән җилбәзәк Миләүшә бу минутта бөтенләй көчсез иде. Шулай итеп, уйламыйча эшләнгән бу уенның ахыры кызның үзе өчен дә, әти-әнисе өчен дә хурлык белән бетте. Туйга чакырылган кунаклар, алып килгән бүләкләрен күтәреп, кире киттеләр — туй булмыйча калды. Үз чибәрлегеннән үзе масаеп, кияүгә «санатка чыкмакчы» булып йөргән һавалы Миләүшәгә хәзер инде — тапса, тапмаса — «солдатны» эзләргә калды. Җитмәсә тагын,— андый чакта гайбәтләре дә табылып кына тора бит аның — «Алмага корт төшкән булган икән!», «Кыз сонынннан терсәкне бик тешләмәкче дә, авыз җитми, кияүне качырып өлергергән» кебек сүзләр дә таралды. Миләүшә Загска шау-шусыз гына үзе барып, җимерелгән эшне төзәтеп булуына ышанычы җитмәсә дә, язылышуның срогын алгарак күчертеп кайтты, ләкин кияү булачак кеше үзе табылмаса, бу тырышлыктан ни файда!

Алты-җиде көн югалып торганнан соң, Сәйяр, арып-талып, карага катып, кайтып керде.

— Үзем укытырга китәчәк районда, укытачак мәктәбемдә булдым, эш белән йөрдем,— диде ул, тизрәк әнисен тынычландырырга тырышып,— ә нишләп болай хәбәрсез китеп баруымны сорама. Анысын үземә үзем дә әйтә алмаган булыр идем.

— Ә туй? Ә Миләүшәң?

— Ул турыда шулай ук кузгатма, әнкәй. Без икебез дә — син дә, мин дә — ялгыш юлдан киткән булганбыз.

Шундый ук кыска, өзек-өзек сүзләр соңыннан Миләүшә белән икe арада да кузгалды. «Сәйяр кайткан» дигән хәбәрне ишетеп, Миләүшә шундук йөгереп килеп җитте — ул гадәттәгечә чибәр, гадәттәгечә ерык авыз иде.

— Син нәрсә, «Фигаро здесь, Фигаро там»? Шаяртып әйткән сүздән тартэга тибеп, югалып йөрисең? Мин бит сине акылга утыртып булмасмы дип кенә...

— Аның караvы, менә хәзер акылга утырдым,— диде Сәйяр, бик тә җитди тавыш белән кызны бүлдереп. Ул Миләүшәгә ничек тә күтәрелеп карамаска тырыша иде,— безнең арада уртак берни дә булмаган, Миләүшә.

— Ә мәхәббәт? Синең Ромео булып кылануларың?

— Барысы да саташу гына булган. Синең саташуың түгел, минем саташуым.

Әлбәттә, Миләүшәнең сүзләре бетмәгән иде әле, Миләүшә әле һич югы бер «колдунланып» карарга, ак тешләрен балкытып көләргә, ничек тә элекке Сәйярны кайтарырга, котыртырга уйлый һәм, әле егетнең үзенә салам кыстырып, әле әнисе Хәятка якты чырай белән сүз катып, тыры-

шып-тырышып эшне җайламакчы була иде. Ләкин барып чыкмады, Сәйяр, сүзне юри вак-төяккә борып, әнисенә эндәште:

— Мунчага барып кайтасы иде, әни. Чиста күлмәк-ыштаннарым бардыр ич минем?

Әйе, ул ничек тә Миләүшәгә күтәрелеп карамаска тырыша, юри шулай тупаслык күрсәтә, әле бер нәрсәгә, әле икенчесенә барып тотына, шул ук вакытта күңеленнән кызның мөмкин чаклы тизрәк чыгып китүен тели иде. Миләүшә дә, инде терсәкне тешләргә омтылыш ясап өйрәнгән Миләүшә дә, төшеп калганнардан түгел, эшне сизеп тора: егет бөтенләй алышынган.

Аптырагач, кыз, балаларча еламсыраган тавыш белән, сәер генә итеп сузып куйды:

— Ә эти мине тирги, гел тирги. Янәсе, мин тәмам барып чыккан эгоистка, имеш. Кем тудырган соң мине әгәр алайга китсә?

Бу минутта Миләүшә бөтенләй кызганыч, ярдәмсез калган сабый хәлендә иде. Юк, күтәрелеп карамыйча булдыра алмады Сәйяр һәм йомшак кына итеп, ләкин уйнарга һәм өметләнергә урын калдырмаслык ачыклык белән әйтте:

— Бала булма, Миләүшә. Әтиең тиргәгәне өчен генә мин сине хатын итеп ала алмыйм. Әйттем и тагын әйтәм: безнең бернинди дә уртаклыгыбыз булмаган. Минем саташуымны, синең шуннан көлеп йөрүеңне исәпкә алмаганда.

Нишләсен бичара туйдан коры калган кыз! Аңарга ишекне теләртеләмәс кенә ачып, атлар-атламас кына чыгып китүдән бүтән юл калмаган иде инде.

...Кыз чыгып киткәннән соң, өйдә беравык авыр тынлык урнашып калды. Бу хәлне тирәнтен кичергән, ул сөйкемле чибәргә карата әле хәзер дә күңелендә аналык җылылыгы тойган Хәят ханым, ниһаять, аптырау катыш инәлү белән сорап куйды:

— Нәрсә дигән сүз булды бу, Сәйяр? Фәрештәдәй кыз, шундый атаана баласы белән?

— Мин белгәне дә житкән,— диде Сәйяр, сүзне тәкәллефсез генә өзәргә тырышып. Һәм шундук кем белән сөйләшкәнлеген абайлап, дәррәү әнисенең муенына сарылды.—...Синең хәлне дә аңлыйм, әнием-җаныем. Борчуларыңны да, минем өчен алган бурычларыңны да аңлыйм, түләргә тырышырмын, икеләтә түләрмен. Әмма ябышмастайны төкерек белән ябыштырырга маташмыйк. Сонгарак калып булса да инде төшендем: мин бер кеше, Миләүшә бөтенләй икенче. Бик чибәр булса да, бик яратсам да ул кызны, сорама, әнием-җаныем, туй булмаячак!

Сүзне артык сузып торырга урын калмаган иде булса кирәк, ана күңеле, авыр булса да, моны сизеп тора иде.

*Апрель-май, 1970.*

## Әхмәт Исхак

# ТӨРЛЕ ЕЛ ШИГЫРЬЛӘРЕ

### Хакыйкатьнең төсе

Хакыйкать асылда
Ап-ак була.
Ана сөте төсле
Саф, пакь була.

Була аның кайчак
Кызылы да,—
Канга манчылганда
Көрәш кызуында.

Хакыйтьнең очрый
Кайчакта сарысы,
Чагылганда анда
Җиңелу сагышы.

Хакыйтьнең булмый
Чуары, аласы.
Һәм шулай ук булмый
Карасы.

Хакыйкать асылда
Ап-ак була.
Ана сөте төсле
Саф, пакь була.

Тик саклагыз аны
Пычратудан:
Күгәрә, пычрана ул
Тик ятудан.

1968

### Утызымны эзлим

Колагыма көне-төне
Бер үк сүзне улыйлар:
— Юньле шагыйрь утыз яшьтә
Янып бетә ул,— диләр.
Ә мин барам инде менә
Җиденче уным белән.
Үтте инде ике утыз
Башымнан берәм-берәм.
Үтте ике Такташ гомере,
Ә яну — бетми һаман.
Мәңгелек ут мәллә миндә! —
Янам да һаман янам.
Аптырыйм үзем дә кайчак
Бу януның көченә:
Өләшсәм, житәр кебек ул,—
Кояштыр! — мең кешегә.

Тынгысыз йөрәк биргәндер,
Күрәсең, язмыш миңа.
Тынмый ул хәтта минут та
Онтылып ялгыш кына.
Нинди хәл булса дөньяда,
Борчылмый калмый шунар.
Ягулык минем йөрәккә,
Күрәсең, өсти шулар.
Әйләнеп бер мәл күмергә,
Сүнә бу, ахры, дисәм,
Заманның җиле күмерне
Дөрләтә өреп кисәк...
Кайда син, минем утызым,
Килмисең нигә һаман?
Мәңгелек ут, ахры, миндә! —
Янам да һаман янам...

18. 07. 68

## Сонет

Күпме дучар булмадым мин югалтуга!
Ин кыйммәтле никадәрле нәрсәм җуйдым.
Күпме дусны озаттым мин соңгы юлга,
Күпме якын туганнардан аерылдым!

Ни эшлисең! Законы шул бу дөньяның,
Бар да фани: булган — бетә, килгән — китә.
Яшь түксәң дә еллар буе, әрнеп җаның,
Күнегәсең барсына да ахыр чиктә.

Мин күнегә алмыйм тик бер югалтуга,
Ятсам-торсам, чыксам-керсәм, әрни җаным.
Сәбәп булдым үзем генә чөнки моңа:
Бушка үткән көннәрем ул һәм елларым.

Белмәдем шул: әрнемәсен җаным, дисәң,
Бер минутны бушка әрәм итмә икән!

Май, 1968

## Яшь дуска

*Вариант*

Елама, яшьлек үтә, дип,
Син менә миңа кара:
Кая яшьлек! — минем әнә
Картлыгым үтеп бара.
Еламыйм шулай да.
Никме?
Еларга тапмыйм ара.

1969

## Беренче яшен

Яшьнәде күктә
Беренче яшен
Һәм түкте җиргә
Эчкерсез яшен.

Һәр тамчы яше
Кояшлы, якты.
Юк, ачы түгел,
Ул шундый татлы!

Әйтмәгез, нигә
Түгел, дип, ачы?
Ул табигатьнең
Шатлыклы яше.

Тыела алмый
Ул шуңа менә,
Күкрәтеп күкне,
Шаркылдап көлә.

3. 12. 68

## Гомер

Буш состав кебек шалтырап,
Үтте дә китте гомер.
Син аны хәзер тотып бак,
Артыннан элә йөгер!

Яшь чагым булса, мин аны
Туктатыр идем куып...

Кайтмый шул яшьлек янадан
Һәм кабат булмый туып!

Ник яздың моны, димәгез,
Файдасызга, карт убыр?
Булмаса мина файдасы,
Яшьләргә гыйбрәт булыр.

20. 11. 68

## Язны сагыну

Җилфер-җилфер җилләр белән
Сер серләшкән яфрак кайда?
Җем-җем итеп, кояш белән
Иркәләшкән яфрак кайда?

Чың-чың итеп чыңгылдаган
Язның яшькелт чыңы кайда?
Йөрәкләрне җилкендергән
Язның яшьлек җыры кайда?

19. 10. 66

## Фил

Фил шулкадәр саклый горурлыгын
Йөртә торып шундый зур гәүдә,
Ыңгыраша, димәсеннәр өчен,
Читкә китеп үлә үлгәндә.

15. 11. 66

## Сөйләмәгез

Сөйләмәгез тузга язмаганны,
Тавык көләр сүзне, иптәшләр:
Картлар — фәлән, картлар — төгән, диеп,
Сөя белә, диеп, тик яшьләр.

Ә чынлыкта, хокук алыр өчен,
Сөя белдем, диеп сөйләргә,
Кимендә бер утыз-кырык еллап
Кирәк берне янып сөяргә!

4. 02. 69

## Тал кызы

Яшь тал кызы,
Иелеп күл көзгесенә,
Аерылалмый
Карап тора үз төсенә.

4. 02. 69

Диңгез балыкчысы уйлый:
«Тотармынмы? Купме?»
Ярда калган яры уйлый:
«Кайтырлармы? Юкмы?»

1968

## Шәһәрдә транспорт хәле

Мәскәүдән мин
Очып кайтам
Ярты сәгать.
Аэродромнан
Өйгә кайтам
Алты сәгать.

1969

## ЮГАЛТУДАН СОҢ

*Мәрхүмә Зәйнәбемә*

Булмаган юкка бу алла,
Җәннәте, тәмуглары,
Буласы икән, бәгырем, ул
Файдага безгә бары.

Җәннәтен итмим өмет тә,
Чөнки без динсез идек.
Инандык реаль тормышка
Һәм, шашып, шуны сөйдек.

Ә булган булса тәмугы,
Эләгеп шуңа, җаным,
Янарга мәңге булса да
Кавышыр идек тагын.

Кутәргән кебек дөньяда
Икәүләп барын, барын,
Кутәрер идек бергәләп
Аның бар азапларын.

Бер сүзен, җанны эретеп,
Әрнүне куар иде,
Елмаеп тик бер каравың
Барсын да юар иде.

Үбүең — булып тәндәге
Бар авыртуның име,
Тәмугы безгә явызның
Җәннәт күк булыр иде.

Ә болай, инде кавышу
Юк, бәгырем, безгә монда.
Ялгызым янам, калып мин
Дөньяның тәмугында...

Булмаган юкка бу алла,
Җәннәте, тәмуглары.
Буласы икән, җаным, ул
Файдага безгә бары.

16. 09. 68

## Кояш тотылган көнне

Кояшка карый кешеләр
Корымлап пыяласын.
Карасын — кызык аларга,
Ә минем юк карасым.

Тотылды минем кояшым
Моннан нәкъ бер ай элек,
Ай түгел, безнең арага
Чалгылы кортка кереп.

Күземне салсам да кайчан
Кояшым, сиңа табан,
Ыржайтып сары тешләрен
Шул кортка тора һаман.

Кешеләр! Кайгырмагыз сез,
Ай анда озак тормас,
Тиз чыгар, сибеп елысын,
Елмаеп сезнең кояш.

Ә минем кояш тотылды
Мәңгегә чыкмас өчен...
Арада тора шул кортка,
Ыржайтып һаман тешен.

22. 09. 68

●

Ул карап үстергән алмагач
Нәрсәдер пышылдап, җилферди.
Мин аңлыйм — юата ул мине:
— Кайгыңны җиңелрәк кичер,— ди.

Ничек соң кичерим җиңелрәк?
Юатма. Күрәм ич, алмагач,
Үзең дә саргаеп кибәсең,
Караучың янында булмагач...

19. 09. 69

## Газәл

Иң яман хәл шул икән, белдем, ярыңнан аерылу:
Ул икән, ярдан түгел, бәлкем, җаныңнан аерылу.

Иң кадерле күпме нәрсәң булса дөньяда әгәр,
Мең кабат җиңел булыр бердән барыңнан аерылу.

Кап-караңгы төнгә әйләнде көнем, йомгач күзең,
Шул икән һәр көн килә торган таңыңнан аерылу.

Шундый зур хәсрәт ишелде, и Карахмәт, өстеңә,
Коткарыр, коткарса моннан тик аңыңнан аерылу.

25. 08. 68

●

Мең кабат дәштем, «җаным!» дип,
Сиңа гомер буена.
Ник алай дип дәшкәнем
Кермәде һич уема.

Ә баксаң, алай дәшүнең
Мәгънәсе тирән икән:

Ул сине җаным шикелле
Күрүдән килгән икән.

Бушлыкка дәшәм шул сүзне
Ни гомер инде менә.
Әйләнә, сүзсез елмаеп,
Тирәмдә шәүләң генә.

Бармы җаным, юкмы? — белмим:
Башымда тоташ томан.
Йөрим мин бүген дөньяда
Җансыз бер гәүдә сыман...

19. 10. 68

## Хорафат

Гомеремдә мин күпме оттырмадым
Үз өемдә яки кунакта:
Бер тиенсез калдым преферанста,
«Подкидной»да калдым дуракка.

Кайгырмадым ләкин беркайчан да,
Тик карадым синең күзеңә,
Һәр вакытны җылы карашыңда
Бер юану эзләп үземә.

Мин ышана идем хорафатка
Шундый хәлләр башка килгәндә:
«Кем уңмаса карта уенында,
Мәхәббәттә уңа»,— дигәнгә.

Ә син карый идең минем күзгә
Кызганудан бигрәк көлебрәк:
«Белә торып минем ятканны,
Ник уйныйсың?» — дигән кебегрәк.

Мин кулга да тотмыйм хәзер карта.
Синең юклык сәбәп моңарга:
«Отармын да кәефем кырылыр»,— дип,
Куркам чөнки карта уйнарга.

6. 06. 69

## Кырда

Хуш исле кар.
Тип-тигез. Ак.
Карыйм көчкә.

— Ят, Әхмәт,— дип,
Җәйгән җәймәң
Төште искә.

1. 03. 69

Нурихан Фәттах

# ӘТИЛ СУЫ АКА ТОРУР

ТАРИХИ РОМАН[1]

## Бишенче бүлек

### I



Ике ел дигәне искән жилдәй үтте дә китте. Баштарак шундый авыр булып, иксез-чиксез кара төн булып тоелган ике ел арттә калды. Бик тиз үтсә дә, Тотыш өчен бу ике ел бөтен бер тормыш булды. Монда, Болгар җирендә ул моңарчы төшендә дә күрмәгән нәрсәләр күрде, башына да китереп карамаган нәрсәләр белде. Монда аның күп нәрсәгә күзе ачылды, күп нәрсәгә карашы үзгәрде. Монда ул беркайда да ирешмәгән атакка иреште.

Булачак киявенең иң ышанычлы болгар ирләреннән дә ышанычлырак икәнлеген күреп, Алмыш хан аңа зур эшләр тапшырды. Тотыклыгының беренче елында, көзгә таба ул — Тотыш углан — ике мең кешелек чирү белән көтмәгәндә суарларны барып басты. Аларның тораларын камап алды, коймаларын яндырып, җимереп, катауларын пыр туздырды. Күп ирләрне кырып, күп байлык талап, Килдеш бинең үзен кулга төшерде. Шулай итеп, болгарлар суарлардан тулысынча үч алдылар. Алмыш хан, моның белән генә чикләнмичә, Килдеш бинең башын чаптырып, аның урынына энесен утыртмакчы булды. Суар бие, Алмыш ханның итеген ялап, күз яшьләрен түгеп, үзен исән калдыруын үтенде. Шуның өчен ул бөтен ыруы белән чумак йоласына күчәргә, Суар-торада мәчет, мәктәп салдырырга сүз бирде.

Алмыш хан бине ярлыкарга кирәк тапты. Шулай итеп, Тотыш угланның җиңүе икеләтә җиңүгә әйләнде. Шушы җиңү уңае белән Алмыш хан зур туй ясады. Туйда Тотыш илнең батыр ирләре белән бергә ханның сул

[1] Дәвамы. Башы 8, 9, 10 саннарда.

ягында утырды. Бөтен агай-эне алдында хан аңа мактау сүзләре әйтте, бөтен агай-эне алдында ул аңа үз кулы белән сычук бирде. Ул тагын да үзенең сүзләрен кабатлады: бөтен выруы, атасы-анасы белән яңа йолага күчкәч, диде, тотыклыгы төкәнгәч, тиешле калымын түләгәч, диде... кызым Аппакны мин Тотыш алыпка бирәм, диде.

Шул көннән башлап Тотышның атагы Болгарда күзгә күренеп үсте. Инде аның Аппак белән бергәләп, атка атланып, көпә-көндез дә, кояш баегач та кеше күзе алдында йөрүенә беркемнең дә исе китмәде. Бергәләп алар яшьләрнең төрле уеннарына бардылар, су кердeләр, сабан туйларда, җыеннарда катнаштылар.

Алар кая гына бармасын, кешеләр аларга сокланып, яратып карадылар. Болгар илендә әле беркемнең дә бер-берсен болай ачыктан-ачык яратып йөргәне юк иде бугай, Болгар илендә әле беркайчан да кыз белән егетнең шундый тиң килгәне юк иде бугай! Тотыш белән Аппак, кая гына бармасыннар, кем янына гына бармасыннар, үзләре белән, әйтерсең, яктылык, җылылык, байлык алып килделәр, әз генә дә кызганмыйча, кешеләргә өләштеләр. Яшьләр арасындагы иң усал сугыш чукмарлары да, Тотышны күреп, юашланып калдылар. Иң караңгы чырайлы кешеләр дә, Аппакны күреп, аның чибәрлегенә исләре китеп, елмаеп карадылар.

Бары бер генә кеше аларның яратышуын да, аларның батырлыгын да, матурлыгын да танырга теләмәде. Теге чакта Корыч-Тимер, ничаклы тырышса да, Аппак белән Тотышка барыбер «уйнашчы» дигән яман ат тага алмады. «Мөселман йоласындагы Аппак өчен, димәк, Тотыш өчен дә ата-баба йоласының көче юк»,— диде ана Алмыш хан.

Тотыш алыпның суарларны җиңеп кайтуы Корыч-Тимерне чын-чынлап тилертә язды. Оятыннан, көнчелегеннән ул инде болай да кеше арасында күренми башлаган иде. Көннәрдән бер көнне ул бөтенләй юкка чыкты. Соңыннан беленде: үзенең унлап сердәше белән ул караңгы бер төндә Урыска качкан. Анда ул урысларны Болгарга каршы яу белән барырга котыртып караган. Болгар икмәген ашап, ач үлемнән котылып калган урыслар аның коткысына бирелмәгәннәр. Сатлык Корыч-Тимер Урыстан да каядыр качып киткән. Шуннан соң ул беркайда да күренмәгән. Берәр җирдә дөмеккәнме, әллә берәр күз күрмәгән, колак ишетмәгән җирләргә китеп барганмы — Болгарда белүче, ишетүче кеше юк. Инде менә икенче ел аның турында берни ишетелми. Шулай итеп, җинүче алып Корыч-Тимер, суга төшкәндәй, юкка чыкты да куйды.

Аның каравы Тотышның эшләре майланган арба кебек тәгәрәп кенә барды. Тотыклыгының икенче елында, былтыр яз, Алмыш хан аны башгыртларга каршы җибәрде. Тотыш башгыртлардан ике ел түләнмәгән каланны көч белән алып кайткач, Алмыш хан аны Болгардан аерылган мукшыларга каршы җибәрде. Шуннан соң күп тә үтмәде, Тотыш алып болгарларның сатучыларына әледән-әле куркыныч тудырып торган, Этил буенча йөри торган каекларны талау белән көн күргән юлбасарларны туздырып кайтты. Кайсы гына якка яу чапмасын, язмыш аңа юл күрсәтеп, җиңү байрагы тотып барды. Киләчәк якты көннәрне якынайту өчен ул, Алмыш ханны, Болгар йортны яклап, үз-үзен аямыйча сугышты. Аның үткер кылычыннан бары ягы каны гына таммады. Кара кан белән бергә аның үткер кылычыннан алтын-көмеш тә тамды. Тик ул алтын-көмеш аның үз калтасына түгел, хан калтасына тамды. Алмыш хан аңа бик аз телем чыгарды. Тотыш үзенең Аппагыннан да, үзенең сөеклесеннән дә зуррак байлыкка ия булу турында уйлап та карамады. Күпме генә атаклы булмасын, нинди генә җиңүгә ирешмәсен, беркайчан да ул үзенең тотык икәнлеген исеннән чыгармады. Аннан соң ул икенче бер нәрсәне дә сизеп алды: Алмыш хан аны тикмәгә генә әледән-әле яуга җибәрми иде бугай. Ул ничек тә аның монда урдада, Болгар-торада азрак булуын тели иде бугай. Кем белә, әллә ул аны яудан кире кайтмас дип тә уйлагандыр! Әйе, әйе, соңгы көннәрдә, тотыклыкның ике елы тулар

алдыннан Алмыш хан кинәт кенә үзгәрә башлады кебек, никтер пошына, борчыла башлады кебек.

Ни булса да булды, ике ел узып китте. Алмыш хан аны бүген үз янына чакырып алды.

— Син ирекле, Тотыш углан... Тотыш алып,— диде ул.— Синең өчен Акбүредән икенче углан килеп җиткәнне көтеп тормастан, мин сиңа ирек бирергә булдым. Сиңа алмаш юлда булырга тиеш. Иленә кайт, мин әйткәннәрне үтә, калым китер. Шунда кияүем булырсын... алла боерса!

Йа тәңре! Йа алла! Тотыш ирекле! Яшәсен ирек! Яшәсен Аппак!

## II

Тотыш юлга җыена башлады. Багдад ягыннан килеп, Болгарда төпләнеп калган Габид атлы тегүчегә ул моннан өч ай чамасы элек туй өчен үзенә кара төлкедән кышкы тун, кызыл атластан җәйге тун тектерергә биргән иде. Тотыш, хан чатырыннан чыккач та, туры тегүче янына юнәлде. Тегүче урдадан читтә, Болгар-тораның яр буе бистәсендә тора. Аның өе агачтан иде, ишегалды зур, иркен иде. Ишегалдында корулы тирмәләр, араннар, абзарлар тезелеп киткән. Шунда ук атлар, кешеләр күренә. Тегүче Габид, Болгарның аксөякләренә яхшы тун, кием-салым тегү белән бергә, читтән, бигрәк тә гарәп ягыннан килгән сатучыларга кунар урын да биреп тора иде. Менә әле дә шулай булып чыкты.

— Өлгермәдем шул, Тотыш алып,— диде ул, кулларын җәеп.— Көтмәгәндә олы кунаклар килеп төште — шулар белән булаштым. Багдадтан! Хәлифә иленнән!

— Кем? — диде Тотыш.

— Фатих ибн Әхмәт! — диде Габид, авызын очлайтып.

Моның белән ул Фатих ибн Әхмәтнең бик зур кеше икәнлеген аңлатмакчы булды. Тотыш ул гарәп сатучысын болай да белә иде. Әйтүләренә караганда, ул монда ел да килә икән. Килгәндә дә ул күбрәк Алмыш хан үзе, аның якын кешеләре теләгән товарлар алып килә, күбрәк аның белән, аның якыннары белән алыш-биреш итә икән.

— Борчылма, Тотыш алып, иртәгә кичкә житешер,— диде Габид, тынычландырып.

— Кара аны, иртәгә кичкә! — диде Тотыш.— Мин — ирекле! Мин туган ыруыма кайтып китәм.

— Әйттем, әйттем! — диде Габид, Тотышны ишеккә тикле озатып.

Көн шундый җылы, якты иде, тирә-як шундый ямьле иде — Тотыш тегелеп бетмәгән туннарын тышка чыккач ук онытты. Тегүчедән соң ул үз тирмәсенә кайтты. Торымтайны да алып бераздан алар Аппак белән Агабазарга киттеләр: атасы-анасы, туганнары өчен бүләкләр алырга кирәк иде.

Юл буена алар шаярып, юк-бар нәрсә сөйләнеп бардылар. Берәр кеше узып киткәч, я аның киеменнән, я атыннан көлделәр, ул да булмаса, юл читендәге берәр агачтан, ялгыш әйтелгән берәр сүздән кызык табып, тыела алмыйча көлешеп бардылар. Тотышныкы кебек, Аппакның да күңеле күтәренке иде. Тик бу күңел күтәренкелегендә шулай да әчкесагыш, әйтелмәгән бер моң сизелә иде. Берничә айдан бергә кавышу турында уйлап сөенүгә караганда, ул озакламый аерылышырга тиешлекләре турында уйлап көяләнә иде, ахрысы. Көлешә-көлешә бара торгач, ул кинәт кенә сорап куйды:

— Син тиз килеп җитәрсең микән? — диде.

— Ким дигәндә — ике айдан,— диде Тотыш.

— Ике ай... Бик күп ич ул! Тизрәк булмыймы, Тотыш?

— Ике ай ике ел түгел. Ике елга түзгәнне ике айга гына түзәрбез инде, Аппагым,— диде Тотыш, ягымлы күз карашы белән кызны иркәләп.

— Минем эчем поша, жылыйсым килә,— диде Аппак, читкә борылып, күз яшен күрсәтмәскә тырышып.— Күңелемне бер уй тырный, Тотыш: үз иленә кайттың исә, атаң-анаң каршы килер дә, сине җибәрмәсләр кебек. Син килмәсәң, нишләрмен мин?

Тотыш анын бу сүзләреннән кычкырып көләргә тотынды. Тик аның көлүе бик ясалма килеп чыкты. Моны ул үзе дә сизенде. Аппак аның үзенең дә күңелен борчыган, әйтергә кыюлыгы җитмәгән нәрсәне тел белән әйтеп бирде! Анын, билгеле, кызны юатасы, тынычландырасы килде. Тик аны юатып кына ул барыбер үз-үзен юата алмады. Ул, бер нәрсәгә дә исе китми, аптырап калмый торган кеше кебек, җиңел генә:

— Уйлама юк-барны! — диде.— Алмыш хан белән туганлашырга кем каршы килсен?! Сөенә-сөенә килешәчәкләр!

— Әйе шул,— диде Аппак, күз яшьләре аралаш елмаеп.

Базарның иң кызган чагы иде. Этил ярыннан читкәрәк, калку җиргә урнашкан, тирә-ягын киез чатырлар, агач кибетләр сырып алган киң язы кеше белән, атлар белән шыгрым тулы. Сатучыларның күбесе үз таварларын туп-туры җиргә өеп ташлаганнар. Кайберәүләренең таварлары, киресенчә, бисккә — багана башларына, аркылы куелган таякларга эленгән. Барысы да кычкыралар, шаулыйлар — үз таварларын мактыйлар, алучыларны яннарына чакыралар. Тирә-якта колак тондыргыч бер гүелдек яңгырап тора.

Базарның шау-шулы төшенә якын бер җирдә бөтенләй диярлек шәрә калган бер кеше зур көрән аю белән көрәшкән булып кылана. Аны балачага, яшь-җилкенчәк урап алган. Көләләр, кычкыралар, аюга көлчә, икмәк кисәкләре ыргыталар. Аю белән көрәшүчедән арырак, икенче бер җирдә тагын да кызыграк: тыгыз түгәрәк уртасында, сары ефәк чатыр янында яшь, шәрә бер хытай очлы пычаклар, утлы таяклар чөеп уйный.

Тотыш белән Аппак аю белән көрәшүчегә дә, хытай кәмитчесенә дә озак карап тормадылар. Алар тагын да арырак, яр буенарак юнәлделәр. Фатих ибн Әхмәтнең кибете шунда, суга якынрак җирдә була торган иде.

Базарга, күрәсең, әле күптән түгел генә килеп туктаган дөяләр төркемен узып, алар яр буена ук килеп чыктылар. Язгы ташудан соң үз ярларына кайта башлаган, болганчык, салкынча Этил өсте төрле илләрдән килгән төрле зурлыктагы, төрле төстәге, төрлечә бизәлгән йөзләрчә каекләр, көймәләр, улаклар белән чуарланган иде. Монда, яр буенда, кибетләр дә, таварлар да күбрәк, төрлерәк иде. Монда төрле төстәге кешеләр күренә, төрле телләрдә сөйләшкән, кычкырган тавышлар ишетелә. Кибетләр янына таудай итеп тыгыз капчыклар өеп куелган, төрле зурлыктагы кисмәкләр, чапчаклар, чүлмәкләр тезелгән. Берәүләр каеклардан ярга тавар бушата, икенче берәүләр каекларга тавар төйи. Әле анда, әле монда — башларын түбән иеп, куркытылган көтү сыман, бергә өелешеп, төркем-төркем коллар тора.

Аяк астындагы эреле-ваклы чүлмәкләргә, төрле комган, савыт-сабаларга орынмаска тырышып, тар аралыктан җайдаклар тагын да алгарак уздылар да, таныш сыман тоелган зур гына бер чатыр алдында туктап калдылар. Якында гына кыздырылган балык, суган исе килә иде — берике кеше, җиңнәрен сызганып җибәреп, учак өстендә, җиз табада балык кыздыралар иде. Тотыш балык кыздыручыларның йөзләренә карангалап торган арада, якында гына кемдер:

— Тотыш! — дип кычкырып җибәрде.— Исәнме! Әссәламе галәйкем!

Тотыш, эндәшүченең Фатих ибн Әхмәт икәнлеген **аңлап,** елмаеп, тавыш килгән якка борылып карады. Чыннан да, аның каршысында гарәп базарганы басып тора иде. Ул — кырык, кырык биш яшьләр чамасындагы бер кеше. Өстенә ал ефәктән тегелгән озын итәкле җәйге тун кигән, башына кара чалма ураган. Аның болай да кара янып чыккан, җил кискән кытыршы бите базардагы ак битле кешеләр арасында тагын да карарак

булып, ерактан ук аерылып күренә иде. Аның кара сакал-мыек арасыннан елтырап-елтырап киткән таза тигез тешләре, киресенчә, ап-ак. Үзенең танышын күрүгә чиксез куаныч белән ул елмаеп торды, ике кулын да күкрәк турысынарак күтәрде дә, баш иеп, аны олылавын белдерде. Тотыш, атыннан төшеп, шулай ук аның алдында баш иде.

— Эзлибез, эзлибез — әллә җир йоткан! — диде ул, шаяртып.

— Җир йотса да гаҗәп ирмәс, базар зур, кеше күп,— диде Фатих ибн Әхмәт, бер күзе белән Тотышка, икенче күзе белән Аппакка караштырып.— Бәрәкаллаһ! Монысы хан кызы Аппак түгелме соң?! Монысы... теге... кем соң әле?

— Торымтай!

— Ие, ие, Торымтай! — диде гарәп.— Әйдәгез, бире узың, түрдән узың! Ни телисез, миндә шул бар. Бөтен Ага-базарда Фатихтан бай сатучы юктыр!

### III

Фатих ибн Әхмәт тагын бу якларга исән-сау килеп житүенә, янадан үзенең танышларын очратуына бик сөенгән шикелле күренде. Сөйләшкәндә ул әледән-әле Болгарны, бу якның урман-суларын, кешеләрен мактап берәр сүз кыстырып куйды, «туган илемдә дә мин сезне бик сагындым», дигән булды. Аның мактау сүзләренә болгарларның, билгеле, күңелләре күтәрелде. Аларның йомшауларын күреп, хәйләкәр сатучы тагын да ныграк кызып китте. Шул ук мәлдә ул, күрәләтә соклану белән, комсызлык белән, хан кызына карап-карап алды. Ахырда түзмәде, күңелендәгесен чыгарды салды.

— Сөбханалла! — диде, ак тешләрен елтыратып.— Синең матурлыкны күреп мин телсез калдым, хур кызы! Аягыма басып йөри башлаганнан бирле мин төрле илләр, җирләр гиздем, төрле кавемнәрне күрдем, ләкин синдәй гүзәлне очратканым булмады! Мин сине танымыйча торам! Быел син тулып пешкән җимеш кеби, тулун айдай! Килешсез сүзләрем өчен миңе гафу әйләнез, сина, Аппак углан, бер соравым бар: син хак мөселман динендәсең. Шулай булгач, ничек итеп син шундый гүзәл йөзеңне теләсә кемгә, теләсә нинди ир кешегә күрсәтеп йөрүдән курыкмыйсән?

Аппак үзенә карата әйтелгән мактау сүзләрен оялчан гына тыңлап торды да гарәпнең соңгы сүзләреннән көлеп җибәрде. Чыннан да ул аның соравыннан да көлмәде, ул үзенең чибәр булуын аңлап, куанып көлде, барлык кешеләрнең үзенә карап сокланууларын тоюдан, янында үзенең сөеклесе булуын аңлаудан куанып көлде. Юл буенда көлешеп килгән кебек, кызга ияреп Тотыш та, Торымтай да көләргә тотынды.

— Гарәпләрнең бар кайгысы шул — хатын-кызның йөзен күрсәтмәү,— диде Аппак, җиңелчә шелтә белән.— Тәңре яраткан матурлыкны кешеләргә дә күрсәтмәгәч, үзенә үзең генә карап торыргамыни соң?

— Матурлык — байлык! Байлык ул саклап тотуны ярата,— диде Фатих ибн Әхмәт.— Ярар, сезнең байлыкны күрдек, инде минем байлыкны күрәек.

Шулай дип ул үзенең чатыр ишеген ачып җибәрде. Тотыш та, Аппак та бөтен җире төргәк-төргәк, капчык-капчык товарлар белән тулган, төрле ят исләр аңкытып торган зур гына чатырга килеп керделәр. Гарәп сатучысы тимерле сандыгын ачты да, аннан бик сакланып кына нидер алды, алган нәрсәсен учында гына тотып Аппакка сузды.

— Менә... миннән бүләк,— диде ул.

Бу сырлап, кырлап чын ташлардан ясалган муенса иде. Аппакның йөзе балкып китте, үзе дә сизмәстән ул «ах!» дип кычкырып җибәрде, муенсаны иплән кенә кулына алды, күз алдына китерде дә муенны турысына куеп карады.

— Ошыймы, матурмы? — диде ул, Тотышка борылып.

— Үзең кебек! — диде гарәп, Тотыштан узып.— Мондый муенса Багдадта юк, Румда юк! Фатихта бар! Алың. Сиңа бүләк.
— Бүләк? Ни өчен? — диде Аппак, аптырап.
— Синең гүзәллекне күргән өчен... Минем күзләремә куаныч биргән өчен! — диде гарәп сатучысы.
Аппак кызарынып, шаулатып көлеп җибәрде, муенсасын муены турында тоткан килеш, Тотышка ыграк борылып, кабатлап:
— Сиңа ошыймы? — диде.
— Ошый,— диде Тотыш, бик үк теләмичә.— Күргән бер матурлык өчен бүләк бирергә туры килсә, синең матур нәрсәләрең монда җитәрлек! Минем калта бик тиз бушаячак...
— Син бүләк бирмәссең — миңа акча да ярый,— дигән булды сатучы көлеп.— Әйт, нәрсәләр күрсәтим?
— Ниең бар, шуны күрсәт! — диде Тотыш.— Мин — ирекле, Фатих! Тиздән илемә юл тотам. Миңа да бүләк кирәк, бик күп бүләк кирәк!
— Алайса, быел көз сезнең туегыз булачак? — диде гарәп, күзен кысып.— Котлыйм, котлыйм! Быел мин сездә көзгә чаклы торам. Мине дә чакырырсың туеңа. Әйдә, сайла! Барысы да бар: кием-салым, кытат, атлас, ефәк, палас, йөзем, өрек, хөрмә!.. Көзгеләр, беләзекләр, йөзекләр, ислемайлар... ут-үлән сулары, им сулары, ачы-ташлар... Йөзем сулары, каптырмалар, төймәләр...— барысы да, барысы да! Әтилдә бушатылмаган биш каек тора, менә монда чатыр тулы, тышта әнә таудай өелеп ята.
Сатучы, бик җитез кыланып, капчыкларын, төенчекләрен чишеп, товарларын берәм-берәм күрсәтә башлады. Тотыш атасына-анасына, үги аналарына, өлкән туганнарына яхшы туннар, күлмәкләр, билбаулар, сеңелләренә, яшь кызларга — төзәнү-бизәнү әйберләре, тәм-төмнәр алды. Атасының авыру икәнлеген уйлап, аңа күп кенә им-том үләннәре, им ташлары алды. Тавар өчен ул кызганмыйча, сатулашмыйча түләде. Аның бу юмартлыгы гарәп сатучысына Аппакның гүзәллегеннән дә ныграк ошады. Ул үзенең товарларын гына түгел, үз товарларын алучыны да мактап бетерә алмады.
Тотыш бик күп бүләк алды. Аларның барысын да берьюлы күтәреп китәрлек түгел иде.
— Кайгырмагыз! — диде шома сатучы, Тотышны тынычландырып.— Болай итәрбез: минем кешеләр өеңә илтеп куярлар. Курыкма, бер нәрсән дә югалмас.
— Ярар, шулай итәрбез,— диде Тотыш, килешеп.
Инде сату-алу бетте дигәч, Фатих ибн Әхмәт янадан тимерле сандыгын ачып җибәрде. Аннан ул энҗе кашлы алтын йөзек алды.
— Менә, онытканмын! -- диде, ак тешләрен балкытып.— Бер генә. Сиңа гына калган, Тотыш углан. Синд ягыннан. Иң булдыклы алтынчылар эше. Төп-төгәл... йөз дирһәм!
— У-у! — диде Тотыш беренче тапкыр.
— Анаңа моннан да матур бүләкне табалмассың! — диде сатучы, үз таварын мактап.
— Ник башта ук күрсәтмәдең? — диде Тотыш.— Калта бушады.
— Анаң булмаса, кәләшеңә! — диде сатучы, йөзекне Аппакның күз алдына китереп.
— Юк, юк! — диде Аппак.— Миңа кирәкми. Миңа инде ул җитәрлек алды. Тотыш, беләсеңме, мин түлим! Анаңа миннән бүләк булыр.
Алып егетнең йөзе яктырып китте.
— Әйе шул! — диде ул, беркатлы бер елмаю белән сөекле кызына борылып.— Анам шундый сөенәчәк! Шуның өчен ул сиңа иң якын, иң сөекле нәрсәсен бүләк итәчәк!
— Тотыш! — диде кыз, чак-чак кына үпкәләп.— Мин аннан бернинди бүләк көтмим.

— Ул сиңа... мине бүләк итәчәк! — диде Тотыш, кызның колагына пышылдап.

## IV

Тотыш бүләкләр алып, туган ягына кайтып китәргә жыенып йөргән арада Ага-базарга уникe каек белән акбүреләр килеп төште. Күзәмеш углан Алмыш ханга узган ике ел өчен калан алып килгән иде. Шуның белән бергә ул Тотыш урынына монда тотык булып калачак иде.

Үзенең туганын, ырудашларын күреп, Тотыш сөенеченнән жылап жибәрде. Бераз тынычлангандай иткәч, ул өйдә калган атасы-анасы турында, туганнары, ырудашлары турында сораштыра башлады. Әллә бик арып килгәнгә, әллә ике ел аерылышып торган арада Тотыштан суынып өлгергәнгә, Күзәмеш углан әллә ни ачылып китмәде. Авыз эченнән генә мыгырданып: «Исәннәр» дип куйды да Тотышның үзеннән сораштырырга тотынды. Бераз иялэнә төшкәч, шулай да әйтеп куйды:

— Анаң сине бик сагынды. Тизрәк кайтырга кушты,— диде.

«Атам сагындымы соң?» дип сорыйсы килде Тотышның. Нишләптер сорамады. Күзәмешнең Кызыл Ярдагыча монда да үзен эре, салкын тотуы өчен пошынды. Туганы Күзәмеш углан гына түгел, башка ырудашлары да аның белән никтер теләмичә генә сөйләшәләр шикелле тоелды. Ике ел буена болгарлар арасында яшәгән Тотышка акбүреләрнең кырыслыгы, караңгы чырайлы булулары бөтенләй чит, ят күренде. Аннары аларның бу салкынлыгын ул элеккечә үзен саңга сукмау дип юрады. «Аз гына да үзгәрмәгәннәр!» дип уйлады ул ырудашлары турында, ачынып.

Шулай да аның күңеле чамадан тыш күтәренке иде — язгы көндә кинәт исеп киткән бозлы жил шикелле, көтмәгәндә йөзенә бәрелгән бу кырыслыкка аның әллә ни исе китмәде. Ул инде алардан — үзенең көнчел туганнарыннан да, караңгы йөзле ырудашларыннан да өстен иде. Ул өешле иде. Ул хан кызын ярата. Ул тиздән хан кияве булачак кеше. Күзәмеш угланнар үзенә ничек кенә карасалар да, аның өчен барыбер.

Каланга дип китерелгән таварларны ханның агычыларына тапшыргач, Акбүре каекларына Тотыш үзенең бүләкләрен, кием-салымнарын, юллык азык-төлеген төятте. Юлга жыену эшләрен бетереп ул үзенең таныш-белешләре белән саубуллашты да Аппак янына килде. Шунда аны Алмыш ханның йомышчысы эзләп тапты.

Башка көннәрдәгегә караганда хан тирмәсендә бүген аңа кеше күп күренде. Аннан да бигрәк, хан янында инндидер ят, чит кунаклар бар иде бугай. Алмыш ханны күреп, Тотыш шаккатты. Хан, авыру кеше сыман, тартылып, агарынып калган иде. Башка чакта үзәккә үтеп керә торган көчле, усал күз карашы ничектер юашланганмы, моңсуланганмы шикелле иде. Ханның бик нык кайгылы икәнлеге әллә каян күренеп тора иде.

— Син китәсең икән, Тотыш алып,— диде ул, күтәрелеп карамыйча, әкрен генә.

— Әйе, жыенып беттем, ханым,— диде Тотыш.— Иртәгә таңнан юлга чыгам.

— Ак юл сиңа, углан. Анаңа, ыы... атаңа, туганнарыңа минем изге теләкләремне тапшыр.

— Тапшырырмын, ханым,— диде Тотыш.

— Син минем ышанычны акларсың дип уйлыйм,— диде хан.

— Акламмын, ханым! — диде Тотыш, ничектер кычкырыбрак.— Мин күп тормам, кош кебек очып кайтырмын, кош кебек очып килермен!

— Сау бул,— диде хан.

Тотышка бик эре, зур булып тоелган кунакларның берсе Баштый улы Габдулла иде. Шушы көннәрдә генә ул түбәннән, Хазар йортның

ханбалыгы Итил-торадан килеп төшкән иде. Бу укымышлы мулланы Алмыш хан яхшы белә иде. Кэтмәгәндә ул Болгарга күңелсез яңалык алып килде. Баштый углы Габдулла, пошынып, ачынып, каганның мөселманнарны эзәрлекләве, җөфүтләрнең узынуы турында сөйләде. Аның сөйләвенә караганда, Итил-торада җөфүтләр белән мөселманнар арасында еш кына бәрелешләр, үтерешләр була икән. Шундый бәрелешләрнең берсендә Габдулла үзе дә катнашкан булган. Алар, кызып китеп, җөфүтләрнең кәнәсәләрен [1] яндырганнар. Каган бу эштә языклы кешеләрне тотып, башларын кисәргә боерык биргән. Габдулла шундый нәрсә буласын алдан ук сизенеп, Итил-торадан качып киткән дә, сыену эзләп, менә монда Болгарга килгән.

Каганның мөселманнарны эзәрлекләвен дә, җөфүтләр белән алар арасында ызгышлар булгалавын да Алмыш хан белә иде. Баштый углы Габдулланың монда сыену урыны эзләп килүендә дә әллә ни яңалык юк. Ни өчен дигәндә, җөфүтләрдән җык күргән чумак хазарлар, туганнарыбыз, кан-кардәшләребез дип, әледән-әле болгар җиренә күчә торалар иде. Әтил, Чирмешән буйларында качак хазарлардан гына торган зурзур авыллар барлыкка килгән иде. Болгар-тораның үзендә дә хазарлар шактый күп иде.

Әйе, болары аның бер дә яңалык түгел. Баштый углы Габдулланың икенче бер яңалыгы исә чыннан да яңалык иде! Габдулланың әйтүенә караганда, Корыч-Тимер хазарларга барып чыккан. Үзен аларга яхшы яктан күрсәтү өчен ул шундук җөфүт йоласына күчкән. Корыч-Тимер Итил-торага килеп җиткәндә, Тәкин углан әле Хазаранда булган. Шунда кышлап ул быел яз Багдадка юл тотарга уйлаган. Корыч-Тимер боларны күргән дә каганга саткан: Тәкин углан сатучы түгел, Алмыш ханның хәлифәгә җибәрелгән яшерен илчесе, дигән. Каган кешеләре Тәкин угланны, Барыс угланны, аларның кешеләрен тотып алганнар, базга ябып сорау алганнар. Шулай да шикле берни тапмаганнар — күрәсең, хәлифәгә җибәрелгән битекне Тәкин углан юк итәргә өлгергәндер. Ике ай чамасы ябып яткырганнан соң, бәйләнерлек берни тапмагач, хазарлар боларны чыгарып җибәргәннәр. Эш бәйләнер нәрсә булмауда гына түгел, эш шунда: хазар мөселманнары безнең кардәшләребезне бер дә юкка ябып яткыралар дип, шаулаша башлаганнар. Болгарлар иреккә чыгуын чыкканнар, тик алар югында таварларын кемнәрдер талап, урлап бетергән. Яшерен илчеләр белән киткән кешеләрнең кайсы тоткында ачтан үлгән, кайсы чыккач таралып беткән. Тәкин углан белән Барыс угланны хазар чумаклары, бераз акча җыеп биреп, угызларга качырганнар. Алар ничек тә Багдадка барып җитәргә сүз биргәннәр. Исәннәрме, юкмы, барып җиткәннәрме, юкмы — беркем белми икән.

Менә шуңа да күңелсез иде хан Тотыш белән саубуллашканда.

Үз кайгысы янсә үз куанычы көчле булганга, ханның ни өчен шулай күңелсез, кайгылы булуы турында Тотыш баш ватып тормады. Бу кайгының кайсыдыр ягы белән үзенә дә кагылганлыгын, үзенең киләчәк язмышына йогынты ясаячагын ул, билгеле, башына да китереп карый алмады.

Ул ярдан кузгалып киткән иртә искиткеч матур, аяз булды. Үзе белән ул Торымтайны да, Бәкәч чәчәнне дә алды. Алар киң Әтил өстеннән, иксез-чиксез су киңлеге артыннан сызылып кына, елмаеп кына чыгып килгән кояшка карап кузгалып киттеләр. Артта, яр буенда, йокысыннан ныклап уянмаган Ага-базар — каралҗым, моңсу каралтылар, коймалар, тирмәләр торып калды, яр буенда бер төркем атлы кызлар: Аппак белән сердәшләре озатып калды. Тотыш, артына борылып утырган килеш, бик озак аларга карап, кул болгап барды. Кызлар шулай ук аңа кул болгадылар, яулык болгадылар.

[1] Кәнәсә — синагога; яһүд динендәгеләрнең гыйбадәтханәсе.

Борылыш артында кызлар да, Ага-базар да күренмәс булгач кына, Тотыш алдына карап утырды да, бер ишкәкченең ишкәкләрен алып, каерып-каерып ишәргә тотынды. Тыгыз, тирән суны тою анда әйтеп бетермәслек куаныч тудырды. Янындагы кешеләрне онытып, бирелеп, ул иште дә ишге. Күзләре аның еракка, алсу кояш ягына текәлде, күңеле аның яр өстендә торып калган җайдак кызларга омтылды. Ул арыганчы, арттагы моңсу карачкылар онытылганчы иште. Шуннан соң чатыр эченә керде дә, йомшак киезгә сузылып, татлы йокыга талды.

Байракларын күтәрмичә генә йөзгән унике каек, кыр казлары сыман бер-бер артлы тезелеп, су өстеннән әкрен генә югарыга үрләделәр.

## V

Ага-базар тамагыннан кузгалып китүгә уналты төн тулды дигәндә, бер матур иртәдә каеклар Акбүре яруы биләмәләренең көньяк чигенә килеп җиттеләр. Үз туган җирләренә исән-сау кайтып җитүләренә чиксез куанган кешеләр шаулашып ярга чыктылар, җирнең үзләренекеме, түгелме икәнлеген тикшереп карагандай, сабый балаларча сикергәләп алдылар, йомшак үләндә аунадылар. Шуннан соң пычак очлары белән кечкенә чокыр казып, чокырга ашамлык калдыклары, сөякләр, төймә, каптырма кебек нәрсәләр күмеп куйдылар. Үз уллары көтеп торган туган җиргә бу аларның бүләкләре-күчтәнәчләре булды.

— Менә бу безнең як, безнең җир! — диде Тотыш Торымтай белән Бәкәчкә, Чулман аръягындагы болыннарга, ерактагы күксел калкулыкларга күрсәтеп,

— Сездә матуррак,— диде Торымтай.

Бәкәч, думбырасын чиртеп, шулай ук үзенең соклануын белдерде.

Ишкәкчеләрнең бер-икесе, коры-сары җыеп, учак ягып җибәрделәр, таган ясап, казан астылар. Каекларда әлерәк кенә тоткан балыклар бар иде — берничә кеше балык әрчергә тотынды. Тотыш, өч-дүрт юлдашын алып, якындагы урманга ауга китте. Анда, урман эчендә, Тоба-күл дип аталган сазлыкта кыр үрдәкләре күп була торган иде. Чыннан да алар монда тиз арада унлап үрдәк атып алдылар. Иртәнге аш өчен шул да җиткән иде — алар артык мавыкмадылар, кире борылдылар да, учак янына килеп, үрдәк йолкырга тотындылар.

Шулай учак тирәсендә мәш килеп, аш-су белән булашып ятканда, каяндыр бер атлы кеше килеп чыкты. Ул бик озын, нечкә буйлы иде. Күрәсең, шуңа күрәдер, ул атланган ат чамадан тыш кечкенә булып күренә иде.

— Әй, Баганай түгелме соң? — диде Тотыш, озын кешене танып.

Баганай урман артындагы унбиш өйлек Тоба-күл авылының башы иде. Тоба-күл кешеләре Акбүредә иң яхшы аучылар, балыкчылар саналалар иде.

— Би углы Тотыш ич! — диде Баганай да.

— Мин бу, мин! — диде Тотыш, ырудашына таба атлап.

Баганай, тәбәнәк киртәдән атлап чыккан сыман, озын аягын җинел генә күтәреп, аттан төште дә, бүреген салды, башын иде, аннары аталарча яратып, читтә йөреп кайткан егетне күкрәгенә кысты. Ул аның бала чакларын, балыкчылар белән бергә балык тотарга йөрүләрен яхшы белә иде. Әнә ул нинди үскән, тазарган! Яшьләр үсә, картлар картая...

Баганай, үзалдына сөйләнгәләп, никтер балавыз сыгып алды. Тотыш аның бер дә юктан шулай йомшап китүен дә, сабый баладай итеп үзен кочаклап, иркәләп торуын да аңлый алмады.

— Кемнәр монда учак ягып яталар дип торсам, бу сез икәнсез,— диде Баганай.— Алайса, кайтып җиттең, углым? Иртәгә атаңның соңгы көне — беләсеңдер ич?

Ничек — соңгы көне? — диде Тотыш, төшенмичә.

— Соңгы көне, углан,— диде Баганай, үз-үзенә ышанып.— Мин бүген юлга чыгам. Иртәгә соңгы көн. Иртәгә кайгы туе.

— Ни сөйлисең, Баганай?! Нинди кайгы туе?! — диде Тотыш, коты алынып.

— Ммм...— диде Баганай, мыгырданып.— Син әллә белмисең? ыы... Күрән би... ыы...

Кинәт ул кычкырып җылап җибәрде. Бөтен болынны, Чулманны, урманнарны тетрәндереп, кайгыга салып, тыела алмыйча җылап җибәрде.

Тотышның кулындагы үрдәге төшеп китте, куллары, аяк буыннары көчсезләнеп калды. Туры гына басып торган Баганай да, баганадай Баганай да нишләптер як-якка чайкала башлады. Тотыш барысын да аңлап алды, шулай да ул әле бер нәрсә дә аңларга теләмәде. Баганайның куркыныч сүзләре дә, кычкырып җылавы да никтер ялган булып тоелды.

— Баганай... Баганай...— диде ул, нидер әйтергә теләп тә, әйтәсе килгән сүзен сыгып чыгара алмыйча.

— Күрән би үлде! Ике ел инде... үлде! — дип кычкырды Баганай, бертуктамый күз яшьләре түгеп.

Тотышның кайгысын уртаклашып, Баганайдан күрмәкчә, ишкәкчеләр дә, Торымтай да кычкырып җыларга, такмакларга тотындылар. Барысы да җыладылар, бары Тотыш кына җылый алмады. Аңа әллә ни булды. Аның күз яшь юллары да, тын юллары да кинәт кенә томаланып калгандай булды. Аяк-кулларын, әйтерсең, авыр чылбырлар белән богаулап ташладылар. «Моннан ике ел элек үлгән», диде ул үз-үзенә, бөтенләй чит кеше турында уйлаган кебек. Димәк, Күзәмеш углан аңа әйтмәгән. Башка ырудашлары да әйтмәгәннәр. Үзләре әнә беренче тапкыр ишеткәндәй, бик нык кайгырган булып, акырып-акырып җылаган булалар. Ялган! Ялган! Баганайның җылавы да, ишкәкчеләрнең җылавы да ялган! Шулай булгач, аның атасы үлгән дигән сүз дә ялган! Ялган бу, ялган!

## VI

Имгәк аяк астында, дип белми әйтмәгәннәрдер, күрәсең, Күрән би үзенең үлемен аяк астыннан тапты. Алмыш хан Акбүре жиреннән кузгалып киткәч тә, көннәрдән бер көнне, Күрән би, үз алдына уйланып, онытылып сырган башыннан төшеп килгәндә, аның аяк астындагы басмасынып китте. Авыр, авыру би эһ дигәнче баш түбән аска мәтәлде. Аста, койма буенда, кырлы чуер ташлар өеме бар иде. Ни булганын аңларга да өлгермәгән би бер нәрсәгә дә тотынып кала алмады — анда бәрелеп, монда бәрелеп, туры шул ташлар өеменә барып төште. Күгәреп, яшәреп беткән ташларга берни булмады, бинең башы исә чүлмәк кебек чәлпәрәмә килде. Акбүре ыруының башы, атаклы Күрән би күз ачып йомганчы аяк сузды.

Бинең үлеме ыру өчен кайгы өстенә кайгы булды. Бине күмгәндә ырудашлары чын күңелдән җыладылар. кычкырып-кычкырып, чәчләрен-башларын тырнап җыладылар. Күрән бинең өенә — капкаларына, койма буйларына, ишек яннарына кайгы байраклары куелды. Күмүнең беренче көннәрендә — бинең хатыннары, туганнары, балалары, соңга табарак — коллар, чуралар үлгән ыру башының ишек төбендә үзләренең шәрә буйларын каеш чыбыркылар белән камчылый-камчылый җыладылар. Ике ел буена берөзлексез диярлек би өе ягыннан ирләрнең шулай ямьсез, кыргый тавышлары ишетелеп торды. Бөтен катау тизрәк соңгы көн, соңгы кайгы көне тууын, кайгы байракларының алынуын, йөрәк өзгеч ләмсез тавышларның тынып калуын көтте. Аннан да бигрәк кешеләр Күрән бинең тол хатыны Койтым бикә ясаячак кайгы туенда — аш-суда бер туйганчы ашап-эчеп калу көнен көттеләр.

Ул соңгы көн якынлашканнан-якынлашты. Ишек төпләрендә үз-үзләрен кыйнап җылаучы коллар тагын да ямьсезрәк итеп, көчлерәк итеп

кычкыра башладылар. Җилдә-яңгырда, карда, кояшта уңып, теткәләнеп беткән байраклар, күзләре, кашлары җуелган агач сыннар, абаклар урынына яналарын куйдылар. Еракътагы ил агаларына — авыл башларына, аксакалларга, үлгән бинең барлык туган-тумачаларына билгеләнгән көнгә кайгы туена килергә белдерү ясалды.

Күрән би үлгәч, аның туганы, ыруда иң атаклы кешеләрдән саналган Утташ кам, йола буенча, ыру башы булып калган иде. Кайгы туеннан соң бер көн тормыйча, корылтай җыелырга, шунда аны би итеп, янадан ыру башы итеп куярга тиешләр иде. Шуннан соң ул, шулай ук йола, түрә буенча, Күрән бинең барлык байлыгына, хатыннарына, балаларына, йорт-җиренә, терлек-туарына, колларына, чураларына баш булып калачак иде. Әлегә исә, ыру башы саналса да, Күрән бинең байлыгына ул түгел, Койтым бикә баш иде. Ыру эшләрен башкарганда да әле Утташ кам Койтым бикә белән, Котан, Акбога, Майчан аксакаллар белән киңәшмичә берни дә эшли алмый иде.

Шулай итеп, барысы да соңгы көнне көтте.

Кайгы туе билгеләнгән көнне төштән соң башланды — би иртәнге күлемдә үлгән иде. Җылау-сыктау тавышлары бердәй тынып калды, байраклар, агач сыннар алып куелды. Шуннан соң Койтым бикә өйдән, көмеш табакка салып, бер кисәк ит, ботка, сычук алып чыкты. Күрән бинең бөтен күче белән ул, әлеге азыкларны күтәреп, иске йортка[1] юнәлде. Анда алар кечкенә чокыр казыдылар, үзләре белән алып килгән ашамлык-эчемлекләрне шул чокырга куйдылар.

— Менә без сиңа ашарга, эчәргә алып килдек, Күрән. Без барысын да йола кушканча эшләдек,— диде Койтым бикә, чокырга карап.— Барлык ыру синең белән соңгы кабат саубуллашырга килде. Бары синең углың, минем колынкаем Тотыш кына кайтып җитмәде, аннары синең углың Күзәмеш тә монда юк. Явыз Алмыш ханга ул тотык булып китте. Тәңре катына баргач, син безнең турыда әйтергә онытма, Күрән! Үзеңнең ыруыңны, сөекле хатыннарыңны, балаларыңны онытма. Без синең өчен изге теләктә булырбыз, син дә тәңредән безнең язмыкларыбызны кичерүен үтен. Тыныч бул, яткан җирең мамык булсын, Күрән! Син мине кеше иттең, син миңа йомшак, ягымлы булдың, син мине барлык хатыннарыңнан ныграк яраттың. Мин сине мәңге онытмам, сөекле ирем!.. Алайса, без туйны башлыйбыз, Күрән?

Әледән-әле борынын тарткалап, күз яшьләрен түгеп ул шулай үзенең үлгән ире белән сөйләште. Бераздан башын калкытып, көндәшләренә, балаларына, туганнарына карады да:

— Ул мине ишетте! Тиздән ул монда килеп җитәр! — диде, кулларын күкрәк турысында кушырган килеш, күккә карап.

Әкрен генә атлап, кайгылы башларын салындырып, алар өйгә кайтып киттеләр. Алар китеп күп тә үтмәде, шул тирәдә исәнеп йөргән этләр табактагы ашамлыкларны ялт итеп куйдылар, сычукны түктеләр. Коймә буенда посып яткан бер-ике сукбай көмеш табак белән бакыр аякны алып сыздылар. Беравык көтеп торганнан соң, үлгән бинең хатыннары, балалары, туганнары иске йортка янадан килделәр. Килделәр дә, күп тормыйча, ашыгып кайтып та киттеләр.

— Би килгән! Итен, боткасын ашаган, сычугын эчкән! — диде Койтым бикә, кунакларга елмаеп.

Ире үлгәннән соң бу аның беренче елмаюы иде.

Күрән бинең туйга килеп житүе, пешкән азыкларны, эчемлекне беренче булып авыз итүе билгеле булгач та, кунакларны сыйлау башланды. Бинең хатыннары, балалары, туганнары, шулай ук барлык зур кунаклар йөз кешене сыйдыра ала торган киез өйдә сыйландылар. Башка кунакларга, чураларга, колларга, бала-чагага туп-туры җир өстенә күп итеп киезләр җәйделәр дә ашамлык-эчемлекне шунда тараттылар.

[1] Иске йорт — каберлек.

Туйны Койтым бикә үзе алып барды. Кунакларны сыйлый башлаганда гына ул түрдә утырды да, ашау-эчү җайга салынгач, киез өйдән чыгып китте. Пешекчеләрне, аякчыларны күрде, тегесен тегеләй итәргә, монысын болай итәргә кушты; җир өстенә тезелеп утырган кунаклары арасында йөрде — кемгә нәрсә биргәннәр, күпме биргәннәр, берәрсен онытып калдырмаганнармы — барысын да карап, күздән кичерде. Урын тапмыйча аптырабрак торган хатыннарны, ирләрне, бала-чагаларны, үзе белән иялтеп, иркенрәк җиргә алып китте; узышлый берәр якын танышының инбашына орынып алды, кайберсенә берәр сүз кушты, я булмаса исәнлек-саулык сорашты.

Койтым бикәнең кайгылы, боек йөзе әле анда, әле монда күренеп калды. Чынында ул инде иренең үлемен күптән онытып бетергән иде. Бикәнең күңелен, бинең үлеменнән бигрәк, бөтенләй икенче нәрсәләр борчый иде. Бүген соңгы көн. Бүгеннән соң ул менә шулай шаулатып, бөтен ыруны җыеп туй ясый алмас. Бүгеннән соң инде шулай якын итеп кешеләрнең иңбашларына орынып китә алмас. Озакламый аның кулыннан байлык та, көч тә китәчәк. Озакламыйча... бүгенге төн көнгә авышкач та ул үзенең явыз ягысы Уттәшнең... Уттәш бинең хатыны булып саналa башлаячак. Беренче төнне яңа би, билгеле, аның өендә кунaчак. Ул инде алдан ук әйтеп куйды. Кемне куяр ул үзенең өлкән хатыны итеп? Тотышка ничек карар ул? Тотыш турында ишетү белән аның чырае сытыла. Элеккечә ул аны каргарга батырчылык итми, шулай да ул аны яратмый да. Тотыш үзе ничек карар бу эшкә? Ул инде үскәндер, көчледер. Үги атасына каршы бер-бер яманлык эшләмәсме ул? Үз атасы булмагач, аны инде элеккечә яклаучылар табылмас. Бер анасының гына яклавы аны үги атаның кырын күзеннән, яманлыгыннан саклап кала алырмы?

Бикәнең күңелен менә шундый уйлар борчыды. Ул инде күптән, бик күптәннән бирле киләчәктә нинди зур үзгәрешләр буласын сизенеп яшәде. Соңгы көннәрдә куркыныч төшләр дә күрде. Ниләр генә булыр инде, ниләр генә күрер инде аның кайгылы башы?

## VII

Койтым бикә бүген саранланып тормады — базларда саклап тотылган барлык кисмәкләрне диярлек кунакларга таратырга боерды: аяктан егылганчы эчсеннәр, диде. Үзе ул сычукны бары авыз итеп кенә карады. Аякчылар, бикәнең боерыгын үтәп, бик юмарт кыландылар. Күп тә үтмәде, әле анда, әле монда кычкырып җырлаган, көлешкән тавышлар ишетелде. Көлү, җыр тавышларына җир селкетеп биегән, думбыра, сорнай чырткән тавышлар кушылды. Кайгы туе сиздермичә генә куаныч туена әйләнде.

Ашау-эчүнең, уен-көлкенең кызган чагында Койтым бикә, арып-алҗып, үз өенә кереп китте. Ак өйдә дә, тышта да аның инде кирәге юк иде. Аның бераз ятып, ял итеп аласы килде.

Бусага янында аның каршысына кинәт бер кеше килеп басты. Ул исерек иде, сыңар күзе аның кара чүпрәк белән бәйләнгән иде.

— Бикәгә минем бер сүзем бар... тыңласа...— диде ул, телен көчкә әйләндереп.

— Нинди сүз? — диде бикә.

— Синең үзеңә генә. Аулакта гына,— диде исерек ир кеше, бик тә серле итеп.

«Кем соң әле бу?» дип уйлады Койтым бикә, тиз генә таный алмыйча. Күзен бәйләгән... Туктале, Талут ич бу! Тотыш чыбыркы белән сугып күзен чыгарган Талут. Моннан ике ел элек ул шул сытылган күзе өчен акча сорап килгән иде. Шуннан соң бөтенләй күзгә-башка күренмәде. Урман арасында яшәде бугай. Нинди яшерен сүзе булыр аның? Тагын

шул күзе өчен акча сорамакчы була микәнни? Кайчагында бик бәйләнчек була бу каралар.

— Әйдә, керик, алайса,— диде ул Талутка.

Өйгә кергәч, ул ишекне эчтән бикләп куйды. Түргә, йомшак урынга барып утырды да, бер сүз әйтмичә көтә башлады. Талут, өйгә керү белән, бикә алдына тезләнде, сыңар күзеннән яшьләр коеп, җыларга кереште.

— Шулмы сүзең? — диде Койтым бикә.

— Бикә, кичер мине, кичер,— диде Талут такмаклап, башын бәргәләп.

— Ни өчен кичерергә? — диде бикә.— Теге чакта акча алган өченме? Тотышны яманлавың өченме? Булган — беткән, оныт.

— Тәңре каршында языклы мин, бикә! — диде Талут.

— Мин сиңа тәңре түгел!.. Әйттем исә кайттым! — диде бикә, үрталә башлап.— Күзең өчен тагын акча кирәкме?

Ул, кабаланып, кулын күлмәк изүенә тыкты да калтасын тартып чыгарды. Аның тизрәк бу исеректән котыласы килде. Акча чылтыравын ишетеп, Талут җылавыннан туктап калды, сыңар күзен елтыратып, бикәнең ак кулына, калтасына карап тора башлады.

— Юк, бикә, миңа акча кирәкми! — диде ул кинәт бөтенләй айнык бер тавыш белән.

Койтым бикә, иелеп, аның йөзенә җентекләбрәк карады. Талут исерек түгел иде.

— Әйтеп кара, алайса, сүзеңне,— диде бикә, калтасын кире яшереп.

— Бикә! Кичерәсеңме мине? — диде Талут.

— Ник? Тотыш өченме? — диде бикә тагын да.— Эш миннән тормас. Тәңре кичерсен.

— Әйт — кичерәсеңме?! — диде Талут исәр кеше сыман, аягына басып.

— Мин сине кичерәм, Талут,— диде Койтым бикә, йомшак кына итеп.

Аны чын-чынлап кызыксыну биләп алды: ни булган моңа? Әллә чыннан да тилергәнме бу?

— Нинди языгым булса да кичерәсеңме? — диде Талут, бәйләнчекләнеп.

— Минем алда синең бернинди языгың юк, Талут,— диде бикә.

— Әйт — кичерәсеңме?!.— дип кычкырды күзен бәйләгән кеше, ярсып.

— Нинди языгың булса да, мин сине кичерәм, Талут,— диде бикә, никтер курка башлап.

— Сүзеңнән танма, бикә! — дип кычкырды ялган исерек, сыңар күзен акайтып.

— Танмам,— диде бикә.

Талут, каты буза эчәр алдыннан тынып торган эчкече кебек, беравык тынын кысып торды да, йөзен чалышайтып, көрсенеп куйды, аннары, башын түбән иеп:

— Иреңне... Күрән бине... мин үтердем, бикә,— диде.

Аның ябык, саргылт йөзе үлекнеке төсле булып, тагын да ныграк агарынып калды, башы тагын да ныграк салынып төште. Искәрмәстән гөрселдәп ул идәнгә ауды.

Койтым бикә, урынында ничек утырган булса, шул көе катты да калды. Шулай күпмедер онытылып, шаккатып, аптырап утырганнан соң ул борын сыртын кашып куйды, изүен чишеп җибәрде. Кисәк кенә аны нидер калтырата башлагандай булды. Шул ук мәлдә күкрәгенең сул ягында, эчтә, тирәндә, авырттырып-авырттырып нидер кузгалып куйды.

— Әйе, мин үтердем, бикә,— диде Талут озак кына тынып ятканнан соң, башын калкытып.— Ике ел буена кара кан йотып яшәдем. Корыдымкиптем, саргайдым. Күрән бинең каны тота мине. Өрәге көн дә төшемә кереп котымны ала, буа, өстемә каплана... үз янына тарта... Мин куркам, бикә! Кешеләрдән, синнән, синең балаларыңнан куркам. Минем кешегә

бармак белән чирткәнем дә булмады. Күрән бигә минем тамчы да ачуым югые. Шулай да мин аны үтердем.

— Ни өчен?! — диде бикә пышылдап, тетрәндергеч итеп.

— Менә шуның өчен үтердем,— диде Талут, күзендәге чүпрәген каплап.— Тотыш минем күземне чыгарды бер дә юкка. Күнелдә углына, сина, бикә, ачу саклап йөрдем. Шунда мине Утташ кам котыртты, аңымны томалады.

— Шуннан, шуннан? — диде бикә.

— Шуннан шул... Күрән би менеп йөри торган баскычның бер басмасын алыштырып куярга ул әйтте. Башыма да килмәгәние. Сагалап кына тордым да, беркем күрмәгәндә... би сырган башына менеп киткәч... таза басманы череккә алыштырдым да куйдым. Би булгач, мин сине унбашы ясармын диде.

— Кем?

— Кем булсын — Утташ!

— Димәк, минем ирем сез казыган базга барып төшкән булып чыга?

— Шулай булып чыга, бикә,— диде Талут.— Мина унбашы булу да, йөзбашы булу да кирәкми. Мин уларга тиеш, бикә! Күрән би янына китеп, мин аның аяк астына егылырга, аның ярлыкавын үтенергә тиешмен. Сина үтенечем шул: минем ишемне, балаларымны ташлама, кыерсытма. Кызым чирле... өч яшьлек... сабыем, балакаем! Аягы йөрми. Шуны уйласам, йөрәкләрем өзелә. Терелт, им ит. Күрәсен, аны да Күрән бинең каны тотадыр. Мин үлсәм, жибәрер. Тотышка бер үпкәм дә юк инде. Яшь кеше... кызып киткәндер. Шундый зур языгым булмаса, бер күз белән дә яшәгән булырыем. Инде булмый, бикә. Тагын шул: Утташ кам... ни... мина Тотышны да...

— Тотышны да?! — диде бикә, аягүрә басып.

— Әйе. Мин баш тарттым.

— Бу турыда тагын кем белә? — диде бикә, үз-үзен тиз арада кулга алып, эчке бер тынлык белән.

— Утташ та мин.

— Мин сине тулысынча... бөтенләйгә... мәңгегә кичерәм, Талут! — диде бикә, дулкынланып.— Син минем күземне ачтың. Турысын сөйләвең өчен мин генә түгел, тәнре дә ярлыкар сине, Талут. Тынычлап яшә. Ишеңне, балаларынны кайгыртырмын — ул турыда борчылма. Мин кичергәч, Күрән би дә йомшар... йолык бирербез.

— Юк, бикә! — диде Талут.— Мин инде уйладым: мин тәнре катына бармыйча, жирдә тынгы таба алмаячакмын. Күрән бинең ярлыкавын мин үзем сорарга тиешмен.

— Бел аны: бу турыда беркемгә тишмә! — диде бикә.— Монда син түгел, Утташ кам языклы. Иң элек без аннан үч алырга тиешбез! Шунсыз Күрән безне кичермәс.

— Колың булыйм, бикә! — диде Талут, чибәр хатынның күлмәк итәген үбеп.

## VIII

Талут чыгып күп тә үтмәде, бикә янына өлкән аякчы килеп керде.

— Таратырга бал бетте, бикә,— диде ул.— Теге өч чиләк керешле тамгалы чапчакларны ачаргамы?

— Ачарга,— диде бикә, аның сүзләрен бик үк тынламыйча.

— Утташ әйтә, Койтым бикә нишләп күренми, ди. Исерде. Үзе жырлый, үзе жылый, үзе тагын бал сорый.

— Минем башым авырта, күнелем болгана — бара алмыйм,— диде бикә.— Әйт: исермәсен, туйны үзе алып барсын, күз-колак булсын.

— Кая ул! — диде өлкән аякчы, кулын селтәп.— Аның үзенә күз-колак булырга кирәк.

Ул, шулай сөйләнеп, өйдән чыгып китте. Койтым бикә анын соңгы сүзләрен бөтенләй ишетмәде. Ул күзләрен йомды. Ул үзендә ниндидер изелүатылу тойды, коточкыч авырлык тойды. Аның өчен тормыш, әйтерсең, уктап калды — аның ни дә булса уйлыйсы да, кайгырасы да килмәде. Шулай да күңеленең бер кырыенда гына энә очы чаклы гына булып, рнетеп, авырттырып, Тотыш эленеп торды. Ул кайтып житмәде. Алмыш ан жибәрмәгәнме, Күзәмеш углан барып житә алмаганмы? Исәнме, үгелме?

Туктале, ана тозак корырга да өлгермәгәннәрме?! Кайтып житмәс борын... юлда... берәр ничек юкка чыгармаганнармы? А, тәңрем!

Бикәнең авыр кайгыдан бастырылып ойый, тына барган йөрәге, оясынан атылып чыккан киек кебек, ыргылып куйды, камырга әйләнә башлаган кан тамырлары буенча, йокымсыраган миен, тойгыларын камчылап, кайнар кан йөгереп узды. «Тәңрем, көч бир, кыюлык бир!» диде бикә, ишекле-түрле йөренеп, нидер эшләргә, нидер кырырга-жимерергә чамалап.

Ул урамга чыкты, йолдызлар белән тишкәләнгән кара төн чыбылдыгына карап алды — әле төн уртасы ерак. Кунаклар инде таралыша башлаганнар. Анда-санда гына исерек тавышлар, жырлар ишетелә.

Бикә кире өйгә керде, пыскып янган учакка утын өстәде, өстен-башын төзәткәләде, көзгегә каранды, агарынган йөзенә кызыллык йөгерсен өчен бераз сычук эчте. Шуннан соң ул янадан урамга чыкты, ак өйгә юналде. Ана кичекмәстән берәрсен күрергә, сөйләшергә, ни дә булса эшләргә кирәк иде. Юкса, ул соңга калачак, бик нык соңга калачак! Кемне күрергә, кем белән киңәшергә соң? Майчан аксакал белән берни барып чыкмас. Булса-калса — Котан, Акбога... Бөтен ыруда, бөтен туган-тумачалары арасында алардан башка бернинди ышанычлы кеше юк. Котан... Котан би... әллә Акбогамы? Анын үги угыллары... Күрәсең, язмыш шулайдыр. Башкача булмый.

Исерешеп беткән, баш-аяк килгән кешеләр арасында Котанны ул бик тиз тапты. Шыпырт кына ана үзе артыннан барырга кушты.

— Кеше күрмәсен. Ашыгыч сүзем бар,— диде ул ана.

Котан күз карашы белән генә ана төшенгәнлеген белдерде. Бикә, елмаеп, кызмача кеше сыман, як-якка чайкалган булып, Утташ кам янына барып әйләнде, үз кулы белән аңа буза салып бирде. Аннары, анын колагына пышылдап:

— Беренче этәч кычкыргач килерсен. Әле төннең чирегә дә юк,— диде.

Шулай сөйләнгәләп, ислемай исләре анкыткан күлмәк итәкләрен жилфердәтеп бикә шул тирәдә бераз буталды да, юкка да чыкты. Ул үз өенә кайтып кергәндә, Котан анда иде инде. Субашы Котан шактый кызмача, шулай да аягында нык басып тора. Койтым бикә ана йомшак урындыкка утырырга кушты. Котан сирәк сакалын сыйпаштырып, елмаештырып бикәнең аяк астына идәнгә тезләнде.

— Анам өендә мина идәндә дә йомшак,— диде ул.

— Бүгеннән башлап син мина угыл түгел, мин сина — ана түгел,— диде бикә.

— Төн уртасы узмаган ич әле, анам... бикә...— диде субашы бер дә юктан кеткелдәп.

Койтым бикә күлмәк итәкләрен жыештыргалагандай итте, көмеш беләзекләренә, ялт-йолт килгән муенсаларына кагылгалап алды, елмайды, учактагы утка яны беләнрәк торган Котанның күзләренә туры карады да:

— Мин сина ошыйммы, углым? — диде.

Беркатлы Котан авызын ерып, ышанып житмәгән шикелле, тын гына карап торды. Аннары кызмача бер кыюлык белән, омтылыш белән, бикәнең тез өстеннән салынып төшкән ак, матур кулына үрелде, тотып алды, жылый-жылый, кәлә-кәлә үбәргә тотынды.

— Анам! Бикә! — диде.— Чынмы? Ялганлыйсыңмы? бикә! Анам! Тагын әйт: чынмы?

Котан тынычлана төшкәч, бикә кулын аның сакал-мыек чытырыннан тартып алды да, кырыс бер ныклык белән:

— Ошасам, шул: синнән башка мин беркемгә кияүгә чыкмаячакмын! — диде.

Субашы Котан авызын ачып, исе китеп тик торды.

— Утташ кам...— диде ул, шулай да үзалдына мыгырданып.

Булачак иренең шундый җебегәнлегенә ачуы килеп, бикә чыраен сытып куйды.

— Тик син шуны аңларга тиешсең,— диде ул боеручан тавыш белән,— мин өлкән хатын гына булмаячакмын. Би урынын да, ыру башын да мин үзем тотачакмын! Ишетәсеңме, мин ыру башы булачакмын! Шуңа килешсәң, иртәдән мин — синең хатының!

Котан, шашынып, янадан бикәнең ак кулын үбәргә тотынды. Нидер исенә килеп ул кинәт аягына басты, беренче тапкыр күргән сыман, сокланып үзенең үги анасына карап тора башлады.

— Утташ кам ничек соң... әллә ничек була түгелме? — диде ул тагын да.— Аңлатып бир: ничек?

Койтым бикәгә чыннан да аңлатып бирергә туры килде. Бары шуннан соң гына булачак кияү җиңел сулап куйды. Үзенең зур, көчле кулына бикәнең ак кулын алып кысты да, чын күңелдән соклану белән — инде икенче төрле соклану белән:

— Синнән дә башлырак, кыюрак кеше калмады ыруда, анам! — диде.— Билек [1] — сиңа, ыру башы — сиңа! Тулысынча мин сиңа буйсынам. Үз урынымда калсам, миңа шул җиткән.

— Антмы? — диде бикә.

— Ант! — диде Котан, бикә биргән сычукны алып.

— Тагын бер сүзем бар,— диде бикә, ант эчкәч.— Тотыш кайткач, аңа берниндн усаллык кылмаска! Мин барысын да үземчә эшләячәкмен. Син минем бер эшемә дә кысылмассың.

— Мин сиңа сүз бирәм! — диде Котан.— Тотышка усаллык кылмам, синең сүзеңнән чыкмам!

— Килештек,— диде бикә.— Төн уртасы җитәдер. Кирәкле кешеләреңне күреп, кисәтеп куй. Акбогага белдер, соңыннан үпкәләп йөрерлек булмасын. Юк, аңа мин үзем әйтермен. Утташ килгәнче өлгерергә кирәк.

— Булды, киттем! — диде Котан, ишеккә борылып,

Шул чакны кемнеңдер бәрелә-сугыла өй алдына килеп кергәне ишетелде.

— Килә! Түзмәгән,— диде бикә, пышылдап.— Бар, кач!

## IX

Койтым бикә ишекне ачып җибәргән иде, каршысына Утташ кам урынына Тотышны — үскән, үзгәргән Тотышны күреп артына авып китә язды. Курку-каушау тиз арада чиксез куаныч белән алышынды.

— Углым, Тотыш! — диде ул, колачын җәеп.

Борынын тартып, шыңшыгандай итеп ул аның күкрәгенә сыенды.

— Кайтты! Исән, исән! Колынкаем, бавыр итем, йөрәк маем... Исән, исән! — диде ул, углының киемнәрен, битен, кулын кайнар күз яшьләре белән чылатып.— Кайчан кайттың? Ничек кайттың? Ник сеңгардың, углым?

— Менә, кайттым инде, анай,— диде Тотыш, елмаеп.— Капкадан кергәндә беркем күрмәде — сакчылар исерек.

[1] Билек — би дәрәҗәсе.

— Син эле дә үз капканнан качып-посып керәсеңмени, углым? — диде ана.

— Мин инде якты көздә кайтып төштем,— диде Тотыш.— Керергә юри караңгыга калдым.

— Ник, углым? — диде бикә.— Әллә берәр нәрсә булдымы?

— Булды, анай,— диде Тотыш, өстендәге киемнәрен чишенә башлап.— Талкысыктан аста, ауган карама янындарак юлбасарлар юлыма аркылы төште. Арлар. Бик каты сугыштык. Өч кешем үлде. Шуларның берсе — якын кадашым. Бәкәч чәчән. Урыны оҗмахтан булсын! Аннары Баганай...

— Баганай? — диде Койтым бикә.— Әйтәм, туйда күренмәде!

— Аларның сүзеннән шуны аңладым: алар минем кайтканны сагалап торганнар, анай. Аларны котыртканнар, анай! Шуңа күрә монда качып-посып кердем. Кичер мине, анам! Күңелем яман нәрсә сизенде. Шулай да мин чигенмәскә булдым. Миңа тозак коручы кем генә булмасын, мин аннан курыкмыйм. Үз өемә, үз анам янына кайтып житеп, кире чигенсәм, атым Тотыш алып булмасын! Алып кайткан бүләкләремне талап алып калдылар, әзәрлекләп булмады. Бары бер йөзек кенә исән калды... булачак киленеңнән сиңа бүләге — ал шуны, изге анам!

Ул куенындагы калтасыннан алтын йөзекне алды да анасының урта бармагына кидерде.

— У-у! — диде Койтым бикә, кояштай балкып, йөзектән күзен алмыйча.— Булачак киленемнән? Кем икән ул минем булачак киленем? Бай булсын, сау булсын ул юмарт килен!

— Соңыннан сөйләшербез ул турыда, анам,— диде Тотыш, киемнәрен коралларын чөйгә элеп.— Иң элек син әйт: шулай ук эшләр яманмыни монда?

Койтым бикә, авызын ачып нидер әйтмәкче булган иде, шул чакны көтмәгәндә өй ишеге ачылып китте — Тотыш кергәндә, күрәсең, өй алды ишегенең келәсен элдерергә онытkан иде. Ана да, угыл да, сүзләреннән бүленеп, керүчегә текәлделәр. Тотыш ялт кына урыныннан кубып, чөйдәге кылычын алды. Елмаерга, туры басарга тырышып, ишек яңаклырына тотынгалап, Утташ кам кереп килә иде.

— Ярты төн узды, бикә! — диде ул, артта калган сул аягын бусага аша күтәреп алырга тырышып.— Кияү килә. Каршы да алмыйсың, бикә!

Тырыша торгач, ул бусагадан аркылы атлады да, борылып ишекне япты, бавын элдерде, аннары билен турайтып, тамак кыргалап, түргә узгандай итте. Каршысында, ут яктысында Тотышны күреп ул чайкалып китте, күзләрен челт-мелт йомгалады, әллә төшләнәмме дигәндәй, сакалын тарткалап карады. Юк, төш түгел иде, ахрысы, бу. Тотыштан бер читтәрәк, усал елмаеп, бикә басып тора иде. Аның шул усал елмаюлы йөзен күргәч тә, Утташ кам барысын да аңлап алды. Аны кинәт очкылык тота башлады.

— Ке... ке... кем бу? Н... н... ни эш бу? — диде ул, кемгәдер ачуланасы килеп.

Аңа беркем берни әйтмәде.

— Ә-ә... Тотыш икән! — дигән булды Утташ кам, «танып» алып.— Тотыш... ничек итеп... ни... ыы?..

Кинәт ул биленнән бөктәсен [1] тартып алды да, ярсытылган аю сыман, Тотышка ташланды. Ул аның кулындагы кылычын күрмәде бугай. Ут яктысында озын тимер ялтырап китте.

— Углым, ярамый! — дип кычкырды Койтым бикә, Утташ камны каплап.

Шул чакны качкан җиреннән — чыбылдык артыннан Котан килеп

---

[1] Бөктә — хәнҗәр.

чыкты. Тотыш белән икәүләп алар тиз арада Утташ камны тотып алдылар, аяк-кулларын бәйләп ташладылар да авызына чүпрәк тутырдылар.

— Исәнме, саумы, Тотыш,— диде Котан, Утташ белән эшләре беткәч, энесенең кулын кысып.

Котан белән Тотыш тыелып кына исәнләште. Нәрсә бу? Нишләп монда дүртенче кеше килеп чыкты әле? Ул анасына сораулы караш ташлап алды.

— Утташ кам сиңа тозак корган, без аңа капкын кордык, углым,— диде Койтым бикә.— Син бу кешене яхшы беләсен, углым. Бу кеше сиңа, миңа көн күрсәтмәскә тырышты. Бу кешенең эче этлек белән, яманлык белән тулы.

— Беләм, анам, барысын да беләм,— диде Тотыш.— Шулай да, анам, төшенмим — нишләтмәкче буласың син аны?

— Мин дә үч алмакчы булам, углым,— диде Койтым бикә.— Синең өчен, үзем өчен, атаң өчен үч алмакчы булам.

— Атам өчен? — диде Тотыш.— Минем ул турыда уйлаганым булмады. Минем атамны ул кыерсыта алмады шикелле.

— Ул аны үтергән, углым! — диде бикә.— Соңгы сүзне иртәгә ыру әйтер. Болай гына эшен бетерсәк, без кеше үтерүче булачакбыз. Моның өчен ыру безне кичермәсие. Үзенең өлкән камын, үзенең биен, ыру башын бары ыру гына үтерә ала. Ырудан, улустан көчле берни юк ажунда, углым!

## X

Корылтай үзенең соңгы сүзен әйтте: ыру башы Күрән бине үтергән өчен Утташ камны тәңре катына озаттылар. Урман эчендәге киң алан читендә, бер-берсеннән ун адым аеры үсеп утырган ике яшь каенның башларын бергә китереп иделәр дә, Утташ камның бер аягын бер агач башына, икенче аягын икенче агач башына бәйләделәр. Шуннан соң каен башларын ычкындырып җибәрделәр... Кешеләр өсләренә кара кан тамудан куркып, тиз генә як-якка сибелделәр.

Талутны Койтым бикә корылтайда яклап чыкты. Шуңа күрә аны исән калдырдылар. Бары Талут үзе генә моңа каршы килде. Ул, бер үк сүзне кабатлап, үзенең Күрән бидән ярлыкау үтенергә тиешлеген әйтте. Аның теләгенә каршы килмәделәр.

Шулай итеп, Койтым бикә җиңеп чыкты. Корылтай аны ыру башы итеп куйды. Билекне ыру башы үзенең углы Тотышка бирде. Субашы Котан белән каравыл башы Акбога гына моңа артык куаныч белдермәделәр. Шулай да аларның да почмагы түгәрәкләнде: Койтым бикә, биргән сүзен үтәп, Котанны үзенә ир итеп алды — үги улының икенче хатыны булды. Акбогага бүләк итеп яңа ыру башы аерым җир бүлеп бирде, биш йөз баш ат, йөз баш сыер, өч йөз баш сарык бирде, коллар бирде.

Кызыл Яр катауда кайгы туена ялганып, яңа туй башланып китте. Таралышып өлгермәгән кунакларга яңадан ачы баллар, бузалар чыгарылды, куйлар, җылкылар суелды.

Туй ыгы-зыгылары үткәч, берничә көннән Тотыш анасына үзенең эч серләрен ачты. Койтым бикә, елмаеп, сөрмәле күзләрен кысыштырып, углына озак кына карап утырды.

Аның углы Тотыш хан кызын ярата! Тотыш — Алмыш хан кияве! Алмыш хан белән алар — Койтым бикә — кода-кодагый булачаклар! Нәрсә бу — язмыш шуклыгымы, әллә соң Болгар ханының бик еракка ташланган җәтмәсеме? Ун мең тиен калым түләргә, бөтен ыруың белән чумак йоласына күчәргә... Бу аз түгел. Хан кызы Аппакка торырлык түләү бу. Моның иң авыры кайсы булыр — ата-баба йоласыннан баш тартумы, әллә ун мең тиен калыммы? Күрәсең, ханның чыннан да үз уйлары бардыр. Акбүрене ныклап торып үз кулына алса, бөтен Чулман

буе аныкы булачак. Тулысынча аныкы булачак. Акбүредән Биарга да ерак түгел. Биардан әнә таланган кешеләр килә. Биарны төн ягыннан, тингездән килгән явыз юлбасарлар талаган. Биар тузган, юкка чыккан. Күрәсең, язмыштыр. Биар ханының җитен чәчле чибәр кызын алып булмады. Таланган, көчсезләнгән Биар белән туганлашуга караганда, үргә менеп барган Болгар ханы белән туганлашу, билгеле, йөз кат, мең кат артыграк. Шулай да... Ах, шулай да, тәңрем, синең серле эшләреңне кем генә белә соң?!

— Мин, углым, синең бер генә теләгеңә дә каршы килмәячәкмен,— диде бикә бик озак сүзсез утырганнан соң.— Син минем бердәнбер куанычым. Син инде үзең би. Үз башың белән уйлап кара: бүгеннән тотып без ата-баба йоласыннан баш тартсак, ыру безгә ни дияр? Безне тыңлап та тормаслар — кулдан тотарлар да, артка тибәрләр дә, чыгарырлар да җибәрерләр: әнә, барыр юлыгыз! Теләсә кая барыгыз, теләсә кемгә би булыгыз! диярләр.

— Нишләргә соң, алайса? — диде Тотыш, караңгы чырай белән.

— Ашыкмаска кирәк, углым,— диде ана кеше.— Күтәргә, ыруны тулысынча үз кулыбызга алырга, кирелэрне үз ягыбызга аударырга кирәк. Утташ кам үлде, аның яклылар үлмәде. Шуны да онытма, чумак йоласына күчсәк, без урталыкта калачакбыз: унда да, сулда да ата-баба йоласындагы ырулар булачак. Алар безгә кырын күз белән караячаклар. Шулай булгач, безгә үз ыруыбызны гына түгел, күршеләрне дә үз ягыбызга аударырга туры киләчәк. Ике айдан түгел, дүрт-биш айдан өлгерсәк тә...

— Дүрт-биш ай! — диде Тотыш, көрсенеп.— Дүрт-биш айда мин саргаеп үләрмен, анам.

— Үлмәссең,— диде Койтым бикә, көлеп.— Яңа иген җитмичә торып мин мең тиен түгел, йөз тиен дә арттыра алмыйм. Калымга гына түгел, әле бүләккә дә дүрт мең тиен кирәк булачак. Безнең базлар, чокырлар бу көннәрдә бушап, такыраеп калды, углым. Би буларак, син үзең карап, тикшереп чык. Шуннан соң күрерсең үз күзләрең белән.

Тотыш би, анасының сүзен тыңлап, чыннан да карап чыгарга булды. Үзенең базларын, чокырларын, таварлыкларын, агылыкларын[1] тикшереп карагач, ул әллә ни байлык юклыгын танырга тиеш булды. Мең тиенлек калым җыю өчен, дүрт-биш ай булмаса да, кимендә бер өч ай көтәргә, тир түгеп эшләргә кирәк булачак иде. Калымнан да бигрәк, Койтым бикәнең йола турындагы сүзләре чынга чыкты. Аксакалларның, ил агаларының берсенең дә тора салып күнеккән, иялэшкән үз йолаларыннан баш тартасылары килмәде. Нык каршы торучыларны үз ягына аудару өчен Койтым бикәгә бик нык тырышырга, төрлечә алдарга-йолдарга туры килде. Бары шуннан соң гына — шактый тартыштан, сатулашудан соң гына ыруның аксакаллары, агай-энеләр чумак йоласына күчәргә теләк белдерделәр. Шуның белән бергә Тотыш биның Алмыш хан кызы Аппакка өйләнүенә килешү дә белдерелде. Боларның барысы да коры сүз генә булып калмасын өчен, Болгар ханына битек язылды, битекне тапшыру өчен Алмыш ханга ырудан ун кеше илче итеп билгеләнде. Шул ук кешеләр хан катына кода булып та керергә тиешләр иде. Яңа йолага күчүдә Тотыш би баш илче булса, ана Аппакны ярэшүдә Майчан аксакал баш кода булды. Илчеләр-кодалар арасына Койтым бикәнең ире Котанны да керттеләр.

## XI

Кырларда-басуларда игеннәр өлгереп, урманнарда яфраклар саргая башлагач, көннәрдән бер көнне Тотыш би ерак юлга җыена башлады. Каекларны яхшылап төзәттерде, буятты, бизәтте. Ишкәкчеләр итеп ул

[1] Агылык — хәзинә саклау урыны.

үзенә бары яшь, чибәр егетләрне генә алды. Шундый эшләрен бетергәч, ул калымга, бүләккә алып барасы таварларын каекларга төятә башлады. Болгар илендә өйләнгән барлык кешеләр ханга иярләнгән бер яхшы ат бирергә тиешләр иде. Шуның өчен дип көтүдән өч яшьлек җирән айгыр кайтарттылар. Айгыр өчен аерым каек җайланды. Калымга, бүләккә дип Тотыш би бер батман [1] яңа бал алды, ун батман яңа богдай, тары алды. Төрлесеннән өч йөз тире, иллеләп чүлмәк савыт-саба, дүрт төң суккан юка киндер, бер кисмәк балык мае, ярты батман кипкән балык алды. Шуның өстенә төрле төзәнү-бизәнү яраклары: ырудашлары ясаган төрле беләзекләр, йөзекләр, алкалар, чулпы ише нәрсәләр, эш, сугыш кораллары алды. Акбүре җирендә нәрсә бар, акбүреләр ниләр ясый алалар — барысын да ул Болгар ханына күрсәтмәкче булды.

Җылы, изге бер таңда, Чулман аръягыннан алтын кояш чыгып килгәндә, Тотыш бинең байраклар белән, төрле төстәге ефәкләр, ат койрыклары белән бизәлгән, төрле төсләргә буялган уналты каегы Кызыл Яр катау тамгасыннан кузгалып китте. Яр буендагы кешеләр, куллар болгап, быргылар кычкыртып, аны изге теләкләр белән озатып калдылар. Акбүре биләмәләрен узып киткәнче, Чулманның әле бер ягында, әле икенче ягында яр башларында җыелып торган төркемнәр күренде, байраклар җилфердәде, күңелле быргы тавышлары ишетелде.

Үз җирләрен узып киткәч, ят кешеләрнең кызыксынуын арттырмас өчен, Тотыш би каеклардагы байракларны, төрле бизәкләрне алып куярга боерды. Уртасында аты, араны булган каекка ул чатыр корырга кушты. Чит ярлар арасыннан алар, утлар яндырмыйча, бары төнлә генә бардылар, көндезләрен исә берәр аулак елга тамагында, я булмаса таллыкта, камышлыкта уздырдылар.

Шулай сакланып бара торгач алар күп кенә авылларны, катауларны узып киттеләр. Иң куркынычы исә әле алда иде. Ул да булса, Шуран катау иде, Ямгырчы би иде. Болгардан Кызыл Ярга кайтканда Тотыш Шуран катау турысыннан төн уртасында гына, бик сакланып кына узып китте. Бу юлы да ул ничек тә шул турыдан иплэп кенә, тавыш-тынсыз гына ычкынырга чамалады.

Алар Шуранга капма-каршы яктан — Чулманның сул як яры буйлап китәргә булдылар. Куркыныч урынга житәрәк, көндез алар яхшылап ял иттеләр, сугышырга туры килсә дип, коралларын җайлап куйдылар.

Күзгә төртсәң күренмәслек кара төндә тавыш-тынсыз гына яр читеннән йөзеп барганда, су өстендә әле анда, әле монда утлар кабынып китте, якында гына ниндидер куркыныч тавышлар ишетелде. Тирә-якта утлар торган саен күбәя барды. Алар ничектер бик житез кыймылдадылар, чайкалдылар, тирбәлделәр, артка төштеләр дә, акбүреләрнең каекларын бар яктан да уратып алдылар.

Үзенең чолганышта калуын күреп, Тотыш бинең эче жу итеп китте. Ул үз каекларына бер тирәгәрәк тупланырга боерды.

— Ничек үләбез — сугышыпмы, сугышмыйча гынамы? — диде ул үзенең юлдашларына.

— Нишләп әле син үләргә ашыгасың, яшь би? — диде Майчан аксакал.

— Ямгырчы би — безнең кеше. Ул бездә кунакта булды,— диде Котан.— Безгә дә кунак булырга тырышып карарга кирәк.

— Тырышып карагыз, атай,— диде Тотыш би.— Мин инде кунак булдым анда... икенче тапкыр кунак булырга теләмим.

— Аларның көче күбрәк.— диде Торымтай.— Бу караңгыда без берни эшли алмаячакбыз.

---

[1] Батман — авырлык үлчәве. Бер батманда күпме авырлык булуы төгәл мәгълүм түгел. Мәсәлән, бер батманда дүрт пот, сигез, унике пот булган дигән фикерләр бар.

Алар шулай кинәшкән арада, төрле яктан утлар белән ерткалангаң төн бөркәнчеге астыннан сиздермичә генә утсыз каек килеп чыкты. Килеп чыкты да, ниндидер зур, көчле балык сыман җитез генә Тотыш би каегына таба килә башлады; сумалалы биек кырые белән акбүреләр каегының кызылга буялган борынына ышкылып алды. Аягүрә баскан Ямгырчы бинең куркыныч карачкысы карангыдан чыгып, акбүреләрнең күз алдында ук күренеп китте.

— Исәнлек-саулык та сорашып тормыйча, кем китеп бара ул минем катау турысыннан? — дип кычкырды Ямгырчы би.

Шулай сөйләнгәләп, шәрә кылычына таякка таянган сыман таянып, ул акбүреләр каегына җинел генә сикерде. Тотыш би кешеләре, нишләргә белмичә, аптырабрак калдылар. Ул да булмады, Ямгырчы би кылычын шакылдатып каек идәненә ташланды, кулларын җәеп, башта Тотыш бине кочаклады, аннары Котан белән Майчан аксакалга үрелде. Ул, ахрысы, кызмача иде. Акбүреләр, сөенергә дә, көенергә дә белмичә, берни эндәшмичә, баскан урыннарында катып тик тордылар. Беренче булып кылыч күтәрергә Тотыш бинең кыюлыгы җитмәде. Ямгырчы би белән булган ызгыш-талашка, орышка инде күп ара үткән иде, тойгылар ничектер көчсезләнә төшкән иде. Кем белә аны, әллә Ямгырчы би элеккеләрне оныттып та бетергәндер...

Биләре артыннан каекка тагын берничә кораллы казаяк сикереп керде. Алар да, бу төнге очрашуга бик тә куанган шикелле, шаулашып, кычкырып исәнлек-саулык сорашырга тотындылар.

— Нинди эш бу? Оят кирәк азрак! Юк, юк, кунак итми җибәрмим,— диде Ямгырчы би, барысыннан да ныграк шаулап.

— Без ашыгабыз, би, — диде Тотыш, телгә килеп, эчке бер киеренкелек белән.— Без сине борчымаска уйлаганыек. Алмыш ханга калан илтә барабыз.

— Калан? Ха-ха! — диде Ямгырчы би, бөтен Чулманга шаркылдап.— Алмыш ханга калан түләргә атлыгып торучылар да булыр икән! Кайгырмагыз — ханга да, каланга да берни булмас. Әйдәгез, борылыгыз. Олы кунагым булырсыз, түрдә утырырсыз... Тирмәләр корылган, казан асылган, мунча ягылган. Юк, юк, беркая җибәрмим! Сычук җитәрлек, ит-май җитәрлек — түрдән узыгыз, кунаклар!

— Борылырга кирәк,— диде Майчан аксакал, Тотыш бинең эндәшмәвен күреп.

— Борылырбыз,— диде Тотыш би теләр-теләмәс кенә.

## XII

Каеклар унга — Шуран катауга борылдылар. Ямгырчы би үз каегына чыгып тормады, кунаклар белән бергә китте. Озын колга башларында чытырдап янган утларын югары тотып, казаяклар алдан бардылар. Алар артыннан карангы чырайлы кунаклар шуышты.

Иң алдан килгән каек яр буендагы субайларга килеп төртелү белән, ярдан шундук элмәкле аркан ташладылар. Басмадан беренче булып Ямгырчы би үзе төште, тешен кысып, аның артыннан Тотыш би атлады. Ярда алар, янәшә баскан килеш, сүзсез генә башка каекларның килеп җитүен көтеп тордылар.

Ул арада, олы кунакларга дип, каяндыр атлар китерелде. Тотыш би үзе белән бары кода-илчене генә алды. Торымтай башлыгындагы кырык кеше яр буенда — каекларда калды.

Кызыл Яр катау кебек Шуран катау да текә яр өстенә урнашкан иде, тик бу турыда яр өсте ергаланып бетмәгән иде, ындыр табагы кебек типтигез иде. Шуңа күрә, капкага керү өчен, ерактан әйләнеп йөрисе юк иде. Катау капкасы якында гына, яр буенда гына иде.

Ташлы сөзәк юлдан югарыга менеп житкәч, Тотыш би түзмәде, артына борылып, аска карады. Төн уртасы узган иде инде. Аста тып-тын булып, агарып Чулман җәелеп ята иде. Ах, шулай да ялгышты бугай ул! Күбрәк көч белән төшәсе калган, бөтен бер чиру белән! Үз язмышына кирәгеннән артык ышанмыйсың микән, Тотыш углан... Тотыш би?

Менә арттагылар да менеп җитте. Төркемләшеп, күпер агачларын дөпелдәтеп алар койма буендагы тирән урлар аша чыктылар, тешсез авызын зур ачып утырган капкадан да үттеләр. Ямгырчы би үзенең кунакларын тар гына урамнан алып китте. Бер ярты чакрым чамасы баргач, алар икенче күпер алдына килеп җиттеләр.

— Менә монысы минем өем,— диде Ямгырчы би.

«Кара, үз урдасын да ур белән уратып алган!» — дип уйлады Тотыш би шаккатып. Борчулы, сак, тынычсыз юлчылар соңгы күпер белән соңгы капкадан керделәр. Керделәр дә, иркен, тигез ишегалдына тарала бардылар. Каршыда, ишегалдының яр ягындагы почмагында, караеп биек агач өй күренде. Агач өйдән сул яктарак, шулай ук караеп, төркемләшеп очлы башлы киез тирмәләр кабарып утыра иде.

— Нишлисез, кунаклар, башта мунча кереп аласызмы, әллә ашап-эчеп аласызмы? — диде Ямгырчы би.

— Йокыдан да яхшысы булмас безгә,— диде Тотыш би.

— Сез теләгәнчә булыр! — диде Ямгырчы би, бик тиз килешеп.

«Ашы да, мунчасы да юк. Юри сөйләнә»,— дип уйлады Тотыш, эче пошып. Чыннан да, урда каты йокыга талган иде, бер яктан да аш-су исе, төтен исе килми иде. Бары тик көзге коры салкында аерата кискен булып, борыннарны ярып, тирләгән ат, җылы тизәк исе аңкый иде.

Ямгырчы би кунакларның барысын да аерым-аерым тирмәләргә урнаштырды. Акбүреләр караңгы, ят өйләргә керсәләр дә керделәр, кермәсәләр дә керделәр. Шулай да, башлары мендәргә тию белән, шундук йокыга киттеләр. Алар төш җиткәнче йокладылар.

Тотыш би кисәк кенә уянды, тирмәдә ниндидер чит кеше барлыгын тоеп, сискәнеп, куркып уянды. Күзләрен ачып җибәргән иде, үзенең аяк очында, үз ятагында елмаеп утырган Тәңкәне күреп, тынсыз калды.

Тәңкә аңа картайган, ямьсезләнгән шикелле күренде. Шул ук озынча ак бит, атасыныкы төсле калын кашлар, тынгысыз зәңгәр күзләр. Шул ук чандырлык, юкалык.

— Исәнме, Тотыш,— диде Тәңкә, балкып.— Бу мин — Тәңкә. Әллә танымыйсың?

— Таныйм,— диде Тотыш би, башын калкыткандай итеп.

— Торма,— диде Тәңкә.

Кискен генә кыланып, кабаланып ул өстендәге киемен салып ташлады, ябу-тунның читен тартып җибәрде. Салкыннан тунган сыман калтырана-калтырана, көлештергәләп, песи кебек ул Тотыш янына кереп ятты. Ятты да, очлы терсәкләре, тез башлары белән кунакның әле бер җиренә, әле икенче җиренә орынгалап, аякларын суузды, аның биленә, аркасына үрелде. Ояга утырган каз кебек ул бертуктаусыз урынын ипләде — әле ябу-тунын калкытты, әле игәген җыештырды. Тотыш, аның шулай анадан тума шәрәлегенә дә, өтеп алырдай кайнарлыгына да, песи баласыдай мыр-мыр килүенә дә әз генә дә исе китмәгән сыман, сагаеп, үлек кебек кымшанмыйча ята бирде.

— Тотыш, ник берни эндәшмисең? — диде Тәңкә, аның борынына кайнар тынын өреп.— Йокың туймадымыни?

— Туймады бугай шул,— диде Тотыш.

— Син мине исеңнән чыгармадыңмы? — диде Тәңкә, иркәләгәндәй итенеп.

— Юк,— диде Тотыш.

— Мин сине көттем. Ике ел буе көттем, Тотыш,— диде Тәңкә, калтыранып.— Таң аттымы, күзем Чулманда булды. Кайтканда кермәгәнсең

Бик үпкәләдем сиңа, Тотыш. Җыладым, көн-төн җыладым. Артыңнан куа китмәкче булдым — атай җибәрмәде. Ник кермәдең шунда?

— Менә... кердем ич.

— Кердең? Син мине алырга килмәдеңмени?

Тотыш урыныннан кузгалып куйды, нидер әйтмәкче булды. Теле, әйтерсең, аңкавына ябышып калды — әйләнмәс булды. Кылыч белән чабып төшерелгәндәй булып, авыр башы кире ятагына ауды. Ташка, бозга әйләнгән йөрәгендә бары бер генә тамыр тыпырчынды. Тимер кебек авыр кулын көчкә күтәреп ул Тәңкәнең биленә салды. Моның белән нәрсә аңларга теләгәнлеген ул үзе дә төшенеп җитмәде. Күңелендә аның, ахрысы, кызгану тойгысы баш калкытты. Ул, ахрысы, аны юатмакчы булды. Ул аны, билгеле, яратмый иде... Юк, ул аны тамчы да яратмый икән... Шулай да ул аны болай гына, җиңел генә читкә дә сыпырып ташлый алмый иде, ахрысы. Кайсыдыр ягы белән, кайсыдыр саны белән ул — Тәңкә — аның күңеленә бик нык сеңеп калган иде. Ул аның яшьлеге иде, тиле, татлы... кайгылы үткәне иде. Шул үткәннең бер китеге, бер кечкенә истәлеге иде. Ничек соң аның күңелен кырмыйча гына, иплəп кенә аңа шул турыда әйтеп бирергә икән?

— Мин Алмыш ханга калан илтә барам,— диде ул, әкрен генә сүзгә башлап.

Яшь хатынның көләч йөзе сүрелеп калды, уттай кайнарлыгы, өреп сүндергәндәй, юкка чыкты. Чандыр беләген Тотышның биленнән алды да, арты белән борылып, йомарланып, читкә шуышты. Бөтен куллары белән каплаган көе, бөтен аркасын, иңбашларын калтыратып, бөтен ятакны селкетеп, җыларга тотынды. Тотыш, өстенә таш бастырып куйгандай, кымшана да алмыйча, үзалдына сызланып, пошынып, тып-тын гына ятты да ятты.

Бозга әйләнгән күңел бик озак яткач кына эри башлады. Өстендәге авыр ташны читкә этәреп, Тотыш аның ягына әйләнде, аның нечкә биленнән кочып, юатып:

— Җылама, мин сине дә алырмын,— диде.

— Мине дә?! — диде Тәңкә, җылавыннан туктап.

— Сине дә...— диде Тотыш кыюсыз гына.— Мин би булдым. Миңа үлгән атамның хатыннары калды.

— Шул гынамы? — диде Тәңкә.

— Шул гына,— диде Тотыш, тотлыгып.

— Каектагы атны кемгә алып барасың? — диде Тәңкә, күз яшьләре аша аңа карап.

— Калан өчен... Алмыш ханга,— диде Тотыш ялганлап.

Тәңкә кинәт өстендәге ябынгычын атып бәрде. Сикереп урыныннан торды да, күлмәкләрен, читекләрен киде, чулпыларын төзәткәләп куйды.

— Мин барысын да беләм! — диде ул коры, усал итеп.— Мин сине ике ел көттем. Суар Килдеш бинең кече улыннан баш тарттым, угыз ябгуыннан [1] баш тарттым. Мин сине көттем. Син — икейөзле!

Корт чаккандай, Тотыш та кинәт сикереп торды.

— Минме икейөзле?! — диде.

— Син! Син! — диде Тәңкә.— Балыкчы куышында кайгылы төннәреңне уртаклашканда Тәңкә кирәгие, инде би булгач, Алмыш хан кызы Аппак кирәк булган! Канечкеч... килмешәк... капкорсак ханның юха җылан кызы кирәк булган!

Тотыш агарынып китте,— әйтерсең, искәрмәстән кемдер яңагына китереп сукты, әйтерсең, искәрмәстән кемдер битенә төкерде... әйтерсең, кемдер аны ләпеккә, пычракка төртеп екты! Кинәт ул ыргактай куллары белән чандыр хатынны эләктереп алды да чүлмәк кебек итеп, агач кебек итеп ятакка орды.

---

[1] Я б г у — угызларның баш кешесе, ханы.

— Икенче теленә аласы булма! — диде ул, ярсуына буылып.

Тәнкә сырты белән төште. Ятак дөп итеп китте. Ни булганын аңлый алмаган яшь хатын «ай!» диде дә өнсез калды. Исенә килә алмыйча ул бик озак ятты. Аннары ыңгырашып куйды, чыраен сытты. Авырлык белән генә урыныннан торды, арты белән шуышып идәнгә басты, билен турайтты.

— Ярар, икенче әйтмәм,— диде ул салкын гына.

Башын югары тотып ул өйдән чыгып китте.

## XIII

Кичкә Ямгырчы би кунакларга аш-су ясады. Нараттан салынган биек өйнең искиткеч итеп бизәлгән иркен, биек бүлмәсендә карамайлы пыскыйлар түгел, көмеш шәмдәлле балавыз шәмнәр янды. Тамнардан, киң түшәмне тоттырып торган терәкләрдән төрле төстәге ефәкләр, атласлар асылынып торды. Тигез идәндә, төрле бизәкләре белән елмаеп, җемелдәп, бай келәмнәр сузылып ятты. Кунакларга утырырга чигүле йомшак мендәрләр куйдылар. Кыздырылган итне сырлап ясалган авыр көмеш табакларга салып китерделәр, ачы балны, бузаны бары алтын аякларда гына бирделәр. Би үзе дә, хатыннары, балалары, туганнары да, алай гына түгел — аш-су, сычук ташучы кешеләре дә — барысы да ят киемнәргә, чит илләрдән килгән бай сатучылар гына кия торган шикелле киемнәргә киенгәннәр иде. Аларның үз-үзләрен тотышында да, сүзләрендә дә ят кыланышлар, ят сүзләр чалынып кала иде. Кунаклар моны бик тиз күреп, сизеп алдылар. Ямгырчы бинең бар нәрсәдә чумакларга охшарга тырышуын аңлавы бер дә читен түгел иде.

Ни генә булмасын, Ямгырчы би ярлы яшәми иде! Моннан ике ел элек кичү янында болгарлар белән бәрелештә җиңелеп, күп талау күрсә дә, ул тиз арада аякка басты. Үзенең бик каты оттырганлыгын аңлап, Алмыш хан алдында аклану өчен, аның казаяклар талаган, теләсә кайда таралган байлыгын үзенә җыйды. Чулманны боз тоткач, баш иеп, хан катына китте. «Ялгышлык белән булды, кичер, ханым»,— диде. Үз кешеләре талаган күп кенә байлыкны ул Алмаш ханга кире кайтарып бирде. Чынында бу — таланган байлыкны кире кайтарып бирү түгел, җиңелгән өчен өстәмә калан булды. Алмыш ханның да Ямгырчы бидән колак кагасы килми иде. Ник дигәндә, Чулманның йозагы — кичү аның кулында иде. Аннары, ул инде күптән чумак йоласына күчкән иде. Би китергән каланның яртысын ул аңа түләнмәгән кулбау [1] өчен дип бирде. Алмыш хан янына үләмме, каламмы дип барган Ямгырчы би баеп кайтты. Аның әле болгарлардан таланган байлыкның үзендә яшереп калдырганы да җитәрлек иде. Шулай итеп, тоттырмас, шома би берьюлы аякка басты куйды.

Казаяк ыруының башы ничек тә кунакларының күңелен табарга тырышты. Ашаган-эчкән арада көйчеләр төрле көйләр уйнадылар. Аштан соң ул үзенең чит илләрдән китерелгән ят җырчыларын, биючеләрен чыгарды. Алар мондагы кешеләргә аңлашылмаган телдә җырлаган сыман сузып, кычкырып, ниндидер җырлар җырладылар, күңелләрне тетрәндереп, шашкын биюләр биеделәр.

Төн урталары якынлашыр алдыннан, ашап-эчеп, күңел ачып туйгач, би үзенең кунакларын мунча керергә алып китте. Мунчада кунаклар ят нәрсәләрне тагын да күбрәк күрделәр.

Мунча нык итеп, иркен итеп таштан салынган иде. Башта акбүреләр җыйнаулашып чарачага [2] керделәр, шуннан соң шәмнәр белән яктыртылган икенче бер бүлмәгә уздылар. Монда аларның өс-башын яшь кырнак-

---

[1] Кулбау — процент янсә «кулагы».
[2] Чарача — мунча алды бүлмәсе.

лар чишендереп алды. Чишенү, утырып ял итү өчен билгеләнгән бу салкынча бүлмәдән ирләр чабыну, юыну бүлмәсенә керделәр.

Әллә болыт булып түшәмгә эссе бу күтәрелгәнгә, әллә почмакларындагы шәмнәр көчсез янганга, монда шулай да карангырак иде. Үз мунчасын яхшы белгән Ямгырчы би алдан атлады, кунакларга кайда юынырга, кайда чабынырга кирәклеген аңлатты. Күзләре ияләнә төшкәч, акбүреләр үзләре дә күрделәр: сулда, идән уртасындарак, эре ташлардан өелгән учак калкып тора: учак янында чабыну өчен баскычлап биек сәке корылган. Уң якка, там буенча, озын утыргыч сузылган.

Ямгырчы би кунакларны кычкырып үз янына чакырды. Учакның икенче ягында имән бүкән калкып тора иде. Ямгырчы би кулындагы агач табакны шапылдатып бүкән өстенә куйды, югарыдан сузылып торган җиз көпшәнең бөкесенә тотынды да:

— Күрәсезме менә моны? — диде.

Шулай дип әйтүгә ул агач бөкене тартып та җибәрде — көпшәдән шаулап кайнар су ага башлады. Агач табак яртылаш тулгач, би икенче яктан сузылган икенче көпшәнең бөкесен ачты — моңысыннан салкын су агарга тотынды. Кунаклар, таң калып, телләрен шартлаттылар, көпшәгә бармакларын тидереп-тидереп карадылар.

— Күрдегезме! — диде Ямгырчы би, мактанып.— Мондый мунча Алмыш ханда да, Суарда да, Булгәрдә дә юк. Итил-торада үзем күреп кайттым, үзем ясаттым. Үз бакырчым ясады барысын да. Суны күрше бүлмәдә казанда кайнатып торалар. Салкын су да шуннан килә. Инде карагыз монда!

Кунаклар: тагын ни белән шаккатырыр инде бу дисәләр, би аларга идәнгә карарга кушты. Анда, идәннең урта бер җирендәрәк, чокырланып торган бер төшендә, әрләән төннегә сыман тишек күренде.

— Юынты сулары шуннан агып китә,— диде Ямгырчы би, аңлатып.— Чулмәк көпшәләр буенча җир астыннан Чулманга коела. Чишмә суы да җир астыннан көпшә буенча килә.

— Бар икән баш үзеңдә дә! — диде Майчан аксакал, бине мактап.

— Юк түгел алай,— диган булды Ямгырчы би кеткелдәп, күңеле булып.

— Чабынырга себеркең бармы соң? — диде Котан, кашынып.

— Булыр,— диде би.

Үрелеп ул ниндидер бауны тартты — арткы салкынча бүлмәдә тоныкына булып кыңгырау тавышы ишетелде. Ишектән баягы кол кызлар килеп керде. Алар, ни дә булса әйткәнне көтеп тормастан, учак янына килделәр. Берсе, кайнар ташларга җиз чүмеч белән су сибеп, каен себеркесе пешерде, икенчесе, кулына сабын, мунчала тотып, кунакларның аркасын ышкырга җыенды.

— Башта син чабын,— диде үги ата Тотыш бигә.

— Бар әйдә, чабын,— диде Тотыш.

Ул, агач табакка көпшәләрдән су агызып алып, юынырга утырмакчы булды. Шул чакны аның янына Ямгырчы би килеп житте.

— Туктале, Тотыш би,— диде ул ничектер серле итеп, елмаеп.— Олы кунагым өчен минем аерым бүлмәм бар. Әйдәле монда!

Ул Тотышның беләгеннән тотып алды, аны каядыр почмакка әйдәде. Монда күзгә ничектер ташланмый калган кечкенә бер ишек бар иде. Шул ишектән алар якты бер бүлмәгә килеп керделәр.

— Моңысы — ак мунча, тегесе — кара мунча,— диде Ямгырчы би.

Монда да шундый ук учак, имән бүкән, җиз көпшәләр бар иде. Монда да там буендагы озын утыргычка сабын, мунчала, агач табак ише нәрсәләр куелган иде.

Котан кебек, Тотыш та сүзне себеркедән башлады.

— Булыр! — диде Ямгырчы би.— Әнә теге бауны гына тарт, ни телисең, шуны кертерләр.

Ул әйткәнчә Тотыш бауны тартып җибәрде — кайдадыр бөтенләй икенче якта тагын кыңгырау шалтыраган тавыш ишетелде. Шундук ишек ачылып китте, ишектән кулына себерке тотып... Тәнкә килеп керде.

— Иң олы кунакларымны минем кызым юындыра,— диде Ямгырчы би көлеп.— Мин кунак түгел, ул сине генә юындырыр. Нишләп котың алынды, Тотыш би? Миннән кыенсынасыңмы? Чыгам, чыгам! Яшьләргә комачауларга... мине теге кем дип белдең? Үзегез юыныгыз, үзегез сөйләшегез. Мин картлачка кара мунча да ярар.

Ясалма елмаеп, иелгәләп-бөгелгәләп ул «кара мунча»га чыгып китте. Тотыш аның уртадагы кечкенә ишекне теге якта ни беләндер бикләп куйганын ишетеп торды.

## XIV

— Әйдә, чабын, би! — диде Тәнкә, баш иеп, елмаеп.

Ул аңа җиз көпшәләрдән су таманлап бирде, сулы табакны биек сәкегә китереп утыртты да табак янына татлы исләр бөркеп торган йомшак себерке сузып салды.

Тотыш, артык икеләнеп тормыйча, сәкегә менде дә шарт та шорт чабынырга да тотынды. Бераз селтәнгәч, ачулы гына:

— Эссе сал! — диде.

Тәнкә көлеп, озын толымнарын чайкалдырып кызу ташка үрелеп су сипте. Чыжлап, ашыгып югарыга эссе бу күтәрелде. Тотыш би чабынган арада Тәнкә, ак, озын аякларын сузып утыргычка утырды да, ашыкмыйча гына юынырга керешге.

Тотыш озак кына чабынды. Чабынып арыгач, кызарынып, янып-пешеп, идәнгә төште, аннары имән бүкән янына килеп, куркып кына җиз көпшәдән өстенә салкын су агызды. Шуннан соң гына ул Тәнкә янына килде.

— Син инде беләсең, шулай булгач...—диде ул, сүз башларга тырышып.

Тәнкә, елмаеп, аңа якынрак күченде, ике куллап аның муеныннан кочып алды да түбән иелгән күзләренә карады.

— Нәрсә «шулай булгач?» — диде ул үчекләшкән сыман.— Тагын күтәреп ормакчы буласыңмы? Ор! Мин синең хатының. Теләсәң нишләт. Мин сине барыбер бирмим. Иң әлек син минеке булдың, минеке! Бирмим!

Көлеп, кабаланып ул аңа ныграк елыша барды. Озын толымнары белән юри аның муенын уратып алды, кечкенә бармаклары белән аның бармак очларын тоткалады; думбыра кыллары чирткән сыман, аның турсайган иреннәренә кагылгалап алды.

Кырыс алып түзмәде — кинәт кымшанып куйды, бөтен йөзе белән борылды да балык кебек шома, яшь хатынны онытылып күкрәгенә кысты.

— Безне күзәтәләр,— диде Тәнкә, чиксез куанып, аның колагына пышылдап.

— Алайса... ник монда без? — диде Тотыш, шулай ук пышылдап, ачуланып.

— Анлашыр өчен,— диде Тәнкә.

Ялт кына ул аягына басты, ак табаннарын ялтыратып, юеш толымнарын салындырып, баягынак үзе килеп кергән ишеккә таба атлады. Ишекне ачып ул андагы кемгәдер нәрсәдер әйтте дә кире үз урынына килеп утырды.

Бүлмәгә өлкән яшьтәге бер хатын килеп керде. Кулына ул яшь бала тоткан иде. Баланы иркәләп сөя-сөя, нидер сөйләнә-сөйләнә ул яшьләр янына килде, Тотышка ничектер кырын күзе белән генә карап алды да баланы Тәнкәгә тоттырды.

— Әннә! Әннә! — диде бала, яшь хатынның борынынннан эләктереп.

Батыр гына кыланып ул әннәсенең тезенә менеп утырды, ике куллап аның күкрәген тотып алды. Кинәт ул идәндә нидер күреп, көлеп җибәрде, җитез генә кире идәнгә төште дә аннан бер чүп кисәге табып алды.

— Кәкәй, ташла! — диде әннәсе.

— Ы, кәкә? — диде бала, аның күзенә карап, бик нык аптырап.

Тотыш, берни эндәшмичә, аның кыланышларын күзәтеп утырды. Ул эндәшә алмады. Аптыраудан, тан калудан ул соңгы чигенә җитте. Имеш, аның углы бар. Тотыш белән беренче углы. Бөтен ажунда йөзләгән, меңләгән, түбән кешеләр арасында яна бер кеше... ике аяклы, ике куллы, күзле, борынлы чын кеше!

— Без сине икәүләп көттек, әттә! — диде Тәңкә юаш кына, углы булып.

— Ни... ыы... ни атлы? — диде ата кеше.

— Атым минем — Күке! — диде әннә углы өчен.

— Күке? Шундый ямьсез ат кушалармыни?

— Атайга карап куштык,— диде әннә, елмаеп.— Телисең икән, без аңа Куаныч-Бога кушабыз. Мәле, мине тотып кала, әттә! Нинди таза, нинди көчле мин! Белеп тол, әннәне кыелсытма, үскәч мин синең якаңнан алылмын! Алып булыл бу! Куаныч-Бога алып!

Тотыш, баланың берәр җирен имгәтүдән куркып, ипләп кенә, саклапын кына аны кулына алды, тезенә бастырды. Күке —Куаныч-Бога, шыңшып, киреләнеп анасы ягына тартылды. Аның нәни көчен тоеп, аның йомшак тәпиләрен, кулларын тоеп Тотыш көлеп җибәрде. Ныграк ачуландыру өчен ул аны юри күкрәгенә кысты, аның уймактай борынын, алсу колакларын тоткалады. Кәкре аякларын атасының тезенә терәп, бала бар көченә карышты, ачуланып, үртәлеп кычкыра ук башлады.

— Хо-хо! Нинди батыр! — диде ата кеше, кеткелдәп.

— Атаң ич,— дигән булды Тәңкә, углына эндәшеп.— Ул әннәне оныткан, син дә аны оныттыңмы әллә?

— Мин «әннә»не онытмадым,— диде Тотыш.— Әннәсе дә, углы да... уземнеке!

— Тотыш?! — диде Тәңкә, аның күзләренә карап, аның чынмы, юримс әйткәнен белергә тырышып.

— Әйе,— диде Тотыш.— Сүзем сүз: сине дә, углымны да беркайчан да ташламам!

— Тотыш! — диде тагын да Тәңкә, шашынып, куанып.

Бер кулы белән углын, икенче кулы белән ирен кочаклады да, җылыйҗылый, көлә-көлә, алмаш-тилмәш икесен дә үбәргә тотынды.

## XV

Шулай итеп, бер яшьлек тә берничә айлык Күке... Куаныч-Бога беркемгә дә баш бирмәгән кырыс атасын аяк астына салды да куйды. Тотыш белән Болгарга, Аппак янына ашкынган какшамас күңелендә нидер кинәт кителеп төшкәндәй булды. Нык тартылган керештәге укны ул, әйтерсең, кире алды. Йөрәгендә дөрләп янган сөю ялкынын ул, әйтерсең, туны белән каплап куйды.

Кызы белән Тотыш би арасындагы татулашуны белеп, Ямгырчы би күз алдында үзгәрде. Ясалма куанычы, ясалма кунакчыллыгы каядыр юкка чыкты. Кунаклар өчен янадан симез сарыклар суйдырды, базларыннан, чокырларыннан чит илләрдән килгән иң яхшы эчемлекләрен — йөзем суларын чыгартты, көн-төн мунчасын җылы тотты. Өч көн буена кунаклар балда-майда йөзделәр, өч көн буена Тотыш би Тәңкә белән татлы бал эчте.

Дүртенче көнне аның чатырына — Тәңкә югында — Майчан аксакал белән субашы Котан килеп керде. Йокысы туймаган, бите җилсенә башлаган Тотыш би алар кергәндә йомшак урында ята иде.

— Углым, Тотыш би, без сина киңәшкә килдек,— диде Майчан аксакал, сүзгә башлап.

— Нинди киңәш тагын? — диде Тотыш теләмичә генә.

— Кинәш дип... узара сөйләшергә,— диде Котан.— Синең безне тыңлар җаең бардыр ич?
— Сөйләшик,— диде Тотыш, урыныннан торып.
— Тотыш би, углым,— диде Майчан аксакал, өч бөртек сакалын сыйпаштырып.— Безгә нидер эшләргә кирәк.
— Нишләргә? Берни аңламыйм — җүнләп сөйләгез, Майчан аксакал,— диде Тотыш би, күзләрен угалап.
— Без менә үзара кинәштек тә сиңа әйтмәкче булдык,— диде үги ата.— Моннан ары икеле-микеле яту ярамас безгә. Без менә кинәштек тә... Тәңкәдә синең углың бар, атабыз Күрән белән урыны җомахта булсын! — Ямгырчы бигә бирргән сүзе бар. Инде менә уйларың да үзгәрде кебек. Ямгырчы бигә кода булып керик тә, калымны түлик тә, кайтыйк та китик! Алмыш ханга никтер аяк тартмый. Яңа йоланы көчләп тагуы да эчне пошыра. Майчан аксакал әнә яман төшләр дә күргән.
— Шулмы сүзегез? — диде Тотыш би.
— Шул, Тотыш углан... би, — диде Майчан аксакал. — Инде болай-болай булган икән, татулык белән... кхм... элеккеләрне онытып...
— Ярар, — диде Тотыш би, килешкән сыман.—Тәңкә — минем ишем, Куаныч-Бога минем углым. Сүземне әйткәнмен икән, мин аларны алып кайтырмын. Тик минем Аппакка да, Алмыш ханга да биргән сүзем бар! Анам Койтым бикәгә биргән сүзем бар! Әйтегез — нишләргә?
— Алмыш ханга да, Ямгырчы бигә дә түләргә безнең калым житәрлек түгел,— диде үги ата.— Безгә икенең берсен сайларга кала. Без сайладык. Безгә Ямгырчы би белән аның кызы кулай.
— Алай сайларга калгач, миңа Аппак кулай! — диде Тотыш би.— Мин Тәңкәне яратмыйм, мин Аппакны яратам!
Майчан аксакал белән Котан бер-берсенә карашып алдылар.
— Яратасың? — диде Котан.— Нинди ярату ул? Алмыш хан сине алыштырып җибәрмәгәндер ич?
— Алмыш хан алыштырмады, менә монда алыштырдылар,— диде Тотыш би, чыраен сытып.
— Бер дә алыштырмадылар, углым,— диде Майчан аксакал.— Күрән би сине Ямгырчы би кызына өйләндерергә тиешие.
— Юк, иң элек ул мине Биар ханның кызына өйләндермәкче булганые,— диде Тотыш би.— Атам үлгәнгә инде өченче ел. Сез минем сүзгә түгел, үлгән атай сүзенә колак саласыз. Мин — би! Минем үзем яраткан кызга өйләнәсем килә! Йола кушмыймыни? Атам сүзе тотармы? Минем Аппакка, Алмыш ханга биргән сүзем тотса? Үз сүземә үзем баш була белмәгәч, нинди би булырмын соң мин?
— Алай булгач, ник җебеп төштең соң монда? — диде үги ата.— Алмыш ханга биргән сүзеңнән курыккач, Ямгырчы бидә кунак булып ятасы да юк!
— Нинди белекле! — диде Тотыш би.— Төн уртасында Чулманда каекларымны чолгап алырга әллә мин куштыммы Ямгырчы бигә?!
— Тәңкәне алып качарга әллә мин куштыммы?! — диде Котан мыскыл белән.
— Нәрсә? — диде Тотыш би, агарынып.
Котан да бер дә юктан кабынып, шундук коралына ябышты.
— Урыныңнан кузгалып кына кара! — диде Тотыш би әкрен генә, үтемле итеп.— Мин сиңа Тотыш углан түгел, Тотыш би булырмын, атай!
Үги ата, кулын кылычыннан алып, кире чигенде.
— Без сиңа әйттек, Тотыш би,— диде Майчан аксакал, тамагын кыргалап. — Калганын үзеңчә эшлә. Кхм... Бездән ирек.
— Үземчә эшләрмен! — диде Тотыш би.— Иң элек Аппакны алып кайтам, Тәңкә белән углымны — соныннан. Өлгерсәм,— быел, өлгермәсәм — җәрингә.
Шул ук сүзләрне ул Тәңкәгә дә әйтте.

— Син әле дә онытмадыңмыни аны? — диде Тәнкә, арты белән борылып, түшенкә итеп.

— Көн дә җир өстенә чыга торган кояшны онытып буламы? — диде Тотыш.

— Ул, алайса, синең өчен — кояш? — диде Тәңкә, никтер тыныч кына.

— Кояш!

— Мин кем?

— Син... син — ай!

— Минем сиңа ай буласым килми,— диде Тәнкә шул ук салкын тынычлык белән.— Минем сиңа кояш кебек буласым килә!

— Күктә ике кояш булмый,— диде Тотыш, көлеп.

— Әйе, күктә бер генә кояш була. Я ул, я мин. Башкача була алмый.

— Була! — диде Тотыш, ачынып.— Ничек аңламыйсың — мин аны гына...

— Ха-ха! — диде Тәнкә, атасы кебек шаркылдап.— Аңламыйсың! Ха-ха! Ничек аңламыйсың — мин сине генә... яратам! Сине генә. Синең бары үземнеке генә булуын телим.

— Алай булмый,— диде Тотыш, ыңгырашып.

Тәңкә торды, иңбашларын селкеткәләп, алтын-көмеш чулпыларын чылтыратып өйдән чыгып китте. Шул китүдән ул бүтән килмәде. Тотыш би, беркая чыкмыйча, беркемне күрмичә, төне буе, көне буе үз тирмәсендә аунап ятты. Икенче көнне кич, караңгы төшкәч, аны Ямгырчы би янына чакырдылар.

## XVI

«Үгетләмәкче була микәнни?» дип уйлады Тотыш Ямгырчы би турында. Алдан ук ул аның белән буласы сөйләшүен күз алдына китерде. Кунак булып яткан дүрт-биш көн эчендә ул инде казаяк ыруы башы белән үзе арасында булган элекке ызгышларны, сугышларны — барысын да онытып өлгергән иде. Соңгы көннәрдә аның уенда бары тик ул үзе дә, Тәңкә белән углы гына иде. Аныңча, ата кеше — Ямгырчы би — кияү кешене якларга тиеш иде. Тәнкәне генә яратамы, Аппакны да яратамы аның кияве — аның өчен барыбер булырга тиеш кебек иде. Тик Тәнкәнең атасы бөтенләй ул уйлаганча булып чыкмады.

— Ха-ха! — дип кычкырды ул, Тотышны күрү белән.— Бу синмени әле, Тотыш би? Бик сагынып көттем мин сине, ике ел буена көттем шушы очрашуны. Кызым Тәнкә кебек саргаеп көттем, Тотыш алып. Син инде тынычландыңмы, онытты бу барысын да дип уйладыңмы? Онытмыйча! Шундый олылап каршыладылар, көне-төне сыйладылар. Җитмәсә күңел ачарга дип, Ямгырчы би аңа үзенең кызын биреп торды. Үз кызын, үзеннән туган бердәнбер кызын биреп торды! Ха-ха! Алмыш ханга калан илтә баручы чибәр егетнең күңеле кырылмасын, каны бозылмасын... Шулай булмыйча, гүзәл Аппакны алырга бара ла ул!

— Туктале, би,— диде Тотыш мыгырданып, кашларын җыерып.

— Туктарга?! — дип кычкырды Ямгырчы би, төкрекләрен чәчеп, булмә буенча әрле-бирле йөренеп.— Мин инде күп тукталып тордым. Яз көне мин синең кайчан узып китәсеңне яхшы белдем, шулай да тукталып калдым. Калым белән, байлык белән төшүеңне көттем. Инде менә монысында алдандым, эләктереп алдым. Шулай да әле утлы табада кыздырып ашамадым — тукталып калдым. Кызымның сүзен тыңладым. Аның өчен түздем. Бары аның өчен генә! Инде түземлегем төкәнде. Кызым миңа барысын да сөйләде. Кызым минем кулларымны чиште. Ха-ха! Тотыш алып! Кияү! Телим икән — кыздырып ашыйм, телим икән, итеңне каклап куям, телим икән — балыкларга, кош-кортларга җим итеп сибәм!

— Син шашкансың, би,— диде Тотыш, ачусыз күренергә тырышып.

— Ха-ха! — диде Ямгырчы би, йодрыкларын селтәп.— Шашмый торсын! Син әллә чынлап та үзеңне Алмыш ханга җибәрерләр дип уйлый-

сыңмы? Аппакны... минә булырга тиеш булган Аппакны алып кайтырмын дип уйлыйсыңмы?! Юк, булмас! Юл ябык. Синең антыңны бозганыңны онытканнардыр дип уйлыйсыңмы?

— Син үзең боздың, би! — диде Тотыш би, кылычына тотынып.—

— ...Казаякларны чебеш урынына кырганыңны онытканнардыр дип уйлыйсыңмы?! — дип кычкырды Ямгырчы би, аның сүзләрен ишетмичә.— Алар барысы да менә монда — йөрәк түрендә! Кызымны инде мин әйтмим дә. Моңарчы сине ул яклап килде. Инде син аның табанын ялап ярлыкау үтенсәң дә, сине якларга аның да көченнән килмәячәк. Ул соңгы сүзен әйтте. Сине этләр җыячак, Көчек би!

Тотыш белән Ямгырчы би арасында өч-дүрт адымлык буш урын бар иде. Шул өч-дүрт адымлык буш урында, уртада, кып-кызыл булып, дүрткел палас җәелеп ята. Ямгырчы би авызыннан утлар чәчеп тузынганда Тотыш ничек тә аннан читтәрәк булырга тырышты. Аннары уртадагы әлеге палас та ике араны бүлеп тора шикелле тоелды. Ямгырчы бинең мыскыллы янаулары соңгы чиккә җиткәч, Тотыш түзмәде, кылычын суырып чыгарды да...

— Ха-ха! — дип шаркылдады явыз би, баш очындагы ниндидер җепкә үрелеп.

Тотыш аның шул соңгы «ха-ха»сын гына ишетте дә, коточкыч булып кыйшайган усал йөзен, акайган күзләрен генә күреп калды. Аяк астындагы палас кинәт убылып китте. Ямгырчы бигә җитәргә бер адым чамасы калды дигәндә, кылычын күтәргән Тотыш каядыр аска, караңгыга ычкынды. Кинәт ачылып киткән баз капкачы шундук кире ябылды. Яктылык сүнде. Ул, әйтерсең, мәңгегә, бөтенләйгә юкка чыкты.

Караңгы, юеш базда күпме ятканлыгын ул үзе дә, башкалар да белмәделәр.

Тотыш бинең үз тирмәсендә юклыгын белеп, акбүреләр пошына башладылар. Алар, катау иясе янына барып, аңа шул турыда сөйләмәкче булдылар. Алар теләкләрен үти алмадылар,— Ямгырчы би кешеләре килеп, берни әйтмичә, аларның коралларын җыеп алдылар, тирмәдән беркая чыкмаска боерып, китеп тә бардылар. Ямгырчы би шулай ук яр астындагы акбүреләрне дә коралсызландырды, каекларны, кешеләрне сак астына алды. Бинең мондый яманлыгын акбүреләр ничек дип аңларга да белмәделәр. Алар шауладылар, янадылар, соңыннан ялына башладылар.

— Ха-ха! — диде Ямгырчы би.

Шулай итеп, каптылар... тәбегә капкан сычканнар кебек каптылар!

## XVII

Каптылар... Шулай да Тәнкә бернинди ямь, кызык тапмады. Эче пошып, Күкесен күтәреп ул койма өстенә менде, Чулманга карап тора башлады. Ул аны менә шулай көтте. Көн дә таң ату белән, баласын кочты да, койма өстендәге үзенең җайлы урынына менеп утырды. Үзенең Күкесенә ул башта «әттә» сүзен өйрәтте, аннары «әттә»нең кем булуы турында сөйләде, аның батырлыгын, матурлыгын мактады. Шулай сөйләнгән, юанган арада ул әледән-әле су өстенә карап алды.

Элек әле ышаныч бар иде. Менә-менә еракта караеп зур, ят каек күренер дә, зур-зур атлап, каектан елмаеп «әттә» чыгар төсле иде, биек коймага үрелеп, үзенең улын, нәни Күкесен тотып алыр төсле иде. Күз алдына татлы күренешләр килә иде, күңел, очар коштай, канат җилпи иде.

Инде алар барысы да юкка чыкты. Чулман өстендә ят каек та күренмәячәк, аннан зур-зур атлап батыр «әттә» дә чыкмаячак... Аның бик нык эче пошты. Үз-үзенә урын таба алмыйча ул өенә кайтып китте. Өендә дә аны салкын бушлык, эч пошу, сыкрау каршы алды. Аңа тик нәни углы гына, углының йөрәк җылысын, тынын, күз карашын тоюы гына күпмедер

тереклек көчө бирен торды. «Әттә? Әттә?» диде бала, кечкенә кулы белән әннәсенең борынынннан тотып. Яшь ананың күзләреннән чишмә булып яшьләр акты.

Ике тәүлек буена ул шулай үз-үзе белән, үзенең теләкләре, тойгылары белән тарткалашты. Ике төн буена ул йокы күрмәде, ике көн буена тынгы белмәде. Өченче көнне барысы да баш-аяк килде. Ул үзенең янында гына булган, шундый көтеп алынган, сагынып алынган иреннән аерым яши алмаганлыгын аңлады. Ул, барысын артка ташлап, эченә йотып, караңгы төшү белән иренең ялгыз тирмәсенә китте.

Тирмә буш иде. Ул аны көтеп торды. Тотыш кайтмады. Шунда ул барысын да аңлап алды. Кызып китеп, атасына әләкләгәндә ул аны аз гына да кызганмаган иде. Инде аның юклыгын... аның юкка чыгуын күргәч, ул куркудан шашар чиккә җитте. Ул коелды да төште. Ул буш, куркыныч тирмәдән шундук чыгып китте, үзе ышанычлы кешеләрен эзләп тапты. Алар ана барысын да төкми-чәчми сөйләп бирделәр. Кинәт аның йөрәге бөтенләй икенче төрле тибә башлады, буталган, суынган каны бөтенләй икенче юнәлештә ага башлады. Үзендә ул искиткеч җиңеллек, күңел аеклыгы, күңел бөеклеге тойды. Бөтенесен ул ап-ачык итеп күз алдына китерде, бөтенесен җентекләп уйлап карады. Тирән баз ишегенең ачкычы атасының тимерле тартмасында саклана иде. Тартма үзе бинен йокы бүлмәсендә ишерен ояга утыртып куелган. Кирәкле ачкычны алу өчен ин әлек ишек төбендәге сакчылар янынан узарга, аннары ата кешенең йоклаган җиренә керергә, аның мендәр астыннан озын бауга бәйләнгән кечкенә тимер ачкычны алырга кирәк. Бу теге җомакларда[1] сөйләнелә торган алтын ачкыч эзләү кебегрәк иде. Җомакта ул җиңел эшләнелә. Менә монда нишләргә? Сакчыларны инде алдарга да, сатып алырга да булыр. Үз атанны, атаң янындагы үги ананнымы... карабашнымы... нишләтергә? Үтерергә? Бәйләп ташларга? Алдарга? Ничек итеп?!

Ул әлегә берни уйлап таба алмады. Шулай да ул башта өенә кайтып, үзенең барлык алтын-көмешләрен калтасына тутырды да, тиз генә атасы өенә килде. Берни әйтмичә, аңлатып тормыйча, ул тышкы ишек төбендәге сакчыга бер уч көмеш ярмаклар бирде. Өлкән яшьләрдәге сакчы учын күзенә якынрак китерде, көмеш ярмакларны күреп: «о-у!» диде. Күзләрен елтыратып, Тәңкәдән:

— Ни йомыш, углан? — дип сорады.

Тәңкә ана яшермичә әйтеп бирде. Сакчы, сыңар күзен кысып, бик нык уйлангандай итеп, куккә, йолдызларга карады.

— Би бүген үзе генә йоклый,— диде ул бераздан.— Аны үтерү берни түгел. Кызгансаң, йокы уты исңәтергә була. Миндә бар.

— Шулаймы?!

— Синең өчен берни кызганыч түгел, углан... кызым,— диде сакчы тыныч кына.— Иң яманы шул — минем яннан ничек үтәргә сиңа? Монысы — иң кыены. Калганы чүп кенә. Син мине бәйли алмыйсың — көчең җитмәс. Үтерергә кинәш итмим. Сиңа берәр таза ир кеше табарга кирәк. Минем кулларымны-аякларымны бәйләргә дә, авызга чүпрәк тыгарга да... кара аны, борынны томалый күрмәгез! Бүлмә янындагы сакчыны да шулай итәрсез. Миңа тагын бер уч бир дә, углан... кызым, бераз көтеп тор. Ул ярмакларны берәр җиргә яшерәсе дә бар әле — бик кыен эш шул ул, кызым.

— Кемне табарга? Кемгә әйтергә? — диде Тәңкә, үз-үзе белән сөйләнгән сыман.— Үзебезнең кешеләргә ярамый. Кунаклар янына барырга туры килә.

— Алар сак астында,— диде сакчы, күңеле сүрелеп.— Кемне үтерергә соң анда? Ай-хай, бик кыен эш шул бу, углан. Яр астында ничек икән? Анда да сак! Булмаса, син миңа тагын бераз арттыр да, кызым, мин тиз

[1] Җомак — әкият.

генә аска төшеп, андагы үзебезнекеләр белән сөйләшеп, берәр тазарагын алып меним. Шунсыз булмый. Мондагылардан булмас — барысы да карткоры. Аннары,— диде ул, пышылдауга күчеп,— болары... кодалар... берсе би янына килеп йөрде. Аларга ышаныч юк. Син монда торып тор. Мин тиз генә килермен.

Күпмедер авыктан сон карангыдан ике карачкы килеп чыкты. Аларның берсе әлеге өлкән яшьләрдәге ишек сакчысы, икенчесе Торымтай иде.

## XVIII

Торымтай аны инбашына күтәрде. Ул бик авыр иде. Тәнкә, Торымтайның сыгылып төшүен күреп, аңа булышмакчы булды.

— Үзем... әйдә, тизрәк! — диде Торымтай, пышылдап.

Алар карангы, тар баскычтан өскә үрмәли башладылар. Төшкәндә дә бик озын тоелган баскыч менгәндә тагын да озынрак тоелды.

Менә алар тар ишек авызына килеп җиттеләр, кысылыштырып тышкы якка чыктылар. Тышта инде баздагы кебек үк карангы түгел иде. Торымтай иплап кенә Тотышны аягына бастырды, ике куллап тотып торган килеш, аның йөзенә карады, ничек тын алуын тыңлап торды.

— Исән! — диде ул, куанып.

— Исән, исән! — диде Тәнкә дә үкси-үкси.— Әйдә тизрәк, Торымтай! Исән!

«Тәнкә! — дип уйлады әкренләп аңына килә барган Тотыш, колак төбендә генә аның тавышын ишетеп.— Сөеклем Тәнкә! Беркайчан да онытмам изгелегеңне, беркайчан да ташламам сине!»

Аның күзенә яшьләр килде, тик шулай да ул җылый алмады — аны яңадан Торымтай күтәреп алды. Алар яңадан кузгалып киттеләр. Кая киттеләр алар? Тотыш берни аңламады. Аңа алар тагын да ниндидер тар, текә баскычтан төшәләр шикелле тоелды.

Әйе, алар чыннан да тар баскычтан төшеп баралар иде. Монысы инде Ямгырчы бинең өй асты базыннан менә торган баскыч түгел, монысы катаудан туры яр буена чыга торган яшерен юл иде.

Көтмәгәндә алда тагын көчсез яктылык күренде, салкынча су исе — таза, җиңел ис килеп бәрелде. Алар өчәүләшеп тагын җир өстенә — Чулман яры буена килеп чыктылар, туктап калдылар. Тотыш, үзенең кайдалыгын аңлап, күзләрен зуррак ачты, бер кулы белән Торымтайга, икенче кулы белән Тәнкәгә тотынган көе, аяклары белән каты җирне тойды.

— Менә без иректә! — диде Торымтай, җиңел сулап.

— Ирektә! — диде Тотыш, ыңгырашып.

— Ашыгырга кирәк! — диде Тәнкә.— Атам йокыдан уянганчы, сезгә тизрәк кузгалып китәргә кирәк. Сакчыларның барысы да бәйләнгән. Аларга тимәгез. Инде урдада калган кешеләрегезне коткарырга да, коралларыгызны алырга кирәк. Алмасагыз да була, сакчыларныкын алыгыз да... Торымтай, син аны үз каегыңа кертеп яткыр,— диде ул, кем турында сүз барганлыгын аңлатып, Тотыш ягына ымлап.— Мин өскә менәм, сезнекеләрне алып төшәм.

— Мин дә синең белән барам, үзең генә булдыра алмассың,— диде Торымтай.

— Юк, синен белән булдыра алмам,— диде Тәнкә кырт кисеп.— Бар...ыгыз, тизрәк булыгыз.

Ул, кирәгеннән артык ашыгып, кабаланып, яңадан яшерен юл авызына кереп юк булды. Торымтай, Тотышны инбашына салып, ниндидер чытыр-чатыр арасыннан, ниндидер кәҗә сукмагыннан иплап кенә, сакланып кына су янына ук төште.

Яр буенда анда-санда бәйләп ташланган казаяклар күренде. Йокыларыннан уятылган, боерык булу белән кузгалып китәргә генә торган

акбүреләр Тотыш белән Торымтайны куанычлы гүелдәп каршы алдылар. Тотыш би, үз кешеләрен, каекларын күреп, ыңгырашып аягына басты.

Аны яр буенда калдырып, Торымтай берничә ир белән тиз генә җир тишегенә таба йөгерде. Күп тә үтмәде, ташлы тар сукмактан бер-бер артлы тезелеп төшеп килгән кешеләр — акбүреләр күренде. Алар, агач ботакларына тотынгалап, яр астына төштеләр, каеклары янына килделәр.

Тотыш би, яр читендә басып торган килеш, үзенең тозактан котылган юлдашларын күздән кичерде. Аларның барысының да исән-сау икәнлеген күреп, ул каекларга утырырга, кузгала торырга боерды.

Каеклар бер-бер артлы китә башладылар. Бераздан яр буенда акбүреләрнең ике-өч каегы гына торып калды. Андагылар Тотыш биненң утыруын көттеләр. Би исә Торымтай белән киткән ирләрне, алардан да бигрәк — Тәңкәне көтте.

Менә алар, чыбык-чабык күтәргән сыман, корал күтәреп, җир тишегеннән килеп чыктылар.

Кораллар төялде, кешеләр урнашып беттеләр. Ташлы ярда Тотыш би генә торып калды. Ул Тәңкә белән саубуллашырга, я булмаса аны үзе белән алып китәргә тиеш иде.

Бәйләп ташланган ырудашлары арасында нидер эшләп булашкан Тәңкә, Тотышның көтеп торуын күреп, башын калкытты, әкрен генә аңа таба килә башлады. Анда әлерәк кенә күзгә бәрелеп торган ашыгу-кабалану да, бизгәк тоткандагы сыман ялкынланып яну да юк иде. Бит алмалары бушанып, сулыгып калган. Йөзендә, күз карашында, үз-үзен тотышында моңарчы булмаган бер нәрсә — читләшүме, салкынлыкмы бөркелеп тора. Андагы бу салкынлык, андагы ныклык Тотышны өркетеп җибәрде. Ул, аның күзләренә туры карый алмыйча, башын түбән иде.

Тәңкә аңа якын ук килеп басты, шул ук өркеткеч бер караш белән, тавыш-тынсыз гына аңа карап тора башлады. Тотыш та сүзсез генә аңа күз ташлап алды. Аларга исә каеклардан ишкәкчеләр карады, җирдәге бәйләп ташланган казаяклар карады.

Тотыш, ике кулын күтәреп, иплән кенә аның беләкләреннән тотып алмакчы булды.

— Юк! — диде Тәңкә, кулларын кискен генә тартып алып.— Бар, кит. Син иркле.

Тотыш би авыр гына көрсенеп куйды.

— Мин килермен. Көт,— диде ул иплән кенә, йомшак кына.— Углымны сакла.

— Ак юл сиңа, Тотыш би,— диде Тәңкә.

— Мин барыбер килермен,— диде Тотыш, юатыр өчен башка бер сүз дә тапмыйча.

— Синнән башка минем беркемем юк,— диде Тәңкә.— Углым да син, син дә углым.

— Ачуланма миңа, Бай бул, сау бул,— диде Тотыш би.

— Житте! Кит, кит! — дип кычкырды кинәт Тәңкә, йөрәк түреннән чыккан бер ачыну белән.

Аның бу чатнап-кителеп чыккан йөрәк өзгеч тавышы Тотышны әллә нишләтеп җибәрде. Аны кызгану тойгысы биләп алды. Ул тагын аңа таба тартылып куйды. Ул аны кочмакчы, юатмакчы булды: Тәңкә, куркып, шашынып, артка чигенде. Шул ук мәлдә ул кәзлек тартып чыгарды. Тотыш би ап-ак булды. Ул, күрәсең, миңа кадый, дип уйлады. Тәңкәнең нык кысылган ирен читендә мыскыллы елмаю чагылып китте. Ул, кәзлек сабын Тотышка сузып:

— Соңгы үтенечем: када миңа, Тотыш! — диде ярым пышылдап.

Тотышның үзеннән-үзе сузылган кулы кире тартылды. Кәзлек [1] төшеп китте. Тәңкә Тотыштан да ныграк агарынып китте.

---

[1] Кәзлек — хатын-кыз хәнҗәре.

— Куркак! — диде ул, җирәнеп.

Ышану буенча, очлы тимерне кулдан төшереп җибәрү яманга юрала иде. Тәнкә кәзлеген алып тормады, кара җылан күргән кебек коты алынып, читкә сикерде, йөгерә башлады.

— Тотыш, тизрәк, тизрәк! — дип кычкырды Торымтай каектан.

## XIX

«Шушы микәнни инде аерылышу?» дип уйлады Тотыш, авыр, кыен бер тойгы кичереп. Ул Тәнкә җинел генә, кыр кәҗәсе кебек кенә йөгергәләп менеп киткән текә яр башына шактый озак карап барды. Ул анда беркемне дә күрә алмады. «Кыр кәҗәсе» әллә шунда куе куаклар арасында яшеренеп калды, әллә шулай тиз арада өскә менеп, өенә кайтып китте.

Әле генә алар янәшә басып торган яр чите, киң күпер, җирдә аунап яткан сакчылар — барысы да артта кала барды. Куркытылган-өркетелгән ишкәкчеләр, котылуларына чиксез сөенеп, аякларын нык терәп иштеләр дә иштеләр.

— Кызурак, кызурак! — диде әледән-әле каек башы, ишкәкчеләрне ашыктырып.

Би утырган каек алданрак кузгалган каекларны куып житәргә, алга чыгарга тиеш иде. Шулай кызулап бара торгач, чыннан да алар куып та життеләр, узып та киттеләр. Агым уңаена каеклар бик шәп бардылар. Арттан куа чыкканчы, ничек тә бу куркыныч төштән узып китәргә кирәк иде.

Шулай ашыгып, кызулап барганда, ишкәкчеләр ярда нindидер нәрсә күреп алдылар. Тотыш та алар караган якка әйләнеп карады. Текә яр читенә чыгып торган таш кисәгендә, ниндидер кеше сыман карачкы күреп ул тынсыз калды. Шундый куркыныч ташта, шундый тирән упкын өстендә басып торырга ничек йөрәге житә аның?! Таш ычкынып китсә, кителеп төшсә? Я булмаса башы әйләнеп...

Туктале, кем соң бу? Тәңкә... түгелме соң?!

— То-ты-ы-ыш! — дип кычкырды шул чакны күк читендә басып торган кеше.

Тотыш аягына басты, ике кулын авызына куеп:

— Тәңкә-әәә! — дип кычкырды.

— То-ты-ы-ыш! — дип кычкырды тагын кыя өстендәге Тәнкә, Чулман өстен яңгыратып.

Каектагы кешеләр, тын алырга да куркып, текә ярга карап бардылар. Кешеләр генә түгел, киң Чулман да, исе китеп, тып-тын калды. Каралҗым яр буйлары, биек наратлар, су өстендә очкан акчарлаклар, кәрәшәләр — барысы да пошынып, борчылып, упкын кырыена барып баскан тынгысыз йөрәкне күзәттеләр. Ник баскан ул анда куркыныч таш өстенә, ник шулай йөрәк өзгеч итеп кычкыра ул каектагы кешеләргә? Күпне күргән чал үзән дә, биек наратлар да, кыялар да берни аңлый алмадылар. Ах, ник баскан ул анда?!

Кулларын бутап, тун чабуларын җилфердәтеп, ул суга баш түбән сикергәч, бөтен җирнең-күкнең асты өскә килде. Чулман туктады, кәрәшәләр, акчарлаклар күктә оча алмыйча катып калдылар. Биек наратлар, кара ярлар, киресенчә, суга иелделәр шикелле. Ах,ниләр булды аңа, ни булды?! Таш сындымы, җил өрдеме, әллә юкса су тарттымы аны? Ник төште ул шундый биектән?!

Адәм баласының егылуын күрмәс өчен, кәрәшәләр, акчарлаклар куркып читкә ташландылар; кайгысыннан Чулман кара янып чыкты, сызланып, сыкравып колак төбеннән салкын җил исеп үтте.

Бу ничектер төштә күргән кебек кенә булды. Шулай да бу өндә — барысының күз алдында булды. Куллардан ишкәкләр төште, йөрәкләр, атылып чыгардай булып, бушлыктагы кешегә омтылды. Барысы да,

авызларын ачып, тораташтай каттылар да калдылар. Монда инде карап торудан башка берни эшләп булмый иде.

Шулай да Торымтай исенә килә алды. Күз ачып йомганчы ул, өстендәге авыр туның салып, суга ташланды.

Тәнкә, күрәсең, Тотыш каегына чамалап сикерде. Баш каектан ул бераз гына алгарак, уң яккарак килеп төште.

...Өстеннән су аккан, төсе качкан, күзләре йомылган ярым үлек Тәнкәне Торымтай белән бер-ике ишкәкче каекка менгерделәр.

— Су эчкән! Суын чыгарырга кирәк! — диде каек башы.

Бер ишкәкче Тәнкәне аягыннан югары күтәрде, бер-икесе аның инбашыннан, башыннан тотып торды. Торымтай иләп кенә аның кулларын кыймылдатты. Чулман төбеннән, үлем тырнагыннан тартып алынган Тәнкәнең бераздан тын алганы ишетелде.

— Тәнрем, ярлыка,— диде каек башы, ике кулын күккә күтәреп.— Ул суга ялгыш егылып төште. Ул үзе сикермәде, үзе сикермәде... Без күреп тордык — аның аягы ычкынып китте. Үзең ярлыка, тәнрем!

Әле генә үлгән кебек күренгән кешенең терелүен күреп ул, куркып, шундук читкә китеп барды. Шулай ук яшь ишкәкчеләр дә тизрәк үз урыннарына утырырга ашыктылар. Тәнкә янында Тотыш белән Торымтай гына торып калды. Салкын тимәсен өчен алар аны тунга төрделәр дә, авызын ачып, ачы бал эчерделәр. Тәнкә күзләрен бераздан гына ачты да, янадан йомды. Ул, ахрысы, йокыга китте. Аның тын алуы тигез иде.

Тотыш би, Торымтайның җиңеннән тотып, аны каядыр читкә әйдәде.

— Карале, юлдаш,— диде ул аңа, пышылдап.— Минем сиңа бер үтенечем бар. Аны мин үзем белән алып бара алмыйм,— диде ул, Тәнкә ягына ымлап.— Әнә анда яр буенда ниндидер кыыш күренә. Бу әле Ямгырчы би җире булырга тиеш. Син аның белән шунда калмассынмы? Суга төшкәнен әйтмә, чирләде, бизгәк тота, диген, өстенә салкын су койдык, диген. Савыккач атасына илтеп куй. Я булмаса минем кире борылып кайтканны көтеп торыгыз. Юк, ул алай теләмәс. Савыккач үзе әйтер тагын. Мин кайтканда Алмыш ханнан көчле алай[1] сораячакмын, юкса безне Шуранда тагын кунак итүләре бар. Шунда мин сезне дә алып китәрмен... җайларбыз әле!

— Тотыш! — диде Торымтай, дулкынланып.— Синең изгелегең аркасында мин янадан үземне кеше итеп сизәм. Син миңа ирек бирдең. Үлгәнче сиңа турылыклы булырга мин үз-үземә сүз бирдем. Кайгырма, барысы да син дигәнчә булыр. Без сине көтәрбез!

— Кара аны: сакла! Алай-болай тагын үзенә үзе кул сала күрмәсен! Углымны ятим калдырса, мәңге кичермәм. Шулай дип әйтте диген!

— Тыныч бул, теләгең үтәлер,— диде Торымтай.

Тотыш би нык итеп аның кулын кысты.

Ярдагы куыш турысына җиткәч, баш каек ярга якын килде, туктады. Торымтай, тунга, киезгә төрелгән Тәнкәне күтәреп, ярга төште. Тотыш би үзенең ышанычлы юлдашына ике уч көмеш акча бирде, ашарларына берике көнлек азык-төлек калдырды.

— Тыныч бул, Тотыш, теләгең үтәлер,— диде Торымтай кабатлап, кул болгап.

## Алтынчы бүлек

### I

Төштән соң каеклар Этилгә килеп керделәр. Кызгылт-болганчык сулы Чулман, ургылып, усалланып, бераз җир үзенчә әз салып барды да, үзеннән икеләтә диярлек киңрәк, көчлерәк Этилгә кушылып, мәңге юкка

---

[1] Алай — гаскәри төркем, отряд.

чыкты. Ярлар үзгәрде, ерагайды. Яр өстендә калкып утырган авыллар, ялгыз өйләр, тирмәләр — барысы да кеп-кечкенә булып күренделәр.

Тотыш, су буенда үссә дә, моннан ике ел элек, беренче тапкыр Әтилне күргәч, уэалдына җәелеп яткан шундый күп суга, шундый зур киңлеккә чын-чынлап таң калган иде. Менә әле дә ул, озак кына аны күрми торгач, үзендә искиткеч бер күтәренкелек тойгысы калка барганлыгын сизде. Ямьсез, күңелсез нәрсәләр онытылды. Бөек көчкә, тере, серле көчкә табыну тойгысы көчәйгәннән-көчәя барды. Очарга җыенган кош сыман ул кулларын күтәрде, аннары иелеп су төбенә карады.

— Олуг Әтил! — диде Тотыш би, туган җиренең бөек үзәненә эндәшеп.— Исән-имин илтеп тапшыр мине сөйгәнемә! Юлымда ак җәймә бул, изге Әтил! Мин, Тотыш би, синең биләмәңә кердем, синең тигез юлыңнан барам. Ачуланма миңа, усалланма, каекларымны каплама, кешеләремне суырма. Менә сиңа калан итеп көмеш йөзегемне бирәм, уналты бөртек көмеш ярмак бирәм, гүзәл Әтил!

Сул кулындагы йөзеген салып ул суга ташлады. Көмештәй су чынлап китте, көмеш йөзек, бөтерелеп, ялт-йолт килеп, төпкә чумды. Шуннан соң Тотыш би санап, берәмтекләп көмеш акчалар ташлады. Әтилгә калан түләнгәч, кешеләр бауга бәйләп чиләк төшерделәр, су алдылар. Әтил суы белән битләрен, кулларын юдылар.

Көн кичегеп барганда, еракта, калкулык өстендә, Болгар-тораның очлы мәчет сырганнары, каргулары, биек койма эчендә бер-берсенә сыенып утырган өй түбәләре караеп күренде.

Болгарга, үзенең сөеклесенә якыная барган саен, Тотыш бине капма-каршы уйлар, теләкләр биләп алды. Аның күз алдына әле күңелле, гүзәл күренешләр килде, әле куаныч күгендә кара болытлар кабарып чыкты да, күңел кылларынниндидер курку-өркүләр тынгысызлый башлады. Ниләр көтә икән инде аны анда? Илләр тыныч микән? Ике айда киләм дип киткән кешенең сонга калуына үпкәләп ятмыйлар микән?

Менә алар кояш баер алдыннан Ага-базарга да килеп җиттеләр. Төн ягыннан яңа каеклар килеп туктавын күреп, кунакларны каршыларга базар башы Бигеш килеп җитте — монда аларны, күрәсең, ерактан ук күтеп торганнар иде. Тотыш би, басмадан төшеп, туры аның янына атлады, күптәнге танышы белән исәнләшкән кебек, аңа елмаеп баш иде.

— Илдә иминлекме, базар башы? — диде.

— Иминлек,— диде Бигеш.

Ул моны ничектер теләр-теләмәс кенә әйткән шикелле күренде. Шулай да Тотышка берьюлы җиңел булып китте. Күкрәген кысып, тынгысызлап торган билгесезлек, өркү тойгысы юкка чыкты. Иминлек булгач, башкасы турында инде борчылып та торасы юк. Бигешкә ул бүләк итеп бер тәпән яңа бал бирде, бер тунлык иләнгән тире, хатынына дип пыяла муенса бирде. Бары шуннан соң гына базар башының симез, шадра йөзендә ягымлылык чаткылары күренә башлады. Алай гына да түгел, ерактан килгән юлчыларга кунакчыллык күрсәтеп ул бераз гына кабаланып та алды: каекларның кайсын кая туктатырга, ярга чыгарылган капчыкларны, төргәкләрне кайда, ничек урнаштырырга кирәклеген әйтте, Акбүре аксакаллары белән исәнләшкәндәй итенеп, баш та иеп алды.

— Кунак өендә буш урын бармы? — диде Тотыш би.

— Синең өчен табарбыз,— диде Бигеш, шадра төрткеләр арасында күмелеп калган кечкенә күзләрен елтыратып.— Миндә кеше күп, шулай да сезнең өчен табарбыз, Тотыш алып...

— Тотыш би,— диде кунак, төзәтеп.

— Тотыш би?! — диде Бигеш, тычкан күзләрен чекрәйтеп.— У-у, болай булгач, җир тишегеннән булса да табарбыз. Баш өсте, Тотыш би!

Акбүреләргә, билгеле, буш җирдә урда корырга да булыр иде. Тик Тотышның алай итәсе килмәде: би кешегә, кияү буласы кешегә, теләсә

чинди сатучы кебек, ярлы-ябагай кебек, кая туры килә шунда тирмә кору килешми иде.

Бигеш тиз арада юлчыларга иярле атлар китертте. Иярле атлар белән бергә жигүле атлар да килде. Арбаларга капчыкларны, төргәкләрне, тәпәннәрне төяделәр. Каеклар янында тиешле каравыл калдырылды. Шуннан соң акбүреләр, берләсе атны житәкләп, югары күтәрелгән байраклар белән, төркемләшеп, ашыкмыйча гына Бигеш өенә таба кузгалып киттеләр.

Ике ягында да тәбәнәк өйләр, куышлар, кием тирмәләр утырган тар гына аралыкны үтеп, алар киң языга — төп базарга килеп керделәр. Базар әле бетмәгән иде. Шулай да кибетләрнең күбесе ябык, анда-монда гына төркемләшеп торган, үзара нидер кызып сөйләшкән, сатулашкан кешеләр күренә иде.

Базар кешеләре Тотыш бине ерактан ук күреп алдылар. Тавар сатулашучылар сату-алудан туктадылар, болай гына сөйләшеп торучылар сүзләреннән бүленеп калдылар — барысы да, кызыксынып, йончылган, шулай да күтәренке күнелле юлчыларга карап тора башлады, үзара пышылдап:

— Тотыш килгән!

— Кодалар белән!

— Кыз алырга килә! — диделәр.

Акбүреләр узып киткәч, пышылдаудан кычкырып сөйләүгә күчтеләр, аз гына да тартынмыйча, арттан төртеп күрсәтә-күрсәтә:

— Әнә шул инде Тотыш алып!

— Кияү булып килә.

— Сонгарак калган шул! — диештеләр.

Үзе турында әйтелгән сүзләрнең барысын да Тотыш ишетә алмады. Ул, кияү буласы кеше буларак, эре генә, кукыраеп кына, иярендә төз генә утырып барды. Шулай да базар кешеләренең арттан чыш-пыш килүе, тыелып көлгән сыман тавышлары аның эчен борып-борып алды. Нидер булган монда. Яхшыга гына булса ярар иде инде!

Байраклы ир-атлар төркеме, базар янынннан үтеп, янадан тар тыкрыклар арасыннан бардылар-бардылар да, урман буендагы, калкулык өстендәге зур гына капка алдында туктап калдылар. Монда базар башы Бигешнең утары урнашкан иде.

Базар башының торган жире бер дә хан урдасыннан ким түгел. Якында гына биек наратлар шаулап утырган тәбәнәк калкулык әллә каян-кая биек коймa белән уратып алынган. Зур, авыр капка янында кораллы сакчылар тора. Капкага илтә торган тар юлга таш түшәлгән, капка алдына тирән үр аша күтәрмәле күпер салынган.

Иркен ишегалда, калкулык өстендә Бигешнең эре наратлардан буралган биек өе калкып утыра. Калкулык астында кечерәк өйләр, каралтыкуралар, абзарлар тезелеп киткән. Тагын да арырак, Әтил буе болыннары ягына табарак, төркем-төркем булып утырган ак чатырлар, тирмәләр күренә. Ул төркем-төркем чатырларда, тирмәләрдә төрле жирдән килгән сатучылар яши. Базар башы Бигешнең бу «кунак өе» үзе бер авыл кебек. Монда кечкенә урамнар да, тыкрыклар да бар иде, чыр-чу килгән бала-чагалар да, үз тирмәләре, үз каралтылары тирәсендә үзләренең көндәлек эшләре белән булашкан — аш пешергән, кер юган, бала имезгән хатын-кызлар да, жыйнаулашып үзара сөйләшеп торган ирләр дә бар. Шулай ук монда көч сынашып, шаулашкан яшьләр дә күренә. Өйләр арасында, урамда, юлда кояшта янган синдләр дә, озын буйлы кара гарәпләр дә, зур борынлы әрмәннәр дә, тажиклар, румнар да бар. Болар барысы да Бигешнең кунаклары иде. Ул аларның товарларын саклый, үзләрен саклый, шуның өчен алардан акча ала, шуның өчен аларның табышына көтү-көтү сарык, жылкы кайтарта. Базар башы Бигеш бөтен Болгар йортта иң бай кешеләрнең берсе санала иде.

Акбүреләргә ул ишегалдының иң кырыйдагы, болын ягындагы бер төшендә буш урын бирде. Шунда аларга ул тирмәләр кордырды. Бигешнең кешеләре акбүреләр «урда»сын тиз арада киртәләп алдылар, «урда» киртәсе янына тагын бер киртә кордылар. Монда алар кичерәк бер көтү сарык куалап керттеләр.

Арыган юлчылар туйганчы яңа ит ашадылар, яңа җирдә, яңа чатырларда тынычлап йокыга яттылар. Тотыш би йоклый алмады. Бер дә юктан күңеленә әллә нинди ямьсез, куркыныч уйлар килде. Базар яныннан үткәндә кешеләрнең кинәт тынып калулары, чыш-пыш килүләре, Бигешнең башта ук ачу китергеч кыланышы — барысы да аның эчен пошырды. «Аппак, исәнме син, көтәсеңме мине, бәгырем?» — дип уйлады ул, сагышланып.

## II

Җәй башында, Тотыш углан ирек алып үзенең туган җиренә кайтып киткәннән соң бер ун-унбиш көн үткәч, Хазар каганыннан Алмыш ханга илче килеп төште. Егерме биш хатыны, алтмыш кырнагы булган кырык җиде яшьлек җөфүт каган Алмыш ханның кызы Аппакны — угыз ябгусының сеңелесе Айкын хатыннан туган гүзәл Аппакны үзенә егерме алтынчы хатынлыкка сораган иде. Болгар ханына язган битегендә ул, янап: «Үзең теләп бирмәсәң, көч белән тартып алырмын»,— дип тә әйткән иде.

Хазар каганының кул астыннан ычкыну, көчле, бай, бердәм Болгар йорт кору турында көн-төн баш ваткан Алмыш хан өчен бу аяз көнне яшен суккан кебек булды. Хазар каганында аның инде бер углы тотык булып ята иде. Ни генә булмасын, ул моны көтмәгән иде. Ул моны башына да китереп карамаган иде!

«Минем кызым мөселман йоласында, кияүгә мин аны мөселманга гына бирәм», диде Алмыш хан каган илчесенә. Илче карулашып тормады, шундук килгән җиренә кайтып китте.

Алмыш хан җиңел сулап калды. «Котылдым!» — дип уйлады ул сөенеп. Тик аның сөенече озакка бармады. Көннәрдән бер көнне, каган илчесенең килеп китүе инде бөтенләй онытылып беткәч, игенчеләр уракка төшкәч, Болгар җиренә каган чирүе басып керде. Алмыш хан шундый көч түгеп яңадан торгызган Болгар-тораны хазарлар төрле яктан уратып алдылар. Субашы Каплан, Алмыш ханның борын төбендә кылыч уйнатып: «Инде бирәсеңме гүзәл кызыңны?» диде.

Каган чирүе урман кебек иде, баштанаяк коралланган ир-атлар усал иде, ярсу иде. Хан уфтанды, көрсенде, кайгысыннан каралай көйде. Кылычка каршы кылыч күтәрергә аның кыюлыгы җитмәде. Тиешенчә ныгытылып өлгермәгән агач коймалар, капкалар, агач өйләр аны берничек тә ягыдан саклап алып калырлык түгел иде.

Шулай итеп, язмышка буйсынырга туры килде. Иң кыен чагында Алмыш ханга тәңре дә, алла да булышка килмәде. Җөфүт каган тагын аннан өстен чыкты. Җөфүт каган тагын аны аяк астына салды. Этил-Чулман күрке, бөтен Болгар йортның күрке... ата-ана мактанычы... яңа гына ачылып килгән тамчы-чәчәк, таң яругы... Чулпан-йолдыз... гүзәл Аппак, кан-яшь түгеп, чит җирләргә, чит кулларга озатылды.

Аппак китте. Кояш сүнде. Болгар күген кара болыт басты. Көлгән, җырлаган тавышлар тынып калды. Биюләр, күңел ачулар бетте. Өйләрдә кот калмады, туган җирдә ямь калмады. Язгы ташу булып, бөек Этилгә көндәш булып, болгарларның күзләреннән кайнар яшьләр акты.

Аппак китте. Болгар илен кара кайгы басты...

Кайгысыннан Айкын хатын аяктан егылды. Ата кеше нишләргә дә белмәде.

Шундый көннәрнең берсендә Алмыш хан янына Баштый углы Габдулла килеп керде. Ул ышанычлы кешеләрнең Итил-торадан яңалык алып килүләре турында әйтте. Бу этлекләрнең барысы да сатлык Корыч-

Тимер эше икәнлеге ачыкланды, диде. Синең гүзәл кызың барлыгы турында каган-биккә ул әйткән, каган-бик исә каганга җиткергән, диде. Аппакның Тотыш угланга бирелергә тиешлеген белгәнгә, Корыч-Тимер сине, ханым, каганга кызыңны бирүдән баш тартырсың дип, ике арада сугыш булыр, хазарлар болгарларны канга батырырлар дип уйлаган, диде.

Боларның барысын да ишетеп, Алмыш хан, йөрәгенә чыдый алмыйча, урыныннан сикереп торды да... Габдулланың изүеннән эләктереп алды.

— Чынмы? — диде ул, авыр гыжылдап.

— Чын, ханым,— диде Габдулла, курка калып.

Алмыш хан, үзенең тилелеген күреп, аңына килде, изүне ычкындырды да, авыз эченнән мыгырданып:

— Кичер...— диде.

Тынычлана алмыйча ул әрле-бирле йөренде, тешләрен шыгырдатты, йодрыкларын йомарлады, янау сүзләре кычкырды. Шулай үзалдына тузынган арада ул тезләнеп торган Габдулланы күреп алды да:

— Тагын сүзең бармыни? — диде.

— Бар,— диде Габдулла.— Әл-Моктадирга... Багдад хәлифәсенә мине илче итеп җибәр, ханым. Мин юлны беләм, мин ничек тә барып җитәрмен дип ышанам.

Кайгысыннан соңгы чиккә җитеп ярсыган, әле булса үз-үзенә урын таба алмаган Алмыш хан кинәт кенә юашланып, ипләнеп калгандай булды. Аның томаланган күз алдында, әйтерсең, яшен чаткысы ялтырап китте. Багдадка илче булып?! Нинди кыю кеше бу? Юри генә сөйләнәме, тынычландырмакчы булып кына?..

— Алаймы? — диде ул, кыска буйлы, юан, таза Габдулланы күздән кичереп.— Илче дисең алайса? Яра-ар... Тәкин белән Барыс угланны юкка чыкты дибезмени инде алайса? Алар булдыра алмаганны син ничек булдырырсың икән — сөйләп карале!

— Мин инде күптән уйлыйм бу турыда,— диде Габдулла.— Сиңа әйтергә кыюлыгым гына җитми торды, күнмәссең дип курыктым.

— Әйе шул,— диде хан, аның сүзен җуплап.— Син минем углым да, туганым да түгел. Син — сатучы да, мулла да... алдарга-юлдарга күнеккән... Миннән кеше, байлык алып, син дә Тәкин углан белән Барыс углан кебек юкка чыкмассыңмы? Ул чагында мин сине ничек юллармын?

— Алай дип уйласаң, җибәрмәссең,— диде Габдулла, тынычлыгын аз гына да югалтмыйча.— Син, ханым, беләсең: синең янга мин байлык эзләп килмәдем. Булган байлыгымны, хатынымны, балаларымны ташлап килдем. Мин төрле кысудан, кысынкылыктан, үлемнән качып килдем. Бар нәрсәгә син көч, байлык күзеннән карыйсың. Син бары байлык белән генә табынасың. Шуңа да көн-төн исерткеч эчәсең, үзең җитмәсә мөселманмын дисең.

— Туктале, тукта — син кем мине... өйрәтергә?! — диде хан, кисәк кенә кабынып китеп.

— Мин беркем түгел,— диде Баштый углы Габдулла тыйнак кына.— Мин сиңа бары шуны гына әйтәм: сиңа, кайгым бар дип, көн-төн эчү килешми, ханым. Караларга син яман үрнәк күрсәтәсең. Йортың-илең таза, нык, бай булсын дисәң, син, йорт башы, иң элек үзең айнык булырга, нык, таза булырга тиешсең.

— Ярар, ярар... Кызык, сөйли бир. Мин билгәләр[1] сүзен тыңларга яратам. Сүзең туры — миңа киңәш бирүче дә кирәк кайчагында,— диде хан, урынында җайлап утырып.

— Тыңласаң, минем сиңа сүзләрем күп, ханым! — диде Габдулла, күнеле күтәрелеп.— Минем йөрәгем яна, ханым! Минем кайгымның чигечамасы юк! Җөфүтләр Хазар илен коры таякка терәделәр инде. Каган берни эшли алмый — көн-төн хатыннары белән күңел ача. Каган — бик

[1] Билгә — укымышлы кеше, галим.

булдыксыз. Белекле сүзне тыңлаучы юк. Илдә таркаулык, ярлылык, томаналык... Карагыз әнә гарәпләргә, румнарга, иранnарга, синдләргә! Аларда белем алга киткән, алар безнең кебек ордым-бәрдем генә эшләмиләр, бөерләренә таянып, көчкә генә ышанып ятмыйлар.

— Кызык, кызык,— диде Алмыш хан, бармаклары белән кылыч сабына шакылдаткалап.— Белеклеләр сүзен тыңларга бик тә яратам мин. Сөйлә әйдә, сөйлә. Төрекләрдә — Болгарда, Хазарда белекле беркем юк димәкче буласыңмы инде син?

— Юк, мин алай димим, ханым,— диде Габдулла.— Төрек ырулары, улуслары таркалып беткән. Син минә Хазардан аерылмакчы буласың, Чулман буе сиңа баш бирмәскә тырыша. Бердәмлек юк. Берсе ата-бабасы йоласын тота, икенчесе — гарәпнекен, өченчесе — румныкын, дүртенчесе — җөфүтнекен. Уйлап карасаң, хазар да, болгар да, кыпчак, угыз да, башгырт та — барысы да бер ата-бабадан. Менә шуңа яна минем йөрәгем, Алмыш хан! Барлык ыруларны, улусларны, барлык илне-көнне берләштерә торган көч кирәк.

— Әйе, кирәк! — диде Алмыш хан, яктырып.— Инде мин сиңа ышанам, Баштый углы Габдулла. Син мин уйлаганча уйлыйсың, мин янган утта янасың. Тик, бел: мин Хазардан аерылырга тырышам. Аерылырмын да!

— Мин синең аерылуыңа каршы түгел, ханым,— диде Габдулла.— Син минем әйтеп бетергәнне көтмәдең.

— Сөйлә әйдә,— диде хан, ым кагып.

— Ни әйтмәкче идем соң әле? Әйе шул... Безгә яңа кот өреpгә яңа көч кирәк. Җөфүтләр таркау. Алар үз калталарын тотыру ягын гына карыйлар. Җөфүт йоласы безгә ябышмады. Ата-баба йоласы искерде, көчсезләнде. Рум йоласы безгә бармый. Таркау улусларны тергезсә, берләштерсә, бары гарәпләр йоласы гына тергезә, берләштерә алачак.

— Шуны да онытма: хазарның көчәюе ул болгарның үлеме дигән сүз!

— Әйе, шулай,— диде Габдулла, килешеп.— Болгарның көчәюе — хазарның үлеме дигән сүз! Менә нәрсә телим мин, ханым! Хазарга үчлекләшеп түгел, җөфүткә үчлекләшеп тә түгел. Юк! Үз улусларымны, үз телемне алдынгы итәсем килә. Гарәп йоласы хазарны да, болгарны да, угыз, башгыртны, кыпчакны да бергә берләштерәчәк. Синең өчен иң җайлы чак. Сиңа мондый җайны кулдан ычкындырырга ярамый, ханым.

— Аңлашылды,— диде хан.— Син — батыр йөрәкле кеше, чын белекле кеше. Синенчә булсын — мин сине дә җибәреп карыйм. Берьюлы шунда Тәкин углан белән Барыс угланны да эзләп табарсың, башка йомышларны да үтәрсең. Шулай да күңелемдә бер төен бар: Хазар аша ничек узарсың икән?

— Кайгырма, ханым,— диде Габдулла.— Аңысы минем эш. Мин Итил-тораны, хазарларны Тәкин угланнардан яхшырак беләм. Мин аннан күз йомып та уза алам. Мин алар кебек бер көтү булып бармаячакмын. Мин бернинди кешесез... үзем генә китәчәкмен! Беркемгә берни сиздермичә... Синең үзеңнән башка беркемгә!

— Үзең генә? — диде хан, ышанып җитмичә.— Сакчысыз, юлдашсыз?

— Әйе, сакчысыз, юлдашсыз. Мин сатучы булып түгел, сатучылар белән китәрмен, аларның бер кешесе булып. Монда ышанычлы бер гарәп бар. Ул мине алып барачак.

— Кем ул?

— Фатих ибн Әхмәт,— диде Габдулла.— Аның булмаган җире, кермәгән тишеге юк. Бөтен Багдадта аннан булдыклы, аннан бай, аннан шома сатучы юк.

— Беләм мин аны,— диде хан.— Тапшырдык алайса, Баштый углы Габдулла! Бүгеннән җыела башла. Ак юл сиңа!

*(Ахыры бар.)*

## Зәет Мәҗитов

●

Йөрәкне син гади бер ит димә,
Һәр тамыры — хикмәт йөрәкнең.
Менә тагын салкын җилең белән
Янар-янмас утны көйрәттең.

Яна йөрәк. Йөрәк — ут күреге,
Кая ташың, тимерең — яндырам.
Китер миңа таудай гамьсезлегең —
Минутында көлгә калдырам.

●

Илдә тормыш, Идел сыман, тулып ага,
Ашыга тормыш, зур дулкыннар кага-кага.
Җилкәнеңне киер, күңел, һәм йөз алга,
Йөз уртадан! су читє — тик йомычкага!

●

Нисң бар күңелеңдә, әйт миңа,
Сүзеңнән зур кайгы туса да.
Әйт миңа, туры әйт, күтәрәм,
Хәсрәте тау кадәр булса да.

Нисң бар күңелеңдә, әйт миңа,
Күңел-яр шатлыктан тулса да.
Әйт миңа, саклыйм күз карамдай,
Нинди генә яшерен сер булса да.

Нисң бар күңелеңдә, әйт миңа,
Сүзләрең үләргә кушса да.
Ризамын түзәргә барысына,
Әйт миңа... әйтмәслек булса да.

●

Бу ни хикмәт, сусап йөрим
Су янында.
Тып-тыныч көн... Тайфун җиле —
Уйларымда.

Урманда тиккә моңайган
Кәкүк сыман,
Бу ни хикмәт:
Син — янымда,
Мин — юксынам.

•

Кояш кына язны ашыктырмый,
Кояш кына карны эретми.
Мин яратам язның янгырлысын,
Язгы янгыр мине өркетми.

Мин яратам язның янгырлысын,
Мин янгырны үземә чакырам.
Янгыр яуса, язлар бердәм килә,
Җир чистара язгы янгырдан.

Янгыр яуса, язлар бердәм килә,
Бозлар шаулый, була зур ташкын.
Көтеп алсаң, кадере күбрәк була
Янгырдан соң чыккан кояшның.

Көтеп алсаң, кадере күбрәк була
Ал шәфәкъле аяз кичләрнең...
Кайсыбыз соң көтми шулай килүен
Сагынылган олы хисләрнең?!

•

Сугылма, җил, килеп тәрәзәмә,
Салкыныңны өрмә, кыш агай,
Үземнең дә күңел котыбымда
Бураннарның шәбе булгалый.

Үземнең дә кайчак йөз борынны,
Мең бармакны килә өшетәсем;
Сай күл кебек тынчу күңелләрнең
Үзәгенә килә үтәсем.

Җирнең бөтен яман затын бергә
Катырмакчы була январем!
Эх, нигә соң күңел мартым килеп,
Тамчы булып тама хәнҗәрем?!

## Фирая Шиһапова

*

Шундый бер моң яши күңелемдә —
Көмеш чыңымы ул тургайның?
Җыры мәллә салкын чишмәләрнең,
Серле шавы мәллә урманның?

Кар юрганын тишеп, умырзая
Шытып чыккан язгы бер таңда;
Калганмы ул кереп күңелемә,
Сердәш, юлдаш булып җиһанда?

Аны әллә шулай моңлы итеп
Арышлармы башта көйләгән?
Бишектән үк бер дә чыкмас булып
Күңелемә минем төйнәлгән.

Шул җыр белән канатланып йөрим,
Очар кебек булып күкләргә,
Туган җирем мирас итеп биргән
Сөю хисе шулай күтәрә.

## Соң аңладым...

Карангы төн. Юлда ялгыз идем.
Әллә ниләр керә уйларга:
Ике авыл арасында кырда
Мин адашкан идем буранда...

Туп-турыга карап барыр идем,
Буран аша утлар яктырмый.
Бер югалттым, тагын чыктым юлга,
Барыбер сине эзләп таптым мин...

Утсыз-нисез сине табуымның
Аңладым мин серен соңыннан:
Синең белән күңелем арасында
Буран күмәлмаган юл булган.

## Муса Сирaҗи

### Сукыр

Күргәнем бар аның моңлы чагын,
Күргәнем юк рухы төшкәнен.
Ул күзләрен баскан кара төстән
Яулап яши җәйгор[1] төсләрен!

Карашлары катып калсалар да,
Ышанычлы атлый аягы.
Юллар ярыр туры юлдаш аңа
Уң кулына тоткан таягы.

Тук-тук... тук-тук... Төртеп уята күк
Үткән яуның шомлы шаңдавын[2].
Тук-тук... тук-тук... Кеше эзли сыман
Окопларда сүнгән таңнарын...

О син, кешем, эзләмә син аннан...
Күзең зәңгәрлеге — күгемдә.
Күз нурларың синең очкынланып,
Күзләремдә яна минем дә!

●

Йолдызлы төн. Авылымның
Тын калган минутлары.
Ай буразна салып йөри
Актарып болытларны.

Ә йолдызлар, җем-җем итеп
Болытлар арасыннан,
Буразнага бөртек булып
Сибелеп бара сыман.

### Пар эз

Таңга чаклы төнге чыкта
Парлап йөрүләр,
Чәчкәләрне, йолдызларны
Барлап йөрүләр...

Бураннарны, давылларны
Ярып үтүләр,
Ак карларны шыгыр-шыгыр
Ерып үтүләр...

Ул эзләргә узган еллар
Яткан кар булып.

Чыклы еллар ул эзләрдән
Очкан пар булып.

Алар күптән табигатьтән
Беткән җуелып.
Тик күңелдә бу саф пар эз
Калган уелып...

Чәч агара... Ә бу эзләр
Яңара бара,
Чыкларны һәм ак карларны
Яра да яра...

[1] Җәйгор — Салават күпере.
[2] Шаңдау — кайтаваз.

## Сәет Кальметов

# КИТАП САТУЧЫ

СКЕТЧ

**КАТНАШАЛАР:**

Сәлим — егет.
Сәлимә — апа.
Закир — жизни.

Заманчарак җиһазланган алты почмаклы өйнең алгы ягы. Вакыт кич белән. Тышта җил дулый. Сәлимә мич тирәсендә кайнаша. Ашыгып Сәлим керә. Башында колакчын бүрек. Өстендә чуар свитер. Аягында киез итек, ниндиләптер берсе ак, икенчесе кара.

Сәлимә *(аптырап)*. Сәлим, син түгелме соң?!
Сәлим *(ачулы)*. Мин булмый, кем булсын!
Сәлимә. Чаңгыда йөри торган кенмени, башсыз...
Сәлим. Җизни өйдәме?
Сәлимә. Нигә ул сиңа?
Сәлим. Авылларга чыкмагандыр бит?
Сәлимә. Җизнәң почтага китте, хәзер кайтыр. Сал бүрегеңне!
Сәлим. Син әйтмәсәң дә беләм.
Сәлимә. Ни дип миңа сыртыңны кабартасың?
Сәлим. Дөньяда бер син генәмени?.. *(Графиннан су эчә.)*
Сәлимә. Өйдә ул-бу юктыр бит?
Сәлим. Әти дә, әни дә исән-сау.
Сәлимә. Башыңа инде нинди бәла төште? Котырган буранда юлга чыкмасаң.
Сәлим. Юкка картайма, күрмәгән буран түгел.
Сәлимә. Өстең бик юка, салкын тимәсә ярый инде.
Сәлим. Тимәс, тимәс, егетләр каны кайнап тора ул.
Сәлимә. Әй, мактанчык! Шулай да борыныңны өшеткәнсең але.
Сәлим. Безнең токымда өши торган борын юк.
Сәлимә. Телеңә салынма инде, бар тизрәк кар белән у, кар белән...
Сәлим *(борынын капшап)*. Бетте баш! Бозланып каткан...

Тиз генә чыгып китә.

Сәлимә. Чирәмледән көрт ера-ера тикмәгә килмәс бу шайтан таягы. Мөгаен, тракторына запчасть кирәктер. Җизниенең дус-ишләре күп дип, гел минем Закирга салыналар. *(Өстәлдәге самоварны алып мич янына куя, күмер сала.)*
Сәлим *(керә)*. Апа, ай-яй, көн суык... *(Кулларын уа.)*
Сәлимә. Кил, борыныңа вазелин сөртик.
Сәлим. Каз мае кирәк, каз мае!

Сәлимә. Өйрәтмә мине, өйрәтмә! *(Вазелин сөртә.)*

Сәлим *(көзге алып карый)*. Апа җаным, борынның габариты зурая төшкән бит!

Сәлимә. Аз-маз гына шешә инде ул. *(Көлеп җибәрә.)*

Сәлим. Ярар, ярар, үчекләмә!

Сәлимә. Үзем дә абайламый торганмын, аягыңа кара, клоун!

Сәлим *(карый)*. Исем дә китми. Кеше психологиясендә мондый гына авария була. Чирәмледән чыкканда кабаландым. Күзгә ак-кара күренмәде. *(Иөренә.)* Әллә бүген мичкә якмадыгызмы?

Сәлимә. Яккан, яккан, хәзер генә томаладым, кайнар чәй эчкәч җылынырсың әле менә.

Сәлим. Чәеңне әбиләреңә эчерт!

Сәлимә. Синең өчен аракы тотмыйбыз шул.

Сәлим. Сельпо председателендә аракы юк!

Сәлимә. Алкоголик сыман сөйләшмә, сиңа килешми. *(Табын әзерли.)*

Сәлим. Апа җаным, ачуланма, суык үзәккә үткән. Менә эчәкләр бозланып каткан шикелле...

Сәлимә. Оялмасаң, әнә мич башына мен!

Сәлим. Әй, апа җаным, синең хәтереңөчен янып торган мичкә керергә риза. *(Киез итекләрен сала да мич башына менеп аякларын салындырып утыра.)* Сельпо председателенең хатыны 22 яшьлек пайщикны мич башына менеп кунакларга мәҗбүр итте. Бик хәтәр факт бу! Апа, сезнең өйдә жалоба кенәгәсе бармы?

Түр яктан пижама кигән Закир чыга.

Закир. Бар, бар, кайниш... *(Артына яшергән шешәне күрсәтә.)* Менә ул!

Сәлим *(мич башыннан төшә)*. Җизни өйдә ич, ник мине алдадың?

Закир. Апаңа үпкәләмә, кайниш. Чәчкә чал төшкәч, гайкалар какшый икән. Врачлар режим куйды. Эштән соң апаң камыр басканда, җизнәң берәр сәгать мендәр изеп ала. *(Көлә.)* Кил, утыр, кунак өчен генә саклап торган ликерның төбәтәен салдырам. *(Утыра.)*

Сәлим. Кунак дип сөйләшмик, ликерның кирәге юк. *(Утыргычны алып, бер читкә китеп утыра.)*

Закир. Кайниш, болай кылануың бер дә килешми!

Сәлим. Вакыты белән килешә ул...

Сәлимә. Әткәсе, борчылма юкка. Борынын өшеткән, әрни торгандыр.

Закир. Китче, без егет чакта борын өшетүне белми идек.

Сәлим. Сез егет чакта сельпо председательләре яшьләрне тинтерәтмәгәндер.

Закир. Сәлимә, кайниш мине дөмбәсләргә килгән, ахры! *(Көлә.)*

Сәлим *(тора)*. Әйе, дөмбәсләргә дип килдем. Безгә диплом белән килгән сатучыны Ташлытауга олактыргансың бит.

Закир. Ярар, шуның белән нәрсә әйтмәкче буласың?

Сәлим. Нигә аны Чирәмледән кузгатырга, сатучы буларак үзен яхшы яктан танытты ич. Товарларны кайтарып тора.

Закир. Кибетне кунак өе сыман бизәде. Сатып алучыга ягымлы, планны арттырып үти, жалоба кенәгәсен сораучы да юк. Озын сүзнең кыскасы, Гөлүсә өчен борын туңдырып йөрим, диген. *(Көлә.)*

Сәлим. Сәлимә апа артыннан йөреп син дә колакларыңны өшеткәнсең.

Сәлимә. Дөрес, дөрес, энекәш. Күрше авылдан чатнама суыкта солдат фуражкасы киеп килә иде. *(Көлә.)* Әткәсе, ул Гөлүсә дигәнегез төскә-биткә ничегрәк соң?

Закир. Миңа калса, алай егылып китәрлек түгел. Яшел күзле.
Сәлим. Үз кадрларыңны да белмисең икән, Гөлүсәнең күзләре зәпгәр!
Закир. Кыска буйлы, чандыр гына...
Сәлим. Акылы булгач, буе нигә. Ефәк яулыкка чорнап куенда ртерлек!
Закир. Кайниш, Гөлүсәнен синдә күңеле юктыр. Ташлытауга күсең дигәч, йөзен дә сытмады, мин приказга буйсынам, ди.
Сәлимә. Менә тагы, кыз бала оялучан була. Чирәмледә егетем р дип чәчрәп чыкмас инде. Әткәсе, бәлки Гөлүсәне үз кибетендә алдырып булыр?
Закир. Булмый. Бу мәсьәлә буенча РПСдан махсус кәгазь килде.
Сәлим. Җизни, син кәгазь кортымыни соң?
Закир. Әйе, кәгазь корты! Гөлүсә иртәгә кибетен тапшыра да итеп тә бара.
Сәлимә. Әткәсе, алай кырт кисмә, бәлки бер әмәлен табарбыз.
Закир. Сүз куертуда мәгънә юк. Мичеңне кара, пироглар көймәсен.
Сәлимә. Шөкер, моңарчы сиңа көйгән пирог ашатканым булмады.
Сәлим. Апа, бер фельетонда кәгазь кортларына көйгән кәбестә шатырга кушканнар иде.
Закир. Фельетон, имеш! Хәзерге яшьләр гайрәт чәчәргә оста!..
Сәлимә. Егет шәп әйтте! Кәгазь кисәгенә аркаланып, яшьләрнең исендә уйнамассың.
Закир. Зинһар дип әйтәм, миңа ябырылмагыз. Чирәмледән китүенә өлүсә үзе сәбәпче булды.
Сәлим. Анысы тагын нинди сәбәп?
Закир. Гөлүсә Чирәмледә китап сатуны начар оештырдымы?
Сәлим. Кем әйтә начар дип, узган атнада сатылган китапларны лчәүгә салсаң, өч центнер булыр иде.
Закир. Шулай шул менә! Гөлүсә китап сату буенча районда рекорд куйды. Ташлытау сельпосында китап сату хөрти. Ничәмә елдан ирле китап сәүдәсен оештыра алмыйлар, Гөлүсәне кузгатуның сере ул гына.
Сәлим *(әрнеп)*. Их, үксеп-үксеп җылыйсы килә...
Сәлимә. Мәхәббәт үзенекен итә ул, җырлата да, җылата да...
Закир. Гөлүсә дип, саргаясы юк синә, кыз районнан китми. Илле илометр ара хәзерге заманда биш атлам җир.
Сәлим. Километрлар саны өркетми. Ташлытауда Гөлүсә рекорд куялмас. Шуңа өзгәләнәм мин. Беләсегез килсә, Гөлүсә бер китап та атмады.
Закир. Сәлимә, сизәсеңме, гыйшык уты егетнең акылын көйдергән.
Сәлим. Көйдерми торсын әле... Сүзем хак... Гөлүсәнең бер генә брошюра да сатканы юк...
Сәлимә. Җизнәң белән бәхәсләшмә. Ул кайсы кибеттә көненә ничәшәр кап шырпы сатылганын да белә.
Закир. Сәлимә, җитте! Хәзер аның белән сөйләшүдә мәгънә юк. Ирамый да. Китапларны центнерлап исәпли башлагач та күңелемә шик алган иде.
Сәлимә. Бичара! Үзе дә шашып килеп керде. Җитмәсә аягында ике төрле итек... Зиһене чуалган, күрәсең...
Сәлим. Әйе, әйе, мин тилергәнмен шул. Көндезләрен басуда трактор белән кар тоттым. Кичләрен йорт саен кереп Гөлүсәнең барлык китапларын мин сатып йөрдем. Мин! *(Торып күкрәгенә суга.)*

*Пәрдә.*

## Рәшит Әхмәтҗанов

# Шагыйрьләр

Карчык кебек төн утырып дөнья
Йон урынына ниләр тетмәгән?!
Эзләп кара шагыйрьләрнең юлын,
Кая табан алар китмәгән.

Хәмер эчкән Хәйям гомергә дип,
Ялгышмагыз әле, кешеләр.
Шагыйрьләрнең тамган күз яшьләре
Төрмәләрнең ташын тиштеләр.

Уйланганнар: аккош моңнарыннан
Изгелекләр иңәр янәсе.
Һәм эзләгән шул чак шагыйрьләрнең
Йөрәкләрен дошман ядрәсе.

Күпме шагыйрь киткән иреннәрен
Суга түгел, утка тидереп.
Чыдаганнар,
Тик кычкырган алар
Шундый көндә генә илереп.

Алар чапкан чакта,
Дага эзе
Уелгандай иреннәренә,
Кычкырганнар: кылычыңны болгап
Кермә, диеп, кеше җиренә.

Тели алар сугыш ялкынына
Олы дингезләрне сибәргә.
Үз каныннан үзе сүзләр ясап
Шагыйрьләргә кыен сөйләргә.

Э бит, бер уйласаң, шушы дөнья —
Шагыйрьләрнең шигырь бүлмәсе.
Алар бүлмәсе һәм алар өчен
Палачларның монда төрмәсе...

Карчык кебек төн утырып дөнья
Йон урынына ниләр тетмәгән?!
Эзләп кара шагыйрьләрнең юлын —
Кая табан алар китмәгән...

1969

●

Баш сөяген касә итеп тиран
Шәрап эчкән элек бу жирдә.
Яшәү хакына син вәхшилекне
Оныт, жирем, оныт, сер бирмә.

Ул касәнең туфрагында бүген
Үрелгәндер күккә имәннәр...
Кылычлар бит безнең башыбызга
Иелмәгән өчен тигәннәр.

1967

## Көз

Урман үзенең нәселен
Үз тирәсенә жыя...
Кошлары киткән урманның
Агачы саен оя.

Яфраклар өстендә — көннәр,
Яфраклар астында — төн.
Әй, көннәр-төннәр яналар —
Урман өсте ал төтен.

Миләшләр — ялкыннар күзе,
Үзәгемне өзәләр.
Алар да киткән кошларны
Сагыналар, түзәләр.

Пар каен сеңелләремнең
Бик тирәндә бөресе.
Карагыз — апасы ябь-яшь,
Саргайган сеңелесе.

Бишәрләп-бишәрләп кенә
Коелалар яфраклар.
Жилпенә сыман күгемдә
Яраланган канатлар.

Әй, урман үзенең нәселен
Үз тирәсенә жыя...
Кошлары киткән урманның
Яшьлеге яфрак коя.

1963

●

Күгемне ятим калдырып
Коега төшкән дә ай —
Янып, балкып ята суда
Бер кызның алкасыдай.

Мин сөйгәнгә — сөймәде ул,
Үземә — үз өлешем.
Никтер шул айга охшатам
Өлешемнең көмешен.

Ай төшкән кое төбенә,
Коены күмә яры —
Сызланып тыныч туфракны
Ишәргә кирәк бары.

Ярамый, барыбер аннан
Елгага күчә аем,
Аннан серләремне сөйли
Таралып тамчы саен.

1966

## Ерак-ераклардан

Ерак-еракλардан тавыш килә...
Кычкыра күк миңа сөйгән ярым.
Үзе таш сын итеп калдырганга —
Кузгалмадым.

1965

## Карт монологы

Без сөюләр белән гаҗәп көчле булдык,
Үлем күрсәк — яшәргә дип типте йөрәк.
— Әй, уныгез яшьлек яшьтәшләрем минем,
Кабердә дә өстегездә канлы күлмәк.
Әй, унсигез яшь чактагы алсулыклар
Байракларга сеңеп калды ул елларда.
Ул елларда закон безнең каты иде —
Үлмә дә син, ач та булма, югалма да.
Сез яшьлекне кичерәсез сөеп, шашып,
Һәм сорыйсыз: картлык нинди була җирдә?
Яшьлектән ул матурмы соң, көчлерәкме?
Нәрсә ул тормышны белү — зур тәҗрибә?
Яшь чагында авыр ташлар тау астында,
Җиңел ташлар гына тора тау башында.
Буыннарым аша минем таулар кучте,
Таш ватылган тавышлар бар тавышымда.
Күпме дошман басып керде туган илгә,
Тик аумады заманаһың баганасы.
Асылганчы шушы биек баганага —
Безнең җирдә янды аларның табан асты.
Шулай дошман безнең җиргә баш булырга
Ач бүредәй шашынып тик йөрде генә.
Мәңгелеккә җир астына керде үзе,
Ия булып бары үзенең сөягенә.
Фаш итәсе бар дөньяның мең мәкерен,
Фаш итәсе бар дошманның мең хәйләсен.
Оран салам ил өстенә: фидакарьләр
Аяк өсте торсын әйдә, бил бәйләсен!
Кулга кылыч тотсын! Кулы тоталмаса —
Юкка гына билгә кылыч бәйләмәсен!
Туган илме, туган телме алдан туган,
Тик мин беләм — бу җир безгә ана булган.
Уяу булсын җир өстендә һәрбер олан,
Елан йокласа да — дошман йокламаган!

1969

●

Артта — үлем, алда — тормыш,
Диде миңа биек тау.
Йөрәгемне тау башына
Алып менәм исән-сау.

Түбән карыйм. Анда минем
Гомерем узган болыннар...
Анда йөри бүреләрне
Җинә алган колыннар.

Әнә тургай сайрап менә
Болытларга кадәрле.
Аның канатында җиргә
Тамчылар төшәр әле.

Кабыкларын салып тауда
Калдырганнар еланнар.
Кабыклардан өркеп кача
Еракларга куяннар.

Ә сез мине уйлыйсызмы
Куркыр диеп яшеннән.
Дөнья күпме дәһшәтләрен
Күкрәгенә яшергән.

Әйтәләр дә бит гомерне
Яңгыр тамчысы диеп —
Суларның тәме үзгәрде
Тормыш ачысы тиеп...

Артта — үлем, алда — тормыш,
Дигән иде биек тау.
Ә мин тугры йөрәгемне
Алып мендем исән-сау.

Тауга мендем. Яңа таулар
Әйтмәделәр алдагын.
Бер көнне мин дә аларны
Мин исән! дип алдармын.

1968

●

Куркыныч булса да, талым,
Тарихың минекеннән —
Мин дә давыл кочагында
Йолкынам да җилкенәм.

Мин дә яшим яр буенда,
Минем дә алда упкын.
Ярны дулкын ишә генә —
Теләсәң кая тотын.

Минем дә өстемә тиздән
Ишелер сыман таулар.
Ә миңа күктә йолдызлар
Барлыгын белми алар.

Әй, синдә тирбәлеп һаман
Сайрап торганга күрә —
Минем дә төнлә төшемә
Сары сандугач керә.

Әй, талым, куркыныч түгел
Язмышың минекеннән.
Мин саклап йөрим бер кызны
Үлемнән һәм үземнән.

Йолдыз булып атыла сөю
Болытлар арасына.
Я хәнҗәр булып кадала
Йөрәгем ярасына.

Гомерне саклый бу җирдә
Кавышыр мизгел генә.
Йөрәгем ярылып үләрмен,
Шушы мизгелнең үткәнен
Тик миңа сиздер генә.

1969

Тәүфыйкъ Сәгыйтов

# ТОРМЫШТАГЫ ЭЗЛӘР



Смена ахыры иде. Инде вакыт кичкә якынлашып килсә дә, май кояшының кыздыруы һаман сүрелми әле, иртән чыгып киткәндә, җиләс булмагае дип алган костюм яисә кофталарны беләкләргә генә салып тотарга мәҗбүр итә.

Көннәрнең эсселәнә башлавы цехларда аеруча сизелә. Станок һәм тимер кызуына май кояшының нурлары да өстәлеп, цех эчен бөтенләй җәй уртасына охшата. Олыраклар сүзе белән әйткәндә, хезмәт тирен күбрәк сарыф итәр чак җитте.

Эшне тәмамлап, станокны җыештыргач, душка кереп коенасың да, көне буе арыганың гүя шунда юылып кала. Цех бусагасын атлап чыгуга, сине җәй һавасы, һәр таң саен үзенең колачларын киңрәк җәюче яшеллек исе кочып ала.

Газимҗан ага да җәй башының шушы иркен һавасын тирән итеп сулап, костюмын иңбашына гына салган килеш, һәрвакыттагыча житез атлап, завод капкасына таба бара.

Бүген май кояшы аның өчен тагын да сөйкемлерәк елмая кебек тоелды. Кичке сменага юнәлүчеләрнең дә, көндез эшләп өйгә, я булмаса мәктәпкә, техникум яисә институт аудиторияләренә юл тотып ашыгучыларның да игътибарын капка янындагы зур гына белдерүләр тактасы җәлеп итте.

Анда эре-эре хәрефләр белән матур итеп язып «Молния» чыгарылган: «Бүген Мәскәүдән телеграмма алынды. «Урак һәм чүкеч» заводы токаре Газимҗан Абдрахмановка «Энергетика һәм күтәртү-транспорт машиналары төзелеше министрлыгының иң яхшы токаре» дигән исем бирелгән. Ветераныбызга мактау һәм дан!..» Шунда ук завод директорының махсус приказы эленгән. Анда Абдрахмановны бу мактаулы исемгә лаек булуы белән кайнар тәбрикләү, аңа яңа уңышлар, сәламәтлек теләү һәм озак еллар буе тырыш хезмәте өчен зур рәхмәт сүзләре язылган.

Кеше саны арткannan арта бара. Һәркемдә горурлык тойгысы. Шул вакыт кайсыдыр кинәт гаҗәпләнү белән бөтенесенә ишетелерлек итеп кычкырып куйды:

— Әнә бит ул үзе килә!

Завод капкасы янындагы кеше ташкыны шушы мизгелдә үк белдерүләр тактасыннан кире якка борылды. Цехлар ягыннан, бер төркем эшчеләр белән, кыска буйлы, тормыш буразналары булып сузылган җыерчыклы йөзенә килешеп торган сары

селы күзлек кигән Газимҗан ага атлый иде. Ул үзе әле берни дә сизми, токарь-рга бакчада үстерелә торган георгиннар турында сөйли, ара-тирә душтан соң бәреп ккан маңгай тирен кульяулыгы белән сөртеп, шул уңайдан кырау төшә башлаган мшак кара чәчен сыпырып төзәтеп куя...

Якынаюга ук, аны котларга дип, кайсыдыр кул сузды, кемдер җылы сүзе белән брикләргә теләде...

— Бөтен цех исеменнән котлыйбыз, Газимҗан ага,— диделәр.

— Бөтен тимерчеләр исеменнән...

— Коючылар...

— Җыючылар...

Төрле яктан яңгыраган бу котлауларны әле аңлап та бетермәгән Газимҗан аганы үтәреп үк алып чөйделәр...

* * *

Җир аз гына кардан арынды исә, Газимҗан ага бакчага юнәлә. Үзенә өстәмә эш эзләүдән генә дә түгел, ничектер, җиргә булган ихтирам яшьли канга сеңеп калган-ламы, хәтта нәселдән күчкәнгәме, аңа һич сүрелмәс мәхәббәт көче тарта аны.

Җир дә тир түгеп хезмәт куйганны ярата бит. Әнә җавабы күз алдында: ботак-ларын көчкә күтәреп торган алмагачлар, чия агачлары, карлыганнар. Икенче бер кы-рыйда кура җиләкләре... Түтәлләрдә чыпчык башы кадәр булып пешкән виктория җиләкләре, ашап туймаслык тәмле помидорлар кызара...

Күршеләр бу участокка, менә җирне ничек итеп бизәп була ул дип, гаҗәплә-нергә, киңәш алырга киләләр. Һәммәсе дә матур итеп бизәкләп ясалган өй каршын-дагы чәчәкләрне күреп хәйран калалар. Әйтерсең лә, Газимҗан Абдрахманов заводта тимер кырдыручы түгел, ә гомере буе бакчачылык һәм чәчәкләр белән шөгыльләнгән агроном. Георгиннар, гладиолус һәм лаләләргә бер күз төшерүе үзе күңелдә нинди зур рәхәтлек тудыра, гүя тормышны тагын да гүзәлрәк итеп бизи ул.

Газимҗан ага җәйнең һәр кичендә, әгәр ул бакчада булса, уллары һәм кызлары, киленнәре һәм кияүләре, оныклары җыелып утырган өстәлгә хуш исле чәчәк бәйләмен үзе алып кереп куя. Әгәр инде өйдә кунарга туры килсә, өстәл өстен барыбер шун-дый ук бүген генә өзгән букет бизи. Ул, аңа карап тора да, гармонен алып яисә пианино янына утырып, үзе яраткан «Һаман истә» көен суза. Бу җыр аңа авыр бала-чакны, туган якның мәңге матур табигатен искә төшерә, гомумән, үткән сикәлтәле юлларны онытмаска, бүгенге тормыш яменең кадерен белергә чакыра кебек.

* * *

— Кеше тормышта нинди эз калдырырга тиеш?

Бервакыт Газимҗан ага улы Рифкать белән сөйләшеп утырганда әнә шул хакта сүз чыкты.

— Тормышта эзегез калырлык итеп яшәргә тырышыгыз. Ә эзне һәркем үзе сала. Иделдәге көймәнең генә эзе юк. Шуңа күрә дә, «көймә килә, эзе юк»,— дип җыр-лыйлардыр. Ә эзләр бала вакыттан ук башлана, улым, ләкин тормышта кеше кал-дырган эзләр урамда яңгырдан соң яисә кар өстендә ярылып яткан эзләр белән генә үлчәнмәскә тиеш ул. Алар бик тиз юкка чыгалар. Әгәр кеше үзенең тырыш хезмәте белән юл салып атлый икән, менә ул эзләр, ташка чукып язгандай, гомерлек була инде.

Юк, гомерлек кенә дә түгел, хәтта мәңгелек тә була ул кайбер эзләр. Дәһи Ленин җитәкчелегендәге большевиклар көрәше әнә шундыйлардан. Алар сызган юлдан хәзер миллионнар атлый. Октябрь революциясенә хезмәт итеп, яшь совет властен сак-лап калу, азатлык һәм бәхет өчен көрәштә һәлак булганнарның исемнәре дә тарих битләрендә!

Газимҗан ага эшли торган «Урак һәм чүкеч» заводы коллективы Елга арьягында оештырылган отрядлар сафына басучыларның шул дәһшәтле көннәрдә күрсәткән батырлыгын да яхшы хәтерли. Болары да тормыштагы эзләр!

Бу турыда заводның тарихында да бик ачык сөйләнә. Аның белән меңләг укучылар, яшьләр һәм дистәләрчә кунаклар да таныша. Революцион традиц буыннардан-буыннарга күчеп, классларадагы тырышлык һәм цехлардагы батыр хезм белән үрелеп, безнең көннәрдә уңышлы дәвам итә.

Шундый бер риваять бар. Туган илгә, газиз туфракка мәхәббәте турында сө ләгәндә, баласына ана болай дигән:

— Туган илне яратам дип авыз тутырып әйтер өчен, аны сагынып җырларга ту хакың булсын өчен, ир-егет туган туфрагында иген игәргә, тимерчелегендә чүк чыңлатырга, чиккә басып, Ватанын ят күзләрдән, чит аяк эзләреннән уяу саклар тиеш. Шул чагында гына аның ил-анага карата әйткән татлы сүзләре чын сүз, алты сүз була.

Газимҗан Абдрахманов коммунист-новаторның эзе һәм сүзе алтын булырлык т чөнки ул туган туфрагында иген иккән, колхоз оештыруда турыдан-туры катнашка кеше, чөнки ул иле җирен һәм күген сугыш елларында цехта көне-төне корал ясас азат итешкән, чөнки Газимҗан Абдрахманов, риваятьтә әйтелгәнчә, «тимерчелект чүкеч чыңлата» — бөтен союзга атаклы «Урак һәм чүкеч» заводында фидакарь хезм итә, шушы тырышлык аңа дан һәм хөрмәт китерде.

...Рифкать Газимҗан аганы ашыктырды:

— Әти, әйдә, кешеләр күп җыелган инде...

— Хәзер, улым, хәзер...

Газимҗан аганы алыштырырга сменага килгәндә бүген улының шатлыгы эчен сыймый иде.

— Әти, сөенче,— диде ул,— белдерү тактасына синең дә зур гына фоторәсемеңне элгәннәр. Директорның махсус приказы бар. Беләсеңме, анда нәрсә язылган: «Иң өлкән хезмәт ветераны Газимҗан Абдрахмановның «Урак һәм чүкеч» заводында эшли башлавына кырык ел тулды. Шул еллар буена һәрвакыт алда, мактаулы булды», диелгән. Шушы уңай белән котлаганнар үзеңне. Кыйммәтле бүләк бирергә булганнар. Тагын белдерү бар — синең хөрмәткә бүген заводта тантаналы кичә булачак.

Дулкынлануы йөзенә бәреп чыкты Газимҗан аганың. Кояшлы майның бу көне бәйрәм төсендә үтәр дип кем уйлаган? Хезмәтнең төбе хөрмәт, диләр, нәкъ шул үзедер инде бу. Өйдә болай да котларлар, хатыны Мәрьям, кызлары һәм кияүләре, уллары һәм киленнәре бөтенесе җыелып бәйрәм итәрләр анысы — туган көннәрне, түгәрәк даталарны үткәрү гадәткә керде инде семьяда. Әмма коллектив котлавы башка нәрсә бит ул. Игътибар да, хөрмәт тә, ихтирам да шунда чагыла инде.

40 ел! Шул вакыт эчендә бу куллардан никадәр тимер узмагандыр да, бу куллар никадәр деталь ясамагандыр.

Газимҗан ага, тирән хисләргә бирелеп, заводның кызыл почмагына атлады. Аны тәбрикләр өчен җыелган халык белән зал шыгрым тулган иде.

Завод ветераны, әле үзенең дә бирелә кырык ел буе эшләвен күптән түгел генә билгеләп үтелгән Әгъзам Низаметдинов аны ишек янында көтеп тора иде. Ул яшьтәшен кочаклап үк алды:

— Котлыйм, кордаш, чын күңелдән котлыйм. Кырык ел элек бирелә эшли башлаганда хезмәт сукмакларын бергә үтәрбез дә, ул безне олылар, тырышлыкка шундый югары бәя бирелер дип кем уйлаган иде, ә?!

— Рәхмәт, туган, рәхмәт!

Газимҗан ага күзләренә ихтыярсыз бәреп чыккан яшьләрен сөртте. Ә Әгъзам ага һаман кулы белән аның җилкәсеннән какты, кабат кочаклап үпте. Бу Газимҗан Абдрахмановны заводның партком члены, цех профсоюз оешмасы председателе буларак түгел, ә бирегә беренче мәртәбә бер вакытларда атлап кергән хезмәттәш дусты буларак тәбрик итүе иде.

Ветераннарны сәхнәгә чакыралар. Алар — коллективның күптәннән бирле килә торган традицияләренең нык тотнаклары, гүя үткәнне һәм бүгенгене тоташтыручы җанлы күпер. Нык ул, аны ватып та, җимереп тә булырлык түгел. Чөнки аларның хезмәтләре предприятиенең гасырдан артык тормышын чагылдырган «Завод — ветеран» китабында да күп язылган, аларның бирелә утырулары һәм бүген цехта эшләү-

ләре тарихның музейларда һәм китап битләрендә генә сакланып калмыйча, бүгенге көн белән тыгыз бәйләнгән булуын, безнең бу көннәр шул чал тарихның аерылгысыз дәвамын тәшкил иткәнен кабат дәлилли.

Абдрахманов белән Низаметдинов, иң беренчеләрдән булып, шәхси клеймо алып эшләүчеләр, димәк, алар ясаган детальне бер кем дә тикшереп тормый; тагын берничә ел арткарак күз салсак, икесенә дә, барлык эшчеләрдән алда, Коммунистик Хезмәт ударнигы исеме бирелгән. Әгәр узган елларга — аларның яшьлек чакларына күз салсак, традицияләр тотнагы икәнлекләре күз алдында: Абдрахманов белән Низаметдинов Казанда беренче стахановчылар, бригадалар оештырып, шаккатырлык рекордлар куйганнар, норманы шулай үтик дип, бөтен шәһәр предприятиеләренә өндәмә-чакыру белән чыкканнар.

Дусың кем икәнен әйтсәң, үзеңнең нинди кеше булуыңны әйтәсе авыр түгел, диләр бит. Абдрахмановның хезмәттәше дә үзе кебек, тормышның сикәлтәле юлларын үткән кеше.

Ә алар хәзерләгән сменага күз салсаң, үзе бер горурлык. Шуңа күрә дә бу турыда олылап җылы сүз әйтергә теләүчеләр күп булды заводта. Менә токарь Александр Бердников:

— Мин Газимҗан ага Абдрахмановка өйрәнчек булып килүемне зур бәхет дип саныйм. Инде хәзер теләсә нинди детальне үзем генә ясый алсам да, Газимҗан ага мине күзеннән ычкындырмый әле. һәрвакыт киңәш бирә. Янында шундый кеше булу, аңардан ярдәм алу — үзе бәхет. Мин үзебезнең Киров районының яшь токарьлары ярышында беренче урынны алган идем, ә шәһәр күләмендә икенче булдым. Бүләк итеп көмеш резец бирделәр. Менә шушы уңышларда Газимҗан аганың өлеше азмыни?!.

Мөҗәһит Габдрахманов, кадрлар бүлеге начальнигы:

— Беләсезме, Газимҗан ага — безнең штаттан тыш кадрлар бүлеге члены. Бер генә утырыш та аның катнашыннан башка узмый. һәр җомгада заводтан үз теләге белән китәргә дип бирелгән гаризалар тикшерелә. Кешеләрне чакырып сөйләшәбез: ни өчен безне калдырырга уйлаганнар, сәбәбе нәрсәдә? Соңгы сүзне Газимҗан ага әйтә, бай тормыш тәҗрибәсеннән чыгып, киңәшләр бирә. Беләсезме, хәзер бездә гариза бирүчеләрнең яртысы кире кала. Монда хезмәт ветераннарының да тырышлыгы зур дип әйтер идем.

Мирсәет Рәхимкулов, завод директоры:

— Ветераннар үзләре генә түгел, һөнәрне алардан өйрәнгән дистәләрчә яшьләр дә заводның алдынгы кешеләре.

Газимҗан ага җылы сүзе, акыллы киңәше белән дә бик кешеләргә ярдәм итә. Шуңа күрә дә завод эшчеләре аңа ерактан ук сәлам бирәләр, тантаналы җыелышларда бертавыштан президиумга сайлыйлар, ә бәйрәм демонстрацияләрендә алгы сафка бастыралар.

Менә быел ул, кырыгынчы мәртәбә завод байрагын тотып, беренче Май демонстрациясенә чыкты. Бер карауда инде бөтенесе дә таныш, күнегелгән кебек: бәйрәмчә киенгән хезмәттәшләр җыела, бергәләшеп колонналар белән Ирек мәйданына юнәләләр. Ләкин шул ук вакытта һәрбер бәйрәм, яңың үзе кебек ук, кабатланмастай истәлекле була. Әле дә хәтерендә аның, беренче тапкыр бу коллектив белән демонстрациягә чыкканда завод бик кечкенә, артель кебек кенә иде. Ә хәзер ул тиңсез үсте. Ул гына да түгел, әле тагын куәтле цехлар сафка басачак, завод үзенең колачын бермә-бер киңрәк җаячак. Аларда да бу өлкән яшьтәге осталар мактәбен узучылар эшләр. Чөнки күп алар, әле һаман ишәяләр. Тезеп куйгач, үзләре бер колонна бит. һәрберсе завод байрагын алып барырга лаеклы...

Бер цехта, бер станокта эшләүче эшче династиясенең гүзәл традицияләре әнә шулай дәвам итә.

Байрак күтәреп, кырыгынчы мәртәбә 1 нче Май демонстрациясенә чыкканда, аларга районның эрләүчеләре, тукучылары, күн эшкәртүчеләре кушылды. Аларның аталары һәм бабалары, Алафузов предприятиесендә эшләп, 1891 елның 1 маенда Казанда беренче мәртәбә баш күтәрәләр... Тагын бер елдан соң шул ук алафузовлылар Николай Бауман һәм Ефим Табейкин җитәкчелегендә беренче маевка уздыралар.

Казан пролетариатының бишеге булган Елга аръягы поселогы кешеләренең азатлык һәм бәхет өчен көрәшеп, кан коюлары бушка китмәде. Киров районы хезмәт ияләре алып килә торган транспарантларда сурәтләнгән хезмәт уңышлары гүя аларга рапорт булып яңгырый һәм вакытсыз корбан булган революционерларның хыялы тормышка ашуын ачык дәлилли. Ә йөзләрчә Кызыл Байраклар җилфердәве алар сызган юлның мәңгелек икәнен ерак-еракларга хәбәр итеп торалар... Ул байраклар ышанычлы кулларда. Аларны Газимҗан Абдрахмановлар кебек хезмәттә чыныккан эшче семьялары, революцион традицияләрдә чыныккан кешеләр алып киләләр.

...Ил язмышы — аның кешеләре язмышында, илнең көче — аның уллары һәм кызлары көчлелегендә, илнең бәхете — аның халкы бәхетендә, диләр. Үзенең фидакарь хезмәте белән генә түгел, эчке дөньясы белән дә матур булган, яшьләрдә үз профессиясенә һәм заводына карата мәхәббәт тәрбияләүче, кирәк булганда үзенең эш сәгате белән генә дә чикләнеп калмый торган олы йөрәкле Газимҗан ага Абдрахманов та илне көчле, бәхетле итүче халык улларының берсе. Андый семьялар безнең галиҗәнап эшче классы үткән тарихи юлны, аның гүзәл традицияләрен һәм бүгенге казанышларын гәүдәләндерә. «Энергетика һәм күтәртү-транспорт машиналары төзелеше министрлыгының иң яхшы токаре» исеме бирелгәч тә, заводта эшли башлавына кырык ел тулу көнен билгеләп үткәндә дә, бу хезмәт ветеранын хөрмәтләү, кыйммәтле бүләкләр, чәчәкләр, аңа карап чын йөрәктән елмаюлар, завод җитәкчеләренең һәм аның иптәшләренең әйткән җылы сүзләре — коммунист Газимҗан Абдрахмановның көндәлек хезмәтенә бәя бирү иде. Аның кырык ел буе токарь булып эшләү дәверендәге эшен чын батырлык диясе килә. Чөнки безнең көннәрдә халык бәхете өчен һәркемгә үрнәк булырлык көндәлек тырыш хезмәт — үзе зур батырлык ул. Шушы завод белән бәйләп, үз язмышын үзе тудырган, шушы коллектив белән үзен бәхетле иткән Газимҗан ага Абдрахманов та бу батырлыкны күрсәтте. Андый гади кешеләрнең шундый хезмәте батырлыкка тиң түгелмени?! Алар җирдә күркәм эзләр калдырмыйлармыни?!

Гали Халит

# КӨРӘШЧЕ ӘДИП ПОРТРЕТЫ

Соңгы елларда Галимҗан Ибраһимов турында байтак кызыклы, яңа фикерләр әйтелде һәм язучының тормышын, бай эшчәнлеген, әдәби-фәнни мирасын өйрәнү юлында игътибарга лаеклы эзләнү-тикшеренүләр башкарылды. Әммә шулай да моңа кадәр Г. Ибраһимовның бөтен тормыш юлын, киң иҗтимагый, әдәби һәм фәнни эшчәнлеген бер бөтен итеп, барлык колачы белән күз алдына бастырган хезмәт юк иде әле. М. Хәсәновның яңа монографиясе[1] — шундый хезмәтләрнең беренчесе.

М. Хәсәнов — Г. Ибраһимовның әдәби мирасын эзлекле өйрәнүне үзенең иҗат максаты итеп куйган яшь галимнәребездән. Аның әлеге темага багышланган мәкаләләре һәм 1964 елда татар телендә чыккан «Галимҗан Ибраһимов» дигән монографиясе шул юнәлештәге беренче уңышлы тәҗрибәләр иде. Аларда ук инде авторның үзе сайлаган теманы яратып өйрәнүе һәм иңләп алырга теләве сизелеп тора иде. Соңгы хезмәтендә исә аның бу сыйфатлары тагын да үсә, камилләшә төшкән һәм моңа кадәр укучыга тәкъдим ителмәгән яңа яклары белән ачылган.

М. Хәсәнов монографиясендә Г. Ибраһимовның бала чагыннан алып соңгы көннәренә кадәр булган гыйбрәтле тормыш һәм иҗат тарихы эзлекле рәвештә күз алдыннан үтә: хезмәт иясе крестьяннарның авыр тормышын якыннан күреп үскән Галимҗанның авылда, аннан соң Оренбург һәм Уфа мәдрәсәләрендә укып йөрүе һәм 1905—07 елгы революция тәэсирендә иске дөньяга нәфрәте көчәеп, яңалык өчен көрәшкә кушылуы... Болар язучының беренче адымнары, беренче тормыш тәҗрибәләре. Бигрәк тә Г. Ибраһимовның, Бәли мулла мәдрәсәсен ташлап, 1906 елда Уфага «Галия» мәдрәсәсенә килеп керүе аның азатлык идеяләре белән тулы әдәби талантына зур этәргеч бирә. Аның искелеккә нәфрәте бу мәдрәсә тәртипләре белән дә сыеша алмый. Шәкерт Галимҗанның Зыя Камали кебек «Галия» мәдрәсәсе тарихында күренекле урын тоткан халфәләр белән тиз арада кискен мөнәсәбәтләргә керүе дә игътибарга лаеклы күренеш. Язучының үз истәлекләрендә бу хакта фикерләр булса да, әлегә кадәр өйрәнүчеләр ул фактны читтә калдыра килделәр. М. Хәсәнов исә моңа тиешле ачыклык кертә (15—18 битләр). Ике елдан соң «Галия»дән китеп, Г. Ибраһимов үз тормышында беренче кыю адым атлый. Ул мөстәкыйль рәвештә «тормыш университетларын» үтәргә тели һәм, 1909 ел азагында Казанга килеп, беренче нәүбәттә университетка керергә уйлый. Ләкин бу теләгенә ирешә алмый. Шуннан соң ул үзен татар демократик культурасын үстерү эшенә багышлый, бөтенләе белән иҗат эшенә бирелә. Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Камал, Г. Коләхметов, С. Рәмиев кебек алдынгы язучылар белән якын мөнәсәбәткә керә. Бу вакытларда аның беренче романтик хикәяләре һәм «Яшь йөрәкләр» романы белән «Татар шагыйрьләре» дигән мәгълүм хезмәте мәйданга чыга, шулай Г. Ибраһимов

[1] М. Хәсәнов. Галимҗан Ибраһимов. Рус телендә. Казан. 1969 ел.

әдәби-эстетик карашларының бер этабы формалаша. Шул ук Казан шартларында аның революцион настроениеләре тагын да үсә, самодержавиегә каршы көрәшүчеләр белән актив мөнәсәбәте көчәя. Киев вакыйгалары шуны раслаСалар кирәк. 1912 ел азагында Г. Ибраһимовның Киевкә китүе электән мәгълүм. Әмма аның бу шәһәрдәге мөселман студентлары арасында революцион эше һәм шуның өчен төрмәдә утыруы соңгы елларгача тиешенчә яктыртылганы, бәяләнгәне юк иде. Беренче тапкыр моңа Г. Мөхәммәтова һәм Р. Ганиевалар игътибар итте. М. Хәсәнов хезмәтендә дә, күп кенә архив материаллары җирлегендә, Киев вакыйгаларының эчтәлеге шактый тулы ачыла. Ибраһимовның Казаннан Киевкә китүе нигездә һәм беренче нәүбәттә конспиратив максатлар, яшерен революцион эш алып бару белән бәйләнгән булган икән. Менә шулардан соң язучының дөньяга карашында һәм иҗатында сизелерлек үзгәрешләр барлыкка килүе дә аңлаешлырак булып китә.

1913 елның көзендә Г. Ибраһимов Казанга кайта. Полиция документларыннан күренгәнчә, Г. Ибраһимовның Ш. Әхмәдиев һәм Ф. Сәйфиләр белән газета чыгару теләге булган икән. Моңа рөхсәт бирелмәгәч, Г. Ибраһимов «Аң» журналында җаваплы секретарь булып эшли башлый. Әмма өч айдан соң, 1914 елның 13 февралендә, кабаттан Киевкә китә. Бу факт гадәттә язучының Казан шартларыннан шәхси ризасызлыгы белән генә аңлатыла иде. М. Хәсәнов исә, архив материалларына таянып, моның да революцион эш белән бәйләнгәнлеген исбатлый. Киевкә икенче баруында Г. Ибраһимов Т. Шевченконың 100 еллыгын үткәрү вакыйгаларына туры килә. Шул уңай белән, «Каһарман шагыйрь» дигән мәкалә язып, халыклар, милләтләр азатлыгы өчен көрәшнең бөек украин шагыйре исеменнән аерылмас булуы турында сөйли. Болар һәммәсе бергә Г. Ибраһимовның революцион настроениеләре, демократик идеяләре әдәби-эстетик ноктадан да тирәнәя һәм ачыклана баруын күрсәтәләр. М. Хәсәнов хезмәтендә әнә шул моментка басым ясалуы бик тә урынлы. Чыннан да, берничә ел эчендә тупланган тормыш тәҗрибәсе Г. Ибраһимовта революция темасына багышланган зур әдәби әсәр тудыру теләген тагын да үстергән һәм ныгыткан булса кирәк. 1913 елда Киевтә кулга алынгач, Г. Ибраһимовның тентелгән әйберләре арасында Горькийның «Ана» романы булуы да гыйбрәтле факт. М. Хәсәновның моны Ибраһимов язарга ниятләгән «Безнең көннәр» романына бәйләп аңлатуын да урынсыз дип булмый. Киевтә бер ай торгач, Г. Ибраһимов Кара диңгез буена — Сухумига килә һәм шунда «Безнең көннәр» романының беренче редакциясен язып Казанга кайта. Ләкин, билгеле булганча, роман басыла башлагач конфискацияләнә һәм Октябрь революциясенә кадәр чыкмый кала.

1915 елның көзеннән 1917 елның февраль революциясенә кадәр Г. Ибраһимов Уфаның «Галия» мәдрәсәсендә укытучылык итә. Танылган язучы һәм җәмәгать эшлеклесе буларак, аның бу мәдрәсәдә эшләвенә, М. Хәсәнов фикеренчә, илдә килеп туган иҗтимагый-политик шартлар төп сәбәп була: самодержавие беренче империалистик сугыш елларында политик эшнең легаль формаларын бөтенләй юкка чыгарырга, революцион фикерләрне буып ташларга тели. Жандармерия Г. Ибраһимов өстеннән күзәтүне дә көчәйтә. Шунлыктан аңа бердәнбер мөмкинлектән — татар яшьләрен тәрбияләү, укыту-мәгариф өлкәсендәге мөмкинлектән файдалану юлы гына кала. «Галия» мәдрәсәсендә Г. Ибраһимовның уку-укыту һәм милли тел-әдәбият мәсьәләләре аша демократик рухта эш башкаруын М. Хәсәнов үзенең хезмәтендә киң итеп күрсәтә алган. Г. Ибраһимов тәэсирендә һәм җитәкчелегендә «Галия» мәдрәсәсендәге иске тәртипләргә каршы протест үсә, чын мәгънәсендә фән укыту өчен хәрәкәт көчәя һәм демократик идеаллар белән рухланган яшьләр сафы арта бара. Бу мәдрәсәдән алдынгы карашлы байтак әдәби көчләрнең һәм җәмәгать эшлеклеләренең чыгуы да очраклы түгел. Аларның күбесен, һичшиксез, Г. Ибраһимов шәкертләре һәм көрәштәшләре дип атарга бөтен нигез бар. «Галия» чорында Г. Ибраһимов татар теленә һәм әдәбиятына бәйле күп кенә фәнни-теоретик һәм педагогик-методик мәсьәләләрне күтәрә, яңача эшкәртә. Аның бу эшчәнлеге дә М. Хәсәнов монографиясендә тулы яктыртылган. Болар һәммәсе Г. Ибраһимовның татар культурасы һәм мәгарифе өлкәсендә алдынгы, демократик карашлар өчен көрәшкәнлеген раслап торалар.

1917 елгы февраль революциясе көннәрендә Г. Ибраһимовның революцион-демократик активлыгы киң колач белән ачылып, күтәрелеп китә. Һәм ул, зур җәмәгать эшлеклесе буларак, сыйнфый-политик көрәш

мәйданына атыла. М. Хәсәновның үз хезмәтендәге шул чорга багышланган бүлекне «Революция солдаты» дип атавы бик урынлы диясе килә. Чыннан да, ике революция арасында Г. Ибраһимов үзенең иҗтимагый эшчәнлеген искиткеч активлык белән җәелдереп җибәрә һәм социалистик революция солдатына әверелә. Язучының революция елларында кайнап торган политик вакыйгалар эченә тирәнтен кереп, аларның тарихи мәгънәсен сизгер аңлап эш итүен М. Хәсәнов моңа кадәр телгә алынмаган күп яңа мисаллар белән дәлилләгән. Бу, һичшиксез, М. Хәсәнов хезмәтенең иң уңышлы өлешләреннән берсе. Ул Г. Ибраһимовның революция башында күрсәткән иҗтимагый эшчәнлеген тулы һәм тирән итеп яктырткан. Хезмәт белән танышкач, Г. Ибраһимовның Мөселман комиссариатында эшләгәндә чын мәгънәсе белән революцион-политик тәрбия мәктәбе үткәнлеген һәм социалистик революциянең максат-бурычларына ачык төшенү дәрәҗәсенә күтәрелүен җанлы итеп күрәсең. Революция башында ук Г. Ибраһимовның дөньяга карашында һәм эшчәнлегендә тирән үзгәреш барлыкка килә, ул тиз арада революцион-демократик позициядән пролетар-социалистик идеологиягә кискен борылыш ясый. Г. Ибраһимов алдынгы татар интеллигенциясенең беренче сафына баскан, бик күпләрне үз артыннан иярткән һәм бик күпләргә үрнәк булган көрәшчегә әйләнә. Шушы хакыйкатьне М. Хәсәнов җитәрлек факт һәм мисаллар белән раслаган.

Социалистик революциянең беренче елларында алган бай политик тәҗрибәсе Г. Ибраһимовның аннан соңгы җәмәгать һәм иҗат эшчәнлегенә төп юнәлеш бирә, нык җирлек әзерли. Аның идеология, культура һәм әдәбият өлкәсендә күрсәткән тырышлыгы М. Хәсәнов монографиясендә шулай ук тулы яктыртылган. Моңа кадәр бөтенләй читләтелгән яки телгә генә алынып үтелгән күп мәсьәләләргә, күп санлы фактларга таянып, объектив бәя бирелгән. Мисал өчен язучының милли мәсьәләгә һәм шул исәптән яңалифкә мөнәсәбәтен генә алып карарга мөмкин. Г. Ибраһимов үзе исән чакта да һәм аннан соң да аның бу мәсьәләләргә карашы күбесенчә кире мәгънәдәрәк, шәхси хаталары итеп телгә алына иде. Боларга карата М. Хәсәнов күп кенә хаклы фикерләр әйтеп, тарихи дөреслекне икенче яктан күрсәткән һәм моны коры сүз белән түгел, ә архив документлары белән раслаган. Г. Ибраһимовның революциядән соң башкарган барлык эшчәнлеге күз алдыннан кичкәч, укучы каршысына аның совет чорында формалашкан зур язучы, җәмәгать эшлеклесе һәм галим булып килеп басуы шиксез. Аның шушы өч төрле эшчәнлеген бер-берсеннән аерып карау кыен. М. Хәсәнов әнә шул өч моментны бергә бәйләп тикшерү юнәлешендә уңышлы адым ясаган.

Югарыда сөйләнгәннәр, әлбәттә, монография эчтәлегенең тик төп схемасын яки канвасын гына күз алдына китерергә мөмкинлек бирәләр. Анда тупланган барлык яңа факт һәм материалларны санап кына чыгу өчен дә әллә никадәр урын кирәк булыр иде. Бер рецензия дә андый җентекле анализны үзенә мәҗбүри бурыч итеп куя алмый. М. Хәсәнов монографиясенең тулы эчтәлеге белән танышу, әлбәттә, укучының үз ихтыярына кала.

Тагын да без игътибарны һәрбер гыйбрәтле фәнни хезмәт белән танышканнан соң туа һәм уйландыра торган кайбер бәхәсле яки аеруча басым ясауны таләп иткән мәсьәләләргә юнәлтү кирәк дип уйлыйбыз. Шулардан берсе итеп, Г. Ибраһимовның Октябрьга кадәрге әдәби-эстетик карашлары үсешен билгеләү, бәяләү мәсьәләсен алырга мөмкин.

Бездә дә иҗат методларын һәм әдәби юнәлешләрне теоретик-фәнни өйрәнү юлында әһәмиятле адымнар ясала башлады. Бигрәк тә XX йөз башы һәм совет чоры татар әдәбиятына багышланган хезмәтләрдә бу мәсьәләләр теге я бу күләмдә чагылыш табалар. Ләкин һәр очракта да бу мәсьәләләр тарихи һәм фәнни яктан дөрес, тулы бәя алалар диган нәтиҗә ясарга иртәрәк кебек. Мәсәлән, критик реализм, романтизм һәм социалистик реализм төшенчәләрен татар әдәбиятына нисбәтән аңлауда һәм аларның үзара мөнәсәбәтләрен яки аерымлыкларын билгеләүдә безгә күп тырышлык күрсәтергә кирәк әле. Болай булмаганда, әнә шул «өч нарат» арасында буталып йөрүләр дәвам итәчәк. Чынлап та, шул ук Г. Ибраһимовның Октябрьга кадәрге иҗат методын билгеләү тирәсендә фәкать соңгы елларда әйтелгән фикерләрне генә алып карасак та, байтак чуарлыклар табарбыз. Берәүләр аның ул чорын туры мәгънәсендә критик реализм белән, икенчеләр прогрессив романтизм белән, ә өченчеләр исә тегесе белән дә, монысы белән дә бәйләп карыйлар. Мондый хәл, бер яктан, иҗат методының катлаулы бер эстетик төшенчә булуын күрсәт-

сә, икенчедән, безнең әдәбият фәненең моны аңлауда күптән билгеле, әзер штамплардан да, субъектив карашлардан да бөтенләй үк азат булмавы турында сөйли шикелле. Шулай ук мәсьәлә теге яки бу карашны яклаучыларга: «Синеке дөрес, ә синеке ялгыш», дип мөһер сугу белән генә дә җиңел хәл ителмәс. Тик тирән тарихи-фәнни тикшерену һәм тәпле бәхәсләр җирлегендә генә ниндидер уртак фикергә килү мөмкин.

Г. Ибраһимовның иҗат методына карата М. Хәсәновның элеккерәк хезмәтләрендә дә байтак фикерләр әйтелгән иде. Һәм бусында да аларга билгеле күләмдә урын бирелгән. Дөрес, хезмәтнең характерына һәм максатына нисбәтән, Г. Ибраһимовның эстетик карашларын һәм әдәби иҗатын анализлау кайбер очракларда тезислар төсендә генә бирелә. Әмма бу әллә ни зур гаеп түгел. Гомумән алганда, безнең хәзерге әдәбият фәненең Г. Ибраһимовны XX йөз башындагы татар әдәбиятында прогрессив романтизм вәкиле итеп каравы билгеле инде. М. Хәсәнов та бу фикерне тулысы белән уртаклаша һәм үстерә: «Г. Ибраһимов иҗатында романтизм бигрәк тә 1910—1912 елларда аеруча ачык күренде, шуңа күрә аны 1905—1906 елгы революциядән соң килгән рәхимсез реакция тудырган күренеш итеп түгел, ә яңа революцион күтәрелешкә авазадашлык итеп карау хаклы булыр. Ниһаять, Ибраһимов иҗатындагы романтизмны татар әдәбиятындагы романтик тенденцияләр белән тыгыз бәйләнештә карарга кирәк, чөнки романтик юнәлеш — халык рухының романтик сыйфатын ачык чагылдырган милли поэзиянең дә, прозаның да характерлы үзенчәлеге иде» (35 бит).

Һичшиксез, тарихи һәм фәнни җирлеге дөрес булган фикерләр әйтелгән. Инде мәсьәләгә конкрет килгәндә, белгечләребез арасында бу фикерләрнең эчтәлеген ачу төрле-төрле, хәтта чуар булып китүе дә гаҗәп саналмаска тиеш. Чөнки фәнни эзләнүләрнең туры юлдан гына, туры сызыктан гына бармавын исбатлап торасы юк. Шулай да бу эзләнүләрнең кайбер әһәмиятлерәк якларын алып караганда, фикер башкалыкларының бик үк ышандырырлык һәм нигезле булмаганлыгын да күрергә туры килә. Бер характерлы мисал төсендә, мәсәлән, Г. Ибраһимов иҗатында романтизм белән реализм бәйләнешенең кайда, нинди очракларда һәм күпме дәрәҗәдә булуын билгеләү тирәсендәге фикерләрне алырга мөмкин. Менә шунда безнең әдәбият фәненең берничә әһәмиятле моментка тиешенчә игътибар итеп җиткермәве аркасында килеп чыккан кыенлыклар белән очрашабыз. Шуларның берсе романтизм белән реализмны капма-каршы куеп, теләсә кайсы алдынгы язучының иҗат методы гел реализм гына булырга тиеш дип караудан гыйбарәт. Шундый караш нәтиҗәсендә булса кирәк, XX йөз башындагы татар әдәбиятында реализм белән романтизм арасындагы катлаулы бәйләнешкә игътибар тик башлангыч хәлендә генә тора әле. Шул процесста туган яңа сыйфатлар һәм үзенчәлекләр нидән гыйбарәт иде? — дигән сорауга җавап урыны да безнең хезмәтләрдә ачык кала. Икенче кыенлык — иҗат методларының чынбарлык, тормыш белән бәйләнешен караганда, реализм һәм романтизм эстетикасының төп критерийларын бер-берсе белән бутау яки алмаштыру. Шуннан инде теге яки бу язучы иҗатында урын алган тормыш материалын тик реализм эстетикасына гына хас дип санау шикелле берьяклы караш килеп чыга. Мәсәлән, электә үк инде татар әдәбиятындагы романтизмның типик бер үрнәге итеп саналган[1] «Яшь йөрәкләр» романында реализм эстетикасын табарга теләү шундый карашның бер чагылышы булып тора. Чынлыкта исә бу романдагы тормышчан сурәт һәм картиналар прогрессив романтизм эстетикасының да тормыш белән бәйләнеше барлыгын гына раслыйлар. Дөрестән дә, әнә шул хакыйкатьне истән чыгармаганда, «Яшь йөрәкләр» романын тулы мәгънәсендә романтизм әсәре дип бәяләргә туры киләчәк. Шуңа күрә аны тартып-сузып реализмга бәйләргә тырышу белән түгел, ә романтизм әсәре итеп бәяләү белән генә без фәнни дөреслеккә ирешербез.

Шулай ук «Яшь йөрәкләр»дә язучының иҗат методы икелекле, эклектик дигән концепцияне дә кабул итүе кыен. «Бирелә инде без,— ди, мәсәлән, И. Нуруллин,— реализм белән романтизм тартышын күрәбез һәм, гомумән, әсәр романтизм белән реализмның янәшә яшәве, ике төрле алым, манера, стильнең аралашып килүе белән характерлы[2]. Безнеңчә, монда да шул ук нәрсә — романтизм эстетикасында тормышчанлык булмаска тиеш дигән караш

[1] Г. Нигъмәти. Сайланма әсәрләр. 1958 ел. «Г. Ибраһимов һәм аның иҗат юлы» дигән мәкаләне карагыз.

[2] И. Нуруллин. XX йөз башы татар әдәбияты. Казан. 1966 ел. 265 бит.

тәэсиреннән котыла алмау гына чагылса кирәк.

Әйе, 1912—1913 еллар тирәсендә Г. Ибраһимов иҗатында романтизм концепцияләре аеруча кискен төс алалар. Шуның бер калку һәм үзенчәлекле гәүдәләнеше булып «Татар шагыйрьләре» мәйданга чыга. Бу әсәр белән «Яшь йөрәкләр» арасына киртә куеп булмый. Аларның икесендә дә бер үк романтик концепцияләр беренчесендә теоретик планда, икенчесендә әдәби-сәнгатьчә итеп формалаштырылды. Аларның икесендә дә язучының бу чордагы романтик карашларына хас булган индивидуализм һәм субъектизм өстенлек итә әле. Ә безнең әдәбият фәнендә моны мөмкин кадәр читләтергә омтылыш сизелә. Шуның бер мисалы тагын Г. Ибраһимовның Тукай иҗатындагы халыкчанлыкка һәм реализмга кире карашын искә алмаска тырышуда да күренә. М. Хәсәнов хезмәтендә дә мондый «искә алып җиткермәү» бар әле. Ә ни өчен тарихи дереслеккә күз йомарга? Бу дереслекне күрсәтү белән без Г. Ибраһимовны гаепләргә җыенмыйбыз бит, ә аның эстетик карашлары нинди кыенлык, каршылык һәм эзләнүләр аша алга баруын күрсәтүне генә максат итәбез. Г. Ибраһимов татар әдәбиятында яңа бер әдәби агым тарафдары буларак чыккан икән, димәк, аның икенче әдәби юнәлеш һәм методларның кайбер принципларын инкарь итүе яки үзенчә бәяләве — бик табигый һәм зарури күренеш. Ләкин моңа карап Г. Ибраһимовның алдынгы әдәбият өчен көрәшүче булуына кимчелек килмәячәк, ә, киресенчә, ул алып барган әдәби көрәшнең җиңел булмаганлыгы расланачак. Чыннан да, Г. Ибраһимовның Октябрьга кадәрге әдәби-эстетик карашларында гомумән традицион романтизмга хас субъективизм һәм индивидуализм күпме генә көчле булмасын, язучының революцион-демократик идеяләргә бәйле иҗатында торган саен тормышчанлык һәм халыкчанлык принциплары ныгый барганы сизелә иде. М. Хәсәнов хезмәтендә дә бу моментка игътибар ителгән. Әмма аның монографиясе турыдан-туры иҗат методлары мәсьәләсенә багышланмаганлыктан, автор үзе тәкъдим иткән кайбер концепцияләрне анализлауга тиешле урын һәм ачыклык биреп җиткерә алмаган, әлбәттә. «Романтизмның мәйданга килүе прогрессив күренеш иде, чөнки ахыр чиктә ул реализмның тирәнәюенә һәм баюына булышты. Ул бер Г. Ибраһимов иҗатының гына түгел, ә бөтен татар әдәбиятының үсешенә куәтле этәргеч бирде, анарда эмоциональ башлангычның көчәюенә китерде, аны кешенең эчке дөньясына тирән үтеп керү мөмкинлеген биргән психологизм шикелле кыйммәтле сыйфатка баетты, сурәтләү чаралары арсеналын байтак киңәйтте. Социалистик реализмга аның аерылмас состав өлеше булып кергән революцион романтизм үзенең тирән тамырлары белән Октябрьга кадәрге прогрессив романтизм катламына китә. Бу бәхәссез тарихи факт һәм аны кире кагу турында уйлау мөмкин түгел» (36 бит),— дип раслый М. Хәсәнов. Әйтелгән фикер бик зур һәм кызыклы. Ләкин монографиядә Г. Ибраһимов иҗатындагы романтизм белән реализм мөнәсәбәте авторның без искә алган концепцияләре яктылыгында эзлекле һәм тулы итеп ачылмаган әле. Ул концепцияләр күбесенчә вәгъдә, заявка булыбрак калалар. Бирелгән анализлар исә «романтизмнан реализмга» кебек схеманы да искә төшерә. Ә инде кайбер белгечләр шул схемага тотынып, М. Хәсәнов хезмәтендәге теоретик мәсьәләләрне һәм, хосусан, Г. Ибраһимовның иҗат методы мәсьәләсен бик туры гына, җиңел генә хәл итү юлыннан барырга телиләр. Мәсәлән, Х. Хәйри М. Хәсәнов монографиясенә язган рецензиясендә: «Г. Ибраһимов — реалист олы язучы, аның Октябрьга кадәрге иҗаты критик реализм юнәлешендә үсте. Октябрьдан соң ул татар әдәбиятында социалистик реализмны нигезләүчеләрдән берсе булды — М. Хәсәновның тикшеренүләрендә үтәли үткән төп сызык, төп фикер менә шул»[1],— дигән бик билгеле нәтиҗә ясау белән чикләнә. Рецензентның тел төбендә Г. Ибраһимовның иҗат мирасын «критик романтизмнан социалистик реализмга» схемасыннан һич тә читкә чыгармаска теләү ятканлыгы сизелеп тора. Мәсьәләнең болай куелышы инде реализм белән романтизмның Г. Ибраһимов иҗатындагы үзара бәйләнешен, мөнәсәбәтен өйрәнүгә юл калдырмый.

Искә алмый калуы кыен булган икенче бәхәсле мәсьәлә «Безнең көннәр» романының язылу датасын һәм язучы иҗатындагы урынын билгеләү белән бәйле. Мәгълүм булганча, бу әсәр 1914 елда язылып та басылмый калган. Ул беренче мәртәбә 1920 елда чыга, һәм шул чор тәнкыйте аны татар совет әдәбиятының күренекле үрнәге дип кабул итә. Әсәрнең азагында «1914—

[1] «Социалистик Татарстан» газетасы, 1970 ел, 6 май саны.

1920» дип куелган. Ә мондый дата «Безнең көннәр» шул еллар аралыгында эшләнгән дигән мәгънәне генә аңлатырга мөмкин. Аннан соң Г. Ибраһимовның элекке әсәрләрен күпчелек очракта яңадан редакцияләп бастыруын да онытмаска кирәк. Һәм бу редакцияләүләрдә яхшы ук принципиаль характердагы үзгәрешләр була торган иде. «Безнең көннәр» романының да 1920 елгы беренче басмасы 1914 елгы вариант кына булмаганлыгын тагын аның эчтәлегеннән аңларга мөмкин. Анда иске һәм яңа редакцияләрнең аралашуын күрсәткән фактлар ярылып яталар; болар арасында язучының 1914 ел тирәсендә әле әйтүе һәм сурәтләве һич тә мөмкин булмаган элементлар аз түгел. Бу мәсьәлә аерым тикшерү һәм анализ таләп иткәнлектән, хәзергә әйтеп китү белән генә чикләнергә мәҗбүрбез.

Әгәр дә «Безнең көннәр» тик 1914 елгы вариант төсендә генә басылган булса, бу әсәр язучының аннан соңгы әдәби әсәрләреннән һәм эстетик карашларыннан күп югары торган бер очраклы факт булып калачак. Ләкин мондый хәлнең булуын раслау кыен. Ниһаять, тагын Г. Ибраһимовның замандашлары фикеренә дә колак салмыйча булмый. Мәсәлән, Шиһап ага Әхмеров үзенең бер чыгышында[1] «Безнең көннәр» романын авторның, 1920 елгы басма өчен, үз кулы белән яңадан язып, типографиягә өлешләп җибәреп торганлыгын әйткән иде. Менә шул сөйләнгәннәрнең һәммәсен искә алып, Г. Ибраһимовның бу романын аның ике чор иҗаты арасында торган яки ул чорларны бер-берсенә бәйләгән әсәр итеп санарга һәм 1914 елгы вариант 1920 елда яңадан эшләнгән дигән нәтиҗә ясарга батырчылык итәбез. Шуңа күрә дә И. Нуруллинның («XX йөз башы татар әдәбияты». 1966) һәм М. Хәсәновның «Безнең көннәр» романын тулаем 1914 елга кайтарып калдыруларын, реаль фактлар белән бик үк исәпләшмичә, Г. Ибраһимовның Октябрьга кадәрге иҗатын, аның идея-эстетик карашларын тагын да баетыбрак күрсәтү өчен эшләнгән бер алым булса кирәк дияргә туры килә. Дөрес, алар кулында язучының байтак вакытлардан соң үзе язган аңлатмасы бар. Ләкин бу аңлатманың ни өчен һәм нинди шартларда язылганын да онытмаска иде. Әдәбият фәнендә вульгар социологизм хөкем сөргәндә, «Безнең көннәр»нең 1920 елгы басмасы турыдан-туры эсерлык идеологиясен үткәргән әсәр дип, авторны хаксызга һәм тупас рәвештә гаепләп чыгулар мәгълүм. Г. Ибраһимовның аңлатмасы нигезендә шундый уйдырмалардан үзен аралап калу өчен эшләнгән булуы мөмкин түгелмени?!. Аның үз иҗатындагы романтизм турында да шуңа охшаш фикере бар ич. Язучының билгеле бер шартларда әйтелгән шәхси фикерләрен тулаем теоретик принципка әйләндерү әдәбият фәне өчен мәҗбүри түгел.

М. Хәсәнов монографиясендә, беренче мәртәбә дияргә кирәк, «Безнең көннәр» романының 1934 елгы соңгы редакциясенә булган характеристикага киң урын бирелгән, һәм бу редакциянең беренчесеннән аермасын ачыклау юнәлешендә зур эш эшләнгән. Соңгы редакциянең иҗтимагый эчтәлеге никадәр бай булуына һәм авторның тарихи-революцион карашнe социалистик реализм позициясеннән торып сурәтләвенә ышандырырлык дәлилләр китерелгән. «Безнең көннәр»нең соңгы редакциясенә ясалган анализ Г. Ибраһимовның совет чорында дөньяга карашы никадәр тиз үсүе турында сөйли. Һәм бу үсеш аның әдәби-эстетик эшчәнлеге белән тыгыз мөнәсәбәттә баруын һәм формалашуын күрсәтә.

М. Хәсәнов монографиясенең тагын бер отышлы ягы итеп Г. Ибраһимовның социалистик революциядән соңгы тарихи һәм әдәби карашларын мөмкин кадәр тулы итеп ачарга теләвен күрсәтергә кирәк. Монда хәзергәчә безнең әдәбият фәне күзеннән читтәрәк торган күп чыганаклар искә алынып, аларның эчтәлегенә һәм әһәмиятенә зур урын бирелгән. Г. Ибраһимовның бигрәк тә 20 нче елларда чәчәк аткан фәнни-әдәби эшчәнлеге гаҗәп киң булганлыгын һәм язучы безнең идеология фронтының алгы сафында торып иҗат иткәнлеген күрсәтә. Шуның белән бергә үк, бу мәсьәләнең тагын кайбер әһәмиятле якларына игътибар итү кирәк булганлыгын да, шундый ихтыяҗ туганлыгын да сизәсең. Шулардан берсе — 20 нче елларда Г. Ибраһимов иҗат иткән иҗтимагый һәм әдәби атмосфераның катлаулылыгын тулырак, конкретрак күрсәтү безнең хезмәтләрдә җитәрлек түгел әле. Күп очракта без язучының үз эшчәнлеген характерлау белән чикләнеп, аның заманы һәм заман белән бәйләнеше турында аз сөйлибез. Әгәр без моңа да тиешенчә игътибар бирсәк, язучы башкарган эшнең дәрәҗәсе һәм кыйммәте

[1] Бу чыгыш 1967 елның 10 мартында А. Шамов җитәкчелегендә үткәрелгән истәлекләр мәҗлесендә булган иде.— Г. Х.

калкурак, үзенчәлекләрәк булып күренәр иде. Аеруча Г. Ибраһимов шикелле эшлеклеләрнең шундый тарихи-әдәби фонда бәяләнүен күрергә теләү бик табигый, әлбәттә. Әмма монда шулай ук безне кәтеп торган кайбер кыенлык һәм каршылыкларга да айнык караш таләп ителәчәк. Ә безнең әдәбият фәнендә мондый карашның бик үк житеп бетмәвен дә инкарь итеп булмый. Шуның бер мисалы итеп, 20 нче еллар дәвамында үзен нык сиздергән вульгар социологизмга мөнәсәбәтне алырга мөмкин. Бигрәк тә татар әдәбият фәне үсешендә бу күренешнең тирән эзләре һәм зарарлары калганлыгын күрми эш итү тарихи һәм фәнни сукырлык булыр иде. Марксизм исеменнән сөйләнгән бу үтә сул вак буржуаз карашлар совет әдәбиятын һәм сәнгатен бозып аңлаттылар һәм бәяләделәр. Марксистик тәнкыйть традицияләре житәрлек булмаган безнең әдәбият фәнендә вульгар социологизм принципларына ияру аеруча нык күзгә ташланып торуын һич тә яшерергә кирәкми. Сәнгатьне һәм культураны турыдан-туры базиска бәйләнгән өскорма дип карау, ягъни бу сыйнфый-идеологик күренешләрнең башка өскорма күренешләреннән аермасын күрмәү аркасында, сәнгатьне, аның төп образлы үзенчәлеген һәм тормышка мөнәсәбәтенең катлаулы булуын исәпкә алмыйча бәяләү гамәлгә кереп китте. Мондый караш, әлбәттә, марксистик эстетиканы аңламау һәм бозу нәтиҗәсе иде. Вульгар социологизм алдынгы язучыларны реакцион сыйныфлар лагерена бирде. Ниһаять, вульгар социологизм иҗат методларын билгеләүгә дә реализмны материализмга, ә романтизмны идеализмга тиң итеп карау ноктасыннан килде. Шуның нәтиҗәсендә романтизм гомумән совет әдәбиятына чит күренеш дип кире кагылды һәм реализм белән романтизм арасына үтеп чыга алмаслык кирттә корылды. «Хәзер инде мондый операциянең зарарлы булуы билгеле. Вульгар социологизмның караңгы фанатизмы да, «бердәм агым» теориясенең ал тескә буялган тарафдарлары талымсызлыгы да бер үк дәрәҗәдә марксистик әдәбият фәненә чит»[1].

Бу сөйләнеп үтелгәннәрнең Г. Ибраһимовка нинди мөнәсәбәте бар соң, дип сораулары мөмкин. Бар шул. Г. Ибраһимов, язучы һәм социолог-галим буларак, нәкъ шундый теорияләр кыздырылган вакытта иҗат итте. Шуңа күрә аларга аның берничә ноктадан мөнәсәбәтә булырга мөмкин. Беренчедән, язучы үзенең теоретик-социологик карашларында һәм әдәби иҗат практикасында вульгар социологизм таләпләреннән ничек югары торды, аларга ничек каршы барды? Икенчедән, марксистик социология белән коралланганда һәм социалистик реализм юлына чыкканда, ул нинди кыенлыклар, каршылыклар кичерде? Г. Ибраһимов совет язучысы булып формалашкан чорның үзенчәлеген истә тотканда, бу сорауларны читләтеп узу һич мөмкин түгел.

Без сугышка кадәрге, аеруча 20 нче еллар татар әдәбияты фәне тулаем вульгар социологизм платформасында торды дигән караштан ерагкбыз. Бу хакта аерым мәкаләләр дә, хәтта монографияләр дә язылды инде. Ул еллардагы әдәбият фәненең һәм тәнкыйтенең марксистик таза тенденцияләре көннән-көн ачыклана һәм үсә баруы күптән исбат ителгән. Шулай ук анда реализмны да, романтизмны да дөрес юнәлештә аңлау бөтенләй юк иде, дигән фикерне дә уртаклашырга җыенмыйбыз. Һәм, икенче яктан, элекке әдәбият фәненең, элекке тәнкыйтьнең уңышларын идеаллаштыру, күпертү исәбенә, аңа зур тоткарлык ясаган вульгар социологизмнан бөрек ташлап кына котылып булмаячак, чөнки аның калдыклары бүген дә бар, аларга каршы көрәшергә кирәк.

М. Хәсәнов монографиясендә исә вульгар социологизм концепцияләрен һәм аның Г. Ибраһимов иҗатына ясаган тәэсирен тәнкыйтьләү өлешчә бар. Әлбәттә, аның төп максаты — язучының әдәби-теоретик карашларында марксистик принциплар ничек өстенлек ала һәм ныгый баруына игътибарны беренче планга куеп күрсәтүдән гыйбарәт. Ул үзенең шул максатына нигездә ирешкән. Әмма шуның белән бергә, әдәби-теоретик көрәш фонының тулылыгын да күрсәтә килә.

Җыеп кына алганда, М. Хәсәновның яңа монографиясе, алда әйткәнебезчә, Г. Ибраһимовның иҗат мирасын төрле яклап һәм бер бөтен итеп өйрәнү юлында уңышлы тәҗрибә булып тора. Аның белән танышкач, күз алдына язучының бай һәм катлаулы тормыш юлы үтеп, тукталусыз көрәшеп һәм иҗат итеп яшәгән зур образы килеп баса.

---

[1] Б. Мейлах. Вопросы литературы и эстетики. Рус телендә. Ленинград. 1958 ел. 238 бит.

# САЛАВАТ КҮПЕРЕ

ДРАМАДАН ФРАГМЕНТ

*Һәрбер шагыйрьдә булган кебек үк, мәрхүм Гали Хуҗиевның да шактый зур архивы бар. Бу юлы безгә аның «Салават күпере» дигән драматик поэмасы белән таныштырырга туры килде. Зур күләмле бу әсәрне автор сәхнәгә кую өчен язган. Үзе исән булса, шагыйрь аны театрларга тәкъдим итәр иде. Бәлки эш арасында автор үзенең бу әсәренә яңа бүлекләр, өстәмәләр, төзәтүләр дә керткән булыр иде. Ләкин вакытсыз үлем аның гомерен өзде. Күренгәнчә, Г. Хуҗиев бу әсәрен әле беркая да тәкъдим итәргә өлгермәгән. Бәлки әсәр өстендә әле кабат эшләргә дә кирәк булгандыр.*

*Без бу санда «Казан утлары» журналы укучыларын шул драматик поэманың бер кисәге белән таныштырырга булдык. Әсәр зур. Анда бик күп геройлар телгә алына. Әсәрнең төп юнәлешендә сугыш елларында тылдагы авыр тормышны һәм дошманны җиңү өчен көрәш көннәрен чагылдыру ята. Драматик поэмада бер-берсен өзелеп сөйгән яшь егет белән яшь кыз да бар. Алар әсәрнең төп геройлары. Бу фрагмент әсәрнең эчтәлеген дә, стилен һәм художество чараларын да беркадәр күз алдына бастырыр дип уйлыйбыз.*

Брест крепосте подвалы. Стеналарда: «Совет Ватаны өчен!», «Хакыйкать җинәр», «Без гомеребезне хак эш өчен бирәбез, безне онытмагыз!» — дигән язулар. Бер почмакта — подвалга төшеп-менеп йөри торган баскыч; шунда ук берничә ящик. Пәрдә ачылганда Хафиз ялгыз.

Хафиз *(урыныннан торып).*

Бишенче көн ятам бу подвалда.
*(Күкрәген тотып.)*
Сызлый ярам биш көн тоташтан.
Камауда без.
Дары сөреме исе,
Янгын исе килә һәр таштан.

Утлы киртә аера алмас безне,
*(Гимнастерка кесәсеннән фото чыгарып.)*
Сәрвиназым, сине белән мин.
*(Подвал тәрәзәсеннән төшкән яктылыкка төбәлеп.)*
Сине
Утлар аша, сугыш сөреме аша
Күңел күзем белән күрәм мин.

Һәм ышанам: һәрчак йөрәгеңдә
Йөртерсең син мине, Сәрвиназ!
Еллар аша дингез-таулар аша
Ишетерсең син мине, Сәрвиназ!
*(Бераз уйланып йөргәч, яңадан яктылыкка төбәлеп.)*

Озакламый, Брест туфрагында
Йомылырлар, бәлки, күзләрем;
Йөрәгемдә йөргән иң кадерле
Тойгыларым, әйтер сүзләрем
Үзем белән бергә күмелмәсен;
*(Кесәсеннән тауштлып беткән дәфтәр чыгара һәм ящик өстенә куеп яза.)*
Язып калыйм... сугыш аяусыз...
Бу юлларым житсә сезгә барып,
Күңелләрне безнең аңларсыз...

Иделбай төшә. Кулында винтовка. Ул тир-тузанга баткан, йөзенә бронза төсе кергән.

Иделбай.

Я, хәлләрең ничек, Хафиз дус?

Хафиз.

Сулыйм әле.
Якыннарга иң соңгы
Сәламем юллыйм әле.

Иделбай.

Сугыш тынып торган арада
Бераз су тапкан идек.
*(Каешыннан алып, фляга суза.)*
Мә, эч әле, китәр хәл кереп.

Хафиз *(йотылып эчкәч)*.

Шундый сусаткан иде.
Рәхмәт инде! Исенә, дускай,
Мине дә төшергәнсең.
Син бит миңа тик су түгел,
Ә яшәү китергәнсең.
Әйе, яшәү китергәнсең.

Иделбай.

Хәлеңне, дускай, аңлыйм.

Хафиз.

Күңелемнең һәр омтылышын
Хатларда сөйләп калыйм.
Житсен алар якыннарга
Кырыс хикәят булып.

Иделбай.

Я, я, Хафиз, алай артык
Бирелмә әле хискә;
Савыгырсың; өзмә өмет,
Төшермә күңелең һич тә.

Хафиз.

Белмим, индер сизә күңелем...

Иделбай.

Болай диген син аңа:
«Кош һавада, ат юлларда,
Егет яуда сынала».

Хафиз.

Әйе, халык дөрес әйткән,
Бездән шулай сорала.
«Кош һавада, ат юлларда,
Егет яуда сынала».

Иделбай *(сәгатенә карап)*.

Хуш хәзергә! Мине көтәләрдер.
Сугыш бит, булмый соңлап...

*(Ашыгып менеп китә.)*

Хафиз.

Мондый дуска һәрчак һәм һәркайда
Ышанып була чынлап.

*(Язуын дәвам иттерә.)*

Сәрвиназым, сүзем шушы сиңа:
Авыр чакта күңелең төшмәсен
Һәм балабыз кеше арасында
Күз көеге булып үсмәсен...

Лейтенант Зиннур Шакиров төшә. Ул да тир-тузанга баткан; йөзе кояшта янган.

Зиннур.

Я, хәлегез ничек, иптәш Вафин?

Хафиз.

Күрәсез, әйбәт түгел.
Хәер, аңлыйм, бу сугышта
Кемгә дә булмас җиңел.

Зиннур *(фотоны күреп)*.

Бу — кемегез?

Хафиз.

Сөйгән яшьлек дустым
Сәрвиназ бу. Менә аңарга
Соңгы хатлар... Булса вакытыгыз,
Телим сезгә укып карарга.

Зиннур.

Я, ничегрәк яздың икән;
Укы, укы; тыңлыйм, туган.
Туган якка хатың аша
Мин дә сәлам юллыйм, туган.

Хафиз *(ара-тирә караштыргалап, яттан укый)*.

Син дигәндә уттай кабындым,
Синең өчен яндым-көйдем мин.
Йөрәк сагышы белән сагындым,
Йөрәк сагышы белән сөйдем мин.

Күңелем һәрчак сине эзләде,
Син, дидем мин һәрбер сулышта.
Күрешмәбез, бәлки, гомергә,—
Үкенечләр була тормышта,
Көенечләр була тормышта...

Зиннур *(бүлдереп).*

Нигә алай дисең? Савыгырсың.

Хафиз.

Әйтәм бит кабат:
Үз хәлемне үзем беләм,
Иптәш лейтенант!

Зиннур.

Барысын, якташ, хисле язгансың;
Ләкин өмет өзмә;
Өзәрбез дә дошман бөҗрасын,
Чыгарбыз бер без дә.

Югарыдан: «Лейтенант Шакиров! Лейтенант Шакиров!» дигән тавыш ишетелә.

Зиннур.

Комбат дәшә. Хуш хәзергә!
Алай өмет өзмә бер дә.

*(Ашыгып өскә менеп китә.)*

Югарыда ату тавышы ишетелә. Хафиз укуын дәвам итә.

Җитсә сиңа соңгы хәбәрем,
Һичбер урын калмас көнләүгә.
Ләкин сине минем кадәрле
Якын итә алмас берәү дә...

Яралы солдатны күтәреп, комбат һәм лейтенант төшәләр.

Хафиз.

*(Бераз аптырап торгач, аларга таба ташланып.)*
Иделбай дус, син дә яралымы?
Ничек булды?..

Комбат.

Мина тиясе
Пуляны ул үз гәүдәсе белән...

Иделбай *(бераз аңын җыеп).*

Һәркем дә бит шулай эшләр иде,
Булса әгәр минем урынымда.
Иптәш комбат!
Коткарырсыз, бәлки, батальонны,
Сез кирәгрәк сугыш кырында.
Иптәш комбат, алай-болай булсам,
Сөйгән нәни улым кала.
Бу сугыштан исән котылсагыз,
Булышыгыз, зинһар, аңа:
Һөнәр алсын, рәтле кеше булсын.
Ышанычым сездә минем!

Комбат.

Тормышыңа тәңгәл яхшылыкны
Онытырга мөмкинмени?!.
*(Китәргә җыенып.)*
Сугышчылар көтә безне.

Хәл белербез, төшеп кабат.

*(Хафизга).*

Сез карагыз Иделбайны.

Хафиз *(честь биреп).*

Есть, була ул, иптәш комбат!

Комбат һәм лейтенант баскычтан өскә менеп китәләр. Хафиз яралы янында кала.

Нишлисең бит, дускай!.. Давылларда
Ава шулай кайчак имән дә.

Иделбай.

Һичбер күреп туймас якты дөнья
Кала, ахры, инде миннән дә.—
Җир-су, кояш, көткән язлар кала;
Якыннарым кала;
тормышны
Үзгәртүче яхшы кешеләр кала...
*(Хафиз кулына башын салып.)*
Алыйм, дускай, соңгы сулышымны,
Башым куеп синең кулыңа.
Еракларда мине сагынып көткән
Газиз анам сөйгән улына
Рәнжемәстер, яуда сынатты, дип,
Ышанычын җиргә салмадым.
Тик кызганыч,
Кайтып, соңгы тапкыр
Уралымны күрә алмадым.
*(Хафизны кочаклап.)*
Хуш, дускаем, без дә аерылабыз,
Аерылмастай идек гомергә...

Хафиз.

Әйе, дускай, ут күршеләр булып
Яшәр кебек идек гел бергә.

Иделбай.

Аерды шул безне нәләт сугыш,
Исән калсаң, мине онытма...

Хафиз *(тетрәнеп).*

Иделбай дус,
Күзләреңне кабат
Ачсаң иде тик бер минутка...
*(Аның күкрәгенә каплана. Бераздан торып.)*
Иделбай дус, тыныч йокла!
Бу дәһшәтләр тиздән үтәрләр.
Без яклашкан изге эшне
Исән дуслар дәвам итәрләр,
Улларыбыз дәвам итәрләр.

Комбат төшә. Кулында фляга.

Комбат *(Иделбайны күреп).*

Иделбай ял итәмени?

Хафиз *(тиз генә торып).*

Ул ни... иптәш комбат!
Ул күзләрен беркайчан да
Ачмас инде кабат...

Комбат *(баш киемен салып, бераз сүзсез торгач).*

Хуш, Иделбай! Тыныч йокла, туган!
Гражданины булып туган илнең,
Үкенмәслек итеп яшь белден
Һәм солдаты булып үлә белдең.

Иделбай гәүдәсен подвалның икенче ягына кертеп куялар. Комбат Хафизның ярасын төзәтеп бәйли.

Шулай, туган, ниләр кичерсә дә,
Иелмәскә тиеш ир башы.

Хафиз.

Коммунистлар икән — һәр солдатның
Аерылгысыз, якын юлдашы.
Сез икәнсез! Сезгә ышанам мин.
Минем хәзер авыр чакларым.
*(Дәфтәр күрсәтеп.)*
Менә минем тормыш иптәшемә
Һәм анама язган хатларым.
Телим барысын сезгә тапшырырга,
Саклау җаен үзегез карарсыз.
*(Дәфтәрен суза.)*
Бу сугыштан исән-сау кайтсагыз,
Якыннарым эзләп карарсыз.

Комбат.

Исән кайтсам, кулдан килгәннәрне
Кызганмам, туган!

Югарыдан тавыш ишетелә: «Иптәш комбат! Иптәш комбат!»

Комбат.

Ник дәшәләр?
Тагын ни булган?
*(Ашыгып өскә менеп китә.)*

Хафиз *(моңаеп).*

Сәрвиназым, яннарыңа
Җил булып исәр идем;
Йолдыз булып, баш очыңа
Таң саен күчәр идем.

Үтәр җәйләр, китәр көзләр,
Җил-яңгыр, давыл булыр.
Кайталмасам бу сугыштан,
Хәсрәтең авыр булыр,—

Авыр булыр, сиңа һәр көн
Юксыну китерер ул.
Чын мәхәббәт — гомер сүнмәс
Салават күпере ул.

Сүнмәсен ул, яктырсын ул,
Нур чәчеп юлларына;
Сүнмәсен ул, яктырсын ул
Гомерен буйларына.

*(Подвал тәрәзәсеннән төшкән яктылыкка төбәлеп.)*

Сез, уйларым, җилдәй очыгыз!
Якыннарым, дуслар, хушыгыз!
Коралдашым мәетен шаһит итеп,
Юллыйм сезгә шушы юлларны:
Без, туган ил, соңгы сулышкача
Синең гадел солдат улларың.
Без — туганлык, дуслык хисе белән,
Кошлар — канат белән көчлеләр.
Сез бит, сез ул —
Илгә һәм тормышка,
Кыләчәккә хуҗа кешеләр...

*(Ярасын чишә һәм стенага каны белән яза.)*

Без туганлык, дуслык хисе белән...

Өстә бомба шартлаган һәм йорт ишелгән тавыш ишетелә. Подвал стеналары җимерелә. Караңгылана. Бераздан Хафиз шәм кабыза һәм гаҗәпләнеп подвал тәрәзәсенә карап тора.

Уйлыйлардыр мине коралдашлар,
Хафиз бетте, харап булды, дип.
Ә мин сулыйм, ә мин яшим әле!
Әмма үлем каты куллы бит —
Тиздән, бәлки, бугазымнан алыр...

Икенче шәмне кабыза һәм аларны ящик өстенә куеп җимерелгән подвал стенасын актара башлый.

Күңелемдәге яшәү омтылышы
Сүнми калса әгәр чак кына,
Караңгыдан, Данко йөрәгедәй,
Алып чыгар, бәлки, яктыга.

**Мөхәммәт Мәһдиев**

# ПРОФЕССОР МӨХӘММӘТ ГАЙНУЛЛИН ҺӘМ ТАТАР ФИЛОЛОГИЯСЕ

Күзлек киеп кую гына кешене галим итми. Галимлек сыйфатлары бөтенләй башка. Галимлек ялгыз тырышлык белән генә килә торган исем дә түгел. Тырышлык, хезмәт сөючәнлек янында, әлбәттә, талант, В. И. Ленин сүзләре белән әйткәндә, сирәк очрый торган күренеш булуы шарт.

Галимнең халык алдындагы бурычы, җаваплылыгы гаять зур. Сине укыйлар, тыңлыйлар, әйткән сүзеңне хәтерлиләр. Син үзеңнең укучыларыңнан, тыңлаучыларыңнан, әлбәттә, алдарак торырга, алар белән чагыштырганда ераграк күрергә, алданрак дөрес юнәлеш бирергә тиешсең. Бер рядовой кеше ялгышса бер бәла, галим ялгышса — мең... һәм, әлбәттә, әгәр синең исемең галим икән, син үзеңне фәнгә багышлагансың икән, үзеңне башкаларга фән сүзе сөйләргә хаклы дип исәплисең икән, рәхим итеп, намуслы бул. Намусыңны яшьтән сакла. Ун ел элек язган хезмәтләреңнән бүген оялып йөрмә. Тагы да начары: ун ел элек әйткән фикереңнән бүген ваз кичеп, нәкъ киресен сөйләмә. Югыйсә, тагын ун ел яшәргә исәп тоткан кешеләр бүгенге сүзләреңә дә ышанмаслар...

Һәр галимнең өенә яки эш урынындагы кабинетына консультациягә барганда аның шәкерте үзенең остазын әнә шулай гадел кеше дип ышанып бара. Булачак диссертациясенең яки дөньяга чыгачак мәкаләсен күтәреп профессор Мөхәммәт Гайнуллинның фатирына барган һәр шәкерте дә аның турында әнә шулай уйлыйдыр.

Соңгы егерме ел эчендә Мөхәммәт Гайнуллиннан фатиха алып фәннең олы юлына чыккан галимнәрнең саны шактый. Алар арасында инде фән докторлары (Г. Рамазанов, К. Мәрган, Х. Госман, И. Нуруллин, Р. Мозаффаров һ. б.) булып җитешкәннәре бар. Утызлап яшь кеше Гайнуллинның ярдәме белән кандидатлык дәрәҗәсен алдылар. Ул турыдан-туры фәнни җитәкчесе булган унике аспирантның унысы диссертация яклады.

Бу кеше турында, аның юбилеен көтмичә, иркенләбрәк бер сөйләшергә, галимнең иҗат лабораториясе турында матбугатта фикер әйтергә, шәт, кирәктер һәм вакытлыдыр!

* * *

Без «галимнең иҗат лабораториясе» дидек...

Профессор Гайнуллинга карата, башта, ихтимал, «иҗат географиясе» дигән сүзне кулланү мәгъкуль булыр. Чөнки Гайнуллин — үзенең гомерен әдәби мирасны барлауга, әдәби мирасның, археологлар теле белән әйткәндә, «культуралы катламнарын» укучы массаларына җиткерүгә багышлаган галим. Әле кырыгынчы елларда ук ул язучы Заһир Бигиевның тормыш юлы, әдәби мирасы белән кызыксынып Ростов-Дон шәһәренә барып чыга. Дәрдмәнд мирасын өйрәнү өчен ул Оренбург, Уральск шәһәрләрендә була, Орск кешеләре белән аралаша. Оренбург-Уральск төбәгендә Тукай, Ш. Мөхәммәдев, З. Бәшири, С. Рәмиев кебек әдәбият әһелләре турында әллә никадәр истәлекләр, хатлар, кульязмалар җыя... Закир Һадиның биографиясен язу, иҗатын барлау өчен аңа Саратовка барырга кирәк була. Шакир Мөхәммәдъяров (Г. Тукайны Петербургта каршы алган, гомеренең соңгы елларында Урта Азиядә яшәп күптән түгел генә вафат булган журналист) белән сөйләшү, Тукайга кагылышлы истәлекләр җыю максаты белән ул Ташкент, Сәмәркандка барып чыга. Сәгыйть Рәмиев иҗатына кагылышлы материаллар җыю максаты белән Астраханьда була. Мәскәү, Ленинград, Баку, Ереван, Ашхабад, Алма-Ата кебек шәһәрләрнең Дәүләт архивлары, әдәби музейлары, ул шәһәрләрдә сакланган шәхси архивлар, кульязмалар, хатлар — Гайнуллинның «иҗат географиясе» әнә шулар.

Без, мәсәлән, язучы Закир Һадиның биографиясен белми идек. З. Һади Тукайлар, Әмирханнар, Камаллар белән матбугат дөньясында кайнашмаган — аның турында матбугатта мәгълүмат юк. Риза Фәхретдиновның био-библиографик «Асар»ына кертелмәгән — чөнки тарихчы бары тик үлгән кешеләрнең генә биографияләрен туплаган. З. Һади исә әдәбият дөньясыннан читтә яшәп, әле 1933 елда гына дөнья куйган. 1947 елда М. Гайнуллин югары уку йортлары өчен «XX йөз башы татар әдәбияты» буенча бер дәреслек-хрестоматия чыгара һәм анда З. Һади турында да кайбер мәгълүматлар бирә. Китап дөньяга тарала. Бераздан Гайнуллин исеменә Касыйм шәһәреннән хат килә. «Сез Закир Һадиның биографиясен белмисез икән. Аның кызлары исән, менә шушы адрес буенча хат язып карагыз», дип касыймлылар аңа берничә адрес бирәләр. З. Һадиның кызлары табыла һәм татар әдәбиятында зур ихтирамга лаеклы гуманист язучының бөтен тормыш юлы кәгазьгә төшерелә, аның әдәби мирасы барлана. Моннан соң инде З. Һадиның әсәрләр җыентыгын хәзерләргә мөмкинлек туа һәм М. Гайнуллин тарафыннан З. Һади әсәрләре дөньяга чыгарыла да. М. Гайнуллин илленче елларда Дәрдмәнднең әдәби мирасын туплау өстендә эш башлый. Иң беренче чиратта шагыйрьнең биографиясен тулыландырырга кирәк була. М. Гайнуллин иң беренче чиратта Дәрдмәнднең Уфадагы кызы Зәйнәп ханымны эзләп таба. Шагыйрьнең Җәгъфәр исемле улы да бер совхозда эшли икән. Болардан тыш Дәрдмәнднең гаиләсендә яшәгән учительницаның кызы — РОНО инспекторы Гөлчирә ханым да шагыйрь турында күп нәрсә сөйли. Дәрдмәнд Октябрь революциясеннән соң эмиграциягә китми, совет властена каршы бернинди хәрәкәткә катнашмый. Аның улы Җәгъфәр Кызыл Армиягә «күңелле» булып языла. Җирле властьлар аның Орскидагы ике катлы йортын үзенә калдыралар. Нindидер аңлашылмаучылык аркасында тентү белән кергәч тә, гафу үтенеп чыгып китәләр: бердән, йортның хуҗасы танылган шагыйрь, икенчедән, улы Кызыл Армиядә «күңелле»... Шулай итеп, М. Гайнуллин шагыйрьнең нәселе, таныш-белешләре белән элемтә урнаштыра һәм нәтиҗәдә Дәрдмәнд әсәрләре, аның кыскача биографиясе белән, дөньяга чыгарыла. Шундый ук эзләнүләр, искиткеч күп хатлар, сөйләшүләр, очрашулар нәтиҗәсендә Шакир Мөхәммәдев мирасы тәртипкә салына. Аның биографиясе языла. Ш. Мөхәммәдевнең әсәрләр җыентыгы хәзер сатуда юк. Ә профессор Гайнуллин чыгарган китап Ш. Мөхәммәдевнең, гомумән, беренче зур җыентыгы иде. Гайнуллинның өендә Ш. Мөхәммәдев мирасы буенча берничә папка бар: ул папкаларда язучының иҗатына, тормышына кагылган йөзләрчә хатлар, фоторәсемнәр.

Фән әнә шулай туа.

Геолог, аркасына капчыгын асып, тайга, таулар, тарлавыклар аша уза, озынборын мыжгып торган сазлыкларда айлар буе яши. Фән туа. Гидролог океан батискафына бикләнеп тәүлекләр буе су төбендә ята, күтәрелә, яңа мәсьәләләрне хәл итәр өчен

тагын шулай су астына төшә. Фән өчен материал җыйный. Филолог берөзлексез архив тузанында кайнаша, газета-журнал төпләмнәрен актара, меңләгән кешеләр белән элемтәгә керә, материал җыйный. Аның язганын гидролог та, геолог та укый. Чөнки әдәбият белән һәр укымышлы кеше кызыксына.

Мөхәммәт Гайнуллин дистәләрчә еллар буе инде татар филологиясенең эш аты ролен уйнап килә. Берәүләр трибунага чыгып шаулыйлар, зарланалар. «Бездә әдәбият фәненә игътибар җитми», диләр. Гайнуллин мондый максат белән трибунага сирәк күтәрелә... Күтәрелгәндә дә кемгә дә булса оппонент сыйфатында гына...

Кемнеңдер сөйләгәне бар: имеш, 1941 елда эвакуация белән килгән рус язучылары Казандагы татар язучылары белән очрашу уздыралар. Шунда әдәби осталык турында сүз кузгала. Татар язучылары алдында чыгыш ясаган Фадеев болай ди:

— Сез әдәби осталык мәсьәләсендә үзегезнең Галимҗаннан өйрәнегез...

Бу гади сүзләр кырык беренче елда әйтелгән булуы белән, әлбәттә, зур кыюлыкның мисалы булып торалар. Гайнуллинның бөтен хезмәтләрендә әнә шундый Фадеевча кыюлык күзгә ташлана. Аның 1947 елда филология фәннәре кандидаты Җ. Вәзиева белән берлектә чыгарган «XX йөз башы әдәбияты» дигән хезмәтендә XX йөз башы әдәбиятына гадәт буенча кертелә килгән Г. Тукай, Г. Камал, Ш. Камал һәм М. Гафури гына түгел, ә Дәрдмәнд, С. Рәмиев, З. Һади кебек язучылар да бирелделәр. Әйтергә кирәк, **бу китап Гайнуллинны галим буларак таныткан беренче зур хезмәт булды.**

КПССның XX съездыннан соң Мөхәммәт Гайнуллин әдәбият тарихы буенча киң планлы эш башлый. Ул югары уку йортлары өчен XIX, XX йөз әдәбиятлары буенча өч томлык хезмәт чыгара (соңгы ике томы доцент Җ. Вәзиева белән берлектә), аерым язучыларның җыентыкларын хәзерли. Әдәби мирас, әдәбият тарихы буенча хезмәтләр чыгаруда ул профессор Габдрахман Сәгъдинең дәвамчысы булып тора. Мөхәммәт ага эшне җимереп, убып эшли. Минем профессор Рәфыйк Нәфиковның архивта һәм гыйльми китапханәдә эшләгәнен күргәнем бар: аның кулында фәнни материал уйнап тора, документка җан керә. Нәфиков бу вакытта кешене күрми, тышкы дөньядан аерылган була. Фәнни хезмәт әнә шулай вакыты белән аскетлыкны таләп итә. Гайнуллинда да бу сыйфат көчле.

— Мин,— ди ул,— тегендә-монда зарланып йөреп эш өчен җаваплылыкны кеше өстенә аударммыйм. Мин күбрәк эшләргә тырышам. Берәр әйбер бастырам икән, димәк, үзем җавап бирәм. Чөнки мин — коммунист...

Гыйлем дөньясында шулай була: галим кеше гомер буе эзләнә, таба, дөньяга чыгара. «Бәндә хатадан хали түгел», диләр. Күп эзләнгән, күп актарынган һәм күп әйбер дөньяга чыгарган кешенең хезмәтләреннән, әлбәттә, ялгышлыклар да табып була һәм бу эш җиңелрәк.

В. И. Ленин болай дигән иде: «Акыллы кеше ялгышлар ясамый торган кеше түгел. Андый кешеләр юк һәм булуы мөмкин да түгел. Бик үк зур булмаган ялгышлар ясап та, аларны җиңел һәм тиз төзәтә белгән кеше акыллы». (В. И. Ленин. Әсәрләр. Татар телендә. 31 том. 20 бит.)

Мөхәммәт ага — үзенең иксез-чиксез хезмәтләрендә киткән кайбер төгәлсезлекләрдән тиз һәм җиңел арына ала торган галим.

Кеше буларак ул киң күңелле, тыйнак характерлы. Үз хезмәтләрен тәнкыйть итеп чыккан кешеләргә карата ул мәкер тотмый. «Ул тәнкыйть иткәнне ярата», дигән шаблон бәядән без ерак торабыз. Тере кеше ләбаса! Син утырып-утырып үзең дөрес дип ышанган әйберләрне язып дөньяга чыгар да, икенче бер кеше (ә еш кына үзеңнең шәкертең!) синең шул хезмәтеңне тәнкыйть итсен... Аны яратуы, чыннан да, читен хәл инде. Ә менә Гайнуллин башкаларның фикеренә һәрвакыт колак сала, тәнкыйть фикеренә игътибарлы була белә. Галим өчен бик кирәкле сыйфат бу.

* * *

М. Гайнуллин әдәбият тарихының моңарчы укучылар массасына мәгълүм булмаган катлауларын ача. Ул прогрессив әдәбиятка кайчандыр үзләреннән файдалы өлеш керткән, ләкин безнең игътибарсызлыгыбыз аркасында күмелеп калган шәхесләрне, фактларны күтәрә, әдәбият тарихындагы «ак таплар»га төс бирә. Аның фикеренчә, XIX йөз ахыры һәм XX йөз башы әдәбиятларында зур-зур шәхесләр янында шул демо-

кратик әдәбиятка хезмәт иткән йөзләгән башка шәхесләр булган. Әнә шуларның да хезмәтен өйрәнми торып, әдәбият тарихының ярдәмчел факторларын белми торып, бөтен бер әдәби процесс турында сүз алып бару мөмкин түгел. Әнә шул максаттан чыгып ул әдәбият тарихы битләренә тәрҗемәче Габделмәннән һәм Солтан Рахманкуловлар, тәнкыйтьче һәм тәрҗемәче Г. Кәрәм, хатын-кыз шагыйрьләр һәм әдәбиятчылар З. Сәгыйдә, М. Мозаффария, З. Бурнашева, М. Акчурина һ. б. шәхесләрне күтәрде. Фактик материалга байлык аның бөтенсоюзга мәгълүм булган беренче китапларында ук күзгә ташланды. «Горький и татарская литература» (1944) дигән хезмәте әнә шул яктан отышлы иде. Гайнуллин эзләп тапкан мәгълүматлар ахырдан аерым тикшеренүчеләр өчен беренчел материал хезмәтен үтиләр. Аның бу китабы заманында рус филологларының игътибарын җәлеп итте, профессор Л. Климович бу хезмәткә югары бәя бирде.

Таныш язучының яңа китабын кулга алганда, ди Лев Николаевич Толстой, болай дип уйлыйсың: «Яле, син миңа тагын нинди яңалык әйтә аласың? Бу юлы син миңа тормышның тагын нинди ягын ачасың?» Гайнуллинның һәр яңа китабын кулыңа алгач, ирексездән, әнә шундый кызыксынулы сорау туа. Һәм укучы алданмый: аның «XX йөз башы татар әдәбияты һәм публицистикасы» дигән капиталь хезмәте бөтен Советлар Союзы галимнәренең ихтирамын казанды. М. Гайнуллин бу хезмәтендә, татар филологиясендә беренче буларак, татарларда вакытлы матбугат тудыру өчен көрәш тарихын, публицистика, әдәби тәнкыйтьнең үсеш баскычларын иҗтимагый планда тикшерә. М. Гайнуллинның бу тикшеренүенә әле ул китап булып чыкканчы ук филология фәннәре докторлары И. Брагинский, Н. Баскаков, Ә. Нәҗип, Л. Җәләй, МГУның СССР халыклары әдәбияты кафедрасы мөдире М. Богданова һ. б. югары бәя бирделәр. Бу тикшеренү китап булып чыккач та игътибар үзәгендә булды. «Литературная Россия», «Советская Татария», «Кызыл таң» газеталарында, «Казан утлары» журналында бу китап турында галимнәрнең зур-зур рецензияләре күренде. Рецензияләрнең барысында да уртак фикер түбәндәгедән гыйбарәт иде: М. Гайнуллин бу хезмәтендә татар халкының тарихындагы бөтен бер чорга тулы экскурс ясый, аның тикшеренүе әдәбият мәсьәләләре рамкасыннан чыгып гомумкультура — театр, музыка, тел, фольклористика мәсьәләләренә кереп китә, татар әдәбиятына рус әдәбияты аркылы көнбатыш әдәбиятының тәэсире, төрек, гарәп, фарсы әдәбиятының тәэсире турында өр-яңа мәгълүматлар бирә. Доктор Әмир Нәҗип бу тикшеренү турында болай дип язды: «М. Гайнуллин хезмәтенең характерлы ягы шунда ки, ул искиткеч зур фактик материалга нигезләп яза. Ул безнең көннәрдә махсус тикшеренүче булмау сәбәпле онытыла башлаган язучылар, шагыйрьләр, галимнәр, журналистларның басылып чыккан барлык әсәрләрен күтәргән һәм анализлаган».

Әдәбият тарихын тикшерүче Мөхәммәт Гайнуллин әнә шундый.

...Укучы, шәт, М. Гайнуллинның биографиясен өмет итә торгандыр. Гайнуллин, язучы Ибраһимов сүзе белән әйткәндә, түбәннән, тормышның төбеннән күтәрелгән кеше. Балта остасы Хәйрулла белән гади авыл хатыны Фатиханың уллары танылган галим булып үсеп җиткән икән, бу — Совет властеның татар халкына нәрсә биргәнен күрсәтеп торган бер дәлил. Аның замандаш галимнәренең барысына да уртак булган бер вакыйга бар: алар Бөек Октябрь революциясе дулкыннары тәэсирендә фән-культура өлкәсенә аяк басалар. Гайнуллинның тормыш юлында да шулай була. 1918—19 елларда ул Тәтеш шәһәрендә укытучыларның кыска вакытлы курсларын тәмамлый, авылда укытучы булып эшли. 1928 елда ул Көнчыгыш педагогия институтына килеп керә, анда актив җәмәгать эше алып бара, институтны тәмамлагач, аспирантурада калдырыла. Сугыш вакытында Татарстан Дәүләт нәшриятының управляющие, Татар Фәнни-тикшеренү институты директоры булып эшли. Бу институт 1945 елда СССР Фәннәр Академиясе системасына кертелә. Ул 1946 елда кандидатлык, 1958 елда докторлык диссертацияләре яклый. Фәнни эшчәнлегенең бөтен дәвамында М. Гайнуллин Казан Дәүләт педагогия институтында, Казан Дәүләт университетында лекцияләр укый, диплом эшләренә җитәкчелек итә, яшь галимнәр әзерли. Егерме елдан артык инде ул Татарстан Мәгариф министрлыгы программасы буенча татар мәктәпләре өчен әдәбияттан дәреслекләр яза.

М. Гайнуллинның иҗтимагый-фәнни эшләре, әлемтәләре әле дә иксез-чиксез. Аның өенә рецензиягә китаплар, фәнни хезмәтләр, мәкаләләр килеп тора. Ул Кыскача Әдәби

Энциклопедиянең редакторы-консультанты, Казандагы Горький музее, университет һәм педагогия институтларының Гыйльми Советлары әгъзасы һ. б. һ. б.

Галимнәр төрле була: берәүләр үзе эшли торган фәнни институтның бер секторында галим, икенчеләре Казан тирәсендә, өченчеләре бөтенсоюз күләмендә дә, халык алдында да, чит илдә дә танылган булалар. Гайнуллин соңгысына керә. Соңгы елларда чит илләрдә чыккан тарихи, филологик хезмәтләрдә профессор Гайнуллинның исеме еш телгә алына: аның тикшеренүләрендәге зур фактик материалны атлап үтү мөмкин түгел.

...Профессор Гайнуллинның эш кабинетына якын гына чолан, кухня, телефон... Монда эшләве бәлки кыендыр?

— Минем,— ди Мөхәммәт ага,— бик зур әрсезлегем бар. Мин эшкә утыргач, ник шунда коридорда трактор кабызмыйлар. Миңа берни дә комачау итми. Тик сәламәтлек кенә какшамасын.

Сәламәтлек... Соңгы елларда аның фатирындагы сары агач баскычтан күтәрелгәндә мин еш кына өй алдында валокордин исен сизәм. Нишләргә? Әллә борчымаскамы? Ишек тоткасына ябышып туктап калам. Ләкин ул инде ишектә кеше барын сизгән, шау-гөр килеп сине сәламли, аягыңа кияргә йомшак туфлиләр күтәреп каршы ала. Әйтерсең, синең түгел, аның синдә үтенече бар. Мөхәммәт ага, гомумән, елмаймыйча кеше каршылый белми.

Гайнуллинның йорты каршында гына Эрмитаж бакчасы. Иртән дә, кичен дә ул анда йөрергә чыга. Юк, ул теге мәзәкләрдә сөйләнә торган, ике аягына ике төрле оекбаш кигән профессорларга охшамаган. Янсә үз хатынын очраткач та «мин сезне кайдадыр күргән кук тиям» дип әйтмәс. Хатыны Җамал апа белән алар бик күп хезмәтләрен бергәләп язалар, бер-берсенә ярдәм итәләр.

...Иртән эшкә йөгереп барганда, сез Эрмитаж бакчасында кулын артка куеп йөргән, кырган башлы берәүне очратсагыз, ул Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, филология фәннәре докторы Мөхәммәт Гайнуллин булыр.

Галия Хантемирова

# ТӘРҖЕМӘДӘ МИЛЛИ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРНЕ САКЛАУ

Тәрҗемәдә милли үзенчәлекләрне саклау — тәрҗемә теориясендә иң аз өйрәнелгән мәсьәләләрнең берсе. Милли үзенчәлек белән милли әдәбиятларның бүгенге дәрәҗәсен бергә бәйләп өйрәнгәндә генә аны дөрес хәл итәргә мөмкин.

Милли әдәбиятларның бүгенге хәле, әйтик, моннан егерме-утыз ел элек булганнан бик нык аерыла. Безнең илдә хәзер милләтләрнең үзара дуслыгы ныгу, интернационализм тойгылары көчәю, уннарча милли культураларның, үзара йогынты ясап, бер-берсен баетып яшәүләре табигый хәлгә әйләнде. Бу — социалистик милләтләрнең коммунизмга бару юлы. Шуңа күрә әдәби әсәрнең милли үзенчәлегенә игътибар көчәю очраклы хәл түгел.

Совет власте елларында безнең илебез халыклары психикасында социалистик ватаныбызга мәхәббәт, интернационализм хисе, башка халыклар белән дус яшәү, революцион актив гуманизм кебек байтак уртак сыйфатлар барлыкка килде. Ләкин совет халыкларының барысына да хас бу уртак сыйфатлар алар арасындагы милли аерымлыкларны юкка чыгармый. Шуның белән бергә милли характер үзе дә гомерлеккә бирелгән, катып калган бер нәрсә түгел, ул, социаль шартларга бәйле рәвештә, үзгәрә килә, әкрен үзгәрә, әмма үзгәрә. В. И. Ленин «Коммунизмда «суллык» авыруы» исемле атаклы хезмәтендә пролетариат диктатурасы бөтен дөньяда җиңеп чыкканнан соң да әле милли үзенчәлекләрнең бик озак сакланачагын, бердәм интернациональ бурычны үтәү өчен милли үзенчәлекләрне җентекләп өйрәнергә, эзләп табарга кирәклеген әйткән иде.

Әдәби әсәрне икенче телгә тәрҗемә иткәндә милли үзенчәлекләрне саклау турында әдәбият галимнәре байтак яздылар. Тик аларның күбесе бу мәсьәләгә бер яклырак карыйлар. Мәсәлән, К. Чуковский, М. Морозов, М. Алексеев, И. Кашкин күбесенчә фразеологияне, теге яки бу милләткә хас гореф-гадәтләрне ничек бирергә кирәклек мәсьәләсен генә куеп, катлаулы проблеманы беркадәр тарайттылар. П. Табахьян исә «Тәрҗемәдә әдәби әсәрнең милли үзенчәлекләрен саклау» дигән диссертациясендә М. Шолоховның «Тын Дон» романын немец теленә тәрҗемә итү практикасында әлеге мәсьәләне карады. Тик ул да диалектизмнар, көнкүреш әйберләре, мәкаль һәм әйтемнәрне ничек тәрҗемә итү белән чикләнә. Ю. Феличкин исә Маяковский, Блок, Есенин, Твардовский поэзиясен француз теленә тәрҗемә итүне тикшергәндә, милли үзенчәлекләрне тел аспектына гына кайтарып калдыра. Автор башка телдәге милли формаларның матурлыгын күрсәтүне дозалап кына бирергә тәкъдим итә. Татарча әйткәндә, берәр чеметем генә бирергә куша. Ягъни, Ю. Феличкин әдәби әсәрнең аның белән ярыша алырдай, тәңгәл килердәй эквивалентын бирүне түгел, таныштыру өчен өлешчә генә матурлыгын күрсәтеп узуны тәкъдим итә. Бу, безнеңчә, бер адым артка чигенү.

Милли үзенчәлек мәсьәләсе теоретикларның гына игътибарын җәлеп итеп калмады, ул тәрҗемә өлкәсендә дан казанган осталарны да үзенә тартты. Мәсәлән, күп кенә халыкларның эposларын союз күләменә алып чыккан тәрҗемәче Семен Липкин бурят халкының героик эпосы «Гәсәр»гә язган кереш сүзендә болай ди: «Милли

характер барлык әсәрләргә караганда да эпоста күбрәк чагыла. Русчада да шул характерны бирү — мавыктыргыч кына түгел, кыен гына түгел, иң мөһим, иң хәлиткеч мәсьәлә. Миңа калса, милли үзенчәлекне табып, шуны тәрҗемәдә дә чагылдыру өчен, барыннан да бигрәк, гомумкешелеккә хас сыйфатларны табарга һәм шуны чагылдырырга кирәк»[1].

Милли үзенчәлекләрне табып, шуны тәрҗемәдә дә чагылдыру — иң мөһим мәсьәлә, дип әйтүе белән автор, һичшиксез, хаклы. Әмма аның миллилеккә без гомумкешелек сыйфатлары аша киләбез дип артык кискен куюы белән килешәсе килми. Юкса, гомумкешелек сыйфаты һәм милли үзенчәлек аерым-аерым яшиләр икән дигән хис кала. Милли һәм интернациональ сыйфатлар, ягъни гомумкешелек сыйфатлары диалектик берлектә яшиләр, үләннәргә сеңгән кояш нурын аерып алып булмаган кебек, гомумкешелек сыйфатларын да аерып карап булмый. Әгәр чәчәкләр белән чагыштырсак, кояш нуры, әйтик, мәк чәчәгенә дә сеңгән, давыл чәчәгенә дә сеңгән. Икесе дә бер үк туфракта үсәләр, икесен дә бер үк яңгырның суы коендыра. Әмма икесе ике төрле. Әдәби әсәргә килсәк, гомумкешелек сыйфаты да, милли үзенчәлек тә аңарда бер-берсеннән аерылгысыз булып, бергәләп яшиләр. Әгәр инде шартлы рәвештә бүлеп карарга кирәк икән, ул чагында өлешчәдән гомумигә таба, ягъни миллидән гомумкешелек сыйфатларына таба килергә кирәк.

Галимнәр арасында: тәрҗемәдә оригиналның милли үзенчәлеген, кабатланмас матурлыгын бирә булмый дип әйтүчеләр дә очрый. Мәсәлән, «Дружба народов» журналы бәхәсендә катнашкан тәнкыйтьчеләрдән Р. Пакальнишкис һәм К. Бязарти тәрҗемә иткәндә милли үзенчәлек юкка чыга дип белдерделәр.

Тәрҗемә практикасында «җирле колоритны» саклау тенденциясе бик көчле. Чит сүзләр никадәр күбрәк булса, «милли колорит та» шулкадәр яхшырак бирелгән була, имеш. Чынында исә чит сүзләр тәрҗемәне аңлауны авырлаштыра, хиснең матурлыгын китереп җиткерергә комачаулый, телне шактый ук чуарлый. Ләкин тәрҗемә практикасы моның белән әле һаман да исәпләшми, егерме-утыз еллар элек ничек тәрҗемә ителгән булса, бүген дә шулай тәрҗемә ителә. Моннан бер гасыр элек үк Гоголь тәрҗемәче М. Максимовичка язган хатында болай ди: «Тәрҗемәдә барыннан да бигрәк сүзгә түгел, фикергә тотынырга кирәк. Дөрес, сүзгә тотыну бик мавыктыргыч нәрсә, чын күңелдән әйтәм, хәзер ул хакта бик салкын кан белән уй йөртсәм дә, мин үзем дә рус теленә берәр яңгыравыклы сүз кертеп җибәрүдән тыелып кала алмаган булыр идем, беркатлылыгым белән мин ул сүзне башкалар да минем кебек үк аңлыйлар дип уйлаган булыр идем. Шуны исеңдә тот, синең тәрҗемәң руслар өчен, шунлыктан малороссларның сүз әйләнмәләрен һәм конструкцияләрен кертә күрмә!»[2]. Бөек Гогольнең моннан бик күп еллар элек әйткән сүзләре бүген дә тәрҗемәдә төп принципларның берсе булып саклана.

Бүгенге заман тәрҗемә практикасында тугандаш халыкларның фольклорыннан, әдәбиятыннан, тарихыннан һәм гореф-гадәтләреннән алган «авыздаш» сүзләр дә кулланыла. Бу, күрәсең, «көчәйтү», «матурлау» ниятеннән чыгып эшләнә. Мәсәлән, татар әсәрләрен русчага тәрҗемә иткәндә еш кына «аксакал» сүзе алына һәм бу сүз казакъларда, кыргызларда йөргән мәгънәдә бирелә. Бу сүз белән казакъ һәм кыргыз әсәрләре аша таныш булган рус укучысында инде «аксакал» белән бәйле төшенчә бар: бу — нәсел башы, зирәк акылы өчен ихтирам ителә торган өлкән яшьтәге кеше. Татарларда исә аксакал туры мәгънәсендә — ак сакаллы карт кеше мәгънәсендә генә кулланыла.

Милли үзенчәлекләрне русчага тәрҗемә итү, рус телендә дә аларның уңышлы яңгырашларын булдыруның үрнәкләрен зур бер әсәрнең тәрҗемәсен җентекләп тикшергәндә күбрәк белеп була. Шуңа күрә без күренекле татар совет язучысы Әхмәт Фәйзинең «Тукай» романына тукталырга булдык.

Тукай турындагы китап — татар халкы турындагы китап ул. Чөнки Тукай үз халкының күңел байлыгын иң тулы итеп чагылдыра алган милли шагыйрь. Табигыйдер ки, шунлыктан, Әхмәт Фәйзинең романында татар әдәбиятының милли үзенчәлекләре аеруча калку булып чагыла. Автор әсәрен роман-эпопея итеп язарга исәпли иде. Ул аның беренче китабын гына да ун ел чамасы язды. Вакытсыз үлем Әхмәт

[1] «Дружба народов» журналы. 1967 ел. 1 сан. 261, 267 битләр.

[2] Гоголь Н. В. Полное собрание. X том. СССР Фәннәр акад. басмасы. 1940—1952 еллар. 311—312 битләр.

Фәйзигә гаять зур бу хезмәтен тәмамлап бетерергә мөмкинлек бирмәде. Тукай турындагы роман шагыйрьнең үсмер чагына җитеп кенә туктады. Әхмәт Фәйзи янәшә рәвештә романның икенче китабын да язган икән диган хәбәр бар. 1953 елда «Литературный Татарстан» альманахында икенче китаптан бер эпизод — Тукайның Петербургка бару эпизоды басылган. Тукай Петр I һәйкәле янында басып тора, аның уйлары Пушкинның «Бакыр җайдак» әсәренә юнәлтелгән, ул рус туганы һәм каләмдәшенең талант көче турында уйлана.

«Тукай» романы татарча беренче мәртәбә 1950—51 елларны «Совет әдәбияты» журналында басылып чыкты. Аерым китап булып 1952 елны басылды. Тулыландырылган икенче басмасы 1956 елны дөньяга чыкты. Русча тәрҗемәсе бераз алданрак — 1954 елны ук басылды, чөнки тәрҗемәче А. Садовский аны кульъязмадан ук тәрҗемә итә башлаган иде. 1966 елны китап, Тукайның юбилее уңае белән, «Советская Россия» нәшриятында кабат басылды. Без әнә шул иң соңгы басма буенча сүз алып барырга телибез.

Әхмәт Фәйзи «Тукай» романын өлгереп җиткән зур художник, сүз остасы булгач язды. Аңарчы ул шагыйрь буларак та, драматург, тәнкыйтьче һәм балалар язучысы буларак та, ниһаять, тәрҗемәче буларак та зур юл узган иде. Романга автор барлык көчен, белемен, әдәби осталыгын, тормыш тәҗрибәсен салган. Тукайның тормышы татар халкының тормышы җирлегендә, зур бер тарихи фонда алып сурәтләнелә. XIX гасырның азагында — XX гасырның башларында рус капитализмы үсү белән беррәттән, татар буржуазиясе дә барлыкка килә, шәһәрдә һәм авылда революцион көрәш чаткылары күренә башлый. Халык эчендә кайнау, «түбәннән күтәрелү» булачак бөек милли шагыйрьнең шәхесе формалашуга китерә. Романда без булачак шагыйрьне чолгап алган мохитның нечкә хисле авыл малаена ничек тәэсир иткәнен күрәбез. Халыкның моң-зары, халыкның башыннан кичергәннәре Тукайның иҗат принцибына әверелә. Романның татарчасын укыган чакта авторның тыенкы итеп язу алымына игътибар итәсең. Әсәр вакыт-вакыт хәтта корырак та кебек тоела. Әмма тышкы корылык аша укучы ташкындай бәреп торган ярсу тойгыларны, эчке кайнарлыкны тоя, озак вакытлар тыелып килгән хис тышка бәреп чыккан чакларда халык күңеленең зурлыгы, тойгыларның муллыгы һәм эчкерсезлеге сине таң калдыра. Ә. Фәйзинең стилендә аның шагыйрьлеге сизелә: җөмләләр киеренке, форма төгәл, таркаулык бөтенләй юк.

Талантлы язучының индивидуаль язу алымын тикшергән чакта без әсәрнең тукымасын таратып ташлап, монысы халыктан, монысы авторның үзеннән дип әйтә алмыйбыз. Лев Толстой сүзләре белән әйткәндә, авторның шәхесе ул шундый бер цемент, тасвир ителгәннәргә карата аның рухи мөнәсәбәте әсәрнең барлык кисәкләрен бергә тоташтыра. Шунлыктан романның стиленә карата без бер генә нәрсә әйтү белән чикләнәбез: татар халкына хисләрне вакламыйча, күңелендә саклау хас. Татар фольклорында мәет күмү йолаларында акырып елау, махсус иҗат ителгән елау формалары юк. Димәк ки, халыктан килә торган милли үзенчәлек буларак, бу хәлне тәрҗемәче бик нык истә тотарга тиеш иде.

А. Садовский стиленә исә, киресенчә, күп сүзлелек, купшылык, детальләрнең мул булуы хас. Авторны «төзәтү», элементар нәрсәләрне укучыга бик җентекләп аңлатып бирергә теләү тойгысы примитивлыкка, банальлеккә алып килә. Тыенкылыкны тәрҗемәче, күрәсең, корылык дип аңлаган һәм романны купсүзлелек белән шактый ук сыекландырган.

«Тукай» романындагы стильнең үзенчәлеген Габдулла Тукайның «күпме какканны вә сукканны» күргән газаплы, иң-иң романтик тормышы да билгеләгән, әлбәттә. Үзенең өе дә булмыйча, казна номерларында ятып, больница койкасында чахоткадан һәлак булган шагыйрьнең тормышын сурәтләгәндә чәчәкле-чуклы стиль сайлап булмаслыгы үзеннән-үзе билгеле. Бәләкәй Апушны уратып алган авыл ярлылары мохиты, Казанның Бишбалта бистәсендәге һөнәрчеләр тормышы, соңыннан татар сәүдәгәрләре, шәкертләр һәм мәдрәсә тормышы — татар җәмгыятенең төрле-төрле катлаулары безнең алдан узып китә. Тәрҗемәченең бурычы җиңел түгел, ул шагыйрь яшәгән заманның барлык катлаулылыгын рус укучысына китереп җиткерергә тиеш. А. Садовский тәрҗемәсен без чын әдәбиятның үзен бирү түгел, милли әдәбият белән таныштыру үрнәгенә кертер идек, чөнки бу — оригиналга тәңгәл килә алырдай тәрҗемә түгел. Роман беренче мәртәбә басылып чыкканнан бирле байтак вакыт узды, милли әдәбиятларның русчага тәрҗемәсенә карата укучыларның да, тео-

ретикларның да таләпләре үсте. Ә романның икенче басмасы Мәскәүдә беренче басмадагы, ягъни 1954 елдагы ук кимчелекләре белән басылып чыкты. Безнең максат бу мәкаләдә, әлбәттә, тәрҗемәне бөтенләе белән анализлау түгел, оригиналның милли үзенчәлекләре русчада ни дәрәҗәдә сакланганны конкрет мисалларда тикшерү һәм бүгенге тәрҗемә практикасында да яшәп килә торган кайбер алымнарны күз алдыннан үткәрү.

«Габдулла чыпталар өстендә өеп утырган җиреннән күзләрен ачып җибәрде. Ат алҗып кына калага кереп килә иде. Габдулла инде күзләрен яңадан йома алмады. Кала үзенең олылыгы һәм сәерлеге белән Габдулланың көчкенә йөрәген каушатып җибәрде. Каланың эченәрәк кергән саен йортлар ишәя, зурая һәм бер-берсенә ныграк елыша бардылар»[1].

Авыл малаеның шәһәргә керүе оригиналда кыска итеп, бик төгәл штрихлар ярдәмендә бирелгән. Габдулланың йоклап килгән җиреннән күзләрен ачып җибәрүе аның шәһәргә беренче мәртәбә гаҗәпләнеп, исе китеп каравын бирә. Әхмәт Фәйзи аңа хас тышкы тыенкылыкка турылыклы булып кала, малай авызыннан: «Шәһәр!» — дип кычкырттырмый. Ә тәрҗемәче баштa, Габдулланы күзләрен «ача төшеп» кенә карата, аннары: «Шәһәр!» — дип үк кычкыртып җибәрә. Бу патетик соклану, безгә калса, иң әүвәл Әхмәт Фәйзинең тыенкы язу алымына туры килми, ә аннары биш яшьлек малайның рухи халәтенә туры килми, аның аңында бит әле шәһәр төшенчәсе юк, ул каршысында пәйдә булган манзараны исе китеп күзәтә генә ала. Өстәвенә тәрҗемәче «сон как рукой сняло» кебек таушалып беткән шаблон тәгъбирне үзләреннән өсти, йортларны да бик тигез икерәткә тезеп куя. Авторда бит авыл малаеның күзенә ташланганы — йортларның ишәюе, зураюы, бер-берсенә елышуы.

Тәрҗемәченең автор алымын бозуы төрле-төрле формаларда чагыла. Бәләкәй Габдулланың күңелен уеп узган көз күренешен алыйк. Автор аны болай сурәтли: «Җәй вакыйгаларга никадәр бай булса, кыш шулкадәр тыныч, буш һәм күңелсез узды... Бу бушлык һәм күңелсезлек көзге пычраклар керү белән үк башланды. Көннәр кыскарганнан-кыскара барды. Яңа бистәне, албасты кебек, караңгылык басты. Урамнары түшәлмәгән Яңа бистә көзнең зарыктыргыч яңгырлары астында тоташ сулыкка әйләнде. Калоша югалтмыйча гына урам аркылы чыгу зур эшкә әйләнде. Бигрәк тә Кече Сембер урамына кереп баткан җигүле атны, арбасыннан туармый торып, алып чыгып булмый, шуңа күрә извозчиклар һәм ломовойлар бу урамга кермиләр, Олы Сембер урамыннан әйләнәләр иде...»

Инде бу өзекнең русчасын игътибар белән күздән үткәрик:

«Наступили сумеречные, тоскливые дни осени. Под непрерывным дождем немощеные улицы слободы превратились в месиво грязи. Стало трудно перейти улицу, не оставив в грязи калоши, а то и все ичиги. Если на Малой Симбирской завязла в грязи телега, лошадь приходилось распрягать и выводить из оглоблей, а телегу вытаскивать с помощью веревок и кольев. Городские извозчики и ломовые объезжали эту улицу по Большой Симбирской» (56 бит).

Тагын бер мәртәбә җентекләп чагыштырып караса, игътибарлы укучы күрәр: романның татарчасындагы эмоциональ сурәт шактый ук томыкланган. Ул замандагы бистә тормышына хас өметсезлек, караңгылык, юеш томан белән еретелгән чынбарлык күренеше тәрҗемәдә кимегән. Ә бит Әхмәт Фәйзи андый өметсезлек тойгысын «тыныч», «буш», «күңелсез» кебек эпитетлар белән тудыра. Бистә өстенә караңгылык ятуын ул албасты белән чагыштырып ала. Албасты авыл малае өчен дөньядагы иң куркыныч зат. Татар мифологиясеннән алынган албасты образы шулай ук ул замандагы ярлы тормышның авырлыгын, куркынычлыгын, өметсезлеген бирү өчен кирәк. Шул якка уй-хисне юнәлтәсе урынга, тәрҗемәче атны ничек пычрак эченнән чыгару турында баш ватып, безнең игътибарны албастыга түгел, ә арбаны күсәкләр, баулар белән тартып чыгаруга юнәлтә, шуның белән ыгы-зыгы тудыра, бая әйткәнебезчә, Әхмәт Фәйзинең язу алымындагы тыенкылыкны киметә. Шушыларның барысының өстәвенә тәрҗемәче А. Садовский милли күренеш әйберләрен дә белми икән әле. Оригиналда пычракта суырылып ката кала, тәрҗемәдә исә читек кала. Беренчедән, читек озын кунычлы, аның пычракта калуы мөмкин түгел, икенчедән: пычрак вакытта читек киеп чыгалар микән!

[1] Ә. Фәйзи. Тукай. Роман. Беренче китап. Төзәтелгән икенче басма. Казан. 1956. 14 бит.

9*

Авторның индивидуаль язу алымы милли үзенчәлек белән тыгыз бәйләнгән булуын әйткән идек. Бу — дөньяны күрүнең бер билгесе дигән сүз. Оригиналда, мәсәлән, мондый җөмлә бар: «Падишалар үлгәндә дә чаң суктылар, үлемнән калганда да чаң суктылар...» Күрәсез, артык бер генә эпитет та юк. Чиркәүнең зурмы-кечкенәме, чаң тавышының моңсумы-дәртлеме икәне Әхмәт Фәйзи тарафыннан күрсәтелмәгән. Татар малае Габдулла чиркәү чаңнарының төрлечә булуын белми бит, ул ике очракта да чаң сугудан гаҗәпләнә генә ала. Бу, бер яктан, Габдулланың, малай буларак, характерына туры килсә, икенчедән, ул татар баласының милли характерына да туры килә. Юл уңаенда әйтеп узыйк, татар теленә хас үзенчәлек, ул да булса, телдә, гомумән, әйберләрне артык шәрыхламау, аларның аерым билгеләрен артык ачыкламау. Әйтик, бездә, «күзләрен зур ачты» дип әйтергә мөмкин. «Кара күзләрен зур ачты» дип әйтеп булмый. Чөнки күзне ачу татарчада инде ул билгеле бер әйләнмә булып әверелгән. Русчада «күз» янына теләсә нинди эпитет куярга була, татарча моны эшләү шактый ук кыен. Менә шул кечкенә генә нәрсәләрдә дә милли үзенчәлек чагылып уза. Тәрҗемәче А. Садовский, милли үзенчәлекне белмәгәнлектән, әлеге чаң сугу күренешен бик күп эпитетлар белән алып, аның тирә-ягын бизи һәм нәтиҗәдә төп нәрсәне — татар малае образын тоныкландыра. «Звонили протяжно и уныло в большие колокола в день смерти царя, звонили во все колокола переливистым звоном по случаю спасения царя...» «Протяжно и уныло» итеп чаң сугу һәм «звонили во все колокола переливистым звоном» кебек нәрсәләр никадәр «матур» булмасын, татар малаен түгел, рус малаен бирәләр. Чөнки андый рәвештә дә чаң сугып булганны бары тик рус малае гына белә, чиркәү чаңнары аңына ана сөте белән кергән малай гына белә ала. Татарчада эпитетсыз чаңнар вакытның тиз узганын бирсә, русчадагы эпитетлы чаңнар вакыт агышын туктата, безне бер урында чиркәүгә карап торырга мәҗбүр итә. Болар бер караганда әллә ни игътибар итәрлек нәрсәләр дә түгел кебек, әмма әнә шул төгәлсезлекләр, тамчыдан күл җыелган кебек, татарчадагы бәләкәй Габдулланы шактый ук бозып рус укучысы күз алдына бастыралар.

Алдарак әйткәнебезчә, романның беренче китабы гына язылып калды һәм анда Габдулланың бала чагы һәм үсмер вакыты гына тасвирланды. Шагыйрьнең шәхес буларак җитлегүен укучы, кызганычка каршы, күрмәде. Шунлыктан бәләкәй Габдулланың мәгърифәтче, күренекле галим һәм язучы Каюм Насыйри белән символик очрашулары аеруча әһәмиятле. Тәрҗемәче моңар бигрәк тә нык игътибар итәргә, аеруча нык өйрәнеп тәрҗемә итәргә тиеш иде кебек.

Каюм Насыйри Габдуллага бәләкәй карандаш бирә. «Әле аның үзеге күп,— диде ул,— сиңа бөтен хәрефләрне өйрәнеп җитәр өчен тәп-төгәл булыр. Хәрефләр язарга өйрәнгәч, сүзләр язарга тотынырсың, сүзләр яза белсәң, китап язарга өйрәнерсең. Инде китап язарга өйрәнсәң, дөньяда иң бәхетле кеше син булырсың.

Каләм белгел, каләм изгегә тартыр.

Каләм белгән кешенең фәһеме артыр,— ди әнә китап...»

Кечкенә генә төгәлсезлекләрнең дә әдәби әсәрне никадәр киметкәнен, милли үзенчәлекне никадәр боза алганын күрсәтү максаты белән, шушы өзекнең русчасын тәкъдим итәбез. «Это ничего, что он маленький,— сказал он Габдулле,— тебе хватит его, чтобы научиться писать. Научишься буквы писать, начнешь складывать из них слова. Сумеешь слова складывать, будешь писать стихи, а потом напишешь книгу. А когда твою книгу напечатают, ты будешь самым счастливым человеком на свете!»

Каюм Насыйри сүзләрендә татар мәгърифәтчеләренең: белем белән акыл гына яктылыкка илтә, дигән фәлсәфәсе салынган. Тәрҗемәче исә моны шагыйрьнең шигырьләрен бастырып чыгару, китабын таратырга омтылу кебек дан яратуга кайтарып калдырган. Әгәр чынлабрак тикшереп карасак, зур художник Әхмәт Фәйзи татар халкының атаклы мәгърифәтчесе теленә никадәр мәгънәле сүз сала, кычкырып торган итеп түгел, үз җаенда, эчке мәгънәсе белән ага торган итеп сала. «Әле аның үзеге күп» дигән сүзләрендә үк инде «үзәк» сүзе үзе белән зур гына йөк алып килә, халык күңелендә яткан зур үзәкне бирә, русчада ул берничек тә бирелмәгән, карандаш кисәгенә әйләнеп, баланы юатуга гына кайтарып калдырылган. Татарчадагы «китап язу» мәсьәләсе дә бары тик үзең иҗат итүгә генә кайтып калмый, шул мәгънәдә генә булса, китап язу биш яшендәге Апушка карата бик юрамалый әйткән сүз булыр иде. «Китап язу» тәгъбиренең китапны күчереп язу мәгънәсе дә бар бит

әле. Шул ук вакытта бу юл уңаенда Габдулланың язучы булачагына да ымлау, кистереп, әзеп әйтү түгел, нәкъ менә ымлау! Шуңа күрә дә ул безнең күңелгә хуш килә, безне ышандыра. Бу әзектә татарча үтемле дидактика да сакланмаган. «Каләм белгел, каләм изгегә тартыр...» тәрҗемә ителсә, рус укучысы татарларның бер психик сыйфатын, белемгә омтылуларын күрә алган булыр иде. Ә бит белемгә омтылу мәсьәләсе биредә шулай ук маңгайга терәп әйтелмәгән, китап шулай куша диелгән.

«Тукай» романының әченче кисәге Жаек каласының килеп чыгуы турындагы легенда белән башланып китә. Автор «шуннан, ярар» кебек сүзләр белән сөйләмдәге паузаларны тотыру алымы да куллана. Тәрҗемәдә боларның берсе дә юк. Габдулла Казан каласына килеп кергән чакта «күз күрмәгән, колак ишетмәгән» гаҗәп күренешләр белән мавыга. Әнә шул әкиятләрдән килә торган «күз күрмәгән, колак ишетмәгән» кебек образлы тәгъбирләр тәрҗемәдә тагын төшеп кала. Габдулланы әнисе: «Җәүһәремме син минем, якутыммы син минем?» — дип сөя. Русчада ул нигәдер: «Милый мой, жемчужинка ты моя» булып чыга. Сәнгать әсәрен чын мәгънәсендә әсәр иткән нәрсә «чуть-чуть» дигән Брюллов. Әнә шул «чуть-чуть» ычкынса, әдәби әсәр тәссезләнә. «Җәүһәремме син минем, якутыммы син минем!» дип дәшүдә кистереп әйтү юк, укучының үзенә уйларга ирек биргән «чуть-чуть» бар, русчасында ул беткән. Парлы әйберләр белән чагыштырып карау, гомумән, татар теленә хас нәрсә. «Алмамдыр шул, хөрмәмдер», «карлыганым минем, бөрлегәнем» дип әйтә халык. «Җәүһәремме син минем, якутыммы син минем!» — дип әйтү өчен татар теленең әнә шул гомуми үзенчәлеген дә белергә кирәк булып чыга.

Тәрҗемәдә милли үзенчәлекләрне саклау, шул үзенчәлекләрне рус укучысына да аңлаешлы формада китереп җиткерү тәрҗемәчедән тырышлык, талант, сиземләү, гаять зур эрудиция таләп итә. Күп вакыт подстрочник буенча тәрҗемә итүче иптәшләр халыкның гореф-гадәтләрен, милли үзенчәлекләрен, тарихын һәм этнографиясен белеп җиткермиләр. Бу хәл русчага тәрҗемә ителгән китапларның әдәби кыйммәтен нык киметә торган була. Моңа мисалларны күпләп китерергә мөмкин. Тукай кадәр Тукайның русчада әле милли телдәге зурлыгы белән, үткенлек белән яңгырый алганы юк. Такташ турында әйтеп тә тормыйбыз, аның русча тәрҗемәдән бөтенләй дә бәхете булмады. Ритмикасы да, аһәңе дә, шаянлыгы да аның русчага күчмәде, фикерләре ничектер саегып калдылар. Ә бит аны юк-бар тәрҗемәчеләр генә түгел, русның күренекле шагыйре Леонид Мартынов тәрҗемә итте. Арада иң уңышлы тәрҗемә ителде дип саналган Муса Җәлил әсәрләренең дә русчасы татарчадан кайтышрак. Татарчада үтә дә ягымлы, йомшак һәм гармоник Муса Җәлил русчасында коры булып, декларатив булып яңгырый.

Хикмәт нәрсәдә соң? Әллә безнең зур шагыйрьләрне дә урта кул шагыйрьләр тәрҗемә итәме? Һич тә юк. Татар әдәбиятының күренекле романнарын, классик шигъриятен күп кенә күренекле рус шагыйрьләре, рус прозаиклары тәрҗемә итте. Күрәсең, биредә гаеп бер тәрҗемәчеләрдә генә дә түгелдер. Шушы көнгә тикле Тукайның, Такташның, Фатих Кәримнең һәм башка шагыйрьләрнең җентекләп, кат-кат тикшерелгән, гыйльми институтларда расланган академик подстрочниклары юк. Кем ничек тели, шулай Тукайга подстрочник ясый, подстрочникта бозылган милли үзенчәлекләр әдәби тәрҗемәгә дә бозылып күчәләр.

Оригинал белән тәрҗемәне игътибар белән чагыштырып карау Әхмәт Фәйзинең «Тукай» романы русчада башкачарак килеп чыгуын бик ачык раслый. Ләкин бу «башкачалык» әсәрнең авторы файдасына түгел, татар әдәбияты файдасына түгел. Оригиналдагы милли үзенчәлек, татар халкына хас сыйфатлар тәрҗемәдә төшеп калганнар яки бозып бирелгәннәр. Димәк, әсәрнең җаны, әкренләп, суырып алынган. Шуңа күрә дә роман татарчадагы кебек яңгыраш ала алмады.

Татарчасында Тукай премиясе белән бүләкләнгән әсәр русча басмасында урта кулрак булып калды. Моңардан без үзебез өчен гаять мөһим бер нәтиҗә чыгара алабыз: әдәби әсәрдә милли үзенчәлек тагып куйган бер нәрсә түгел, мавыктыру һәм кызыктыру өчен эшләнгән экзотика гына түгел, бәлки аның органик бер өлеше, әгәр зуррак итеп әйтсәк, милли үзенчәлек ул — әсәрнең җаны, аның табигате, аның сәнгатьчәлеген билгели торган аерылгысыз бер сыйфаты. Тәрҗемә теориясе моңарчы булган тәрҗемә практикасын җентекләп өйрәнеп, уңай якларны берләштерергә һәм шуның белән милли үзенчәлекләрне башка телгә дә күчерүнең дөрес юлларын табуда тәрҗемәчеләргә булышырга тиеш.

**Рәфыйк Гарәфетдинов,**
тарих фәннәре кандидаты

# ӨЧ РЕВОЛЮЦИЯ БӨРКЕТЕ

*«...Ямашевтан бер генә ел соң, аның белән бергә социал-демократ большевиклар сафында эшли башлап, үзенең ару-талуын белмәве, тырышлыгы, гадәттән тыш фидакарьлеге, иң каты кысу-җәберләү вакытында да үз юлыннан кайтмавы белән аерыча урын тотканнарның берсе һәм беренчесе, шөбһәсез, Галимҗан Сәйфетдинов булды».*

Г. ИБРАҺИМОВ.

...1917 елның апрелендә, Мулланур Вахитов һәм Галимҗан Сәйфетдинов инициативасы буенча, татар хезмәт ияләре арасында революцион эш алып бару өчен Казанда Мөселман Социалистлар Комитеты оештырылды.

Аның составында большевиклар һәм сул эсерлар белән бергә Совет хөкүмәте өчен көрәшүче, социалистик революцияне яклаучы татар революцион-демократлары да бар иде. Бу, әлбәттә, карт большевикларга шушы оешманың үз эчендә дә большевистик идеяләр өчен көрәш алып бару бурычын йөкләде. Галимҗан Сәйфетдинов большевизм канатын тәшкил итте, бөтен комитетны большевистик итү өчен көрәште.

Галимҗан Сәйфетдинов царизмга, буржуазиягә, партия дошманнарына каршы көрәштә Мулланур Вахитовның юлдашларыннан берсе булды. Партия эшенә чын күңелдән бирелгән, турылыклы һәм курку белмәс татар революционеры иде ул.

Галимҗан Җамалетдин улы Сәйфетдинов 1882 елның 29 гыйнварында элекке Оренбург губернасы Троицк шәһәрендә туа. Бала чагы энесе Фазылҗан һәм сеңелесе Хәдичә белән бергә шул шәһәрдә үтә. Әтиләре Җамалетдин абзый белән әниләре Хәбибҗамал апаның балаларына уңай йогынтылары зур була. Галимҗан яшьтән үк һөнәргә өйрәнә: әтисенә читек-кәвеш тегү эшендә булыша.

Галимҗан 1895 елда, 13 яшендә, рус классына укырга керә. 1898 елда Троицк шәһәр училищесында укый башлый. 1901 елны Казанга килеп, Татарская учительская школага керү имтиханнарын уңышлы башкара. Бирелә Х. Ямашев, Г. Коләхметов һәм башкалар белән таныша. Алар белән бергә рус һәм чит ил язучыларының әсәрләрен өйрәнә. Бигрәк тә Ж. Ж. Руссо, Вольтер, Карамзин, Пушкин, Лермонтов, Фонвизин, Аксаков, Кольцов, Грибоедов, Тургенев, Гоголь һәм башка язучыларның әсәрләрен яратып укый.

1903 елда Галимҗан революцион прокламацияләр белән таныша һәм Казан революционерлары белән аралаша. 1904 елның апрелендә самодержавиегә каршы оештырылган революцион сходкага катнаша[1]. Шул ук елның май башында, укулар беткәч, каникул вакытында акча эшләп алу һәм алдынгы эшчеләр белән аралашу теләге белән, Урал якларындагы алтын прискаларына китә[2]. Ул анда эшчеләр сыйныфының алдынгы вәкилләре белән аралаша, социал-демократлар түгәрәкләренә катнаша, эшчеләр арасында революцион эш алып бара башлый. Алтын прискаларыннан Галимҗан тик августның урталарында гына Казанга кайта. Бу вакытта ул гади укучы гына булмый инде, ә социал-демократ-агитатор булып әверелә. Ул студентлар, шәкертләр, укучылар һәм эшчеләр арасында революцион эш җәелдерүдә катнаша.



Галимҗан Сәйфетдинов 1913 елда. Казан. (Фоторәсем беренче тапкыр басыла.)

1904 елның сентябрь — октябрь айларында Казан губернаторы исеменә Верхно-Уральск чиновникларыннан, алтын прискалары урыныннан, бер-бер артлы Г. Сәйфетдиновның «җәмгыять өчен куркыныч» кеше икәнен раслый торган хатлар килә. Казан губернаторы кушуы буенча, Учительская школаның педсоветы, 1904—1905 уку елының 1 нче чирегендә «4» һәм «5» билгеләренә тәмамлавына карамастан, Галимҗанның тәртибенә «4» билгесе куярга карар кабул итә. Г. Сәйфетдиновны яшертен күзәтү башлана[3]. Ләкин куркусыз Галимҗан революцион эшен туктатмый, ә, киресенчә, тагы да киңрәк итеп җәелдереп җибәрә.

1903 елда Галимҗан Учительская школа укучылары арасында социал-демократик түгәрәк оештыруга актив катнаша. Рус телен яхшы белүе нәтиҗәсендә, Казандагы гимназия, университет студентлары, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шәкертләре һәм завод-фабрика эшчеләре арасында оештырылган революцион оешмалар белән элемтә урнаштыра, алар арасында агитатор булып чыгышлар ясый. Сәйфетдинов школаның революцион карашлы укучылары арасында үзен булдыклы җитәкче, әзерлекле пропагандист һәм ялкынлы агитатор итеп таныта, укучылар белән бергә, завод-фабрика эшчеләре арасында сходкалар оештыра, революцион прокламацияләр тарата, политик речьләр белән чыга. Шундый сходкаларның берсе 1904 елның 8 ноябрендә үткәрелә. Галимҗан эшчеләргә социал-демократларның программасын аңлата һәм аларны эксплуататор стройга каршы көрәшергә чакыра[4]. Ләкин речен сөйләп бетерә алмый, полицейскийлар аны кулга алалар.

Ике көннән соң Галимҗан башка иптәшләре белән иреккә чыгарыла һәм полиция күзәтүе астына алына. Г. Сәйфетдиновның революцион эшкә актив катнашуы Учительская школа җитәкчеләренә дә ишетелә. Бу мәсьәлә турында 1904 елның 12 ноябрендә школа җитәкчеләре махсус педсовет җыелышы үткәрәләр. Җыелыш түбәндәге карарны кабул итә: «Укучылар арасында тискәре идеяләр таратуы һәм революцион хәрәкәттә актив катнашуы өчен Г. Сәйфетдиновны школадан чыгарырга»[5]. Шулай итеп, 1904 елның 12 ноябрендә Галимҗан Учительская школаның 4 нче классыннан куыла.

Галимҗан Сәйфетдинов, школадан чыгарылгач, Казанда төпле эш таба алмый. Ул үзенең тамагын туйдыру өчен аерым кешеләрнең балаларына русча дәресләр биреп көн күрә.

---

[1] ТАССР ҮДА, ф. 199, терк. бер. 1, эш 542, 532—533 битләр.
[2] Шунда ук. 364 бит.
[3] ТАССР ҮДА, ф. 142, теркәү берәмлеге 1, эш 72, 94 бит.
[4] Шунда ук, Ф. 199, теркәү берәмлеге 1, эш 542, 373—377 битләр.
[5] Шунда ук, 389 бит.

Укудан куылу, тормышындагы уңышсызлыклар Галимҗанның канатын сындыра алмыйлар.

1905 елның 5 февралендә Казанская Татарская учительская школа инспекторы тарафыннан язылган хатта бу хакта ачык әйтелә: «Галимҗан Сәйфетдинов школадан куып чыгарылганнан соң, Казанда үзенә билгеле бер эш таба алмый, төрле революционерлар белән очрашып, ул татар яшьләренә, бигрәк тә школа укучыларына, хәзерге хөкүмәткә каршы революцион юнәлеш бирә. Әмма, минем тарафтан Сәйфетдиновны школага кертмәс өчен чаралар күрелүгә карамастан, укучылар белән школадан тыш очраша, хәтта школа бинасына да төрле юллар белән үтеп керә. Мәсәлән, 4 февральдә сәгать 12 дә Сәйфетдинов, школага кереп, укучылар арасында агитация эшләре алып барды. Шуннан соң укучыларның үз-үзләрен тотышы кискен үзгәрде. Ә миңа, укучыларны яңадан тынычландыру өчен, бик зур хезмәт куярга туры килде...»[1]

Г. Сәйфетдинов жандармерия, полиция һәм провокаторларның күзәтүеннән дә курыкмый, революцион сходкаларда, җыелышларда үзенең политик речьләрен сөйли. 1905 елның 11 февралендә, татар приказчиклары җыелышында, забастовкага чакырып чыгыш ясаган вакытта, Галимҗанны тагын кулга алып, «полиция чаралары белән» частька озаталар[2], революцион түгәрәктә катнашуы өчен судка бирәләр. Ләкин Казан округ суды прокуроры Галимҗан Сәйфетдиновны төрмәгә утырту яки сөргенгә җибәрү өчен җитәрлек сәбәпләр таба алмый, аның эшен туктата. Ләкин буржуаз элементлар, милләтчеләр, ничек кенә булса да Галимҗаннан котылырга теләп, губернатор исеменә аны туган ягына, Троицк шәһәренә сөргенгә җибәрүне таләп иткән хатлар язалар[3].

Г. Сәйфетдинов яшерен полиция күзәтүе астында булуга карамастан, революцион эшен дәвам итә, политик җыелышларда катнаша, Алафузов, Крестовников һәм башка завод эшчеләре арасында төзелгән социал-демократлар оешмасында революцион речьләр белән чыга. Шул елларда ул Казанның мәдрәсә шәкертләре, Учительская школа укучылары, реалистлар һәм гимназистлар түгәрәгенең утырышлары үткәрелә торган «Сарай» исемле бинада беренче тапкыр Мулланур Вахитов белән очраша. Бу елларда Партиянең үзәк органнары битләрендә татар революционерлары турында язылган мәкаләләрдә Г. Сәйфетдиновның революцион эшенә зур бәя бирелә.

1905 елгы революция вакытында Галимҗан РСДРПның Казан комитетында эшләгән Я. М. Свердлов, В. В. Адоратский, И. А. Кулеша, Н. Н. Накоряков һәм башкалар белән таныша[4]. Алар йогынтысы белән марксизм-ленинизм тәгълиматын өйрәнә. Казандагы күренекле революционерлар белән бер сафта эшләү, 1905 елгы революцион хәрәкәтләр яшь көрәшченең политик яктан үсешен тизләтәләр. Ул Казан РСДРП комитеты каршында татар халкы һәм укучы яшьләр арасында эшләү өчен төзелгән пропаганда группасына член булып керә, бөтен көчен кызганмыйча шунда эшли. Комитетның кушуы буенча, татар эшчеләре арасында ана телендә агитация эше алып бара, татар эшчеләре өчен большевистик прокламацияләрне, листовкаларны русчадан татарчага тәрҗемә итә һәм эшчеләр арасында тарата. Бу прокламацияләрнең күбесе халыклар дуслыгына, пролетар интернационализмга багышланган була. Менә шуларның берсе:

> «Татар иптәшләр!.. Һәрвакыт исегездә тотыгыз: без сезне җәберләүче вә изүче патша хөкүмәтенә каршы көрәшкә чакырабыз. Без һәрвакыт уртак дошманны бары тик рус халкы белән бердәм союзга кереп кенә җиңеп була,— дибез.
>
> Рус эшчеләре дә, татар эшчеләре дә бер гаилә булып тату яшәргә тиешләр. Чөнки аларның язмышлары уртак... Эшчеләргә җиңү бары тик милләт эшчеләре— татарлар, руслар, яһүдләр, әрмәннәр белән берләшеп, кулга-кул тотынышып көрәшкәндә генә киләчәк. Шул чакта гына алар бәхетле тормышка ирешә алачаклар».

Г. Сәйфетдинов җитәкчелегендә бу прокламация Крестовниковлар заводы эшчеләре арасында 200 дән артык, Арсланов заводы эшчеләре арасында 100 дән артык,

---

[1] Шунда ук, теркәү берәмлеге 542, 550 бит.
[2] Шунда ук, 553 бит.
[3] Шунда ук, 549—550 битләр.
[4] Шунда ук, эш 735, 4 бит.

Утямишевләрдә — 50, Гольдбергта — 20, Зальмда — 50, Казан эшчеләре арасында барысы 800 дән артык таратыла[1]. Галимҗан кулы белән язылган прокламацияләр Казан эшчеләре арасында гына түгел, Оренбург, Астрахань, Троицк, Уфа, Баку, Чиләбе һәм башка шәһәр эшчеләре һәм шәкертләре арасында да киң тарала.



Галимҗан Сәйфетдинов РСДРП-ның Казан комитеты члены. 1905 ел.

1905 елның икенче яртысында большевистик прокламацияләрне һәм брошюраларны русчадан татарчага тәрҗемә итеп, аны тарату эшен Казан РСДРП комитеты тулысынча Галимҗанга тапшыра. Күренекле язучы һәм революционер Г. Ибраһимов бу турыда болай дип яза: «Бу эшнең (русчадан татарчага большевистик прокламацияләрне һәм брошюраларны тәрҗемә итү эшенең — Р. Г.) беренче җитәкчесе Хөсәен Ямашев булды, ә соңрак бу эш Г. Сәйфетдиновка тапшырыла. Ул бу эшкә бөтен көчен бирде». Ленинчыл «Пролетарий» газетасы 1905 елгы 15 номерында: «РСДРП Казан комитетында барлык прокламацияләрне диярлек татар теленә тәрҗемә итәләр, татарлар арасында тараталар һәм хезмәт ияләре тарафыннан зур кызыксыну белән укыйлар»,— дип язылган.

1905 елның март аенда гына да алты большевистик прокламация татар теленә тәрҗемә ителеп, хезмәт ияләре арасында 2371 данәдә таратыла[2].

1905 елның 12 декабрендә Галимҗан Сәйфетдинов РСДРП Казан комитетының башка членнары белән бергә кулга алына һәм төрмәгә ябыла. Шул вакытта аның квартирасыннан уңлаган яшерен прокламацияләр, революцион брошюралар һәм җырлар табыла[3].

1905 елның 15 декабрендә төрмәдә Галимҗаннан сорау алалар. Ул революцион эш белән бәйле бер генә сорауга да җавап бирми:

«— Сез социал-демократлар партиясе членымы!

— Җавап бирергә теләмим.

— Татар телендә прокламацияләр яздыгызмы! һәм аларны эшчеләр арасында тараттыгызмы!

— Мин татар телендә прокламацияләр язмадым һәм таратмадым.

— Кулга алынган вакытта сезнең квартирадан алынган прокламацияләрне һәм брошюраларны сез кайдан алдыгыз!


— Мин аларны шәһәрнең төрле җирләреннән таптым, кайберләрен каян алганымны белмим. Хәзер хәтеремдә юк. Ә брошюраны мин кешедән алдым, ул кешенең исемен сезгә әйтергә теләмим»[4].

Сорау алганда биргән җаваплары Галимҗан Сәйфетдиновның турылыклы революционер, большевиклар юлында нык торучан политик эшче икәнен ачык күрсәтәләр.

Галимҗан Сәйфетдиновны башта губерна төрмәсенә утыртырга дип хөкем итәләр дә, урын булмау сәбәпле, Казандагы озатып җибәрү төрмәсенең 14 нче камерасына ябалар. Галимҗан бу камерада Алафузов заводының ике эшчесе белән бергә утыра.

Бу «озатып җибәрү төрмәсе» Казанның башка төрмәләренә караганда да начар һәм пычрак була. Галимҗан төрмәнең эчке хәлләрен болай сурәтли: «Камерада һава бик дымлы һәм салкын. Йоклау чишенмичә, кием белән коры тактада, постель юк, ашау бик начар, без бүген ашаудан баш тарттык»[5]. Галимҗан Сәйфетдинов төрмә-

[1] Г. Ибраһимов. Татары в революции 1905 года, 1926, 34 бит.
[2] Шунда ук, 85 бит.
[3] ТАССР УДА, ф. 32, терк. бер. I, эш 53, 1, 4, 5, 6 битләр.
[4] Шунда ук, эш 735, 19—20 битләр.
[5] Г. Ибраһимов. Татарлар 1905 елгы революциядә, Казан, 1925, 124 бит.

Казан төрмәсендә жандармнар тарафыннан төшереп алынган фото. 1906 ел. (Беренче тапкыр басыла.)

ләрдә дә революцион эшен мөмкин кадәр дәвам иттерергә тырыша. Яшерен рәвештә революцион китаплар укый һәм аларның эчтәлекләрен иптәшләренә аңлата. Ләкин китаплар табу бик читен була. Төрмәдән бер иптәшенә язган хатында Сәйфетдинов болай ди: «...Китаплар бик кирәк. Миңа түбәндәге китапларны китерә алмассыңмы икән: Бах. «Экономические очерки», Эрфурт программасын, Оларның «Франция революциясе тарихын», Маркcның тәгълиматларын» [1].

Г. Сәйфетдинов Казанның «озату төрмәсендә» алты айдан артык утыра. Патша эчке эшләр министрының 1906 елның 24 июнендә чыгарган карары буенча, Галимҗан Сәйфетдинов полиция күзәтүе астында 2 елга үзәк шәһәрләрдән һәм үзәк губерналардан ерак урынга сөргенгә озатылырга тиеш була. Сөрген вакытын уздыру өчен, алдан уйланып куелган план буенча, ул татарлар күп яшәгән Оренбург шәһәрен сайлап ала. Җирле чиновниклар Галимҗан Сәйфетдиновның Казан эшчеләре һәм интеллигенциясе арасында авторитеты зур булуны исәпкә алып, аны ике ел урынына өч елга сөргенгә җибәрергә карар чыгаралар. Шулай итеп, күренекле татар революционеры Галимҗан Сәйфетдинов 1906 елның 3 июлендә «Общества по Волге» пароходына утырып, полиция күзәтүе астында Оренбург шәһәренә 3 елга сөргенгә озатыла [2].

Галимҗан, Оренбургка килгәч үк, җирле социал-демократлар белән таныша [3]. Татар һәм башкорт эшчеләре арасында революцион түгәрәкләр оештыра, эшчеләрне, крестьяннарны, шәкертләрне самодержавиегә каршы көрәшкә чакыра торган прокламацияләр чыгаруны һәм таратуны җайга сала.

Г. Сәйфетдинов язган һәм татар, башкорт эшчеләре арасында таратылган прокламацияләрнең берсендә, барлык милләт эшчеләрен гомуми дошманга — царизмга каршы көрәшергә чакырып болай диелгән: «Гомуми көрәш гомуми бәхетле тормыш төзү өчен оештырыла. Ирекле (социалистик — Р.Г.) дәүләттә һәрбер милләт өчен үзбилгеләнү, ягъни аерылып чыгу һәм мөстәкыйль дәүләт төзү хокукы булачак һәм аерым милләтләргә карата берникди җәберләү һәм эзәрлекләү булмаячак. Менә ни өчен социал-демократлар бөтен мөселманнарны Россияне ирекле иту өчен көрәшчеләр

---

[1] Г. Ибраһимов. Татарлар 1905 елгы революциядә, Казан, 1925, 124 бит.
[2] ТАССР ҮДА, ф. 199, тәрк. бер. I, эш 735, 16 бит.
[3] Ул Оренбургта большевик Арцыбушев (Маркс) белән бергә революцион эш алып бара.

сафына чакыра»[1]. Бу прокламациядә милли мәсьәлә буенча В. И. Ленин программасының эчтәлеге бирелә һәм анда Ленин идеяләренең татар социал-демократлары арасына үтеп керүе ачык тасвирлана.

Шул ук вакытта Г. Сәйфетдинов Оренбургта чыга торган газеталарга пролетар интернационализм, пролетариат гегемониясе, эшчеләр һәм крестьяннар союзы турында күп кенә мәкаләләр яза. Мәсәлән, «Степь» газетасы битләрендә Галимҗан Сәйфетдиновның милләтчеләрне, царизмны, капиталистларны баштанаяк фаш итә торган мәкаләләрен очратабыз. «Степь газетасының 1906 ел 58 санында басылып чыккан мәкаләсендә ул, «Гассан» исеме астында, «Иттифак» партиясенең III съездын үткәрергә әзерләнүче татар буржуазиясенең һәм милләтчеләренең чын йөзен күрсәтеп, большевиклар исеменнән түбәндәгеләрне яза: «Без, эшчеләр сыйныфы вәкилләре, татар эшчеләренә кисәтү ясыйбыз, бу партия («Иттифак» — Р. Г.) — фәкать байларның, эксплуататорларның интересларын гына яклый торган партия. Татар буржуазиясе татар эшчеләренең рус эшчеләре белән якын туганнар кебек кулга-кул тотынып эксплуататорларга каршы көрәшүеннән һәм аларның өешкан куәтле көчләреннән куркып, бөтен барлыгы белән эшчеләр сыйныфына каршылык күрсәтергә һәм аның сыйнфый аңын караңгыларга тырышалар.




Казан губерна жандарм идарәсе архивындагы бу «дело»га революционерның «гөнаһлары» теркәлгән.

Татар эшчеләренә алар, дини фанатизмнарын кулланып, «бөтен мөселманнар интересын яклый торган» ниндидер мөселманнар партиясе кебек хитрый механика өештырырга үйлыйлар...

Без, эшчеләр, сезнең партиягезгә каршы килабез, чөнки ул бары тик эшчеләр сыйныфының аңын караңгылату өчен өештырылган бер тозак кына... Ә без сезнең өешмага каршы үзебезнең эшчеләр өешмасы белән җавап бирербез. Безнең үзебезнең социал-демократик эшчеләр партиясе бар»[2].


Оренбургта вакытта Галимҗан Сәйфетдинов Казандагы иптәшләре белән элемтәнә өзми. Оренбургка күчкәч үк ул көрәштәш дусты Хөсәен Ямашев белән яшерен элемтә урнаштыра. Шулай ук Галимҗан Казаннан тентүләр, кузатүләр вакытында күчеп китәргә мәҗбүр булып, төрле шәһәрләрдә: Астраханьда, Бакуда, Чиләбедә яшәүче революционерлар белән дә элемтәгә керә.

1906 елның ахырында Галимҗан Сәйфетдиновның Хөсәен Ямашев белән язышкан хатларыннан күренгәнчә, алар икесе дә эшне киң җәелдереп җибәрү, революцион хәрәкәтне җитәкләү һәм татар хезмәт ияләре арасында большевистик идеяләрне пропагандалау өчен татар телендә большевистик газета чыгарырга кирәк дип табалар.

Шул уй белән Хөсәен Ямашев 1906 елның октябрь ахырында үзенең якын көрәштәш дусларының берсе Галимҗан Сәйфетдинов янына Оренбургка килә. Галимҗан

[1] Прокламациянең эчтәлеге «Степь» газетасының 1906 ел 82 нче санындагы «Соңгы хәбәрләр» бүлегендә «Мөселманнар, сезгә безнең сүзебез» дигән исем астында басылып чыга.

[2] «Степь», Оренбург, 1906 ел, 16 июнь, № 68.



СВѢДѢНІЯ

Жандарм агентлары тарафыннан Г. Сәйфетдинов өстеннән язылган донесениелар.

Сәйфетдинов Хөсәен Ямашев белән ике айдан артык «Урал» газетасын тудыру өстендә эшли. РСДРП Үзәк Комитетының зур булышлыгы, Хөсәен Ямашев, Галимҗан Сәйфетдинов һәм башкаларның армый-талмый эшләүләре нәтиҗәсендә 1907 елның 4 январенда (иске стиль белән) Оренбург шәһәрендә татар телендә беренче социал-демократик легаль газета — «Урал» чыга башлый.

«Урал» газетасының баш идея җитәкчесе — Хөсәен Ямашев. Ләкин газета чыгару белән бәйләнгән авыр катлаулы көндәлек эшләрнең күбесен, берсүзсез, Галимҗан Сәйфетдинов башкара. Ул шул ук вакытта «Урал» газетасының иң актив журналистларының берсе булып та таныла. Галимҗан «Урал» битләрендә бик әһәмиятле большевистик мәкаләләрен бастыра. Мәкаләләрен ул үзенең бабасы исеме «Баязит», «Баязитов» яки бабасының әтисе «Сәйфи» псевдонимы белән чыгара. Үзенең мәкаләләрендә Г. Сәйфетдинов большевиклар партиясенең максатларын һәм бурычларын, пролетариатның революциядәге җитәкче ролен, эшчеләр белән крестьяннар союзын ныгыту кирәклеген аңлата, милләтчеләрне фаш итә, бөтен милләт хезмәт ияләренең көчләрен алпавытлар һәм капиталистларга каршы оештыруның зур әһәмияте турында сөйли. Патша цензурасының җентекләп тикшерүенә карамастан, Галимҗан газета битләрендә татар хезмәт ияләрен рус эшче-крестьяннары белән иңгә-иң торып көрәшергә, самодержавиене бәреп төшерергә һәм Россиядә демократик тәртип урнаштырырга чакыра. Галимҗан Сәйфетдиновның теоретик мәкаләләре эшчеләрне берләштерүдә һәм аларның сыйнфый аңын үстерүдә, крестьяннар белән эшчеләр союзын ныгытуда, аларны пролетар интернациональ хистә тәрбияләүдә зур роль уйный.

Марксистик идеяләрне пропагандалауда, хезмәт ияләрен революцион рухта тәрбияләүдә Галимҗан Сәйфетдиновның «Урал» редакциясендә басылып чыккан брошюралары да әһәмияткә ия булып тора. Мәсәлән, «Гомуми сайлау хокукы турында»[1], «Россия социал-демократлары партиясе, авыл халкы өчен нәрсә булдырырга тырыша» һәм башка брошюраларның[2] мөселман халыклары арасындагы ролен күрсәтеп, Оренбург губернасы жандарм идарәсе начальнигы болай дип яза: «Бу брошюралар хәзерге капиталистик стройны тәнкыйть иткән, аның белән көрәшергә чакыра торган һәм җирне конфискацияләргә, национализацияләргә өндәгән материалларны үз эченә алган»[3].

Галимҗан Сәйфетдиновның «Урал»дагы революцион эше Оренбург, Уфа, Чиләбе татар эшчеләрен тәрбияләүдә генә түгел, ә бәлки Россиядәге бөтен төрки халыклары өчен дә әһәмияткә ия булып тора. Г. Сәйфетдиновның ялкынлы мәкаләләре, брошю-

---

[1] ТАССР ҮДА, ф. 199, терк. бер. I, эш 735, 1—21 битләр. (Жандармерия документларыннан күренгәнчә, бу китапның кульязмасы 1905 елның декабрендә Казанда Г. Сәйфетдиновның квартирасын тентегәндә табылган.)

[2] Г. Сәйфетдинов «Урал» редакциясендә рус теленнән татарчага тәрҗемә ителгән революцион җырлар җыентыгы да чыгара. Бу җыентык «Эшчеләр Марсельезасы», «Авыл кешесе җыры», «Бердәм, иптәшләр» һәм башка бик күп революцион җырларны үз эченә ала.

[3] КПСС Тат. өлкә комитеты партархивы, ф. 36, терк. бер. I, эш 18, 122—123 битләр.

ралары үзбәкләр, казакълар, әзербайҗаннар, башкортлар арасында да киң тарала. Галимҗан Сәйфетдинов «Урал»да эшләгән вакытта большевикларның Казан, Уфа, Оренбург һәм башка шәһәр комитетларының прокламацияләрен татарчага тәрҗемә итеп тә бастыра. «Урал» редакцияләреннән чыккан прокламацияләр Урал һәм Идел буе шәһәрләрендә, авылларында тарала.

Патша хөкүмәте, әлбәттә, «Урал» газетасының мондый революцион эшчәнлеге белән килешеп тора алмый.

1907 елның 27 апрелендә «Урал» газетасы полиция тарафыннан ябыла. Шул уңай белән Г. Сәйфетдиновның квартирасында тентү ясала. Бу вакытта Сәйфетдинов, полиция рапортыннан күренгәнчә, Хөсәенов йортында «Урал» газетасы һәм конторасы янында яшәгән. Гәрчә тентү бернинди нәтиҗә бирмәсә дә, Оренбург губернасы жандарм идарәсе начальнигы аны сорау алуга тарта. Ләкин Галимҗан, һәрвакыттагыча, үзенең революцион эшчәнлеген яшерә һәм үзен гаепле дип санамый. Шуңа да карамастан, жандарм идарәсе Сәйфетдиновны «мөселман халкы арасында үтә зарарлы һәм җитди агитатор» итеп таныл, 1907 елның 21 маенда, этап белән, Вятка губернасы Уржум шәһәренә сөргенгә озата [1].

Ләкин Г. Сәйфетдинов анда озак тормый, чөнки революцион эш белән шөгыльләнергә Уржумда мөмкинлекләр дә, мохит та булмый. Ул, РСДРПның Урал өлкә комитеты ярдәме белән, 1907 елның октябрь башында Уржумнан Уфага кача. Галимҗан Уфада яшерен рәвештә яши һәм РСДРПның Уфа комитеты членнары белән аралаша. Ләкин Уфада тентүләр һәм кулга алулар башлана. Һәм ул 1907 елның декабрендә Чиләбе шәһәренә күчә. Анда да озак тора алмый, Петропавловск шәһәренә барып, шундагы типографиягә эшкә урнаша. Анда революцион фикердәге Гариф һәм Закир Яруллиннар аша казакъ, кыргыз халыклары арасында революцион эш алып бара. Биредә дә ул үзенең политик мәкаләләрен җирле матбугат битләрендә бастыруын дәвам иттерә һәм марксизмны пропагандалый.

1908 елның җәендә Г. Сәйфетдинов туганнарын күрергә Троицк шәһәренә кайта, ә сентябрьдә яңадан Уржумга — сөрген җиренә килә.

1909 елда Галимҗанның сөрген срогы бетә. Ул, Хөсәен Ямашев белән хат аша килешүләрдән соң, Казанга кайта. Галимҗан Сәйфетдинов бу вакытта Казанда татар революционерлары арасында теоретик яктан хәзерлекле, политик яктан корычтай нык, төрмә-сөрген авырлыкларында чыныккан иң күренекле революционерларның берсе була. Аның инициативасы буенча шул ук елның 25 июлендә Казан социал-демократлар җыелышы үткәрелә. Бу җыелышка жандарм идарәсенә күптән билгеле булган Абрам Комлев, Хөсәен Ямашев һәм башкалар килә. Анда революцион хәрәкәтне күтәрү, социал-демократик эшне халык арасында киң җәелдерү, марксизм-ленинизм тәгълиматларын хезмәт ияләре арасында тарату кебек мәсьәләләр карала.

1907—1910 елларда Галимҗан Сәйфетдинов үзенең публицистик эшен дә киң җәеп җибәрә. 1909 елның 7 аенда гына да «Камско-Волжская речь» газетасы битләрендә аның 10 нан артык чыгышы урнаштырыла [2]. Царизмның, татар буржуазиясенең, милләтчеләрнең эзәрлекләүләренә карамастан, ул үзенең мәкаләләрендә буржуаз элементларга, самодержавиегә, милләтчеләргә кискен каршы чыга һәм хезмәт ияләрен пролетариат байрагы тирәсенә туплануга чакырып мөрәҗәгать итә.

1912 елда, М. Жаков җитәкчелегендәге Казан РСДРП комитеты җимерелгәннән соң, Галимҗан Сәйфетдинов, башка күренекле революционерлар белән берлектә, Казанда үтә яшерен социал-демократлар группасы оештыруга актив катнаша. Бу группага В. В. Адоратский, Н. Е. Сапрыгин, Хөсәен Ямашев һәм башкалар керәләр. Яшерен группа Казандагы бөтен социал-демократик хәрәкәткә җитәкчелек итә башлый. Галимҗан Сәйфетдинов бу группада, дусты Хөсәен Ямашев белән бергә, элеккечә, татар эшчеләре арасында алып барыла торган революцион эшкә җитәкчелек итә. Алар үзләре тирәсенә алдынгы татар эшчеләрен, демократик интеллигенцияне, революцион студентларны туплыйлар, һәм шуларга таянып, татар эшчеләре арасында самодержа-

---

[1] Р. М. Раимов. Татар телендә беренче социал-демократик газета. «Совет әдәбияты», Казан, 1945 ел, № 5, 39 бит.
[2] «Социалистик Татарстан», Казан, 1966 ел, 30 август.

виегә, буржуазиягә, милләтчеләргә каршы көрәш идеяләрен, марксизм-ленинизм тәгълиматын киң тараталар.

1912 елның 13 мартында, күренекле революционер Хөсәен Ямашев кинәт вафат булгач, Галимҗан Сәйфетдиновка эш тагын да арта. 1912—1914 елларда ул В. И. Ленин җитәкчелегендә чыга торган «Звезда», «Правда» газеталарын һәм Самара большевиклары тарафыннан чыгарылган «Заря Поволжья» журналын халык арасында киң тарата, большевиклар партиясе Үзәк Комитеты, аның үзәк органнары, В. И. Ленинның үзе белән элемтә урнаштыра. Н. К. Крупскаяның күптән түгел табылган язу дәфтәрендә бик күп революционерлар белән бергә Галимҗан Сәйфетдиновның да Казан адресы язып куелган [1].

Галимҗан Сәйфетдиновның большевиклар партиясе өчен авыр елларда Ленин белән элемтә урнаштырып, аның идеяләрен һәрьяклап яклап чыгуы, хезмәт ияләре арасында аны пропагандалавы бик күп нәрсә турында сөйли. Соңгы вакыттагы тикшеренүләр нәтиҗәсендә, Сәйфетдиновның хәзерге көнгә кадәр билгеле булмаган яңа яшерен исеме ачылды. Аның партия кушаматы «Ибниәмин» икәнлеге расланды [2]. Шунсы кызык: ул, партия кушаматы итеп, элекке кушаматлары кебек, семьясындагы кешенең исемен алган. Бу исем үзенең яңа туган баласының исеме була. Хәзер аның улы Ибниәмин Галимҗанович Казан институтларының берсендә доцент булып эшли. Шушы исем белән Галимҗан Сәйфетдинов партиянең үзәк органнары һәм Үзәк Комитеты белән язышып тора. Алардан партия әдәбияты һәм Казан большевикларын кызыксындырган күп сорауларга җавап ала. Мәсәлән, ул 1913 елның 31 январенда Ленин «Правда»сы редакциясенә милли мәсьәлә турында аңлатуны сорап мөрәҗәгать итә:

«...Минем бу сорауга [милли мәсьәләнең кайбер сорауларына — Р. Г.] нигезле билгеле карашым юк, сезгә мөрәҗәгать итәм һәм социал-демократларның бу сорауга карата булган фикерен тулы, аңлаешлы итеп язуыгызны үтенеп сорыйм.

...Сездән җавап көтеп, хөрмәт белән калучы «Ибниәмин» [3].

Икенче бер җирдә Галимҗан болай дип яза:

«Милли мәсьәләгә социал-демократиянең карашы нинди булырга тиеш! Минә бу сорауны үзем генә чишә алмыйм» [4].

Озак та үтми, Галимҗан Сәйфетдинов бу хатка каршы партиянең үзәк органыннан тулы җавап хаты ала.

Моңа кадәр РСДРП Үзәк Комитетының бу елларда татар большевикларына җибәргән күрсәтмәләре генә билгеле иде. Югарыда күрсәтелгәнчә, димәк, бу бәйләнеш ике яклап та алып барыла һәм бу бәйләнешнең Казандагы үзәге Галимҗан Сәйфетдиновта була. Чөнки Галимҗан Сәйфетдинов, бу елларда күренекле марксист-ленинчыларның берсе буларак, Казан губернасында гына түгел, ә Идел һәм Урал буе шәһәрләрендә, партиянең үзәк органнарында киң танылган була. Бу бәйләнеш В. И. Ленинның һәм РСДРП Үзәк Комитетының татар халкы демократик вәкилләренең идея үсеше, эшчеләр хәрәкәте, партия эше турында даими кайгыртып торуын өстәмә рәвештә раслый.

В. И. Ленин идеяләрендә тәрбияләнгән большевик Галимҗан Сәйфетдинов чын пропагандист һәм актив агитатор, «Правда» газетасының беренче чыккан көннәреннән үк, аның Казандагы хәбәрчесе була. Ул «Правда» газетасын, бигрәк тә Ленинның мәкаләләре басылган саннарын, яшерен юллар белән күп итеп ала һәм аны халык арасында: «Яхшы газета», дип,— киң тарата.

Галимҗан Сәйфетдинов «Правда» газетасы битләрендә милләтчеләрне, самодержавияне, алпавытларны фаш итеп, татар эшчеләрен явыз дошманга каршы пролетар интернационализм байрагы астына оешырга, Ленин «Правда»сын укып тәрбияләнергә мөрәҗәгать итеп мәкаләләр яза. Мәсәлән, 1913 елның 25 январенда чыккан «Правда» газетасының 20 нче санында аның «Татар эшчеләренә» дигән мөрәҗәгате басылып чыга. Бу мөрәҗәгать турыдан-туры В. И. Ленин һәм РСДРП Үзәк Комитеты күрсәтмәсе нигезендә языла һәм газетаның алгы битенә басыла. Шул ук вакытта бу мәкалә Казанда татар телендә чыга торган буржуаз газеталарны баштанаяк фаш итә, аларны

[1] «Исторический архив» журналы. Мәскәү, 1959, № 1, 17 бит.
[2] ОРҮДА, ф. ПДМБ, терк. бер. 1913, эш 5, бүлек 28, Л. Б. 9 бит.
[3] Октябрь революциясенең үзәк дәүләт архивы, полиция департаментының махсус бүлеге, терк. бер. 1913, эш 5, бүлек 28, Л. Б., 1 бит.
[4] Шунда ук, 1 битнең кире ягы.

«буржуаз газета», «буржуазия интересларын яклаучы газета» икәнен төрле яклап ачыклый. Татар эшчеләрен рус пролетариатыннан үрнәк алып, «Правда» кебек эшчеләр сыйныфы тормышын, аның көрәшен һәм таләпләрен яктыртучы газета оештырырга чакыра. «Правда» газетасының 1913 нче елның 25 январенда чыккан битләрендә Галимҗан Сәйфетдиновның түбәндәге сүзләре язылган:

«...Безнең арабызда русча укый-яза алырлык кешеләр бик күп һәм аңдыйларның саны артканнан-арта бара. Шуңа күрә мин рус телен аңлаучы барлык иптәшләргә эшче газетасы «Правда»га булышлык күрсәтергә тәкъдим белән мөрәҗәгать итәм.

Бу газета рус эшчеләренең генә түгел, ә, милләтенә карамастан, барлык пролетарийларның, рус, еврей, татар эшчеләренең — капитал изүе астында булган барыбызның да интересларын яклый. Рус хуҗа да, татар хуҗа да бер үк дәрәҗәдә эксплуатацияли. Без капитал белән көрәштә үзебез кебек үк рус эшчеләренә кул бирәбез.

Иптәшләр, бу газета тирәсенә берләшик! Бу газетага үз хаҗәтләрегезне, үз тормышыгыз турында языгыз! Русча укый белгәннәрегез аңа язылыгыз, аны һәр җирдә таратыгыз, анда язылганнарны русча аңламаучы иптәшләргә татарча тәрҗемә итеп укыгыз!» [1]

Галимҗан Сәйфетдинов, оста җитәкче, тәҗрибәле пропагандист, күренекле революционер буларак, Хөсәен Ямашев һәм Гафур Коләхметов тарафыннан татар интеллигенциясе арасында оештырылган демократик түгәрәкләргә дә актив катнаша, аларның утырышларында марксистик речьләр сөйли, пролетар интернационализм нигезләрен пропагандалый. Аның катнашында үткәрелгән җыелышларның күбесендә политик, экономик, социаль, милли мәсьәләләр тикшерелә. Мәсәлән, 1914 елның 20 февралендә Г. Кариев квартирасында булган татар демократлар җыелышында Галимҗан Сәйфетдинов беренчә тапкыр чыгыш ясый. Ул бу чыгышларында татар демократларын «идея эшенә», пролетариатның революцион көрәшенә актив кушылырга чакыра. Шул ук вакытта татар буржуазиясе вәкилләре һади һәм Садретдин Максудовларның, Галимҗан Галиевнең, Гаяз Исхаковның һәм башка күз буяучы «социалистларның» татар хезмәт ияләренең кискен дошманнары икәнен аңлата. Аларның төрле милләт эшчеләре сыйныфы арасында үзара сугышка өндәүче программасы берничек тә социал-демократлар программасына якын килмәвен ачыклый [2]. Ләкин җыелышта катнашучыларның кайберләре татарлар арасында яңа күтәрелеп килгән милли хәрәкәтне тар милләтчелек юлына борырга маташып чыгыш ясыйлар. Боларның барысына да Галимҗан Сәйфетдинов каршы чыга, революцион социал-демократлар күзлегеннән чыгып, татар халкының милли-азатлык хәрәкәтенең үсешенә дөрес бәя бирә һәм аны пролетар революцион көрәшкә кушылырга чакыра.

В. И. Ленинннан, РСДРПның Үзәк Комитетыннан хатлар аша алынган күрсәтмәләрдән чыгып, ул марксизм-ленинизмны пропагандалый [3].

Соңыннан Галимҗан Сәйфетдинов, җыелышта катнашучыларга мөрәҗәгать итеп, «Бөтен милләтчелек лагерена каршы юнәлдерелгән» (документта шулай язылган — Р. Г.) җыентык чыгарырга тәкъдим ясый [4]. Җыелышта катнашучыларның күбесе җыентыкны большевик Хөсәен Ямашев истәлегенә багышлап чыгарырга карар кабул итә [5].

Галимҗан Сәйфетдиновның революцион чыгышлары, марксизм теориясенең чисталыгы өчен көраше татар демократлар оешмасы членнарында тирән эз калдыра һәм аларның политик яктан үсүен тизләтә. Аның фидакарь эшчәнлеге нәтиҗәсендә татар демократларының алдынгы вәкилләре халык арасында марксистик идеяләрне таратуда, хезмәт ияләрен пролетар интернационализм рухында тәрбияләүдә һәм аларны царизмга каршы көрәшкә күтәрүдә большевиклар партиясенең ярдәмчеләре булып күтәреләләр. Царизмга каршы көрәштә тирән эз калдырган, милли-азатлык хәрәкәтенең күренекле вәкилләре Галимҗан Ибраһимов, Фатих Әмирхан, Шәһид Әхмәдиевләр шундыйлардан.

Билгеле булганча, яңа революцион күтәрелеш (1910—1914) елларында милли мәсьәлә Казан татарлары арасында да зур урын ала. Татар буржуазиясе бу елларда

---

[1] «Казан утлары» журналы, 1967, № 5.
[2] ОРҮДА, ф. ПДМБ, терк. бер. 1914, эш 32, бүлек 28, Л. Б, 25 бит.
[3] Саратов өлкә дәүләт архивы, ф. 51, терк. бер. I, эш 25, 1913 ел, 590 бит.
[4] ОРҮДА, ф. ПДМБ, терк. бер. 1914, эш 32, бүлек 28, Л. Б, 25 бит.
[5] СӨДА, ф. 51, терк. бер. I, эш 25, 1913 ел, 590 бит.

җыелышларда булмасын, «Ил», «Кояш», «Аң» һәм башка буржуаз газета битләрендә булмасын, эшчеләр хәрәкәтенең интернациональ бердәмлегенә каршы чыгалар. Казан большевиклары, аерым алганда Галимҗан Сәйфетдинов, буржуаз милләтчеләрнең бу омтылышларына отпор бирәләр. Мәсәлән, 1914 елның 3 январенда 200 дән артык татар эшчеләре җыелышында[1] Галимҗан Сәйфетдинов, милләтчеләргә каршы чыгып, милли мәсьәлә буенча партиянең ленинчыл программасын һәм политикасын болай дип аңлата:

«Аңлы эшчеләр милли хәрәкәттә диннән чыгып эш итәргә тиеш түгелләр, чөнки дин белән эшчеләр арасында бернинди дә уртаклык юк. Эшчеләр бу мәсьәләдә сыйнфый интереслардан чыгып эш итәргә тиешләр, чөнки бөтен эшчеләр интереслары гомуми»[2].

Галимҗан Сәйфетдинов бу сүзләрне В. И. Лениннан һәм РСДРП(б) Үзәк Комитетыннан хат аша алынган күрсәтмәләрдән чыгып әйтә.

Галимҗанның мондый чыгышларын буржуаз милләтчеләр ачу белән каршы алалар, хәтта ораторга каршы кул көче куллanудан да тартынмыйлар[3]. Ләкин большевик Галимҗан Сәйфетдинов милләтчеләрдән курыкмый. Ул милли изүнең хәтта иң кечкенә күренешләренә һәм милләтчелекнең барлык төрләренә каршы аяусыз көрәшә, барлык милләт эшчеләренең бердәмлегенә, аларны эшчеләр хәрәкәтенең төп үзәге һәм җитәкче көче булган рус эшчеләре тирәсенә тупланырга чакыра. Сәйфетдинов ленинчыл милли мәсьәлә буенча Казанда чыга торган «Камско-Волжская речь» газетасы битләрендә дә еш чыгышлар ясый.

Мәсәлән, шул газетаның 286 санында ул, приказчикларга мөрәҗәгать итеп, капитализмга каршы көрәштә барлык милләт эшчеләренең тыгыз бердәмлеген, аларның бердәм пролетар оешмага берләшүен таләп итә[4].

Беренче бөтендөнья сугышы елларында Галимҗан Сәйфетдинов Казанда яши[5] һәм царизм терроры һәм провокацияләре шартларында революцион эшен дәвам итә, революцион пропаганда өчен барлык мөмкинлекләрдән файдаланырга тырыша: легаль кооперативта, больничный кассада эшләп, империалистик сугышка, самодержавиегә, милләтчеләргә каршы эшчеләр арасында агитация алып бара, сугыш, тынычлык һәм революция мәсьәләләре буенча В. И. Ленин күрсәтмәләрен яклап чыга һәм аларны тормышка ашыру өчен армый-талмый көрәшә. Билгеле булганча, Галимҗан сугыш елларында В. Журалев һәм башка большевиклар белән бергә «Копейка рубль бережет» дигән кооператив оешмада эшли. Кооператив 2500 дән артык кешене берләштерә. Шуларның яртысы диярлек татарлар була[6].

Галимҗан Сәйфетдинов, кооператив эше белән дигән булып, Казан губернасының күп кенә өязләренә, шәһәрләренә йөри. Самара, Саратов, Царицын, Астрахань шәһәрләрендә була, аларда җирле большевиклар белән очраша, алар белән яшерен элемтәләр урнаштыра.

Төрмәләрдә утырып революцион чыныгу алган Галимҗан Сәйфетдинов бу елларда әнә шулай легаль оешмаларны үзе эше өчен оста файдалана белә.

Галимҗан Идел буе шәһәрләрендә йөреп кайткач, үзе эшли торган «Экспорт конторасы»ның филиалы булган Шәмәрдәнгә килә. Бирдә ул шулай ук кооператив оешманың эшен җайга салып җибәрә. Тирече-һөнәрчеләр һәм крестьяннар арасыннан алдынгы карашлы ышанычлы кешеләрне кооперативка тарта, «Профессиональ уку» түгәрәге оештырып, аның занятиеләрендә сугыш, тынычлык һәм революция мәсьәләләре турында чыгышлар ясый.

Галимҗан Сәйфетдинов, Февраль буржуаз-демократик революциясе җиңгәннән соң, Казанга кайта һәм РСДРП(б)ның Казан комитеты членнары белән элемтәгә керә. Әйтеп үткәнебезчә, татар хезмәт ияләре арасында туган телендә социализм идеяләрен аңлату, барлык революцион һәм демократик көчләрне берләштерү, татар буржуа-

---

[1] «Камско-Волжская речь». Казан, 1914 ел, 5 январь, № 4.
[2] ОРҮДА, ф. ПДМБ, терк. бер. 1913, эш 5, бүлек 28, ЛБ., 1 бит.
[3] СӨДА, ф. 51, терк. бер. I, эш 25, 1913 ел, 552 бит.
[4] «Камско-Волжская речь». Казан, 1913 ел, 31 декабрь, № 286.
[5] Г. Ибраһимов һәм кайбер башка галимнәр үзләренең хезмәтләрендә Г. Сәйфетдинов империалистик сугыш елларында армиядә булды, дип ялгыш язалар.
[6] ОРҮДА, ф. ПДМБ, терк. бер. 1916, эш 16, бүлек 28, Л. Б. 13 бит.

зиясенә һәм аның җырын җырлаучыларга каршы, милли азатлык хәрәкәтен үстерү һәм җитәкләү максатыннан чыгып, 1917 елның апрелендә, күренекле татар революционерлары Мулланур Вахитов белән берлектә, ул Мөселман социалистик комитетын (МСК) оештыра. Мөселман социалистик комитеты турыдан-туры Казан партия комитеты җитәкчелегендә эш итә. Галимҗан Сәйфетдинов һәм Мулланур Вахитов үзләренең планнарын, үткәргән чараларны РСДРП(б)ның шәһәр комитетына җиткереп торалар. Яңа күрсәтмәләр алалар. Г. Сәйфетдинов, башка татар большевиклары белән бергә, 1917 елда Казанда 1 нче Май бәйрәмен оештыруга һәм үткәрүгә җитәкчелек итә.

Мөселман социалистик комитетта, большевиклардан тыш, сул эсерлар да, социал-демократ-интернационалистлар да була. Бу хәл комитетның эшчәнлегендә чагылмый калмый. МСК тарафыннан җибәрелгән хаталар, аерым алганда, милли-культура автономиясе төзү политикасын яклау, Учредительное собраниегә сайлауларда милләтче элементлар белән берләштән үз кандидатларын кую кебек ялгышлыклар нәкъ әнә шулай комитет составының чуар булуыннан килеп туа. Хәтта комитет җитәкчеләренең үз араларында да фикер каршылыклары килеп чыга. Галимҗан Сәйфетдинов менә шул хаоста большевизм канаты булып бара, бөтен комитетны шуңа әйләндерү өчен көрәшә. Ул МСК җибәргән хаталар белән килешеп тора алмый һәм «аеруча җитди эш белән шөгыльләнү өчен» (Г. Сәйфетдинов сүзләре.— Р. Г.) комитеттан китә.

Шушы ук елның җәендә ул күңелендә йөргән икенче бер гаять кыю планын тормышка ашырырга керешә: вакытлы хөкүмәтнең таянычы булган коралды көчләрдән иң ышанычлысы — юнкерлар арасында таркату эшләре алып бару нияте белән, Казандагы юнкерлар мәктәбенә писарь булып керә һәм озак та үтми мәктәпнең укучысы итеп алына.

Ләкин шулай да ул МСК белән элемтәне өзми. Комитетка юнкерларның нинди настроениедә булулары турында мәгълүматлар биреп бара, аннан политик китаплар алып, аларны ышанычлы юнкерларга тарата, юнкерлар арасында революцион эш алып бара. Кыскасы, ул биредә революция өчен большевистик карашлы солдатлар әзерли.

Боек Октябрь көннәрендә Галимҗан Сәйфетдинов, Советлар яклы юнкерлар белән берлектә, яңа тәртипләр урнаштыруда актив катнаша. Бу көннәрдә Галимҗан җитәкчелегендәге революцион көчләр юнкерлар мәктәбендәге коралларны һәм касса акчасын Хәрби-революцион комитетка тапшыралар.

Октябрь революциясеннән соң да Галимҗан Сәйфетдинов күп вакытын эшчеләр арасында үткәрә, ул төрле җәмәгать оешмаларында эшли. Мәсәлән, үзенә таныш булган тиречеләр профсоюзын оештыруда башлап йөри, бүтән төр һөнәрле эшчеләр кооперативларын тәртипкә кертүдә булыша...

1918 елның 6 августында Казанга акгвардиячеләр һәм акчехлар бәреп керәләр. Г. Сәйфетдинов бу вакытта А. Маликов, К. Саттаров, В. Шәфигуллин һәм башка большевиклар белән Казанда кала. Яңа шартларга карап көрәш тактикасын үзгәртә. Ул акчехлар тарафыннан көчләп үткәрелгән мобилизациягә эләгә, дошманның үз арасына үтеп керә һәм анда таркату эшләре алып бара. Ләкин Галимҗан Сәйфетдиновның шуннан соңгы тормышы һәм эшчәнлеге турында хәзергә чаклы төпле материаллар табылганы юк иде әле. Шуңа күрә дә кайбер кешеләрдә Галимҗанның революцион эшчәнлегенә һәм аның фаҗигале үлеменә шик туган иде. Моның сәбәбе, әлбәттә, аның тормыш юлы һәм революцион эшчәнлеге әлегә кадәр фәнни күзлектән чыгып тиешенчә тикшерелмәүдән килеп туган булса кирәк.

Күптән түгел, Галимҗан Сәйфетдиновның хатыны һәм улы белән очрашкач, алар аның соңгы көннәре турында түбәндәгеләрне сөйләделәр: «Казанга акчехлар килеп кергәч озак та үтмәде, аклар, башка күп кешеләр белән бергә, Галимҗанны да көчләп «ирекле армиягә» мобилизацияләделәр. Безгә билгеле булганча, ул анда, башка большевиклар белән бергә, аклар гаскәрен таркату эше алып барды. Ул үзенең революцион эшләре турында, кичләрен квартирага кунарга кайткач, сөйли торган иде. 8—9 сентябрьләрдә кичләрен кызыллар ягына качу турында сүз алып барды һәм кичен, караңгы төшкәч, өйдән чыгып китте. Шуннан соң, суга төшкәндәй, юкка чыкты. Безнеңчә, Галимҗан татар милләтчеләре күрсәтүе буенча 1918 елның 10 сентябрендә аклар тарафыннан кулга алынган һәм җәзалап үтерелгән...

Совет хөкүмәте һәм Коммунистлар партиясе, Галимҗанның революцион эшчән-

легенә зур бәя биреп, аның әти-әнисенә РСФСР күләмендә персональ пенсия билг е-ләде»[1].

Бу сөйләшүләрдән соң без Мәскәү, Казан, Уфа, Оренбург, Киров һәм башка шәһәр архивларын тагын да җентекләп өйрәнергә керештек. Нәтиҗәдә югарыда әйтелгән шәһәр архивларында Г. Сәйфетдиновның революцион эшчәнлеге һәм фаҗигале үлеме турында күп кенә материаллар сакланганы ачыкланды. Мәсәлән, Мәскәү архивларында 1926 елның 13 январенда Татарстан мәгариф халык комиссары каршындагы Академия үзәге председателе, күренекле революционер, галим, әдип Галимҗан Ибраһимов һәм шул ук оешманың гыйльми секретаре[2] иптәш Норкин имзалар куйган документ саклана. Бу хакта Академия үзәге тарафыннан Г. Сәйфетдиновның тормыш юлын, революцион эшчәнлеген һәм фаҗигале үлемен өйрәнелүе, шулай ук кайбер материалларның җыентыкларда басылып чыгуы әйтелә.

Шул ук елның 23 январенда ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты каршындагы истпарт бүлеге мөдире, күренекле тарихчы Н. Знаменскийның, Г. Сәйфетдиновның татар халкының күренекле революционеры икәнен раслап, Татарстан социаль тәэминат халык комиссары исеменә язылган хаты табылды[3]. Шул ук материаллар арасында Г. Сәйфетдинов белән бергә МСКда эшләгән большевиклар Каюм Саттаров, Хәсият Гайнуллин, Вәли Шәфигуллиннарның имзалары, партия билетлары номерлары күрсәтелгән һәм аларның имзаларын партиянең Казан комитеты секретаре, Татарстан партия матбугаты секретаре, Казан шәһәр советы эшләре управляющийлары печать белән раслаган, Г. Сәйфетдиновның 1900 елдан алып яшерен революцион эштә катнашуы, 1905 елдагы революциядә күренекле большевик булып самодержавиегә каршы көрәшүе, төрмәләрдә, каторгаларда булуы һәм соңгы чиктә акчехлар тарафыннан атып үтерелүе турында документлар табылды[4].

Г. Сәйфетдиновның революцион эш өчен 1918 елда акчехлар тарафыннан үтерелүе турында башка документлар да ачык сөйлиләр. Шулай итеп, хезмәт халкының бәхетле тормышы өчен капитал ияләренә каршы үз-үзен аямыйча көрәшкән, җаны-тәне белән партиягә бирелгән революционер-большевикның гомере акчехлар кулыннан киселә.

1926 елның 1 мартында ТАССР Үзәк Башкарма Комитеты Президиумының 33 нче, РСФСР Үзәк Башкарма Комитеты Президиумының 1926 елның 26 апрелендәге һәм 1933 елның ТАССР Үзәк Башкарма Комитеты секретариатының 80 нче утырышларында Галимҗан Сәйфетдиновның Коммунистлар партиясе һәм эшче-крестьяннар хөкүмәте өчен революцион эшчәнлегенә югары бәя бирелә, аның әти-әнисенә РСФСР күләмендә персональ пенсия бирергә карар кабул итәләр.

Көрәш кырында татар халкының кыю егетләре Хөсәен Ямашев, Мулланур Вахитовлар белән иңгә иң куеп бер сафта атлаган Галимҗан Сәйфетдиновны без бүген горурлык хисләре белән хөрмәтләп искә алабыз.

---

[1] Истәлекләрне үземнең кыскача язмам буенча китерәм.
[2] РСФСР Социаль тәэминат министрлыгының персональ пенсионерлары архивы, 4684 нче эш, 1 тасвирлама, 3 бит.
[3] Шунда ук. 1—10 битләр.
[4] Шунда ук.

**Вэзих Исхаков**

# АЛТМЫШ ДҮРТЕНЧЕ КАВАЛЕР



Гражданнар сугышы фронтларында катгы көрәш барган чор. Кызыл сугышчыларның батырлыкларын билгеләү, аларны данлау өчен яшь Совет хөкүмәте беренче орден — Кызыл Байрак ордены булдыра.

Бу турыда карар кабул ителгәч тә Яков Михайлович Свердлов Халык Комиссарлары Советы Председателе В. И. Ленинга мөрәҗәгать итә:

— Беренче орденны кемгә бирик икән, Владимир Ильич? — ди ул.

— Һичбер шикләнүсез иптәш Блюхерга бирергә кирәк, Блюхерга! — дип җавап бирә Ильич.

Ул инде бу вакытта Блюхерның батырлыклары, аның Белореттан Күңгергә кадәр юл үткән атаклы Урал рейды хакында хәбәрдар була.

Бу орден белән гражданнар сугышында катнашкан байтак кына татар егетләре дә бүләкләнә. Шулар арасында ике тапкыр Кызыл Байрак ордены алучы батырларның берсе — Хөсәен Мәүлетов. Аның беренче ордены — 64 нче номерлы.

Хөсәен Мәүлетов Совет власте өчен барган аяусыз каты көрәш елларында гаҗәеп зур каһарманлыклар күрсәткән кеше. Башта ул Пермь округының татар-башкорт комиссариатына җитәкчелек итә. Аннары гражданнар сугышына актив катнаша. Анда полкка, бригадага командалык итә.

Гражданнар сугышы фронтыннан партия Үзәк Комитеты аны Хәрби академиягә укырга җибәрә. Аны тәмамлагач, берничә ел чит илдә СССР консуллыгында эшли. Ә аннары, гомеренең азагынача, Кызыл Армиянең Генераль штабындагы бүлекләрнең берсенә җитәкчелек итә.

## Комиссар

1918 ел. Яз.

Пермь округ Башкарма Комитеты бинасы алдындагы мәйданга Кызыл Армиянең 7 нче укчы Урал полкы тезелгән. Шәһәр халкы җыелган. Аларның күбесе түшләренә әлмәкләп кызыл тасма кадаганнар. Һәммәсе бәйрәмчә киенгән, һәммә кеше шат. Язгы кояш та аяз күк йөзеннән елмая, кешеләрнең шатлыгын уртаклашкандай, үзенең

жылы нурларын җиргә коя. Мәйдан өстендә Кызыл байраклар җилферди.



*Х. Мәүлетов 1937 елда.*

Мәйдан уртасына такталардан трибуна эшләп куйганнар. Ул кызыл ситса белән уратып алынган. Трибунага бер-бер артлы ораторлар күтәрелә. Алар — рус, латыш, еврей, татар, башкорт — һәркем үз телендә сөйли.

Менә трибунага тагын бер оратор чыга. Ул хәрби киемдә. Түшендә кызыл бант.

— Иптәшләр! — дип башлый ул үзенең сүзен татар телендә.— Совет власте дөньяда һәм кешелек тарихында беренче тапкыр барлык хезмәт иясе халыкларына ирек бирде, аларны байлар, капиталистлар изүеннән, эксплуатациядән, коллыктан мәңгелеккә азат итте. Милләтләр арасында тигезлек, дуслык, туганлык һәм хезмәттәшлек игълан итте.

Оратор, халыкка карап бераз тынып торды да, болай диде:

— Иптәшләр! Менә мин, элек булса, сезнең алдыгызга чыгып шушылай ана телендә сөйләп тора алыр идемме? Юк, әлбәттә. Сез моны яхшы беләсез.

— Дөрес, энем.

— Кая инде ул безнең халыкка үз телендә алай сөйләп торулар...

Халык төркеме гөж килеп ораторның фикерен хуплавын белдерә. Ә трибунага менгән егет сүзен дәвам итә:

— Совет власте безгә ирек, азатлык алып килде. Шуңа күрә дә, иптәшләр, әйдәгез үзебезнең яшь Совет республикасының революцион оешмаларын — эшче, солдат һәм крестьян депутатлары Советларын ныгытыйк. Башында бөек Ленин торган Халык Комиссарлары Советын — революциянең тулы хокуклы хөкүмәтен бөтен яктан яклыйк...

Аннары оратор революцион оешмаларга теләктәшлек күрсәтү белән бергә, Кызыл Армия сафларын ныгыту турында озак кына сөйли. Аның сафларына язылырга өнди.

Трибунага чыгып әнә шулай сөйләгән бу кеше — Пермь округының эшче, крестьян һәм кызылармеец депутатлары Советы башкарма комитеты каршында яңа гына төзелгән округ мөселманнар комиссариаты җитәкчесе комиссар Хөсәен Мәүлетов иде.

Хөсәеннең тормышы кече яшьтән үк зур авырлыклар, михнәтләр белән үтте. Әле җиде яше дә тулмаган иде, әнисез калды. Ныклап аякка да басып өлгермәде — 1900 елны Чистайдан бәхет эзләп Пермьга күчеп килгән әтисе Баһаветдин агай да дөнья куйды.

Үзенең үтә зирәклеге, нык тырышуы сәбәпле генә белем алып, укуын дәвам итә алды ул. Ә империалистик сугыш башлану белән фронтка озаттылар. Өч елга якын гомере шунда — каты сугышларда, окопта узды. Быелтыр көз, Октябрь революциясе алдыннан гына, каты яраланып Пермь госпиталенә кайтарылган иде ул.

Монда аның туганнары яши. Монда аның яшьлеге үткән. Әйе, нык таныш аңа бу шәһәр. Шуңадыр инде, дөньяның ачысын-төчесен татырга өлгергән Хөсәен, бик тиз большевиклар белән дуслашып китте. Үзе дә партия сафына керде. Менә аңа комиссариат белән җитәкчелек итүне тапшырдылар.

Аның кул астындагы Пермь мөселман комиссариаты кыска гына вакыт эчендә әллә никадәр эшләр башкара. 1918 елның җәендә комиссариат Күңгер, Кизель, Екатеринбург, Оса, Красноуфимск шәһәрләрендә һәм Надеждинск белән Чусовой заводлары янындагы Советларда мөселман эшләре буенча өяз комиссариатлары оештыра. Бу шәһәрләрдә һәм заводларда тамыр җәяргә исәп тоткан хәрби-шура, милли-шура

кебек февраль революциясеннән соң татар буржуаз милләтчеләре тарафыннан оештырылган контрреволюцион учреждение һәм оешмалар бөтенләй таратылып, алар урынына совет оешмалары — комиссариатлар төзелә.

Пермь мөселман комиссариатына уфалылар да зур гына ярдәм күрсәтәләр. Шул ук җәйне бу комиссариат карамагына Уфадан берничә работник җибәрелә. Алар үзләре белән күчмә типография дә алып киләләр. Озакламый комиссариат Хөсәен Мәүлетов редакциясендә «Кызыл Урал» исемле газета чыгара башлый. Бу — Пермьда татар телендә чыгарылган беренче большевистик газета. Газета битләрендә Совет хөкүмәтенең күп кенә мөһим карарлары, декретлары басылып чыга.

Ул көннәрдә Хөсәен Мәүлетовның көрәштәшләреннән берсе булган, ә хәзер персональ пенсионер Нигъмәт Еникиев менә нәрсә дип яза: «Без, Бәләбәй өязе Башкарма Комитетының алты члены: Атнагулов, Байков, Курмиев, Гафуров, Габитов һәм мин Пермьга, аның округ мөселман эшләре комиссары иптәш Хөсәен Мәүлетов карамагына килдек. Ул безне шатланып кабул итте һәм, һәрберебезгә эш биреп, урыннарга тәгаенләде. Мин, мәсәлән, Пермь округ мөселман комиссариатының оештыру-агитация бүлеге мөдире булдым...» Бер үк вакытта Н. Еникиев башка эшләр дә башкара, өеруча газета чыгаруга зур булышлык күрсәтә.

Комиссариат татар телендә берничә брошюра да бастыра. Шул исәптән, «В. И. Ленинның кыскача биографиясе» һәм башка мөһим генә директивалар тәрҗемә ителә. Ләкин, планнары зур гына булса да, бу эшне алар туктатырга мәҗбүр булалар.

Вакыйгалар көннән-көн куера бара. Көз җитә. Көнчыгыш фронтта хәлләр кискенләшә. Колчак армиясе Пермьга якынлаша. Ул Совет республикасының төньяк өлешен басып алган Англия-Америка интервентлары белән кушылырга ашкына.

Кызыл Армия частьлары дошманның көчләренә каршы бик каты сугышлар алып бара. Ләкин дошман явы аларны һаман кысрыклый һәм менә шушы авыр шартларда Хөсәен, кулына корал алып, сугышчылар сафына баса. Ә ярты елдан соң ул инде полк белән командалык итә башлый.

## Батырлыкка дан

Шулай да була бит: кеше үзенең тормышында иң кыен, иң куркыныч минутлар кичергәндә бу турыда уйлап та карамый. Ә инде әнә шул авырлыклар, иң куркыныч вакыйгалар артта калдымы, кем генә булмасын, ирексездән бу хакта уйлый торган, хәтта үзенең башыннан үткәннәргә хәйран калып, шаккатып калучан була. Ак казакларның Идел корпусын тар-мар иткәннән соң, Хөсәен Мәүлетов белән дә менә шулайрак булды.

Теркстан фронты частьлары, Мугаджар станциясе янында Теркстан республикасы отрядлары белән очрашканнан соң, Колчакның Көньяк армиясе калдыклары, әерым алганда, ак казакларның Илек корпусы, Уел ягына, далага кереп китәләр. Аклар, тизрәк Уел шәһәренә барып җитеп, аның ныгытмалары артына яшеренеп, шунда ышыкланып торырга уйлыйлар. Аларны куып бару өчен махсус экспедицион җыелма отряд төзелә. Һәм аның төп ядросы булып өченче татар укчы полкы тора.

Хөсәен Мәүлетов командалыгындагы бу отряд, көзге каты суыкларда, ноябрь аенда, Уел елгасын аша кичеп, шәһәрне азат итә. Бу җиңүне, фронттагы IV армиянең Джамбейтаны алуы белән бәйләп, М. В. Фрунзе менә болай дип яза: «Бу ике үзәкне алу безнең кулга барлык кыргыз далаларын бирде». Ә бит моңа ирешү өчен күпме көч түгелгән, күпме михнәтләр кичерелгән иде!..

Чыннан да, Хөсәен Мәүлетовның бу җиңүгә ничек ирешүен күрсәтү өчен, шул хакта язылган документтан кечкенә бер өзек китереп үтү урынлы булыр. «Безгә 14 ноябрьдан да калмыйча Уелны алу турында боерык бирелгән иде,— дип язылган татар бригадасының көндәлегендә.— Үзенең төп максатына ирешү — Уел ныгытмасын алу өчен безнең отряд Бегалыдан чыкты. Баштагы отрядка өченче батальон һәм батарея кушылганнан соң, безнең барлык отряд — өченче татар укчы полкы, өченче батарея, кавалерия дивизионы һәм атлы ике пушкасы белән Беренче кавбригада — Уелга һөҗүм итә башлады. Пехотага ачык тигез урыннан дошманга туп-туры карап

барырга туры килде, ә кавалерия, частьларга бүленеп, флангларга җибәрелде. Безнең полк иң авыр шартларда хәрәкәт итте: бер яктан — Уелга кереп торган җирдә үтә алмаслык баткаклык һәм сазлык, ә икенче якта — ярыйсы гына тирәнлектәге һәм туңа башлаган Уел елгасы. Сугышчыларның киемнәре начар иде, ә яртылашы ялан аяк диярлек... Бу сугышларда күрсәткән казанышлары өчен өченче полкны «Кызыл беркетләр» полкы дип атадылар...»

Әнә шушы уйларга бирелеп, Хөсәен кулларын баш астына куеп чалкан яткан, түшәмне күзәтә иде.

Якында гына җыр тавышы ишетелде:

**Уелып кына аккан Уел**
**Уйландыра уйчан ирләрне...**

Бу җыр Хөсәенне кинәт сискәндереп җибәрде.

— Кара әле, Яхъя бит! — дип сокланып куйды.

Ә җырчы, чыннан да, башкорт халкының моңлы озын көен бик матур тавыш белән җырлый иде.

Аннан яңа гына булып үткән вакыйгалар — соңгы сугыш — Хөсәеннең күз алдына килеп басты. Сугыш картиналары бер-бер артлы кабатлангандай тоелды. Менә куып барган дошман белән йөзгә-йөз килеп беренче очрашу. Алда куәтле, сугыш алып баруның барлык кагыйдәләре буенча өйрәтелгән, баштанаяк коралланган дошман гаскәрләре тора. Ә аның отрядындагы сугышчыларга патроннар гына да җитәрлек түгел иңмәсәм. Һәрбер хәрәкәтне, һәрбер адымны искә алып, аңа дөрес юнәлеш биреп торырга кирәк.

Хөсәеннең беренче тапкыр отрядны кузгатып һөҗүмгә күчәргә теләве уңышсыз тәмамланды. Бераздан ул тагын да алга омтылып карады, ләкин бу юлы да уңышсыз чыкты.

Аклар, әллә инде бу хәлне сизенеп, әллә башка берәр сәбәп беләнме, активлаша башладылар. Пулеметлар тыкылдавы көчәйде һәм менә шундый иң киеренке минутларда, үлем куркынычы күз күреме арада торганда, Хөсәен бөтен акылын җыеп, үзенең төп максаты — дошманның планын җимерү — турында уйлый иде.

— Командир алгы сызыкта!

Кызылармеецларның колактан колакка әйткән бу сүзләре тиз арада окопларга таралды.

Алар командирның якында гына, үзләре белән бергә булуын тоеп, рухланып һәм дәртләнеп киттеләр.

— Ул монда килдеме, атаканы көт тә тор, егетләр! — дип куйды кызылармеецлардан берәү.

— Булса соң, командир белән бергә күңеллерәк тә ул,— диген булды икенчесе.

Ләкин шаяртып торыр чак түгел иде. Шул арада булмады, окоплар буйлап команда тапшырылды:

— Атакага әзерләнергә!

Сүз башлаган теге кызылармеец түземсезләнеп:

— Әйттем бит! — дип, иптәшенең кабыргасына төртеп алды.

Беренче командадан соң ике-өч минут та үтмәде, отряд командирының көр тавышы яңгырады:

— Революция дошманнарына, Совет власте дошманнарына каршы минем арттан алга, иптәшләр!

Кызылармеецлар, аягүрә торып, киң стена булып кинәт алга ташландылар. Сугыш яланын тутырып, кинәт күк күкрәгәндәй көчле «ура!» яңгырады.

Аклар, бу хәлне күреп, котырынып ут ачтылар. Ләкин кызылларның дәһшәтле килүе аларда паника тудырды. Алар коралларын ташлап артка таба сыпырта башладылар.

Хөсәен Мәүлетов җитәкчелек иткән отряд белән акларның Илек корпусы арасында барган каты сугышлар берничә көн дәвам итте.

Һәм менә, ниһаять, җиңү.

— Бу операция өчен сез хөкүмәт бүләгенә тәкъдим ителдегез,— диделәр Хөсәенгә бригада штабында.

Шатлыклы хәбәрне ишетү Хәсәеннең күңелен күтәреп җибәрде.

Хәсәен маңгаена бәреп чыккан тир бөртекләрен сөртеп алды да кесәсеннән портсигар чыгарды.

— Әйе, бу җиңү безгә ансат кына бирелмәде шул,— диде әченнән генә. Аннан иплап кенә папиросын кабызды да, бинтка урап муенына аскан кулын тотып карады.— Ә бит күпме иптәшләребез сугыш кырында ятып калдылар...

Бу турыда уйлау Хәсәенгә авыр иде, әлбәттә.

Хәсәеннең фикерен ординарец Яхъя Адымов бүлдерде.

— Сезне сорыйлар, иптәш командир,— диде ул.

— Кем бар, кем сорый?

— Менә крестьяннар килгән.

Хәсәен үз алдында бер төркем крестьяннар басып торганын күрде. Алар үзара нидер пышылдап, нидән башларга белмәгәндәй кыймыйрак торалар иде булса кирәк. Шунда өлкән генә яшьтәге берсе, Хәсәеннең үзләренә табан борылганын күргәч, сүз башлап җибәрде:

— Исәнмесез, иптәш командир!

— Саумысыз, иптәшләр!

— Кем монда сезнең баш кеше була?

— Мин. Ә ни йомыш?

— Әйе, кем, менә без, крестьяннар, сезне җиңү белән котларга килгән идек, иптәш кызыл командир. Бик нык җәфа чиктек без аклардан...— Карт нидер әйтеп бетерми туктап калды. Аннан ул кулындагы бүреген йомарлап бераз торды да иптәшләренә карап куйды. Бары шуннан соң гына ул яңа Хәсәенгә мөрәҗәгать итте:

— Менә Евдокимның кызын,— карт иң артта басып торган озын гына мужикка төртеп күрсәтте,— аларның бер офицеры, тегә ни...

— Сез миннән ни телисез соң?

— Әйе кем, иптәш командир, әнә шул офицер исән. Баягынак без аны тотып алдык, бәйләдек...

Хәсәен хәзер генә крестьяннарның ни өчен килүләрен аңлап алды. Әйе, бу кешеләр Кызыл Армиянең килүен, аның акларны куып җибәрүен көткәннәр ич! Әйе, әйе. Бу шулай. Ул куанычыннан үзенең яраланмаган кулы белән картны кочаклады.

— Их, бабакай, кадерлем минем! Кая, алып килегез сез аны монда! — Аннан Хәсәен үзенең ординарецына кычкырды:— Яхъя, ярдәмләш!

— Бик зур чинлы офицер ул, штабтан...

— Ничего, бабай, анысын тикшергәч белербез. Күп күргән инде без андыйларны...

Һәм, чыннан да, ак офицер зур гына козгыннарның берсе булып чыкты. Ул Илек корпусының штаб офицеры икән. Контузия алгач, күрәсең, үлгән диптер, аны ташлап киткәннәр. Кызылларның Уелны алганын белгәч, ул качарга теләгән. Ләкин аны крестьяннар тотып алганнар һәм бәйләп ташлаганнар.

— Сез кыргый дивизиядән түгелдер бит? — дип сорады ул Хәсәеннән.

— Мин сезне аңламыйм.

— Безнең корпуска каршы кызыллар ниндидер бер кыргый дивизия җибәрделәр. Руслардан түгел. Тамак төбе беләнрәк сөйли торган халыклар... Татарлармы шунда...

— Әх, менә нәрсә икән! — Хәсәен көлеп җибәрүдән чак-чак кына тыелып кала алды.— Сез үзегезнең корпуска каршы сугышучылар турында әйтәсез булырга кирәк.

— Әйе.

— Ул бердәнбер җыелма отряд иде, подполковник әфәнде.

— Булуы мөмкин түгел!

— Теләсәгез ни дип уйлагыз, әмма факт күз алдыгызда.

Әйе, акгвардеецка башка әйтер сүз калмады...

* * *

Ләкин бу җиңү ансат кына булмады. «Ак казаклар һәм Алаш Орда белән көрәшү,— дип яза Татар бригадасының шул чактагы хәрби комиссары Якуб ага Чанышев,— өченче полкка бик кыйммәткә төште. Ул үзенең бик күп сугышчан командирларын һәм сугышчыларын югалтты. Бу сугышларда батальон командиры Шәйхетдинов, пуле-



*1919 ел. Х. Мәүлетов — полк командиры.*

метчик Габитов, аерым татар кавалерия дивизионы командиры А. И. Мельников, политработник Абдрахман Шакиров иптәшләр аеруча кыюлык күрсәттеләр.

Мәүлетов Хөсәен белән комиссар Гали Касимов, җыелма отрядка менә дигән командалык итеп, үзләренә йөкләтелгән зур хәрби һәм политик бурычны намус белән үтәп чыктылар. Бу сугышларда алар байтак тәҗрибә туплап, аны Бохара ханлыгын туздырганда уңышлы файдалана алдылар...»

Бу сугышларда каһарманлык күрсәткән тагын бер кеше хакында әйтәсе килә. Ул — Усман Фәхретдинов. Өченче татар укчы полкының батальон командиры. Әле беренче империалистик сугыш фронтларында ук батырлыклары өчен дүрт тапкыр Георгий медале һәм башка медальләр белән бүләкләнгән ул. Өченче татар укчы полкы оештырылганның беренче көненнән алып шушы полк составында була һәм күп, бик күп сугышларда катнаша. Кызыл Армиянең Үзәк архивында саклангаң бер документта: «Усман Фәхретдинов үзенең батальоны белән акгвардеецларның һәм атлы казакларның берничә полкларын тар-мар итте һәм күп кенә трофей алды», — дип язылган.

Акларның Илек корпусын тар-мар итүдә күрсәткән батырлыклары һәм отрядка оста командалык иткәне өчен Совет хөкүмәте Хөсәен Мәүлетовны каһарманлык символы булган Кызыл Байрак ордены белән бүләкли һәм ул Совет власте тарафыннан чыгарылган иң беренче орденның 64 нче кавалеры була...

## «Безнең Чапай»

«Батыр үзе үлсә дә, даны үлми», — дип, халык юкка гына әйтми ул. Лбищенск шәһәрендә 25 нче дивизия штабы һәм даны киң таралган дивизиянең начальнигы герой Чапаевның һәлак булуы кызылармеецларның йөрәген әрнетә. Бу хәбәр тиз арада татар бригадасына да килеп җитә.

— Менә син аны, шундый кеше дә һәлак булгач, әй!

— Сугыш ул, туганкай, атаң-анаң бармы дип сорамый шул.

— Алай...

— Үч алырга кирәк, менә шул.

Шуннан соң берникадәр вакыт үткәч, Төркстан фронтының Революцион Хәрби Советы бу дивизиягә легендар командир Чапаев исемен бирә.

Бу вакытта ук инде Василий Иванович Чапаевның исеме бик популяр була. Аның даны еракка-еракка тарала. Исеме һәрбер кызыл командирга, һәрбер кызылармеецка аеруча якын һәм кадерле була. Ә дошман аны ишетсә тетрәп, каушап кала.

— Чапайны әйтәм, безнең яктан дип сөйлиләр.

— Куй әле, энем. Нишләп ул сезнең яктан булсын ди. Безнең яктан ул — Уралдан. Әнә үзенең Уралы өчен нинди сугыша иде бит.

— Дөресен әйтим, егетләр, хаталанасыз. Ишеткәнсездер ич, Идел буендагы шәһәргә аның исемен дә бирделәр. Балаково диделәрме әле. Хәзер ул Чапаев шәһәре дип аталачак. Димәк, ул безнең якташ — Идел буеннан...

Менә шулайрак сөйләшә иде кызылармеецлар үзара. Һәркайсы аларның бу геройны үзенчә якын итә, аңа кайнар ихтирам саклый иде. Һәрберсе аны үзләренең якташы дип саный, шуны исбат итәргә тырыша. Ә менә инде Идел буе Беренче аерым татар укчы бригадасына килсәк, андагы солдатлар арасында бу темага аеруча кызу бәхәсләр бара иде.

— Безнең Хөсәен Мәүлетов та батыр бит, ә?

— Әлбәттә. Әнә узган сугышларны гына искә ал әле.

— Әйе ләбаса. Башка берәү булса шулкадәр көчле дошманга каршы чыгарга куркыр иде. Ә ул үзе атакага алып китте.

— Җитмәсә күпме әсир алдык диң...

— Әйтмә дә инде, абый. Кыюлык аңарда җитәрлек. Баш та яхшы эшли үзендә. Молодчина, башка һич сүз әйтеп булмый.

— Ярман сугышында да булган шул. Сугышның рәтен-җаен белә.

Бригаданың командирлары һәм сугышчылары, хәтта үзләре дә абайламастан, шул көннәрдән соң Хөсәен Мәүлетовны «безнең Чапай» дип йөртә башлыйлар.

Бер-бер урында аның турында сүз чыкса:

— Ә-ә, безнең Чапай хакында әйтәсезме? — ди торган булалар.

Хөсәен Мәүлетов бригадада иң популяр исемнәрнең берсенә әверелә. Аның исеме күп тапкырлар Төркстан фронты командующие приказларында да телгә алына. Хөсәен Мәүлетовның батырлыклары, ул башкарган эшләр турында фронтның Революцион Хәрби Советында да яхшы хәбәрдар булалар. Әйе, әгәр халык сүзләре белән әйтсәк, егетнең даны үз кулында ул — батырны яу тудыра, көрәш чыныктыра...

## Тәвәккәл — таш ярган

Урал таулары арасында һәм Оренбург далаларында барган туктаусыз каты сугышлар, айлар буена юньләп йокы күрмәү, һәм шулар өстенә соңгы сугышларда алган берничә яра Хөсәеннең сәламәтлеген нык кына какшата. Ул күзгә күренеп ябыга, йончый.

— Сиңа азрак ял итәргә иде, Мәүлетов, — диләр аңа бригада штабында.

Әмма Хөсәеннең моның белән килешәсе килми.

— Сез нәрсә, иптәшләр, — ди ул, бу тәкъдимне кире кагып, — шундый утлы өермәләр кубарып дошманны куган бер мәлдә, ничек итеп ял итеп ятыйм?

Ләкин хәле аның көннән-көн авырая. Бигрәк тә Уел елгасын кичкәндә салкын тидерү һәм аннан соң тиф белән авыру сәбәпле, Хөсәен аяктан егыла. Лазареттан чыгып бераз тазара төшкәч, аны Армия штабына чакырып алалар. Анда ул Армия командующие белән очраша.

— Сәламәтлек белән шаярырга ярамый, иптәш Мәүлетов, — ди аңа командир. — Алда эшлисе бик күп эшләр бар. Ә сез бу килеш озакка чыдый алмассыз.

Ул, дусларча хәстәрлек күрсәтеп, Хөсәеннең ай-ваена карамастан, хәзер үк беркне ай ял итеп алырга куша.

— Кая барырга телисең, шунда кит. Рөхсәт. Хәл җыйгач та безне эзләп табарсың.

Хөсәен башын иеп командарм янныннан чыкканда, коридор стенасына элеп куелган шыксыз гына зур көзгегә күзе төшеп, аптырап кала.

— Бәй, бу ни бу?!

Бите очлаеп киткән, зур гына күзләре эчкә баткан берәү көзгедән Хөсәенгә карап тора. Тик менә шунда гына, көзгедән кыяфәтен күргәч кенә, Хөсәен чыннан да нык үзгәргәнен, арыганлыгын аңлый. Хәтта беленер-беленмәс кенә булган шадрасына кадәр сизелеп тора хәзер.

— Әйтәм аны, барысы да ял ит тә ял ит диләр, йончылганмын икән шул,— ди ул, көзгегә тагын бер тапкыр күз салып.— Җитмәсә кулы сызламаса икән...

Хәсәен, шулай үз алдына сөйләнә-сөйләнә, үзен кетеп торган вестовое Яхъя янына килә. Аның кулындагы тезгенне алып, атка менеп алгач, болай дип сүз башлый:

— Ялга китәргә диләр бит әле, Яхъя? — Ә тегесенең эндәшмәгәнен күргәч, үзе үк өстәп куя:— Тик миңа кая барырга икән, ә?

Ләкин Яхъяның моннан соң да:

— Белмим шул,— дигән сүздән башканы әйтмәве Хәсәеннең ачуын китерә.

— Син нәрсә, авызыңа су каптыңмы әллә, сөйләшергә дә иренеп барасың.

— Юк ла, иптәш командир. Әле, теге ни, сез ял дигәч, кинәт әллә нишләп туган яклар искә төшеп китте дә, шуны уйлап бара идем.

— Сагындыңмы әллә?

— Бәй, сагынмый ни, кем туган-үскән илен сагынмый инде ул?! Әнә мал да ашаган җиренә кайта, диләр. Без бит әле кешеләр, сагындыра инде ул, иптәш командир.

Бераз вакыт икесе дә эндәшмичә баралар. Сүзне янә Хәсәен башлый:

— Сагындыра, диген, ә?

— Ә как же.

Хәсәен Яхъяның Пермь ягыннан икәнен дә, гаиләсендә кемнәре барлыгын да һәм тормышлары ни хәлдәрәк икәнен дә — барысын да бик яхшы белә. Пермь ягында барган сугышлардан алып гел үзе белән бергә йөргән бу кешене ул ярата да, үзенең якын ярдәмчесе, дусты итеп тә тоя.

— Пермьны күреп килгәндә әйбәт булыр иде,— ди ахырда Хәсәен.— Без киткәндә бит ул дошман кулында калган иде.

Дөрес, сирәк-саяк кына булса да Пермьнан Хәсәенгә хәбәрләр килгәли. Андагы туганнары аңа хат язгалап торалар. Вакыты булганда ул аларга үзе дә җавап яза. Шунда үскәнгәме, әллә инде революцион эшкә бик актив кушылып, аның эчендә кайнашып йөргән көннәрен искә төшерепме, Хәсәен үзе дә Пермьны нигәдер сагына, еш кына хәтерләп куя. Бигрәк тә аннан акларны кууда катнаша алмавы аның йөрәген әрнетә, эчен пошыра.

— Ярар, синеңчә булсын әйдә,— ди ул, Яхъяга күз кысып.— Пермьны күреп килик әле, алайса...

Инде күңеле белән кайтырга уйлагач, хәзер ул ашкына, тизрәк анда буласы килә. Һәм 1919 елның көзендә, Яхъя Адымов белән икәүләп, алар юлга чыгалар.

«Юл азабы — гүр газабы» дигән мәкаль әгәр дә әнә шул чорда тугандыр дип әйтсәк, һич тә хата булмастыр. Тимер юл транспортында, урыны-урыны белән, башбаштаклык хөкем сөрә. Поездлар станцияләрдә озаклап торалар. Кайда ягулык җитми, кайда паровоз юк...

Хәсәен дә, аның юлдашы Яхъя да, ял итәсе урында болай йөреп, тәмам ялыгып бетәләр.

— Юл түгел бу, этләнү генә, иптәш командир,— ди Яхъя, кул селтәп.

— Әйтмә дә инде, Яхъя дус,— дип, Хәсәен дә аңа кушыла.— Менә Камбаркага барып җитик тә, аннан пароходка утырырбыз. Алай итсәк, бәлки, Пермьга тизрәк барып җитәрбез.

Ләкин Камбарка станциясендәге бер вакыйга аларны берничә көн туктап калырга мәҗбүр итә.

Станциягә килеп төшү белән Хәсәен шикләнеп куя: чөнки кешеләр, ут чыккандагыдай, әле тегеләй, әле болай йөгерешәләр. Кычкырышкан тавышлар да ишетелгәли. Хәсәен, озак уйлап тормыйча, станция начальнигын эзләп китә.

— Ни булган, бу ни эш? — дип сорый ул, тәбәнәк кенә буйлы начальникны тапкач.— Халык нигә болай кылана?

Йөзе агарып, куркудан ни эшләргә белми аптырап калган начальник камалы тун кигән, биленә кылыч белән наган таккан һәм сумка аскан, ә туныңың тышкы ягына ук орден беркетеп куйган папахалы кызыл командир килеп басканын күргәч, йөзе ачылып китә.

— Эх, иптәш, эшләр харап монда...— ди ул, авыр сулыш алып.

— Ни бар соң? Нигә аңлатып әйтмисең?

— Буржуйлар баш күтәргән. Станциядә фетнә купты...

— Фетнә?!

— Әйе, исполкомны да кырып ташлаганнар дип торалар.

Хөсәен фетнәнең кем тарафыннан һәм кайчан башлануы турында сораша. Станциядә эшчеләр бармы дип белешә.

— Эшчеләр бар да ул,— ди станция начальнигы, өметсез генә кул селтәп.— Тик минә алар арасында өметлеләре аз. Провокациягә бирелгәнлекләре сизелә.

— Ашыгыч рәвештә берәр чара күрергә кирәк. Сарапул яки Ижевскига хәбәр итегез.

— Иткән идек тә, әлегә җавап юк.

Станция начальнигының ярдәме белән Хөсәен Мәүлетов шунда ук станция каршысындагы мәйданда эшчеләрнең митингысын оештыра. Алар алдына чыгып речь сөйли.

— Иптәшләр, ни эш бу, моны ничек дип аңларга? — дип мөрәҗәгать итә ул митингка килгән кешеләргә.— Менә мин фронттан кайтып килә́м. Анда безнең туганнарыбыз кан коеп сугыша. Совет властеның дошманнарын куа... Ә монда, ерак тылда, ниндидер бер төркем буржуй калдыгы безнең иптәшләрне тукмап ташлаган. Фетнә оештырганнар...

Ләкин Хөсәен фикерен дә әйтеп бетәргә өлгерми, җыелган халык төркеме арасыннан кемдер бәрә:

— Тыңламагыз шуны, күрмисезмени, ул кызыл бит! — дип аның сүзен бүлдерә.

Шунда бу кешенең сүзләрен куәтләгән икенче тавыш ишетелә:

— Баганага асарга кирәк үзен, мәлгуньне,— дип кычкыра аңысы.

Хөсәеннең йөзе агарып китә: «Ничәмә ел фронтта булып, сугышларда үлмәгәнне, нинди мәгънәсез харап булуың бар!» — дигән уй яшен тизлеге белән аның башыннан үтә.

...«Юк, юк! — Хөсәеннең кинәт кабынган ачуы куркуны да, әле генә сизелер-сизелмәс булып алган йомшаклыкны да шунда ук юкка чыгара — бирешергә ярамый!» Тәне буйлап электр тогы үткәндәй тоела аңа. Ниндидер бер көч керә. Ул, үзе дә сизмәстән, кесәсенә салып куйган наганын уң кулы белән кысып тота. «Алай-болай була калса, алар мине тереләй әлә алмаслар»,— ди ул, үз-үзенә. Ә янында гына кулына маузер тотып торган Яхъяны да күргәч, тагы да тынычлана төшә.

— Кайда, кем ул, килеп карасын,— Хөсәеннең әллә кайдан, күкрәк түреннән чыккан ачулы тавышы мәйданны яңгырата.— Баганага асарга кирәк, янәсе. Менә, күрәсез бит, иптәшләр, алар монда да, сезнең арагызда да барлар, явыз коткы таратучылар. Әгәр телисез икән, асыгыз мине. Ләкин сезгә үземнең сүземне әйтергә ирек бирегез.

Хөсәен әллә ни озак сөйләми. Әмма ул үзенең кыска гына речендә дә фронт хәлләре турында аңлатып, илдәге вакыйгалар турында төшендереп бирә. Эшчеләрне буржуй һәм кулак йогынтысына бирелмәскә өнди.

— Әнә бит алар ничек: кызылларны туздырганнар, имеш. Сезне монда кулаклар алдый, иптәшләр, ышанмагыз,— ди ул.— Дөрес түгел бу сүз. Кызыл гаскәрләр акларны пыр туздырып, өермәләрен өертеп куып бара. Әгәр миңа ышанмыйсыз икән, әнә солдат, аннан сорагыз.

Хөсәен Яхъяга төртеп күрсәтә. Ә тегесе, үзенең командирын бирелеп тыңлаганнарын күреп, маузерын яшереп тыныч кына басып тора.

— Кызыл Армия контрреволюцион бандаларны безнең илебездән, Советлар Россиясеннән кырып-себереп куып бара,— дип дәвам итә Хөсәен үзенең чыгышын.— Хәзер безнең җиңүләребезне беркем дә инкарь итә алмый. Бәлки, менә болар, адәм актыклары, ояларында ысылдап яткан еланнар шикелле, аны кире кагып маташалардыр. Әйе, алар безне, безнең Совет властен яратмыйлар. Без моны күптән һәм яхшы беләбез. Чөнки без алардан җирләрен, безне талап җыйган байлыкларын, кулларыннан властьларын тартып алдык...

Фронтовик кызыл командирның чыгышы станция эшчеләренә бик нык тәэсир итә, һәм алар фетнәчеләргә каршы отпор бирү өчен Хөсәеннән ярдәмен сорыйлар.

— Син, иптәш, безгә булыш инде,— диләр алар.— Барысын бергә дөмектереп ташлыйк шул явызларның.

— Ярый,— ди Хөсәен.— Мин риза.

Хөсәен Мәүлетов Камбарка станциясендә бер атна тора. Анда ул эшчеләр белән бергә фетнәчеләргә каршы көрәш алып бара. Һәм, бары Сарапул каласыннан ярдәм килгәч кенә, Яхъя белән икәүләп алар Пермьга китәләр. Эшчеләр аларны олылап, пароходка утыртып озатып калалар.

1919 елның декабрь аен Хөсәен Мәүлетов Пермьда үткәрә. Монда ул эшчеләр һәм крестьяннар алдында күп тапкырлар чыгыш ясый, аларны фронт хәлләре белән таныштыра. Кызыл Армиягә ярдәм оештыра.

Ә ел азагында, кайтуына бер ай тулды дигәндә, ул яңадан үзе командалык иткән полкка, Төркстан фронтына китә.

* * *

Хөсәен Мәүлетовның йөрәге тибүдән туктаганда аңа әле нибары кырык дүрт яшь була. Әнә шул кыска гына гомере дә аның күпләр өчен үрнәк була алырлык данлы көрәш эчендә үтә. Ул, ярлы бер кустарь гаиләсеннән чыгып, патша армиясенең рядовой солдатыннан, үзенең тырышлыгы аркасында, офицер дәрәҗәсенә күтәрелә, Кызыл Армиянең талантлы зур командиры һәм дәүләт эшлеклесе булып җитлегә.

Хөсәен Мәүлетов — революция каһарманы. Ул Урал тирәсендә яшәгән татар һәм башкорт эшче-крестьян массаларын оештырып, аларны революцияне якларга күтәрүче. Ә соңрак, Совет властеның дошманнары яу булып калыккач, кулына корал алып, шул яуга каршы чыккан кеше. Һәм, ахыр килеп, Хөсәен Мәүлетов гражданнар сугышы чорындагы татар егетләре арасында иң мактаулы, исемен данга күмгән геройларның берсе. Совет хөкүмәте аны әнә шул елларда ике тапкыр Кызыл Байрак ордены белән бүләкли. Бохара крепостен алуда һәм аннан әмирне куууда күрсәткән батырлыгы өчен М. В. Фрунзе аңа үз кулы белән көмеш кылыч тапшыра. Ә Хөсәен Мәүлетов командалык иткән Өченче полк революцион Кызыл Байрак белән бүләкләнә.

**Йолдыз Вәлитова,**
филология фәннәре кандидаты

# ҖЫРДАЙ МАТУР ГОМЕР




Идел... Җәйге кояшлы көннәрдә күз камаштыргыч зәңгәрлек белән балкып, Россиянең буеннан-буена агып узган мул сулы мәһабәт елга. Идел — халык рухының символы. Илебез халыкларының героик тарихына бәйле күп онытылмас вакыйгалар нәкъ менә аның ярларында шаулап узган.

Идел өстендә төрле җырлар яңгыраган. Степан Разин һәм Пугачев хакындагы гайяр җырларны да, бурлакларның хәсрәт-сагыш белән тулы моңнарын да, хатын-кызның ачы, авыр язмышы турында сөйләгән сагышлы җырларны да һәм тирән наз, кайнар дәрт белән сугарылган мәхәббәт җырларын да тыңлаган Идел. Идел өстендә күп халыкларның җырлары яңгыраган. Рус, татар, мордва, мари һәм чуваш җырларын ишеткән Идел. Ул җырлар исә явызлык һәм коллык патшалыгын каһәрләгәннәр, ирекле тормыш хакына аяусыз һәм рәхимсез көрәшкә чакырганнар, хезмәт кешеләренең алдагы бәхетле көннәргә булган какшамас ышанычын, аларның гел яктыга, кояшка омтылучан тынгысыз рухын чагылдырганнар.

Менә шул җырлы-моңлы Иделнең кырт кына көньякка таба борылып ага башлаган төшендә, текә ярлы биек тау өстендә әле узган йөзләрнең башларында ук Сембер исемле артык зур булмаган губерна шәһәре урнашкан булган. Матур яз һәм җәй көннәре килүгә шәһәрнең тын бакчалары һәм урамнары куе яшеллеккә төренгән, үлән һәм чәчәкләрдән аңкыган хуш ис, сайрар кошларның җыры белән тулган. Таҗ тавыннан (шәһәрдә текә булып Иделгә килеп терәлгән шундый исемдәге биек тау бар) сыек зәңгәрсу томан белән өретелгән иксез-чиксез ераклыклар ачылган, кояшта ялтырап яшел юрган ябылган болыннар, очсыз-кырыйсыз күк киңлекләре күренгән. 1903 елның август иртәсендә, шуннан 33 кенә ел алда дөньяга Ленинны биргән мәшһүр шәһәрдә, тимер юл машинисты Сафиулла ага Измайлов гаиләсендә берничә бала өстенә тагын бер кыз бала дөньяга килгән. Аңа Асия дип исем кушканнар...

Бу — җырга, моңга бай як. Сембер якларында элек-электән җыр сөюче, аның кадерен, тәмен белүче кешеләр яшәгән. Сафиулла Измайловның зур һәм тату гаиләсендә дә халык җыры бәяләп бетергесез байлык саналган, олысыннан алып кечесенә кадәр һәркем гаилә хорында катнашкан. Арада көчле һәм ягымлы тавышы белән аерылып торганы үсмер кыз Асия булган.



*Асия ханым Измайлова.*

...Асия тиктормас табигатьле, зирәк бала булып үсә, **кечкенәдән** үк өй эшләренә һәм укуга һәвәслеге белән аерылып тора. Әмма аңа озак укырга туры килми. Гаиләнең материаль хәле начарланып китү сәбәпле, укуын ташлап, постау фабрикасына эшкә керергә мәҗбүр була. Эштән кайткач, өй эшләрен эшләшә, бәләкәй энеләрен һәм сеңелләрен караша. Шулай, буыннары да ныгырга өлгермәгән кыз җилкәсенә рәхимсез дөнья үзенең бөтен авырлыгын сала. Аның бердәнбер юанычы булып җыр кала, беркемгә дә ачарга кыймаган иң яшерен уй-хыялларын ул җыр белән уртаклаша.

1917 елның Октябре җитә. Бөек революциянең сафландыргыч давылы хезмәт ияләрен хокуксызлыкта һәм коллыкта яшәргә мәҗбүр иткән авыр богауларны себереп түгә. Шәһәр һәм авыл урамнарында яңа җырлар: көрәш һәм азатлык җырлары, ялкынлы революция җырлары яңгырый башлый. Аларның көрәшкә өндәүче канатландыргыч сүзләре үндүрт яшьлек Асия күңеленә дә бик хуш килә. Аның алдында белем дөньясына чуму, мавыктыргыч иҗат эшенә керешү өчен киң мөмкинлекләр ачыла. Һәркәрсә белән кызыксынырга яратучан, тиктормас табигатьле кыз үзе дә яшь совет республикасында барган вакыйгаларның ташкынлы агымыннан читтә калырга теләми. Әле постау фабригында эшләгәндә үк кичләрен эшче балаларын укырга-язарга өйрәтә. Ахырдан, халык арасында мәгърифәт нурлары чәчү теләге белән, педагогия курсларына укырга керә.

Асиянең әтисе, карт эшче Сафиулла абзый, революциянең беренче көннәреннән үк актив төстә яңа тормыш төзүчеләр сафына баса. Балаларын да ул революция эшенә, халык бәхете өчен көрәш эшенә бирелгәнлек рухында тәрбияли. Асиянең абыйсы Шакир Измайлов шул давыллы елларда ук күренекле совет һәм партия эшчесе булып китә, аның бу өлкәдәге эшчәнлегенә хәтта В. В. Куйбышев югары бәя бирә. Асия үзе дә бөек революция идеяләренең тантанасы, социаль тигезлек һәм прогресс өчен барган гомум халык көрәшенең алгы сафында була. Музыкаль һәм артистлык сәләте бик иртә ачылган яшь кыз, бу көрәштә корал итеп, җыр сәнгатен сайлый. 1918 ел ахырында аны эшчеләр тарафыннан оештырылган театр коллективына алалар, һәм бу театр шәһәр һәм өлкә хезмәт ияләренә культура хезмәте күрсәтү буенча актив эшчәнлек җәелдереп җибәрә. Эшче театрында эшләгән елларда Асия татар һәм рус драматургларының пьесаларыннан уннарча рольләр уйный, көннән-көн үзенең артистлык сәләтен һәм профессиональ белем дәрәҗәсен күтәрә бара. Ул, зур теләк һәм эчке күтәренкелек белән, акгвардиячеләрне, чит ил интервентларын, буза куптарган атаманнарны һәм Совет властеның башка дошманнарын тар-мар итү өчен сугышка китүче кызыларменцлар алдында чыгышлар ясый. Үзенең игелекле тыңлаучылары өчен популяр халык җырларын башкара, кызыл сугышчылар күңелендә рух күтәренкелеге, гүзәл киләчәккә ышаныч тәрбияләрлек революцион җырлар җырлый.

Асия Измайлова гади кешеләрнең йөрәк тибешен тойган, аларның уй һәм омтылышларын яхшы белгән, чөнки ул үзе дә шул халык арасыннан чыккан кеше, хезмәт

кешеләренең үз баласы. 1920—22 елларда РКП(б) ның Сембер губерна комитеты һәм губерна мәгариф бүлегенең инструкторы булып эшләгәндә, агитатор һәм пропагандист кызның дәртле, кайнар сүзе иң ерак, иң караңгы авылларга кадәр барып җиткән, кулакларның, динчеләрнең һәм муллаларның ээәрлекләвенә дә карамастан, иптәшләре белән халык мәгарифенең яңа учакларын — авылларда хезмәт мәктәпләрен оештырган, шуларда үзе үк турыдан-туры укыту эше белән шөгыльләнгән көннәрдә дә ул шундый ук булып кала. 1921 елда Идел буенда коточкыч ачлык башлангач та Асия халыкның үз баласы булып кала. Ачлыктан интеккән кешеләрне күреп, аның йөрәге әрни, ачтан интегүчеләр фондына акча җыю өчен, ул, ару-талуны белми, спектакльләр, концертлар оештыра.

1921—1922 елның кышында Асия Измайлова Ленин комсомолы сафларына баса. Партия һәм комсомол тәрбияләп үстергән бәхетле совет кызларына багышланган көр күңелле җырлар җырлау теләге яшь җырчы күңелендә, бәлки, нәкъ әнә шул көннәрдә тугандыр?.. Күпмедер вакыттан соң аның бу теләге чыннан да тормышка аша: Асия Измайлованың репертуары яшьлек дәрте һәм шатлык хисләре ташып торган «Комсомолка Гөлсара» җыры белән баый. Асия Измайлова рухланып башкарган бу җырны яшьләр алкышлап каршылый һәм күтәреп ала.

Аның сәхнә эшчәнлеге уңышлы гына башлана. Шулай да эш процессында үзенә иң кирәкле мәгълүматларның җитеп бетмәвен ул теләсә кемгә караганда үзе күбрәк аңлый һәм, үзлегеннән тырышып уку юлы белән, алардан котылырга омтыла. Бу мәсьәләдә ярдәм эзләп, бөек сүз художниклары А. Пушкин һәм Г. Тукайга, А. Островский һәм Г. Камалга, А. Чехов һәм Ш. Камалга, М. Горький һәм Г. Ибраһимовка мөрәҗәгать итә. Баш-аягы белән аларның кеше язмышларын һәм характерларын тетрәндергеч көч белән сурәтләгән үлемсез әсәрләренә чума. Бары тәпле белем, зур сәяси һәм профессиональ әзерлек кенә классикларның һәм совет композиторларының операларындагы рольләрне дөрес, ышандырырлык итеп башкарырга мөмкинлек бирәчәген ул торган саен ныграк аңлый бара. һәм, актив комсомолка, талантлы һәм өметле җырчы буларак, партия һәм совет оешмалары аны, укуын дәвам итү, профессиональ осталыгын камилләштерү өчен Мәскәүгә җибәрергә булгач, ул бу хәбәрне шатланып каршылый.

1922 елда ул илебезнең башкаласы Мәскәүгә күчеп килә. Башта РСФСР Халык мәгариф комиссариаты каршындагы педагогия курсларында укый. Аннары Көнчыгыш хезмәт ияләренең коммунистик университетына (КУТВ) керә. Биредә аны коммунистик полк сафына алалар. Университетта Асия күренекле марксист галимнәрнең эчтәлекле лекцияләрен тыңлый, алар алып барган семинарларга йөри. Бер үк вакытта ул музыка техникумында да дәресләр тыңлый, өстәвенә, Мәскәү театрларындагы яңа спектакльләрне карап бара, хәлдән килгәнчә, мәшһүр артистларның концертларында булырга тырыша. Каян вакыт тапкан да ничек өлгергән?!.

Киң халык массалары белән элемтәсен Азия Измайлова студент елларында да өзми. РКП(б)ның Мәскәү шәһәр комитеты һәм РКП(б) Үзәк Комитеты каршындагы Татар-башкорт секциясенең кушуы буенча, ул Мәскәү шәһәрендәге һәм Мәскәү өлкәсендәге завод-фабрика эшчеләре янында еш була. Завод цехларында, кызыл почмакларда һәм клубларда татар эшчеләре агитатор Измайлованың ялкынлы сүзләрен, ә җырчы Асиянең эчкерсез җырларын тыңлыйлар. Коломенскидагы машина төзелеше заводында аны хәтта ЧОН отрядына член итеп алалар.

Башкала тормышы аның сәхнәгә, җыр сәнгатенә булган омтылышын тагын да көчәйтә төшә. 1922 елның ахырында Мәскәүдә Үзәк дәүләт эшче татар театры ачыла, аны оештыруга Асия Измайлова да күп хезмәт һәм күңел көче сала. Шуның белән бергә, ул андагы төп иҗат көчләренең дә берсе була. Театрның нигезен Г. Айдарский, Г. Саттаров, Г. Камская, С. Садыйкова, А. Мәһдиев, З. Агишева кебек Мәскәү вузларында укучы яшь талантлар тәшкил итә. Спектакльләр Мәскәү залларында гына куелып калмый, татар артистларының уенын Мәскәү өлкәсе, Донбасс, Урал һәм Себер тамашачылары да яратып карый. Театр артистлары турыдан-туры завод-фабрика цехларында, аерым очракларда хәтта шахта чилегенә утырып забойга төшеп, күмер шахталарында, рудникларда, шулай ук колхоз-совхоз кырларында спектакльләр, концертлар күрсәтәләр.

Гастрольләр вакытында Асия Измайлова халык арасында киң таралган җырларга

ислак сала, аларны җыя, язып ала. Соңыннан, зур осталык белән төрле концертларда башкарып, аларга яңа гомер бирә. Мәшһүр «Шахта» көе, мәсәлән, шундый бәхетле язмышка очрый. 1924 елда артистка аны Донбасста язып ала һәм репертуарына кертә. Менә ничә еллар инде «Шахта» көе теләрдән төшми. Аның Урта Азия республикаларындагы, Башкортстан, Казагыстан һәм Әзербәйҗандагы гастрольләре һәрвакыт зур уңыш белән уза. Ул өзлексез төстә бу милли республикаларның музыкаль фольклорын өйрәнә, аның иң яхшы үрнәкләре белән Казан, Мәскәү һәм башка шәһәрләрнең музыка сөючеләрен таныштырып бара.

Асия Измайлова хезмәт иясе массалары белән даими аралашып яшәргә ярата торган, һәрвакыт яңалыкка омтылучан кеше. Артист һәм гражданин буларак аның йөзен билгеләүче төп сыйфатлар әнә шулар. Шул сыйфатлары аңа радио үзенең беренче адымнарын гына атлаган көннәрдә үк әле бу башлангычның, күп миллионлы тамашачылар белән аралашу өчен, сәнгать осталары алдында искиткеч перспективалар ачуын, аларны әдәбият һәм сәнгатьнең югары казанышлары белән таныштыру юлында күреләгән мөмкинлекләр тудыруын аңларга ярдәм итә. Рус сәнгатенең Л. Собинов, А. Нежданова, Н. Обухова, А. Доливо, О. Ковалева кебек мәшһүр вәкилләре белән бергә, ул бөтен илне гигант бер концерт залына әйләндергән беренче радиотапшыруларда катнаша. Тагын берничә елдан аның башкару осталыгы белән Казан һәм Ташкент радио тыңлаучылары да якыннан таныша.

1927 елда Асия Измайлова, даими эшләү өчен, Казанга күчеп килә. Казанга килүгә ул яңа, социалистик татар мәдәниятен тудыручы кешеләр — язучылар, артистлар, композиторлар даирәсенә эләгә. Яшь татар совет интеллигенциясе вәкилләреннән композитор С. Сәйдәшев, трибун шагыйрь Һ. Такташ, язучы Ш. Усмановлар аның иҗади һәм рухи үсешенә аеруча көчле йогынты ясый. Биредә А. Измайлованың энергиясе, эшләү сәләте бермә-бер ачылып китә, матур һәм көчле тавышлы, бай һәм күп төрле репертуарлы, ниһаять, югары башкару культурасына ия булган артистканы халык тиз арада күреп, яратып өлгерә. Аның Татарстан шәһәрләрендәге һәм авылларындагы күпләгән концертлары һәрвакыт гаять җылы каршы алына һәм зур күтәренкелек белән уза. Артистканың беренче опера партияләре өстендә эшли башлавы да шул чорларга карый. 1927—1928 елларда ул М. П. Мусоргскийның «Борис Годунов» һәм А. Бородинның «Князь Игорь» операларындагы төп рольләрне башкара.

1928 елның җәендә, Казанга А. М. Горький килгәч, Асия Измайлова бөек пролетар язучысы белән очрашып сөйләшү бәхетенә ирешә. Билгеле булганча, әлеге шатлыклы вакыйга уңае белән, Татарстан иҗат интеллигенциясе вәкилләренең мәшһүр язучы белән очрашу кичәсе уздырыла. Кичәгә җырчы А. Измайлова да чакырыла. Тантаналы өлештән соң башланган концертта ул, зур күтәренкелек һәм чын илһам белән, татар, башкорт, үзбәк һәм әзербәйҗан халык җырларын башкара. Уңыш көткәннән дә артык була. Алкышлау һәм яңадан чакыруларның чиге булмый. Гаять таләпчән, югары зәвыклы художник тәнәфестә җырчы янына үзе килә, аңа чын күңелдән чыккан тирән рәхмәтен белдерә һәм, истәлек өчен, артистканың «Халык көйләре альбомына», бары Горькийга гына хас афоризм белән: «Хөрлек — гүзәллекне, ә гүзәллек хөрлекне сөя. 4/VIII — 28 ел. М. Горький»,— дигән сүзләрне яза.

Шул ук 1928 елның августында Асия Измайлова физикларның Казанда уздырылган IV халыкара съезды делегатлары алдында җырларга чакырыла. Съездның председателе, күренекле совет галиме, академик А. Иоффе, чыгышы өчен, артистканы кайнар котлый һәм үзенең гүзәл җырлары белән ул Мәскәү, Ленинград тамашачыларын да ешрак шатландырсын иде, дигән теләк белдерә. Съезд тәмамлангач, Казан дәүләт университетының Актлар залында делегатлар һәм артистлар бергәләп фотога төшәләр. Бу кызыклы фото Асия ханымда әле дә саклана. Фотоны, артына дулкынландыргыч сүзләр язып, академик А. Иоффе үзе бүләк иткән: «Яңа татар сәнгатен иҗат итүче зур артисткага, физикларның Идел буенда узган IV съездында катнашучылардан. 1928 елның 12 августы. А. Иоффе».

Артистканың иҗат язмышы, аның өзлексез үсүе, профессиональ осталыгын камилләштергәннән камилләштерә баруы турында кайгыртып, академик А. Иоффе беренче Халык мәгариф комиссары А. В. Луначарскийга махсус хат яза. Анатолий Васильевич халык арасыннан чыккан талантларга һәрвакыт аерым игътибар һәм сизгерлек күрсәткән. Аның тәкъдиме буенча, 1929 елда Асия Измайлова Мәскәү дәүләт филармония-

сенең солисткасы булып эшли башлый. Элеккечә үк бик еш гастрольләрдә була, концертлар белән күмер чыгаручылар, тимер юл төзүчеләр, иген үстерүчеләр янына бара. СССР халыклары театрлары һәм сәнгатьләренең 1930 елда уздырылган беренче бөтенсоюз олимпиадасында, югары башкару культурасы һәм үз иҗатында яңа совет тематикасын чагылдыруы өчен, артистка грамота белән бүләкләнә.

Бу елларда да ул үзенең элекке традицияләренә турылыклы булып кала: гел халык арасына омтылып яши, промышленность предприятиеләре эшчеләре, бишьеллык төзелешләрендә эшләүчеләр, укучылар һәм студентлар, төрле учреждение һәм оешма хезмәткәрләре янында була, армый-талмый шуларга хезмәт итә. Асия Измайлова 1923 елда ук үзе беренче тапкыр чыгыш ясаган «Красный богатырь» заводы эшчеләре янына аеруча еш бара.

Ул көннәрне искә төшереп, 1925 елдан КПСС члены Кояш Вәлитова болай сөйли: «1929 елда партиянең Мәскәү шәһәр комитеты мине, идея-политик эшне көчәйтү максаты белән, «Красный богатырь» заводы каршындагы балалар бакчасына мөдир итеп эшкә җибәрде. Тиздән мин завод парткомы каршындагы татар секциясенең җаваплы секретаре итеп сайландым. Председателебез кадровой эшче, акбур цехының мастеры коммунист И. Гыйбадуллин иде. Секторларга бүленеп, билгеле бер план буенча эшли башладык. Культура-агарту секторы (аңа үзешчән сәнгать түгәрәкләре оештыру, дингә каршы кичәләр үткәрү, революцион бәйрәмнәрне билгеләп үтү, концертлар, спектакльләр, әдәби кичәләр уздыру эше йөкләнгән иде), үзе билгеләгән чараларны уздырганда, заводка укытучыларны һәм журналистларны, М. Җәлил, Ә. Фәйзи, М. Максуд, Ә. Ерикәй кебек шагыйрь һәм язучыларны, Х. Мәүлетов, Я. Чанышев кебек гражданнар сугышы каһарманнарын, гражданнар сугышында полк командиры булган М. Шаһиәхмәтовны (ул бу вакытта ВЦИК аппаратында референт булып эшли һәм татар эшче театрына җитәкчелек итә иде), популяр җырчыбыз Асия Измайлованы еш чакыра иде. Шунысы хәтердә аеруча нык калган, Асия килгән көннәр завод эшчеләре өчен чын мәгънәсендә бәйрәмгә, зур вакыйгага әйләнә иде...»

Бу вакытта А. Измайлова музыка, эстрада һәм циркларның РСФСР дәүләт берләшмәсендә солистка булып эшли. Тиздән аны шушы гаять зур берләшмәнең директор урынбасары итеп куялар, ә коммунистлар үз оешмаларына секретарь итеп сайлыйлар. Иҗтимагый-политик активлык үз-үзенә таләпчән һәм җитди карый белә торган артистканың иҗат эшчәнлегенә зыян китерми. Киресенчә, бу ике як аңарда үзара керешеп һәм бер-берсенә булышып яши. Үзенең профессиональ осталыгын камилләштерү турында ул бер генә минутка да исеннән чыгармый. Һәм 1934 елның башында Мәскәү дәүләт консерваториясе каршында Татар опера студиясе ачылгач, инде бай гына тормыш һәм иҗат тәҗрибәсе туплаган артистка эчке бер канәгатьләнү белән шунда укырга керә. Н. Сперанский, Е. Ковылькова, С. Друзякина, Н. Райский кебек күренекле профессорлардан дәрес алу, Ф. Каверин, В. Нардов, Л. Баратов кебек сәхнә мастерларыннан осталыкка өйрәнү аңа үз талантын тагын да үстерә һәм шомарта төшәргә мөмкинлек бирә. Сәләтле, тырыш, көчле тавышы һәм зур сәхнә мөмкинлекләре булган Асия курсларны уңышлы тәмамлый һәм, студия бетергән башка җырчылар белән бергә, 1939 елда Казанга кайта, тиз арада опера театрындагы төп көчләрнең берсенә әйләнә.

Театрның яшь артистларына турыдан-туры опера һәм балет сәнгатенә караган мәсьәләләр белән генә чикләнергә туры килми, алар театрны оештыру, аның яшәүяшәмәве белән бәйле авыр һәм катлаулы мәсьәләләрне чишәргә, театрның үз йөзен, үз репертуарын булдырырга, опера сәнгате өлкәсендәге яңа форма һәм алымнарны эзләү белән бәйле күп нәрсәләрне хәл итәргә тиеш булалар.

Театрдагы төп иҗат көчләрнең берсе буларак, Асия Измайлова сәнгатьтә ленинчыл партиялелек һәм халыкчанлык, реализм һәм чын новаторлык принципларының ныгуы өчен көрәшә. Бу көрәштә үзенә фикердәшләр, мәсләктәшләр таба. Шуларның берсе шагыйрь Муса Җәлил булгандыр, мөгаен. Югыйсә, ул артисткага либреттоларын бүләк итәр һәм үзенең «Алтынчәч»е өстенә түбәндәге сүзләрне язар идемени:

«Сөекле җырчы, татар сәнгатенең якты йолдызы Асия ханым Измайловага, тирән хөрмәтем һәм дуслыгымның билгесе.

Муса Җәлил. 15/VI — 1941.»

Үзенә тапшырылган опера партияләре өстендә А. Измайлова уйланып һәм илһамланып эшли, хәтердә калырлык тормышчан образлар иҗат итә. Әсәрнең стилен һәм авторның максатын тирәнтен аңларга тырышу, кеше психологиясен һәм тормышны якыннан белү, чын мәгънәсендәге югары культура һәм профессионализм, алга куелган максатны тормышка ашыруда искиткеч тырышлык — шулар барсы артисткага берсе икенчесенә бөтенләй охшамаган үзенчәлекле типлар тудырырга булыша. П. Чайковскийның «Евгений Онегин» операсындагы шук һәм җилбәзәк табигатьле Ольга, Ш. Гуноның «Фауст»ыннан кайнар һәм кыю йөрәкле Зибель, Н. Җиһановның «Качкын» операсыннан явыз һәм мәрхәмәтсез алпавыт Бикә, М. Мозаффаровның «Галиябану» операсыннан Бәдига карчык әнә шундыйлар. Татар совет сәнгатен үстерүдәге зур хезмәтләрен искә алып, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы аңа Республиканың халык артисткасы дигән мактаулы исем бирә.

...Совет кешеләренең тыныч хезмәтен бүлеп, икенче дөнья сугышы башлана. Төзүче халык сугышчы халыкка әйләнә. Аның барлык көче һәм теләге социалистик Ватанның бәйсезлеген саклауга, фашист илбасарларын себереп түгүгә юнәлә. Көрәшең, яшьлек елларын исенә төшергәндер, совет сугышчылары алдында Асия Измайлова аерым бер дәрт һәм эчке җылылык белән җырлый. Сугыш башыннан алып ул артистларның М. В. Фрунзе исемендәге Совет Армиясе үзәк йорты тарафыннан оештырылган интернациональ фронт бригадаларына җитәкчелек итә. Бу бригадалар хәрәкәттәге армия солдатлары алдында бик күп концертлар куя. Иптәшләре белән бергә, Асия Измайлова да блиндажларда, солдат землянкаларында чыгышлар ясый. Аның чын күңелдән башкарган җырлары сугышчылар өчен туган илдән килгән сагынычлы сәлам булып яңгырый. Моның өчен фронтовиклар аңа кайнар рәхмәт хисләрен белдерәләр. Җырчының архивында, шул заманнан калган иң кадерле истәлекләр тәсендә, өч почмаклы солдат хатлары, төрле хәрби частьлар тарафыннан бирелгән почет грамоталары, рәхмәт язулары, кыйммәтле бүләкләр саклана.

Татар опера һәм балет театрының партия оешмасы секретаре буларак, Асия Измайлова оборона фондына акча җыю мәсьәләсендә дә башлап йөри. Театр коллективы җыйган бу акчага соңыннан хәрби самолет төзелә. Аның патриотлык хисләре тагын бер фактта бик ачык күренә: сугышның беренче көненнән соңгы көненә кадәр айлык хезмәт хакының яртысына якынын, шулай ук концертлар өчен тиешле гонорарының күп өлешен ул оборона фондына биреп бара.

Үзен тәрбияләп үстергән, аның таланты һәм иҗат эшчәнлеге өчен бөтен мөмкинлекләрне тудырган халыкның турылыклы кызы буларак, ул халык кайгылары һәм борчуларыннан тыш яшәүне күз алдына да китерә алмый. Аның репертуары өзлексез төстә халыкның яңа һәм борынгы җырлары белән тулылана тора. Мәсәлән, аның концертларында:

> **Сары, сары, сап-сары,**
> **Сары чәчәк саплары,—**

дип башланган борынгы рекрут җыры нык урын ала.

Бу моңлы җырны Баһави исемле көтүче малай авызыннан яшь Ульянов та еш ишеткән. В. И. Ленинның туганнан туган кардәше Н. И. Веретинниковның «Володя Ульянов» исемле истәлекләр китабына караганда, гади кешеләрнең авыр солдат хезмәтенә тирән нәфрәтен чагылдырган бу җырны ул тәэсирләнеп тыңлый торган булган. Сугыштан соң Мәскәү радиосы Н. И. Веретинниковның истәлекләр китабы буенча эшләнгән тапшырулар циклы оештыра. Шул тапшыруларның берсендә Баһави җыры Асия Измайлова башкаруында яңгырый.

Асия Измайлованы халык күп мәртәбәләр үзенең илчесе итә, депутат итеп сайлый: Казан шәһәр советы депутаты, Мәскәүнең Дзержинский район совет депутаты, шул ук район башкарма комитетының президиум члены, партиянең район, шәһәр һәм өлкә конференцияләре делегаты, сәнгать эшчеләре профсоюзларының өлкә һәм бөтенсоюз съездлары делегаты, партиянең район комитеты члены, сәнгать эшчеләре профсоюзларының Мәскәү өлкә комитеты президиум члены... Халык хезмәтчесе дигән мактаулы исемне ул бөтен гомере буена намус белән йөртә.

Асия Измайлова күп милләтле совет сәнгатен яшь көчләр белән тәэмин итү турында да даими рәвештә кайгыртып яши. Татарстан хөкүмәтенең 1944 елгы карары

белән, ул Чайковский исемендәге Мәскәү дәүләт консерваториясе каршындагы татар опера һәм ГИТИС каршындагы татар драма студияләренең директоры итеп билгеләнә, 1951 елга кадәр шул постта уңышлы эшләп килә. Опера студиясен — 25, драманыкын шулай ук 25 кеше тәмамлый. Хәзер аларның күбесе (В. Шәрипова, Ә. Галимова, А. Аббасов, В. Жарков, Ш. Әсфәндиярова, Р. Бикчәнтәев, А. Галиева, Д. Ильясов, Г. Камалова, А. Хәйруллина, П. Исәнбәт һ. б.) опера һәм драма театрыбызның төп көчләреннән санала. Театр белгечләре Р. Усманова һәм Х. Кумысников, телестудия режиссеры А. Старкова, Республика Әлмәт күчмә театры баш режиссеры Г. Хәсәенов шулай ук аның укучылары. Үзенең педагоглык эшчәнлеген Асия ханым елдан-ел киңәйтә бара. Тиздән ул Мәскәү дәүләт консерваториясе вокаль факультетының иң авторитетлы педагогларыннан берсенә әйләнә. Илебезнең милли республикаларыннан (Татарстан, Удмуртия, Чувашия, Калмык һәм Тува) килгән яшьләр вокаль серләренә аңардан өйрәнәләр. Югары вокаль культурага ия булган педагог буларак, аларны ул рус һәм совет музыка сәнгатенең иң югары казанышлары белән таныштыра, аларга җырчы сәнгатенең күп яшерен серләрен өйрәтә. Үзләрен шулай мавыгып укыткан, югары сәнгать дөньясына алып кергән, бик юмарт төстә үзенең бай тәҗрибәсен уртаклашкан һәм сәләтләренә дөрес юнәлеш биргән укытучыларын студентлар да ярата. А. Измайлованың күпчелек укучылары бүген милли театрларның, Мәскәү, Ленинград, Киев кебек зур шәһәрләрдәге театрларның төп көчләреннән санала.

Яшьләрне өйрәтү белән бергә, Асия ханым үзе дә укудан туктамый. Мәскәү консерваториясенең вокаль факультетын тәмамлауга, кандидатлык экзаменнарын тапшыра. Татар җыр сәнгате өлкәсендәге күп еллык күзәтү һәм тикшеренүләрен ул «Татарча җырлаганда дөрес сөйләү» исемле фәнни хезмәтендә гомумиләштерә. Аның бу хезмәте күренекле белгечләр тарафыннан уңай бәя ала һәм кандидатлык диссертациясе итеп якларга тәкъдим ителә.

Асия ханым әле бүген дә Мәскәү дәүләт консерваториясендә эшли, коллективның тирән хөрмәтен казанган укытучы буларак, менә ничә ел рәттән инде вокаль факультетының партия оешмасы секретаре итеп сайланып килә. Ул һаман тынгысыз, кайнап торган тормыш уртасында, әйтерсең, аның күңеле каршында еллар да көчсез.

Кеше язмышлары төрле-төрле. Һәр язмышка шәхеснең кабатланмас индивидуальлеге һәм тарихи чор үз эзен сала. Асия Измайлованың тормыш һәм иҗат юлы татар совет музыка сәнгате тарихындагы иң матур һәм үзенчәлекле сәхифәләрнең берсе. Халык җыры кебек үк гүзәл һәм пакь, мәңге кайнар һәм нәфис аның гомере.

# РЕВОЛЮЦИЯ БАҺАДИРЛАРЫ

*Моннан ярты гасыр элек Октябрь социалистик революциясе казанышларын саклап калу өчен яшь Совет республикасының күп милләтле тугандаш халыклары белән бергә татар эшчеләре һәм крестьяннары да үз-үзләрен аямыйча көрәштеләр. Совет властена куркыныч янаган һәрбер җирдә татар хезмәт ияләре, кулларына корал алып, Бөек Октябрьны саклаучылар сафына бастылар. Үзләренең хәрби антларына тугры булган татар кызыл частьлары, командирлар һәм гади сугышчылар гражданнар сугышы тарихы битләренә мәңге онытылмаслык даны сәхифәләр яздылар, шәхси батырлык һәм Ватанга бирелгәнлек үрнәкләре күрсәттеләр. Аларның кыюлардан да кыюлары тиңдәшсез батырлыклары өчен ул вакыттагы иң зур хәрби бүләк — Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнделәр.*

**Мәскәүдә, Совет Армиясе Үзәк Дәүләт Архивында, Совет власте өчен кайнар көрәш елларында татар сугышчыларының батырлыклары турында сөйләүче күп кенә документлар саклана. Түбәндә без татарлар арасыннан кайбер командирларны һәм сугышчыларны Кызыл Байрак ордены белән бүләкләү турында Республика Революцион Хәрби Советы приказларының күчермәләрен урнаштырабыз. Журнал өчен аларны, Совет Армиясе Үзәк Дәүләт Архивының өлкән фәнни сотруднигы О. А. Полетаев әзерләде.**

### РЕВОЛЮЦИОН ХӘРБИ СОВЕТ ПРИКАЗЛАРЫ КҮЧЕРМӘЛӘРЕ

*№ 56* *8 май, 1919 ел.*

**Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнәләр:**
**258 нче Волынь укчы полкыннан —**
**...Атлы команда разведчигы иптәш Нәбиулла Гайбатдуллин. Ул, рота командирының элемтәчесе буларак, Тернәт авылы янында сугыш барган вакытта донесение белән полк штабына военкомга җибәрелә. Юлда аның атын үтерәләр, ә үзенең сул аягы яралана. Дошманның өзлексез атып торуына һәм ярасының көчле сызлавына да карамастан, иптәш Гайбатдуллин полк штабына кадәр түше белән шуышып бара һәм донесениене тиешле кешесенә тапшыра. Бары тик шуннан соң гына ул ярасыларны бәйләү пунктына китә...**

Республика РВС[1] председателе урынбасары — Э. СКЛЯНСКИЙ
Республиканың барлык Кораллы көчләре
Башкомандующие — ВАЦЕТИС
Республика РВС члены — АРАЛОВ

[1] Революцион Хәрби Совет.

№ 160 *10 апрель, 1920 ел*

РВСРның[1] 1919 ел 511 нче номерлы приказы нигезендә 6 нчы Армия Реввоенсоветының Кызыл Байрак ордены белән бүләкләвен расларга:

82 нче укчы полкыннан —

...3 нче рота кызылармеецлары Феоктистов Иван Павловичны, Хәсәнов Манафины, Мортазин Сәхитне, Хәмидуллин Хәкимулланы, Матушкин Дмитрийны... Архангельский губернасындагы Мург авылы тирәсендә чигенүче дошманны куып барганда аның юлын кисү максаты белән алар үзләре теләп башка разведчиклар белән бергә дошман тылына үтеп кергәләр һәм, куркусызлык, тәвәккәллек күрсәтеп, бирелгән бурычны уңышлы үтәүгә, дошманны тулысынча тар-мар итүгә булыштылар.

Республика РВС председателе урынбасары — Э. СКЛЯНСКИЙ
Республиканың барлык Коралы көчләре
Башкомандующие — С. КАМЕНЕВ

№ 208 *27 апрель, 1920 ел*

РВСРның 1919 ел, 511 нче һәм 2322 нче приказлары нигезендә 14 нче Армия Реввоенсоветының Кызыл Байрак ордены белән бүләкләвен расларга:

...59 нчы укчы полктан — 5 нче ротаның отделение командиры иптәш Малов Михаилны, шул ук рота сугышчысы иптәш Хәйбуллин Галиулланы. Алар орудиеләрен әле икенче урынга күчерергә өлгермәгән дошман батареясына каршы беренчеләрдән булып һөҗүмгә ташландылар һәм 2 орудие, 2 пулемет, 15 ящик патрон кулга төшерделәр...

Республика РВС председателе урынбасары — Э. СКЛЯНСКИЙ
Республиканың барлык Коралы көчләре
Башкомандующие — С. КАМЕНЕВ
Республика РВС члены — КУРСКИЙ

№ 225 *4 май, 1920 ел.*

...РВСРның 1919 ел, 511 нче номерлы приказы нигезендә Төркстан фронты Реввоенсоветының Кызыл Байрак ордены белән бүләкләвен расларга:

...439 нчы укчы полктан — 3 нче батальонның хәрби комиссары иптәш Сәләхетдинов Гаметдинне. 1919 елның 14 июлендә Парамонов хуторы янында барган сугышта үзенең ялкынлы сүзләре һәм шәхси үрнәге белән ул җиргә яткан сугышчыларны контрһөҗүмгә рухландырды.

...РВСРның 1919 ел, 511 нче номерлы приказы нигезендә 9 нчы Армия Революцион Хәрби Советының Кызыл Байрак ордены белән бүләкләвен расларга:

...181 нче укчы полктан — иптәш Кәшәфетдинов Аркамидулланы. Шушы елның 7 январенда ул Персиновка янында барган сугышта безнең частьлар һөҗүмгә күчкәндә беренче булып атакага күтәрелде һәм үз артыннан бөтен ротаны ияртте...

183 нче укчы полктан — кызылармеецлар Хәлиуллин Нәбиулланы, Насыйбуллин Паиисадимны, Нәбиуллин Мөхәммәтҗанны. 1919 елның 21 октябренда Бурляевка һәм Ивановка [Новохоперск шәһәре тирәләре] авыллары янында алып барылган сугышта, полк дошман кавалериясе чолганышында калгач, алар үзләренең шәхси батырлыклары һәм башка барлык чаралар белән үз рота-

---

1 Республика Революцион Хәрби Советы.

ларында ихтыяр көче һәм тәртип саклап, инде якын ук килеп җиткән дошманга атаата, соңгы кешеләр булып чигенәләр. Шушы вакытта иптәш Насыйбуллин авыр яралана...

191 нчы укчы полктан — отделение командиры иптәш Катлихмәтов Нурмөхәммәтне. 1919 елның 10 октябренда Шемякин хуторы янында барган сугыш вакытында яралануына да карамастан, ул ахырга кадәр сафта кала...

197 нче укчы полктан — атлы разведчиклар командасы кавалеристы Рамазанов Сафиулланы. 1919 елның 24 октябренда 193 полкка элемтәче итеп җибәрелгәч, ул дошман кулына эләгә һәм аның 10 разведчигы тарафыннан коралсызландырыла. Ләкин ул югалып калмый; башта дошманның төп көчләре кайда урнашканлыгын ачыклый һәм күз иярмәс җитез тизлек белән атка сикереп атлана да үз полкына чаба. Дошман көчләренең безнекеләр көтмәгән җирдә урнашканлыгы ачыклана. Безнең сугышчыларның позицияләре алмаштырыла һәм аларга дошманга каршы көчле удәр ясарга мөмкинлек туа. 27 октябрьда безнең һөҗүм вакытында элемтәче буларак 193 нче укчы полкка барышлый ул дошман олавына һөҗүм итеп, аның штабындагы карталарны, оператив приказларны һәм башка хәрби документларны кулга төшерә...

Республика РВС председателе урынбасары — Э. СКЛЯНСКИЙ
Республиканың барлык Кораллы көчләре
Башкомандующие — С. КАМЕНЕВ
Республика РВС члены — КУРСКИЙ

*№ 478* *24 сентябрь, 1920 ел*

РВСРның 1919 елгы 511 нче һәм 2322 нче номерлы приказлары нигезендә 9 нчы Кубань армиясе Реввоенсоветының Кызыл Байрак ордены белән бүләкләвен расларга:

200 нче укчы полктан — Рамазанов Шиһавали Алим улын. Үзенә катнашырга туры килгән барлык сугышларда, кыюлык һәм тәвәккәллек күрсәтеп, ул бик күп батырлыклар эшләде. Соңгы тапкыр ул Мелиховская станциясен алганда дошман сафлары эченә бәреп керде һәм 6 казакны кылыч белән чабып үтерде, 15 ен әсир итеп алды...

Республика РВС председателе урынбасары — Э. СКЛЯНСКИЙ
Республиканың барлык Кораллы көчләре
Башкомандующие — С. КАМЕНЕВ
Республика РВС члены — ДАНИШЕВСКИЙ

*№ 481* *5 октябрь, 1920 ел*

...РВСРның 511 нче һәм 2322 нче номерлы приказлары нигезендә 1 нче Армия Реввоенсоветының Кызыл Байрак ордены белән бүләкләвен расларга:

3 нче Татар укчы полкыннан — полк командиры иптәш Мәвмәдев Хөсәенне һәм шул ук полкның комиссары Касыймов Галине. 1919 елның 14 ноябрендә Уел елгасы буенда булып узган сугышта полкка тулы состав белән ачык урында һөҗүм итәргә туры килде. Бернинди кыенлыкларга да карамастан, әлеге иптәшләр үз-үзләрен аямыйча күрсәткән шәхси батырлыклары белән кызылармеецларны рухландырдылар. Шуның нәтиҗәсендә полк, елганы йөзеп һәм җәяүләп кичкәннән соң, каршы якка тын алырга да ирек бирмичә, Уел ныгытмасын яулап алды һәм бернинди ялга туктап тормастан, чигенүче дошманны куып баруында дәвам итте.

1 нче батальонның элекке командиры иптәш Шәйхетдиновны. 1919 елның 14 октябренда дошман офицерлар отряды һәм 12 пулеметы булган атлы казак полкы белән Бегала поселогын уратып алып ут ачкач, иптәш Шәйхетдинов, отряд командирының приказын да көтеп тормыйча, үзләрен чолгап алган офицерлар отряды өстенә ташланды һәм аны чигенергә мәҗбүр итте. Аның өстәвенә ике пулемет кулга төше-

релде. Аннан соң безнең кавалерия килеп җиткәч, югарыда телгә алынган отряд тулысынча юк ителде.

3 нче ротаның взвод командиры Хәлилов Шәрифне. 1919 елның 14 октябрендә ул Бегалинск янындагы сугышта, каршы якның көчле ут ачуына да карамастан, һөҗүм башында алга ыргылды һәм взводын үз артыннан иярткә. Нәтиҗәдә дошманның һөҗүме туктатылды.

Пулемет командасы взвод командиры Хәлиуллов Җиһаншаны. 1919 елның 14 ноябрендә Уел ныгытмасына һөҗүм вакытында пехота Уел елгасына килеп җитеп, аның аша кичү булмаганлыктан, бераз вакытка тоткарланып калгач, иптәш Хәлиуллов, дошман ачкан тоташ ут астында пулеметы белән суга сикерде һәм елганың каршы як ярына чыгып, аны кичүче безнең сугышчыларны үз уты белән яклады.

3 нче ротаның отделение командиры Рамазанов Насыйбулланы. 1919 елның 14 ноябрендә Бегалинск янындагы сугышта ул үзенең взвод командиры үрнәгендә алга ташланды һәм, яралануына да карамастан, сафта калып, дошман пулеметын юк иткәнчегә кадәр отделениесе белән командалык итте һәм канын күп югалтудан һушсыз булып егылды.

Республика РВС председателе урынбасары — Э. СКЛЯНСКИЙ
Республиканың барлык Кораллы көчләре
Башкомандующие — С. КАМЕНЕВ
Республика РВС члены — ДАНИШЕВСКИЙ

*№ 490* — *11 октябрь, 1920 ел*

РВСРның 1919 ел, 511 нче һәм 2322 нче номерлы приказлары нигезендә, 15 нче Армия Реввоенсоветының Кызыл Байрак ордены белән бүләкләвен расларга:

...96 нчы укчы полктан — җәяүле разведчиклар командасы старшинасы иптәш Прокофьев Михаил Трофимовичны, пулеметчылардан Соловьев Иван Никифоровичны һәм Хәбитов Хәбибрахманны. 28 мартта Частые авылына башланган һөҗүм вакытында да, шул авылда засадада торганда да, алар башка иптәшләре белән бергә, дошманның сан ягыннан өстен булуына һәм аның көчле ут ачуына да карамастан, кыю һәм бердәм рәвештә «Ура» кычкырып атакага ташландылар, дошманның 27 кешесен әсир итеп алдылар, винтовка һәм пулеметларын кулга төшерделәр...

Республика РВС председателе урынбасары — Э. СКЛЯНСКИЙ
Республиканың барлык Кораллы көчләре
Башкомандующие — С. КАМЕНЕВ
Республика РВС члены — ДАНИШЕВСКИЙ

*№ 502* — *17 октябрь, 1920 ел*

...РВСРның 1919 ел, 511 нче һәм 2322 нче номерлы приказлары нигезендә 9 нчы Кубань Армиясе Реввоенсоветының Кызыл Байрак ордены белән бүләкләвен расларга:

...187 укчы полктан — 6 нчы рота командиры Рәхмәтуллин Ганиулланы. 1920 елның 20 мартында каршы як бертуктаусыз ут яудырып торганда, яртылаш җимерелгән тимер юл аша Кубань елгасын кичкән вакытта бу операциягә каршылык күрсәтү максаты белән дошман һөҗүмгә күчте һәм кызылармеецлар сафында буталыш тудыра язды. Шул чагында иптәш Рәхмәтуллин үзенең тәвәккәллеге белән кызылармеецларны рухландырып, дошман һөҗүмен кире кайтарырга өндәде. Бу нәти-

җәсез калмады: кызылармеецлар, үз сафларында тәртип урнаштырып, дошман һөҗүмен туктаттылар һәм безнең гаскәрләрнең Кубань аша чыгуын тәэмин иттеләр...

Республика РВС председателе урынбасары — Э. СКЛЯНСКИЙ
Республиканың барлык Кораллы көчләре
Башкомандующие — С. КАМЕНЕВ

*№ 531* *10 ноябрь, 1920 ел*

...РВСРның 1919 ел, 511 нче номерлы приказы нигезендә 11 нче Армия Реввоенсоветының Кызыл Байрак ордены белән бүләкләвен расларга:

283 нче укчы полктан — 4 нче рота сугышчысы иптәш Касыймов Алине. 1920 елның 2 июнендә ул үзе теләп разведкага бара һәм 4 нче рота белән 2 нче рота арасындагы участокта урман артыннан дошман пехотасы килгәнлеген күрә. Моны сизеп алган дошман Касыймовка каршы ут ача һәм аны ике тапкыр яралый. Шуңа да карамастан, ул дошман пехотасының хәрәкәт итүе турында донесение алып кайта һәм сугыш тынганчыга кадәр сафта кала.

Республика РВС председателе урынбасары — Э. СКЛЯНСКИЙ
Республиканың барлык Кораллы көчләре
Башкомандующие — С. КАМЕНЕВ

*№ 57* *17 февраль, 1921 ел*

...РВСРның 1919 ел, 511 нче һәм 2322 нче номерлы приказлары нигезендә 12 нче Армия Реввоенсоветының Кызыл Байрак ордены белән бүләкләвен расларга:

...223 нче укчы полктан — рота командиры Гәрәев Мөгъсинне. 1919 елның 11 октябрендә Балатай хуторы янындагы сугышта безнең ике батальон чолганышта кала һәм зур югалтуларга дучар ителә, батальон командирлары һәлак булалар. Шунда ул 50 ләп кешедән группа төзеп, аның белән командалык итүне үз өстенә ала һәм бу группа, дошман боҗрасын өзеп, үзләренә ярдәмгә килүче частьларга кушыла...

Республика РВС председателе урынбасары — Э. СКЛЯНСКИЙ
Республиканың барлык Кораллы көчләре
Башкомандующие — С. КАМЕНЕВ

*№ 264* *20 сентябрь, 1921 ел*

...РВСРның 1919 ел, 511 нче номерлы приказы нигезендә 9 нчы Кубань армиясе Реввоенсоветының Кызыл Байрак ордены белән бүләкләвен расларга:

197 нче укчы полктан — отделение командиры Җәләлетдинов Сабирны һәм кызылармеец Сәйфетдинов Закирны. 1919 елның 24 декабрендә Дон елгасенең Зимовный һәм Бобровский хуторлары тирәсенә разведкага җибәрелгәч, алар дошманның ут яудырып торган пулеметын кулга төшерәләр...

Республика РВС председателе урынбасары — Э. СКЛЯНСКИЙ
Республиканың барлык Кораллы көчләре
Башкомандующие — С. КАМЕНЕВ

# 1918—1919 ЕЛЛАРДА КАЗАНДА КУЛЬТУРА ХӘРӘКӘТЕ

*Татарстанның 50 еллыгына багышлыйм.*
Автор.

## Татарстанда беренче гыйльми оешма

Татар әдәби теленең берничә йөз еллык тарихы бар. Бөек Октябрь революциясенә чаклы бу тарих ислам дине белән бергә килеп кергән гарәп теле йогынтысы астында үтте. Татар һәм гарәп телләре арасында төзелешләре ягыннан берниндн якынлык яки охшашлык булмаса да, гарәп теленә карата төзелгән кагыйдәләр татар теленә көчләп тагылып килде. Шуның аркасында ул үзенең эчке мөмкинлекләре, табигый үзенчәлекләре нигезендә үсә алмады. XIX йөзнең соңгы яртысында халкыбызның прогрессив вәкилләре моңа каршы протест белдерәләр. Мәсәлән, татар әдәби телен үстерү һәм аның орфографиясенә реформа кертү кирәклеген яклап, бөек мәгърифәтчебез Каюм Насыйри үзенең реформа проектларын тәкъдим итә. XX йөз башларында, бигрәк тә 1905 елгы революциядән соң, К. Насыйри күтәргән прогрессив фикерләр Галимҗан Ибраһимов, Мөхетдин Корбангалиев, Гыймад Нугайбәк, Гыйбад Алпаров шикелле алдынгы татар интеллигенциясе вәкилләре тарафыннан хуплап каршы алына. К. Насыйри карашларын яклап, алар матбугат битләрендә чыгышлар ясыйлар. Шул чорда Казанда, Уфада һәм башка урыннарда татар орфографиясен яхшырту буенча укытучылар җыелышлары үткәрелә.

Татар җәмгыятендәге дини консерватизм тормыштагы һәр яңалыкка каршы булган шикелле, тел өлкәсендә күтәрелгән реформа хәрәкәтенә дә каршы чыга. Шуңа күрә, татар орфографиясе Бөек Октябрь революциясенә шактый чуалчык булып, фәнни яктан бик аз эшләнгән хәлендә килеп керде.

Бары тик Октябрь революциясеннән соң гына бу мөһим мәсьәләгә җитди игътибар бирелә башлады. Беренче империалистик сугыш китергән, гражданнар сугышлары тудырган һәртөрле авырлыкларга карамастан, 1918 елның маенда Казанда Бөтенроссия мөселман укытучыларының өченче съезды үткәрелде.

Съездның көн тәртибенә ике мәсьәлә куелган иде: 1] Совет властена мөнәсәбәт; 2] Татар теле орфографиясен фәнни нигезләрдә тәртипкә китерү.

Ул чор өчен гаять актуаль булган сәяси мәсьәлә белән бер рәттән съездның көн тәртибенә орфография мәсьәләсе дә куелуы очраклы хәл түгел иде, әлбәттә. Совет



Галимҗан Ибраһимов, 1918 ел. Бу рәсем Казанда үткәрелгән Бөтенроссия мөселман укытучыларының III нче съездында төшерелгән.

чорында беренче уку елы булып тарихка керәчәк 1918—1919 уку елына әзерләнүгә бирелгән зур әһәмият нәтиҗәсе иде бу. Чөнки шул уку елында яңа мәктәпләрдә, башка предметлар белән беррәттән, татар теле дә тулы хокуклы предмет буларак укытылырга тиеш иде. Шул ук вакытта бу — татар теленең үсеш тарихында баганалы зур юлга аяк басуы иде.

Көн тәртибендәге беренче мәсьәлә буенча съездга Мәскәүдән (Үзәк мөселман комиссариатыннан) хөкүмәт вәкиле сыйфатында килгән Г. Ибраһимов доклад ясады. Докладның темасы үзенең характеры белән шул көннәр өчен бик тә актуаль булганга, өстәвенә ул Галимҗанга хас җитдилек һәм пафос белән укылганга, делегатлар аны зур игътибар белән тыңладылар. Докладтан соң кайнар фикер алышулар һәм бәхәсләр башланып китте. Реакцион настроениеле бер төркем делегатлар докладка каршы чыктылар һәм төрле юллар белән башкаларны да үз якларына аударырга тырыштылар. Ләкин йөзләрчә еллар буена иске тормышта изелеп килгән милләтнең хокуксыз һәм кимсетелгән укытучылары тегеләрнең коткысына бирелмәде. Докладның тирән эчтәлекле һәм инкарь ителмәслек дәлилләр белән беркетелгән булуы һәм укытучылар арасында киң танылган Мөхетдин Корбангалиев, Шаһид Әхмәдиев, Гыйбад Алпаров, Хуҗа Бәдыйгов, Габдрахман Сәгъди шикелле делегатларның докладчыны бик нык яклап чыгулары теге реакцион төркемне чигенүгә китерде. Нәтиҗәдә съезд зур күпчелек белән Г. Ибраһимов тарафыннан тәкъдим ителгән Совет властен тану турындагы резолюцияне кабул итте. Шулай итеп татар укытучылары Совет властеның туууына әле 5—6 гына ай тулган көннәрдә үк аны яклап чыктылар һәм үзләренеке итеп таныдылар.

Икенче мәсьәләгә караган докладны Фатих Сәйфи-Казанлы ясады. Аның докладыннан соң башланган фикер алышулар вакытында орфография мәсьәләләре буенча элек-электән үк кипә торган бәхәсләр, сүз көрәштерүләр кызып китте. Кайберәүләр 6 сузык авазлы орфографияне, икенчеләре 10 сузык авазлы имланы[1] яклап чыктылар. Искелекне яклаучылар арасында татар әдәби теленә кергән гарәпчә сүзләрне элеккечә гарәп теле кагыйдәләре буенча язуны алга сөрүчеләр дә, татар теле кагыйдәләренә буйсындырып язарга өндәүчеләр дә булды. Шунлыктан бер фикергә килеп, съезд исеменнән бердәм карар чыгару мөмкин булмады. Шушы уңайсыз хәлне күреп, съездда хөкүмәт вәкиле сыйфатында катнашкан Г. Ибраһимов гыйльми һәйәт[2] төзергә һәм шул һәйәткә, каралачак мәсьәләне гыйльми нигезләрдә җентекләп тикшереп, ел азагында Казанда Бөтенроссия күләмендә беренче хат һәм имла конференциясе үткәрүне йөкләргә диган тәкъдим кертте. Аның бу тәкъдиме съезд тарафыннан бертавыштан кабул ителде. Шуннан соң гыйльми һәйәт сайланды. Казанда татарлар арасында революциядән соң сайланган беренче гыйльми оешма әнә шундый шартларда барлыкка килде һәм «гыйльми һәйәт» исеме белән культура тарихыбызга керде.

---

[1] Имла — орфография.
[2] һәйәт — коллегия.



Рәсемдә: 1919 елны Казанда үткәрелгән «Беренче хат вә имла конференциясе» делегатларыннан бер төркем.
Беренче рәттә (сулдан уңга) профессор В. А. Богородицкий, Әминә Мөхетдинния, Мостафа Собхи, Мөхетдин Корбангалиев; икенче рәттә сулдан икенче (беренче иптәшнең исем-фамилиясен хәтерләмим — Ф. Х.) Фазыл Хәмидуллин, Ярулла Нәҗметдинов, Габделхәй Минмөхәммәтов, тюрколог Н. И. Ашмарин һәм Дәүләт Сафин.

Съезддан соң берәр ай үткәч, 1918 елның июль урталарында гыйльми һәйәт оешып эшли башлады. Ләкин ул озак яши алмады, шул ук 1918 елның август урталарында булган аклар фетнәсе вакытында таратылды.

Әлеге фетнә көннәрендә гыйльми һәйәт совет дошманнары тарафыннан таратылган булса да, аның халык күңелендә калган якты идеясе, халыкчан рухы совет кешеләрендә сүнмәде.

Фетнәчеләр Казаннан сөрелгәч, Үзәк мөселман комиссариаты тирәсендә оешкан коммунист-большевиклар һәм совет платформасында торган революционер-интернационалистларның Мәскәүдә үткәрелгән гадәттән тыш җыелышында гыйльми һәйәтне яңадан аякка бастыру мәсьәләсе куела һәм аны оештыру төрек коммунисты Мостафа Собхига тапшырыла. Үзенә тапшырылган бу җаваплы эшне үтәү максаты белән М. Собхи сентябрь башларында Казанга килә. һәм шул ук айның уртугызында гыйльми һәйәт яңадан оештырылып, алдан төзелгән план белән эш башлый. Бу яңа составка элекке составның берничә ышанычлы члены һәм совет платформасында нык торган яңа агъзалар кертелә. Мостафа Собхи һәйәтнең рәисе итеп билгеләнә.

Шул уңай белән кайберәүләр: «Гыйльми һәйәтне яңадан төзү өчен Мәскәүдән ни өчен чит ил кешесе, Казан әхвәле белән якыннан таныш булмаган кеше җибәрелгән, ә ни өчен ул көннәрдә Мәскәүдә яшәгән, Бөтенроссия мөселман укытучыларының III съездында гыйльми һәйәт оештыру мәсьәләсен башлап күтәргән, аны сайлауда актив катнашкан Г. Ибраһимов җибәрелмәде икән!» — дип сукранып башлыйлар. Ләкин бу хәлнең билгеле сәбәпләре була, әлбәттә. Хикмәт шунда, ул чорда Г. Ибраһимов Мәскәүдә булса да, каты авырып, больницада ята. Сәламәтлеге какшаган булганга, ул хәтта Үзәк мөселман комиссариаты коллегиясендә эшләүдән дә азат ителүен сорап гариза бирә. Сәламәтлеге әйбәт булмау аркасында, ул 1918 елның азагында, 1919 елның гыйнварында гыйльми һәйәт тарафыннан Казанда Бөтенроссия күләмендә

үткәрелгән беренче хат[1] вә имла[2] конференциясенә дә турыдан-туры катнаша алмый.

Ләкин Мостафа Собхинең Мәскәүдән Казанга гыйльми һәйәтне яңадан аякка бастыру өчен җибәрелүендә Г. Ибраһимовның катнашы, әлбәттә, булган. Мәскәүдә Үзәк мөселман комиссариатында бергә эшләгәндә Г. Ибраһимов Мостафа Собхинең гыйлем кешесе, Истамбул университеты профессоры, төрки телләр белән таныш булуын яхшы белгән, шунлыктан ул аның Казанга җибәрелүен дә, яңадан төзелгән гыйльми һәйәтнең беренче председателе булып сайлануын да яклаган дип уйларга кирәк.

Мостафа Собхи җитәкчелегендә эшли башлаган гыйльми һәйәтнең беренче план һәм структурасы түбәндәгечә иде:

Тел, әдәбият вә тарих шогъбәсе[3];

Музей, театр вә сәнаигы нәфисә[4] шогъбәсе;

Ибтидаи[5], гали[6] ибтидаи мәктәпләр һәм семинарияләр өчен программалар төзү шогъбәсе;

Матбугат шогъбәсе;

Дарелфонун[7] вә китапханә шогъбәсе.

Бу шогъбәләр (бүлекләр) үз нәүбәтләрендә группаларга бүленгән иде. Мәсәлән, татарча энциклопедия группасы, халык әдәбияты һәм тәрҗемә группасы, этнография группасы, археология группасы, гыйльми көчләр җыю группасы һәм башкалар...

Кыскасы, гыйльми һәйәт Бөек Октябрь революциясеннән соң Казанда мәгариф һәм культура өлкәсендә киң план белән эш башлап җибәргән беренче зур гыйльми оешма иде. Ул үзенең структурасы һәм планы белән генә түгел, башкарган эшләре белән дә культура һәм мәгариф тарихыбызда мактаулы урын алып алды.

Атап әйтсәк, гыйльми һәйәт 1918 елның ноябрендә, Бөек Октябрь революциясе тудырган яңа мәктәпләргә туры юл күрсәтүче педагогик журнал — «Мәгариф» журналы чыгара башлады. Ул журнал битләрендә аерым фәннәрне яңача укыту программалары һәм аларга аңлатмалар басылып чыкты. Яңа шартларда ачылган эш мәктәпләрендә укыту-тәрбия эше башлап җибәргән яшь татар укытучылары өчен ул материаллар бәяләп бетергесез кыйммәтле документлар иде.

1918 елны гыйльми һәйәт органы буларак басыла башлаган бу журнал, өч саны чыгып бераз тукталып торганнан соң, 1921 елның апреленнән Татарстан мәгариф комиссариаты органы буларак чыга башлады һәм хәзер дә укытучыларның бик зур ярдәмчесе булып торуын дәвам итә[8].

Гыйльми һәйәт башкарган мөһим эшләрнең тагын берсе шунда, ул уннарча еллар буена чуалчык хәлдә яшәп килгән, халык арасында мәгариф, аң-белем таратуга комачаулаган имласызлыкка чик кую буенча зур өлеш кертте. Мөселман укытучыларының III съезды тарафыннан тапшырылган тарихи наказны эшкә ашыру йөзеннән, гыйльми һәйәт 1919 елның гыйнварында Казанда зур хәзерлек белән беренче Бөтенроссия хат вә имла конференциясе үткәрде һәм анда имлабызның киләчәк юнәлеше билгеләнде.

Берничә ел шушы исемдә яшәгәннән соң, гыйльми һәйәт Гыйльми үзәк (акадцентр) дип йөртелә башлады. 1923—1928 елларда аңа танылган әдип һәм фән эшлеклесе, художество фәннәре академиясе члены Галимҗан Ибраһимов җитәкчелек итте. Ул елларда Гыйльми үзәк аеруча зур эшчәнлек күрсәтте. Аның инициативасы һәм актив катнашы белән Октябрьга чаклы иҗат ителгән прогрессив әдәбиятыбыз фондына керган бик күп әдәби әсәрләр яңадан басылды. Газиз Гобәйдуллин һәм Гали Рәхимнәр тарафыннан язылган борынгы әдәбиятыбызның 3 томлык тарихын, Габдрахман Сәгъдинең XIX йөз һәм XX йөз башы татар әдәбияты тарихы, татар театрының 20 еллыгы (1906—1926) турында җыентык һәм культурабызның башка тармаклары буенча бик күп

---

[1] Хат — язу.
[2] Имла — орфография.
[3] Шогъбә — бүлек.
[4] Сәнаигы нәфисә — нәфис сәнгать.
[5] Ибтидаи — башлангыч.
[6] Гали ибтидаи — югары башлангыч.
[7] Дарелфонун — университет.
[8] 1938 елдан бирле «Совет мәктәбе» исеме белән чыга.

башка капиталь хезмәтләр дөньяга чыкты. Төрле типтагы татар мәктәпләре өчен аерым фәннәр буенча программалар, дәреслекләр, методик кулланмалар төзелде һәм басылды. Шул рәвешчә Гыйльми үзәк. Мәгариф комиссариатының зур бер бүлеге сыйфатында, күп еллар буена республикабызда мәгариф һәм культура хәрәкәтенең кайнап торган үзәге булды. Гыйльми һәйәт тарафыннан башланып Гыйльми үзәк тарафыннан үстерелгән мәгариф, культура эшләре, торган саен киңәя һәм катлаулана бару сәбәпле, бер оешма рамкаларына сыймый башлады һәм, характерларына карап, алар төрле гыйльми-фәнни учреждениеләр карамагына күчтеләр. Хәзер ул эшлер, киңәйтелгән функцияләрдә, Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты, культура һәм мәгариф министрлыклары, укытучыларның белемен күтәрү институты, Татарстан китап нәшрияты тарафыннан дәвам иттерелә. Шул рәвешчә, Гыйльми үзәк үзенең тарихи миссиясен үтәп, функциясен заман таләп иткән яңа оешмаларга тапшырды.

Гыйльми һәйәт эшчәнлеге турында сүз барганда аның оештыру эшләрендә якыннан катнашкан һәм М. Собхинең урынбасары булып эшләгән беренче татар хатын-кызларыннан Әминә Мөхетдинияне искә алмый үтү мөмкин түгел. М. Собхи һәйәттә булмаган очракларда Әминә һәйәт утырышларында рәислек итте һәм җаваплы эшләр башкарды. 1919 елның гыйнварында Казанда үткәрелгән беренче хат вә имла конференциясендә дә ул якыннан катнашты.

## Беренче хат вә имла конференциясе

1919 елның башы иде. Яшь совет власте гаять авыр көннәр кичерә, гражданнар сугышы фронтларында Бөек Октябрь казанышларын эчке һәм тышкы дошманнардан саклап калу өчен кискен сугышлар бара. Әнә шушы авыр моментта Казанда 22 көн буена (1—22 январь) Бөтенроссия күләмендә чакырылган «Беренче хат вә имла конференциясе» эшләде һәм анда Совет власте чорына үтә чуалган хәлдә килеп кергән татар язуы һәм орфографиясе мәсьәләләре тикшерелде.

Конференцияне чакыру башта 1918 елның декабрена билгеләнгән иде. Ләкин ул, алдан күрелмәгән бик күп төрле объектив сәбәпләр аркасында бер айга кичеккән, 1919 елның январь башында гына үткәрелде. Ул сәбәпләрнең берсе конференциянең зурлап үткәрелүе булса, икенчесе аның көн тәртибенә кертелгән күп санлы һәм катлаулы мәсьәләләр буенча тирән эчтәлекле докладлар белән чыгарлык гыйльми кадрлар, тел галимнәре табуга бәйле иде. Барлык докладлар өчен Казанның үзеннән генә докладчылар табу мөмкин түгел, чөнки 1918 елның җәендә Казанда булып үткән ак бандитлар фетнәсе гыйльми көчләр сафын шактый сирәкләндергән иде. Шуңлыктан докладчыларны башка шәһәрләрдән чакырырга кирәк булды. Ул чордагы транспорт һәм элемтәнең нормаль эшли алмавы оештыру эшләрен тагын кыенлаштырды. Ә конференция карамагына тәкъдим ителәчәк докладлар гыйльми һәйәт каршында төзелгән махсус комиссия тарафыннан тикшерелеп үткәрелергә, анда редакцияләнергә, алар буенча резолюция проектлары хәзерләнергә тиеш иде. Шуңлыктан гыйльми һәйәт башта өзерлек чаралары күрде. Конференция җыелыр алдыннан бер ай чамасы элек төп докладчылар Казанга чакырылып, алар зарур шартлар белән тәэмин ителделәр. Шуннан соң гына эш җайга салынды.

Конференциягә гыйльми яктан хәзерлек эшләре күрү буенча илебезнең төрле өлкәләреннән 30 лап тел белгечләре һәм укытучылар чакырылды. Алар арасында Г. Нугайбәк, Г. Ибраһимов, Х. Бәдигый, Г. Сәгъди, Һ. Максуди, мөгаллим Фатыйх Сәйфи, Ш. Әхмәдиев, Х. Гали, З. Рәмиев, Р. Фәхретдинов, Н. Думави, Г. Гафуров, И. Рәхметуллин, Н. Ф. Катанов, Н. И. Ашмарин, А. Н. Самойлович, С. Е. Малов, В. А. Богородицкий, Г. Алпаров, М. Корбангалиев, Г. Шәрәф иптәшләр дә бар иде.

Конференция җыелыр алдыннан гыйльми һәйәт тарафыннан доклад һәм резолюция проектлары хәзерләү өчен комиссия төзелеп, аның составына Х. Бәдигый, М. Корбангалиев, Г. Шәрәф, М. Собхи кертелгән иде.

Югарыда без конференциянең 22 көн дәвам итүен әйткән идек. Аның шулай озакка сузылу сәбәпләреннән берсе — көн тәртибенә куелган мәсьәләләрнең күплеге (барлыгы 10 мәсьәлә) һәм катлаулыгы иде. Биредә аларның берничәсен генә китерик:

1. Әдәби татар телендә ничә сузык (гласный) аваз бар һәм бу авазларны билгеләү өчен ничә һәм нинди галәмәтләр[1] алынырга тиеш!

2. Татарча сүзләрне язу өчен ничә сузык аваз алырга кирәк: 10 мы, 9 мы, 6 мы, 5 ме, 3 ме!

3. Калын вә нечкә «у», «и» авазлары мөрәкәпме (катлаулымы), бәситьмы (гадиме).

4. Татар әдәби телендә ничә тартык (согласный) аваз бар, бу авазларга нинди галәмәтләр алынырга тиеш!

5. Татар әдәби телендә сөйләнүе утырып җитмәгән кайбер сүзләрнең имласы.

6. Чит телләрдән кергән сүзләрнең имласы һ. б...

Күренә ки, бүгенге телебез яки орфографиябез өчен сәер тоелган бик күп мәсьәләләр моннан 50 ел элек «Беренче хат вә имла конференциясе»нең көн тәртибенә кертелгән һәм 22 көн буена тикшерелгән. Монда искитәрлек бер нәрсә дә юк. Чөнки безнең орфографиябез совет чорына, югарыда да әйтелеп үткәнчә, бик аз эшләнгән хәлдә килеп кергән иде, шуңа күрә дә әлеге укытучылар съезды һәм конференция бу мәсьәләне совет властенең беренче елларында ук тәртипкә китерү юлына бастылар.

Беренче хат вә имла конференциясенең әһәмияте теоретик яктан гына түгел, политик, иҗтимагый-культура һәм практик яклардан да зур булды. Ул хезмәт иялəре арасында грамоталылык һәм мәдәният тарату юлында иң көчле корал булып саналган тел, язу, орфография мәсьәләләре буенча совет чорында беренче тапкыр сүз әйтте, татар язуы һәм орфографиясенең киләчәктәге юнәлешен билгеләү буенча гыйльми яктан расланган юллар сызды.

Ул конференция турында басым ясап тагын шуны искәртәсе килә: конференциянең эше интернациональ характерда барды. Анда татар тел белгечләре генә түгел, бәлки рус, поляк, төрек, башкорт, хакас, чуваш һәм башка милләт вәкилләре дә катнашты.

Конференция гыйльми һәйәт председателе М. Собхи җитәкчелегендә үтте. Кайбер утырышлары конференция президиум составына кергән М. Корбангалиев, Г. Шәрәф рәислеге астында үтте. Фатыйх Сәйфи-Казанлы һәм бу юлларны язучы конференциянең секретарьлык эшен алып бардылар.

Конференция исеменнән 6 январьда Совнарком председателе Владимир Ильич Ленинга түбәндәге телеграмма җибәрелгән иде:

«От конференции по реформе татарской орфографии
6 января 1919 г. Москва, Председателю Совнаркома, Ленину

Представители татарской интеллигенции и учащиеся, собравшиеся по почину мусульманской научной коллегии на конференцию для выработки рациональной орфографии родного языка, приветствуют Вас как поборника просвещения пролетарских масс, сумевшего привлечь интеллигентные силы народа к активной деятельности на этом поприще и как борца на пути освобождения языка и литературы малых национальностей, выбирают Вас почетным председателем конференции.

Президиум конференции Мустафа Субхи,
М. Курбан-Галиев»[2].

Ф. ХӘМИДУЛЛИН,
пенсиядәге укытучы.

---

[1] Галәмәтләр — билгеләр, хәрефләр.
[2] Ленин и Татария. Татарстан китап нәшрияты, Казан, 1970 ел, 220 бит (рус телендә).

В. Климентовский

# УНИВЕРСИТЕТНЫҢ БЕРЕНЧЕ СТУДЕНТЫ




Сергей Тимофеевич Аксаков төп Казан кешесе түгел. Ләкин аның тормышы Казан белән бик нык бәйле. Ул Казанда башта гимназиядә, аннан соң университетта укый. Нәкъ менә шул студент елларында әдәбият һәм театр белән кызыксына башлый.

1799 елның кышында, гимназиягә укырга урнаштыру нияте белән, сигез яшьлек Сережаны әнисе Казанга алып килә. Ләкин урнаштырмый: сәламәтлеге бик шәптән булмаган улын чит кешеләр кулына калдырып китәргә кызганып, аны яңадан үзе белән алып кайта. Әмма малайның шул чакта Казанга килүе эзсез калмый. С. Т. Аксаков бу хакта соңыннан үзенең «Истәлекләр»ендә «минем бөтен киләчәгем шул баруда билгеләнде» дип яза.

1800 елның декабрендә Сережаны атасы Казанга яңадан алып килә. 1801 елның 15 гыйнварында Казан гимназиясенең рус теле буенча өлкән укытучысы Л. С. Левицкий үз квартирасында Сережадан имтихан ала һәм аның И. И. Дмитриев шигырьләрен, Н. М. Карамзин әсәрләрен бик яхшы итеп, тәэсирләнеп укуын, дөрес һәм матур итеп язуын, гомумән, киң мәгълүматлы булуын күреп куана. Шуннан соң Сережаны, гимназиянең казна хисабына тәрбияләнүчеләре исәбенә кертеп, укырга алалар, чәчен кырдырып гимназия формасы кидертәләр. Ул чорларда гимназия губернатор йорты белән рәттән салынган төп бинасына — Воскресенская (хәзерге Ленин урамы) урамында урнашкан була. (1825 елда гимназия һәм губернатор йорты бинаалары 12 колонналы үзәк портик белән тоташтырылып, университетның уң һәм сул канатларын тәшкил итә һәм шул хәлендә ул бүгенгәчә тора бирә.)

Әти-әнисеннән аерылу болай да авыр булган Сережага шактый кыенга туры килә. Туган якларын сагына, тора-бара сагышы зур хәсрәткә әйләнә һәм ул каты нерв авыруы белән чирләп китә. Шуның өстенә, гимназиядә укый башлавының беренче көннәреннән үк гимназия надзирателе Н. И. Камашев та малайны яратмыйча гел кимсетеп тора. Хәтта аның авыруына да ышанмый, юри кылана һәм башка гимназистларга начар үрнәк күрсәтә дип саный. Бары тик малайның хәле чиктән тыш кыенлашкач кына, аны лазаретка озата. Шуннан соң, бу хәлгә йөрәге түзә алмыйча, әнисе Сережаны «Аксаково»га үз өйләренә алып кайтып китәргә мәҗбүр була.

Сережа өйләрендә бер ел тора. Балыкка йөри, китап укый. Шулай итеп тыныч шартларда ял итүе, әти-әниләре, туганнары янында иркенләп яшәве нәтиҗәсендә бер елда малайның сәламәтлеге тәмам ныгый һәм әнисе аны яңадан Казанга гимназиягә укырга илтә.



1803 елда гимназиянең урта классында укыган чагында Сережа рус телен һәм әдәбиятын бик әйбәт укытучы Николай Мисаилович Ибраһимов[1] белән очраша. Укытучы белән укучы арасында тора-бара якын дуслык урнаша һәм Аксаков соңыннан да остазын еш кына сагынып исенә ала. Ибраһимов кай ягы белән малайның күңелен җәлеп итә соң? дигән сорау туарга мөмкин. Хикмәт шунда, Ибраһимов үзе дә яшь, яңарак кына Мәскәү университетын тәмамлап, Казанга эшкә кайткан кеше була һәм ул гимназистларга диктант текстларын Ломоносов, Карамзин, Дмитриев әсәрләреннән алып бирә. Аннары ул текстларны кычкырып укыта, художество эшләнешләрен аңлата, шулай итеп, балаларда әдәбиятка мәхәббәт тәрбияли. Шуның өстенә Ибраһимов үзе дә шигырьләр яза торган шагыйрь җанлы кеше була һәм 1806 елда әдәбият түгәрәге оештыра. Ул оештырган түгәрәк һаман саен зурая, үсә барып, 1814 елны «Туган телне яратучыларның Казан җәмгыяте»нә әйләнеп китә һәм 1853 елга тикле яши.

Әдәбиятны аңлый һәм ярата башлавына Ибраһимов зур булышлык иткәнлеге турында Аксаков үзе менә болай дип яза: «Бу кеше миңа әдәби юнәлеш бирүдә зур ярдәм итте һәм аның истәлеге минем өчен бик кадерле. Иң беренче булып мине ул хупләды һәм чын юлга чыгарга булышты».

Аксаковта әдәбиятка мәхәббәт тәрбияләүдә шулай ук зур ярдәм иткән укытучыларның тагын берсе — Григорий Иванович Карташевский. Карап торышка шактый кырыс һәм күңелсез кеше булса да, асылда Карташевский намуслы һәм туры сүзле була. Шуның өчен Сережа аны үз абыйсы шикелле якын күрә. Карташевский да малайны бик тиз үз итә башлый һәм аңа укытыр өчен Державин, Ломоносов, Сумароков, Херасков, Дмитриев, Капнист әсәрләрен яздырып ала. Ә инде Сережа француз телен өйрәнгәннән соң аңа француз классиклары әсәрләрен дә табып укыта башлый. «Григорий Иванович поэтик матурлыкны, автор фикерен һәм сүзләрнең мәгънәсен миңа шундый шәп итеп аңлата иде,— дип яза соңыннан Аксаков үз «Истәлекләр»ендә,— минем әдәбият белән кызыксынуым тиздән дәртле мәхәббәткә әверелеп китте».

Әдәбиятны аңларга, аны яратырга өйрәтсә дә, Картышевский Сережаның үзенә язарга рөхсәт итми. Башта бик ныклап һәм күп итеп зур әдипләрнең әсәрләрен укырга, телне яхшылап өйрәнергә, шуннан соң гына яза башларга киңәш бирә...

Казан гимназиясенең чыгарылыш (югары) классында укыганда гимназистлар шактый озакка сузылган забастовка күтәрәләр. Ул забастовка нәтиҗәсендә сигез гимназист укудан куып чыгарыла. Ә забастовка башлануның сәбәбе болай: бер көнне гимназия хезмәткәрләреннән берәү (квартирмейстер) үз кулы астында эшләүче инвалидны таяк белән кыйнап ятканны күреп, гимназистлар бик каты тавыш куптаралар һәм кыйналучыны якларга керешәләр. Квартирмейстер теге кешене кыйнаудан туктарга мәҗбүр була. Ләкин шундук, гимназистлар начальствога каршы бунт күтәрделәр дип, директорга рапорт язып бирә.

Үз чиратында гимназистлар да, квартирмейстерны эшеннән алуны таләп итеп, директорга гариза бирәләр. Ләкин гимназия директоры Лихачев аларның үтенечләрен канәгатьләндерми генә түгел, бәлки кайбер гимназистларны хәтта җәзага да тарттыра. Менә шул гаделсезлеккә ачу итеп, гимназиянең барлык классларында укучылар да берничә көн укырга йөрмиләр. Гимназия директоры каушап кала һәм квартирмейстер-

[1] Нигъмәт Мирсәет улы Ибраһимовны руслар шулай атап йөрткән.

ны, инһаять, эшеннән алырга приказ чыгара. Шул ук вакытта, «бунтарьларга» карата чара күрүне үтенеп, губернаторга да мөрәҗәгать итә. Аксаков ул вакыттагы хәлләр турында менә болай дип яза: «Төшке аш вакытында кинәт залга мылтыклар һәм штыклар белән коралланган солдатлар килеп керә, алар артыннан губернатор һәм директор күренә. Директор югары класста укучы уналты кешене, исемнәрен белән дәшеп, чакырып ала... һәм солдатлар сагы астында аларны карцерга алып китәргә боера... Гимназиянең барлык тышкы ишекләре янына мылтыклы һәм штыклы икешәр солдат, карцер ишеге төбенә дүрт солдат куела. Шушы куркынычсыз хәлләрдән соң ике атна үткәч, мин вакытлыча китеп торган ялдан кайттым һәм ятимләнеп калган классыбызга барып кердем... Бу аяныч вакыйгага мин, һичшиксез, бик кызып катнашкан булыр идем...»

1805 елның 14 февралендә, артык зурлап тантана итмичә генә, Казан университеты ачыла — гимназия университетка әверелдерелә. Ә 1805 елның 22 февралендә гимназистларны залга җыйныйлар да университетның беренче директоры И. Ф. Яковкин аларга университет уставыннан студентларның бурычлары турындагы статьяларны укый. Аннары гимназиядән механик рәвештә университет студенты итеп күчерелгән өлкән класс укучыларының исемлеген игълан итә. Ул исемлектә иң беренче итеп Сергей Аксаков исеме язылган була. С. Т. Аксаковны беренче Казан студенты дип атаган материалларны укырга туры килсә, гаҗәпләнмәгез — бу чыннан да шулай. Аксаков үзе дә студент булуына горурлануын яшерми һәм соңыннан ул чакларны түбәндәге сүзләр белән искә ала: «Иң беренче эшем итеп мин үзем килгәнче дежур надзирательнең кладовоенда сакланып торган студент шпагамны алдым. Аннары без Александр Панаев белән бергә, шпагаларыбызны тагып, якшәмбе көнне көн буе шәһәр урамында йөрдек. Ул чакта болай йөрү яңалык булганлыктан, кешеләр безгә кызыксынып карап калалар иде, һәм без шуңа рәхәтләнеп йөргән идек».

Ул көннәрдә студентларның нинди халәттә булганнарын әдип менә болай итеп искә ала: «Барысы да кочаклашалар, бер-берен котлыйлар һәм, студент исемен күтәреп йөрү оят булмасын өчен, берничә айда үзләренең җитешсез якларын төзәтеп житкерергә сүз бирешәләр иде... Ул чакта гимназиянең өлкән яшьләренең ничек итеп чын күңелләреннән мәгърифәткә, фәнгә омтылып торганнарын хөрмәт белән искә алмый мөмкин түгел. Дәресләрне кендез генә түгел, хәтта төннәрен дә әзерли торган идек. Барыбыз да ябыгып, йөзләребез агарып бетте һәм, бу хәлне күреп, начальство безнең алай чамадан тыш тырышлыкны туктату чараларын күрергә мәҗбүр булды. Дежур надзиратель төннәр буена йокы бүлмәләренә кереп, шәмнәрне сүндереп һәм сөйләшеп яткан кешеләрне тыеп йөри, чөнки без караңгыда да материалларны бер-беребезгә күңелдән кабатлый торган идек. Безнең барысын да белергә тырышуыбыз аркасында укытучыларга да тынычлык юк: алар безнең белән класста вакытта гына түгел, класстан тыш вакытларда да, хәтта бәйрәм көннәрендә дә шөгыльләнергә мәҗбүрләр иде».

Фәннәрне яхшылап үзләштерергә тырышу белән берраттән, студентлар дөнья хәлләреннән дә хәбәрсез булып ятмыйлар: ул елларда барган сугыш хәрәкәтләре белән кызыксыналар, аңа үз мөнәсәбәтләрен белдерәләр. «Аңарчы да безнең тарафтан котеп алына торган һәм кызыксынып укыла торган Дмитрий Княжевич хатлары 1805 елда аеруча зур политик кызыксыну тудыра башлады. Ул вакытта Наполеон белән беренче сугыш бара иде. Белмим, ни өчендер, сугыш вакыйгалары турындагы хәбәрләр безгә бик авырлык белән һәм соңга калып килә, ә Княжевич аларны безгә тиз һәм тәфсыйллап хәбәр итә торган иде. Шуның өстенә аның хатлары рус коралына зур мәхәббәт белән сугарылып язылган була һәм безгә электр тогы кебек тәэсир итә торган иде. Дмитрийның энесе Александр Княжевич «Абыйдан хат!» дип кычкырып җибәрүгә, без аны шундук урап алабыз да, тын да алмыйча, аның кычкырып укыганын тыңлап торабыз. Хәтта гимназистлар да, безнең янга җыелып, аның хатларын тыңлыйлар иде. Без атаклы Багратионны аеруча нык ярата идек. Берваклт аның дошман кулына калдырылган җирдән үз отряды белән французларның бөтен бер армиясе аша үтеп чыкканлыгын ишеткәч, шундый итеп сокландык, шундый итеп ура кычкырып җибәрдек, ул вакыттагы куанычыбызны язып аңлатырга хәтта мин сүз дә таба алмыйм. Безнең яшьлек дәверендә төрле хәлләр булды, һәм ул елларны мин хәзер дә сагынып искә алам».

С. Т. Аксаковның театр белән беренче танышуы һәм ныклап торып кызыксынып китүе шулай ук Казанда укыган елларына туры килә. Әле гимназиядә укыган чагында ук Сережаны абзыйсы Казандагы Есипов театрына алып бара һәм алар «Песнелюбия» («Җыр ярату») операсын һәм «Братом проданная сестра» («Абыйсы тарафыннан сатылган кыз») комедиясен карыйлар. Бу спектакльләр малайга шул тикле тәэсир итә ки, ул хәтта укуын да онытып, бөтенләй театр белән саташып яши башлый. Бары тик яраткан укытучысы Карташевский гына аны яхшылап үгетләп, яңадан яхшы укый башларга һәм театрны онытып торырга мәҗбүр итә. Ә инде малайның театрга дәрте сүрелеп, ул яңадан гимназиядә элеккечә яхшылап укый башлагач, Карташевский кичләрен үзе аның белән театр хакында әңгәмәләр алып барырга керешә: Сережаны театр тарихы, атаклы рус һәм чит ил артистларының тормышлары белән таныштыра. Шуннан соң гына Карташевский Сережаны театрга алып бара. Бу турыда Аксаков «Истәлекләр»ендә менә ничек итеп язылган: «...без театр турына җиткәч, ул (Карташевский — В. К.) кучерга: «Театр ишеге төбенә туктат!» диде. Кучер атын театр ишеге төбенә китереп туктаткач, Григорий Иванович чанадан сикереп төште, ә мин куанычымнан бөтенләй аптырап калдым, кыймылдый да алмыйча утыра бирдем. Григорий Иванович түзә алмыйча көлеп җибәрде һәм миннән: «Нәрсә! Әллә театрга керәсегез килмиме!» — дип сорады. Мин юләр кешедәй куанып сикереп төштем. «Колбасники» («Колбасачылар») дигән операны карадык. Я ходаем! Нинди бәхетле идем мин ул көнне!..»

Шуннан ары күп тә үтми. Сережа Есипов театрында «Недоросль» («Җитлекмәгән егет») «Ошибки или утро вечера мудренее» («Ялгышлар яки иртә кичтән зирәкрәк») исемле пьесаларны, «Нина или сумашедшая от любви» («Нина яки мәхәббәттән акылын югалткан») исемле операны карый. Карап кына да калмый, кайткач ук, гимназия тәрбиячеләренә сиздермичә генә, үзе караган спектакльләрдәге рольләрнең сүзләрен яттан өйрәнә. Театрны шулай ураткaнга, Сережа 1804 елны ук үзенең классташы Александр Панаев белән дә бик якыннан дуслашып китә. Сережа кебек үк театрга мөкиббән киткән Александр гимназиядә «Аркадские пастушки» («Аркад көтүчеләре») исемле кулъязма журнал чыгара башлый һәм төрле псевдонимнар белән ул журналда повестьләр, шигырьләр урнаштырып бара. Аның бу эше Аксаковка да кызыклы булып тоела һәм ул да, дусты Панаевка сиздермичә генә, шул журналга язгалый башлый[1]. Гимназиядә укыган вакытларында чыгара башлаган журналны университет студенты булгач та чыгаруны дәвам итәләр. Бертуган Панаевлар, бертуган Перевощиковлар һәм Аксаковның башка дуслары әдәбият белән һаман саен күбрәк мавыга баралар: шигырьләр, хикәяләр язалар, көнбатыш язучыларының әсәрләрен тәрҗемә итәләр.

Аксаков һәм аның иптәшләре бер үк вакытта театр белән дә элеккечә үк кызыксыналар. 1805 елның кышында атаклы Мәскәү артисты Плавильщиков, Казанга килеп, Есипов театрында уйный башлагач, студентлар аеруча дәртләнеп китәләр. «Партерда яисә креслоларда утырып карарга студентларның хәленнән килми: партердагы урын бер сум, ә кресло бәясе ике тәңкә дә илле тиен тора иде,— дип яза Аксаков үзенең «Истәлекләр»ендә.— Шунлыктан безгә арзанлы илле тиенлек урыннарга гына утырып карарга туры килә торган иде. Ләкин бу безнең өчен бик тә уңайсыз: спектакльләр сәгать җиденче яртыда башлана, ә безнең лекцияләр алтыда гына бетә. Димәк, театрга спектакль башланганда гына барып җитәргә мөмкин, ә ул чакта инде әлеге арзанлы урыннарның да алгы рәтләренә кешеләр утырып беткән, безгә бары тик берни күреп булмый торган арткы эскәмияләр генә калган була торган иде. Шул уңайсызлыктан котылу өчен түбәндәге чараны куллана башладык: сәгать бишләрдә үк тазарак һәм көчлерәк ике-өч студент театрга баралар да теге арзанлы эскәмияләрнең алгы рәтләреннән безгә урын алып куялар һәм, без килгәнче, бүтән кешеләрне утыртмыйча, саклап торалар. Баштарак безнең ише арзанны «яратучылар» тавыш чыгарсалар да, соңыннан бу гадәткә күнектеләр һәм бары да тыныч кына үтеп китә торган булып китте. Без театр башланганда гына килеп керәбез һәм әзер урыннарга барып утыра торган идек. Башта алдан бара торган студентлар класстан сиздермичә генә чыгып сыза торганнар иде, ләкин соңыннан, бу хәлнең сәбәбен аңлагач, профессорлар да,

[1] Бу журнал Мәскәүдәге үзәк архивта хәзер дә саклана — В. К.

укытучылар да кайбер тыңлаучыларның юкка чыгуына бармак аша карый торган булдылар. Ә хөрмәтле Ибраһимов исә: «Театрга барырга вакыт түгелме икән, әфәнделәр!» дип кайчакларда үз классын ярты сәгатькә алданрак та җибәрә торган иде.

Афишалар табу да үзебезнең студентларга йөкләнә, басма афишалар шәһәрдә юк иде. Кайбер дәрәҗәле кешеләр язма афишаларны театр конторасыннан алалар, ә куелачак пьеса һәм анда уйнаячак артистлар турында шәһәр халкына театр ишеге төбендәге колоннага дүрт кадак белән беркетеп куелган игълан аша хәбәр ителә иде. Мин дөресен әйтергә тиешмен, без афишаларны урлый торган идек. Театр ишеге төбенә киләсең дә игъланны укып торган буласың. Аннары, якын-тирәдә кеше юк чакта, тиз генә афишаны куптарып аласың да, табышны кесеңә тыгып, университетка кайтып китәсең. Соңыннан, студентларның бу хикмәтен сизеп алгач, театр тотучы Есипов студентларга афишаны театр конторасыннан алырга рөхсәт итә башлады. Плавильщиковның уены миңа театр сәнгатендә яңа дөнья ачты...»

Аксаков һәм аның иптәшләре Плавильщиковның уйнавын шулкадәр яраталар, хәтта, аңарга охшарга тырышып, үзләре дә спектакльләр куя башлыйлар. Студентлар йоклый торган бүлмәләрнең берсендә Веревкинның «Так и должно» («Шулай тиеш») исемле комедиясен һәм Сумароковның «Приданое обманом» («Ялган бирнә») исемле пьесасын уйныйлар. Аларның уеннарын тамашачылар бик хуплап каршы ала. Ул спектакльләрдә Сережа төп рольләрне башкара. Аннары, «тәртипләре әйбәт булган өчен бүләк йөзеннән», попечитель студентларга университет бинасында сәхнәләр куеп, пәрдәләр элеп театр уйный башларга рөхсәт итә. Шуннан соң тотрыклы театраль труппа төзелә һәм аның җитәкчесе итеп бертавыштан Сережа Аксаков сайлана. Сережа театр өлкәсендә шундый тырышып эшләп йөри ки, рольләрне әйбәт башкаруына хөрмәт йөзеннән, Есипов аңа хәтта спектакльләргә йөрү өчен үз театрындагы бер креслоны да бүләк итә.

1806 елның 17 декабрендә Аксаков Ибраһимов оештырган әдәби түгәрәккә кертүне үтенеп гариза бирә. «Зима» («Кыш»), «К соловью» («Сандугачка») исемле шигырьләрен китерә һәм түгәрәккә член итеп алына.

Театр һәм поэзия белән мавыгудан тыш, Аксаков Казанда укыган елларында бөҗәкләр коллекциясе җыю белән дә шөгыльләнә. Буш вакыты булган саен ул үзенең дусты А. Панаев белән бергәләп Казан бакчаларында, шәһәр тирәсендәге болыннарда күбәләкләр җыеп йөри.

Әти-әниләренең киңәше буенча, Петербургта хезмәткә урнашу нияте белән, 1807 елда Аксаков Казан университетыннан китәргә гариза яза. Әти-әнисенең сүзен тыңлап, китәргә ризалык бирсә дә, Казан университетыннан аерылу Сережага бик читен була. Университет белән хушлашкан вакытын «Истәлекләр»ендә ул менә ничек итеп сурәтли: «Үзара кочаклашып, без барлык аудиторияләрне, бүлмәләрне һәм залларны йөреп чыктык. Аннары озак итеп кочаклашып һәм үбешеп тордык. Бөтенләйгә хушлашып, студентлар һәм хәтта гимназистлар да мине озатырга ишек төбенә чыктылар. Мин баскычтан акрын гына төштем. Кыен һәм бик күңелсез иде миңа. Мин борылып тагын бер мәртәбә иптәшләремә, университет бинасына карадым һәм йөгерә-атлый китеп бардым...»

Сергей Тимофеевич Аксаков Казанда укыган елларын гомере буена онытмый һәм һәрвакыт сагынып, хөрмәт белән искә ала. «Минем күңелемдә сакланган барлык яхшылыклар өчен, мин үземне миңа ул яхшылыкларны биргән гимназиягә, университетка, иҗтимагый фәннәргә бурычлы дип саныйм»,— ди ул. (Аксаков. Воспоминания. Собр. соч., в 4-х томах. Т. 2, Москва, 1955 г.)

С. Т. Аксаков Казанда укыганда фатирда торган йорт хәзер дә исән әле. Ул — Карл Маркс урамындагы 57 нче йорт.

# БӘЛӘКӘЙ РЕЦЕНЗИЯЛӘР

**Х. Хәйри. ПОИСКИ И СВЕРШЕНИЯ. Рус телендә. Казан. 1970 ел.**

Әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче Хәсән Хәйринең юбилей көннәрендә дөньяга чыккан яңа китабы соңгы ун ел эчендә татар совет әдәбияты узган юлны яктыртуга багышланган.

Пропагандистларга һәм агитаторларга, шулай ук киң катлау укучыларга адресланган ул китап «Уңай традицияләрне үстереп...» дип исемләнгән кереш бүлек белән ачыла. Әдәбиятыбыз узган зур юлга экскурс рәвешендә язылган әлеге бүлектә, кыскача гына булса да, революциягә кадәрге уңай традицияләргә тукталып узыла һәм татар совет әдәбиятының төп үсеш этаплары күздән кичерелә. «Яңа чикләрдә» («На новых рубежах») дигән икенче бүлек бүгенге әдәби хәрәкәткә гомуми күзәтү төсендә язылган. Күп санлы фактларга һәм мисалларга таянып, автор партиянең XX съездыннан соң әдәбият-сәнгать өлкәсендә барлыкка килгән үзгәрешләр, сан һәм сыйфат яңарышлары турында сөйли.

Китапның шуннан соңгы бүлекләрендә татар совет әдәбиятының аерым жанрлары тикшерелә. Һәр бүлек нинди дә булса конкрет жанрга багышланган. «Эпик киңлеккә омтылу» («Стремление к эпической широте») дип исемләнгән бүлектә, мәсәлән, прозаиклар иҗаты, соңгы ун ел эчендә дөньяга чыккан роман-повестьлар, хикәяләр һәм очерклар тикшерелә.

«Шигъри талантларның күп төрлелеге» дигән бүлек, исеменнән үк күренгәнчә, поэзия өлкәсендәге яңа тенденцияләрне күзәтү максаты белән язылган. «Драматургларның эзләнүләре» дигәнендә сүз сәхнә әсәрләре турында бара, «Иҗади дуслык» исемле соңгы бүлек татар һәм рус әдәбиятларының үзара бәйләнешен тикшерүгә, шулай ук әдәби тәрҗемә мәсьәләләренә багышланган.

Шул рәвешчә, автор әдәбиятның барлык тармакларын колачлап алырга, соңгы ун ел эчендәге әдәби хәрәкәтнең тулы картинасын күз алдына бастырырга омтыла. Һәм ул теге яки бу язучы иҗаты, аның аерым әсәрләре хакында кызыклы гына фикерләр әйтә, татар совет әдәбиятындагы төп жанрларга (проза, поэзия, драматургия) шактый тепле, әтрафлы бәя бирә, матур-матур гомумиләштерүләр ясый.

Дөрес, китаптагы барлык бүлекләр дә бер югарылыкта язылмаган. Тәнкыйтьче һәм әдәбият галиме буларак, Хәсән Хәйри — күбрәк проза әдәбиятын һәм поэзияне өйрәнү белән шөгыльләнгән кеше. Үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, аерым бәхәсле урыннары булуга да карамастан, «Эпик киңлеккә омтылыш» һәм «Шигъри талантларның күп төрлелеге» дигән бүлекләр уңышлырак та, тирәнрәк тә эшләнгән. Ә драматургиягә багышланган бүлек турында исә алай әйтеп булмый.

Җыентыктагы кайбер бүлекләр таркаурак язылган, кабатлаулар байтак очрый. Редактор үз эшенә игътибарлырак һәм таләпчәнрәк караган очракта (китапның редакторы — И. Ф. Киндер), алардан котылу әллә ни кыен булмас иде, билгеле. Редактор һәм корректорларның игътибарсызлыгы аркасында киткән башка төрле хаталар да очрый. Яшь шагыйрь Рәдиф Гатауллин, мәсәлән, «Г. Гатауллин» дип (55 бит), ә Рөстәм Мингалимов — «Г. Мингалимов» дип (68 бит) ялгыш басылган һ. б.

Әмма, өнә шундый характердагы кайбер кимчелекләре булуга да карамастан, тулаем алганда, китап уңай тәэсир калдыра. Автор кирәкле һәм мактаулы эш башкарган.

«Эзләнүләр һәм ачышлар» исемле бу китап татар совет әдәбиятының бүгенге хәле һәм торышы белән кызыксынучы һәр кеше өчен файдалы кулланма булачак.

**М. Хәбибуллин. ҖИДЕ ЮЛ ЧАТЫНДА. Повесть, хикәяләр. Казан. 1969 ел.**

Җиде юл чатында... Яшь прозаик Мөсәгыйт Хәбибуллинның беренче җыентыгына кергән яңа повесте әнә шулай атала. Һәм

чыннан да, әсәрнең төп герое Әнрүсә, мәстәкыйль тормыш юлына чыгып, шатлык-кайгылар һәм газап-сөенечләр белән тулы зур дөнья белән күзгә-күз очрашкач, жиде юл чатындагы кеше кебек, бер мәлгә аптырап, югалып калгандай була.

Аптырамаслык та түгел бит, әле унҗидене генә тутырып килгән яшь кыз җилкәсенә берьюлы күпме борчу-мәшәкать өелә. Һич тә уйламаганда-көтмәгәндә сөекле әнисе үлеп китә. Кыз үзен бик үк өнәп бетермәгән, кырыс табигатьле әтисе карамагында яши башлый. Дөресрәге, дөнья мәшәкатьләреннән читтәрәк йөргән, вакытын күбрәк шау-шулы мәҗлесләргә йөреп, дус-ишләр даирәсендә уздырырга яраткан әти кеше үзе Әнрүсә кулына кала...

Мәктәптә Әнрүсәне җырчы артисткабыз дип йөртәләр. Заманында ул Казан хәтле Казанга барып җырлаган, хәтта бүләкләр алып кайткан кеше, мәктәпне тәмамлауга артистка булырга хыяллана. Ләкин кызның тормыштагы шушы иң зур теләге дә чәлпәрәмә килә. Аңа ике сүз дә әйтми торган роль бирәләр, әмма шуны да рәтләп уйный алмый. Әллә каушый, әллә куркып кала. Ул да түгел, аларны үги әниләре Мөнирә ханым ташлап китә, әтисе эчәргә салыша. Кызның баш өстендә тагын болытлар куера...

Күпмедер вакытлар нишләргә белми аптырап йөргәннән соң, Әнрүсә Сабитова, ниһаять, ныклы бер карарга килә: ул эшкә керергә тиеш, бу кыен хәлдән аны бары тик эш, хезмәт кенә коткарып калачак. Һәм ул нефтьне судан, тоздан чистарта торган цехка замерщица булып эшкә урнаша. Күп тә үтми, үзенең сагыш-газаплары белән беренче мәхәббәт килә, кызның йөрәгенә шаян-җор телле, шамбы балыгыдай шома, ялтырап торган тыгыз кара тәнле Вәсил исемле егет килеп керә. Шулай Әнрүсә тормышта үз урынын тапкандай була, ул һәртөрле шик-шөбһәләрдән арынып, тынычланып кала.

Ләкин тыныч кына, киноларга, танцы кичәләренә йөреп кенә яшәп булмый икән шул. Тормыш кыз алдына яңадан-яңа мәсьәләләр куя тора. Һәрберсе турында уйлан, һәрберсенә җавап тап: Әнрүсәне үз итеп, якын итеп йөргән Ләйсән апасы әнә ирен ташлап китә. Дөрес эшлиме ул?.. Цехтагы эшләр дә, ул уйлаганча, шома, матур гына бармый икән бит. План үтибез дип, халык милкен әрәм-шәрәм итүләргә юл куела икән. Әнрүсә нишләргә тиеш?.. Кыен хәлләрдә кала-кала, тормышның шундый четрекле яклары белән очраша-очраша Әнрүсәнең характеры ныгый, дөньяга карашы формалаша.

Шушы кечкенә генә повестьта Әнрүсәдән тыш та әллә ничә образ бар: әтисе Галим, Мөнирә ханым, Вәсил, Нажия, Ләйсән, Сальма, Фатих Гафиятович, Айхәл, Марс һ. б. һәркайсының диярлек үз йөзе, үз характеры бар. Күбесе җанлы кеше булырак хәтердә кала. Бер сүз белән әйткәндә, яшь автор шактый кызыклы, заманча яңгырашлы әйбәт әсәр иҗат иткән.

Тик ахырга таба М. Хәбибуллин бик кызулый, укучыларны тынычландырырга ашыга төшкән кебек. Күтәрелгән мәсьәләләрнең байтагы, хәл ителмәгән килеш, «онытылып» кала. Автор безнең игътибарны мәхәббәт, гаилә эчендәге туганлык мөнәсәбәтләре тирәсенә генә тупларга тырыша. Нәтиҗәдә шактый киң сулыш белән башланып киткән повесть үзеннән-үзе кысылып, тараеп тәмамлана.

«Җиде юл чатында» исемле повестьтан тыш, җыентыкка тагын «Чын төш» һәм «Сәер мәхәббәт» исемле ике хикәя дә урнаштырылган. Болай аларның һәркайсы әйбәт тәэсир калдыра. Шулай да «Чын төш» дигәне материалының зурлыгы, характерларының нигезле эшләнүе белән, аерылыбрак тора.

**Мөхәммәт Садыйков. ЗӘҢГӘР ОФЫКЛАР. Шигырьләр. Татарстан китап нәшрияты. 1970**

Яшь шагыйрь Мөхәммәт Садыйковның исеме поэзия сөючеләргә моннан өч ел элек «Беренче карлыгачлар» сериясендә басылган җыентыгы аша таныш. Ул җыентыкка кергән шигырьләр яшь әдипнең каләмдәшләре һәм укучылар тарафыннан уңай яктан бәяләнде. Беренче иҗат уңышлары белән канатланган Мөхәммәт күптән түгел икенче җыентыгын бастырып чыгарды. «Зәңгәр офыклар» дип аталган бу җыентыгына аның кырыклап шигыре урнаштырылган. Җыентыкны ачып җибәргән «Кинән бер, күңелем» шигырендә шагыйрь Кокушкинода Ильич яшәгән музей-йортка килгәч туган кичерешләре белән уртаклаша, дөнья халкының бөек юлбашчыга карата булган кайнар мәхәббәте турында сөйли. Шигырь җыйнак һәм гади итеп язылган түбәндәге юллар белән тәмамлана:

Мин геҗәме? Аны күрер өчен
Ярты дөнья монда килгәндәр.
Ленин әшенең җиңәчәген уйлап
Киңәш бер, күңелем, киңәш бер.

Туп та, атом да җуя алмаслык Ленин имзалары турындагы шигырьне дә тирән дулкынлану һәм горурлану хисе белән укыйсың. Нибары уналты юлдан торган шушы кыска гына шигырендә автор Ленин идеяләренең планетага көннән-көн киңрәк колач белән җәелә баруын күз алдына шактый тулы китереп бастыра.

Мөхәммәт Садыйков гомумән кыска язарга ярата. Аның күпчелек шигырьләре өч-дүрт строфадан артмый. Кыскалык исә үз нәүбәтендә шагыйрьдән моңарчы әле башкалар тарафыннан кабатланмаган яңа поэтик детальләр эзләп табуны, бүгенге таләпчән укучыны ышандырырлык көчкә ия булган сүзләр сайлап алуны сорый. М. Садыйков үзенең иҗатында әнә шул таләпләрдән чыгып эш итәргә тырыша. «Минем мәхәббәтем», «Яшәү гимным», «Малай чакка кайту», «Төнге басу буйлап», «Поши», «Осталар» һәм «Балыкчы» шигырьләрен укыганда яшь әдипнең үз тавышын, үз моңын ишетәсең. Бабаларыбызның җуелмас эзе калган җир-туфракның һичнәрсәгә алыштыргысыз икәнлеген белдереп, «Минем мәхәббәтем» шигырендә ул менә болай ди:

Җиргә нәселем салган урак тамга
Гасырлардан килә, ерактан...
Шул мәхәббәт алтын башак булып
Ватанымның гербын ураткан.

Мондый уңышлы юлларны башка шигырьләрдән дә китерергә мөмкин булыр иде. Ләкин, шуның белән беррәттән, «Зәңгәр офыклар» җыентыгында укучыга инде әллә кайчан таныш булган фикерләрне тагын бер тапкыр кабатлап чыгуга корылган шигырьләр дә юк түгел. «Тракторчы», «Сабан туен көтеп», «Йорт яме килен беләң», «Сугыш ярасы», «Аланнарда йөрим», «Урал эшчеләре җыры» шигырьләре, мәсәлән, поэзиябезгә беринчи дә яңалык алып килми. Кайбер шигырьләрен ахырынача эшләп бетерергә Мөхәммәт Садыйковның түземлеге җитми, аларны ул ярым-йорты килеш калдыра. Менә шуңа күрә дә «Илизага», «Төнге җәйләүдә», «Яшәү көче», «Язлар язга охшамый», «Кич утырып кызлар чигү чигә», «Урнашу» кебек әйбәт фикерле шигырьләр җыентыкка каралама хәлендә килеп кергәннәр. Киләчәктә Мөхәммәт Садыйковтан шигырьнең техник эшләнешенә дә игътибарлырак булу сорала. Югыйсә, хәзергә әле аның шигырьләрендә ритмик яктан кытыршы урыннар, «үсентеләр-күзәтәләр», «тәлгәшмиләш», «бу чаклы-чәчәкне», «урак ай-урлаган», «тезләре-сызлавы» шикелле ятышсыз рифмалар шактый еш очрый. Алдагы җыентыкларында яшь шагыйрьнең мондый кимчелекләрдән котылуын күрәсе килә.

**ТЫЛСЫМЛЫ ТЫРЫС. Хикәяләр, шигырьләр, әкиятләр. Татарстан китап нәшрияты. 1970.**

Татарстан китап нәшрияты, мәктәпкәчә яшьтәге балаларга атап, кечкенә китапчыклар җыелмасы бастырып чыгарды. Китапны сатудан килгән акча тынычлык фондына биреләчәк.

«Тылсымлы тырыс» дип исемләнгән бу җыелмага язучыларыбызның балаларга багышланып язылган кыска-кыска хикәяләре, әкиятләре, шигырьләре тупланган. Бу китапчыклар арасында В. Маяковскийның «Нәрсә ул яхшы, нәрсә ул начар», Бари Рәхмәтнең «Сара-врач», Әхмәт Исхакның «Елка», Әминә Бикчәнтәеваның «Дәү әнием», Зәки Нуриның «Без инде хәзер зурлар», Шәүкәт Галиевнең «Камырша» шигырьләре, Г. Тукайның «Кәҗә белән сарык әкияте», А. Алишның «Утлы йомырка», Җ. Тәрҗемановның «Ябалак белән тавык» әкиятләре, И. Туктаровның «Җир җиләге», А. Әхмәтнең «Баһау белән бозау» хикәяләре бар. Аларның барысы да диярлек бала кызыксынып тыңларлык гади сюжетка корылганнар һәм аңлаешлы җиңел тел белән язылганнар. Бу әсәрләрнең күбесе бала күңелендә туган җирне ярату, аның табигатенә соклану, өлкәннәрне олылау, ихтирам итү, бәләкәйдән үк тыйнак һәм эш сөючән булып үсү тойгысы тәрбияли.

Җыелмадагы китапчыкларга төрле темаларга язылган шигъри һәм чәчмә әсәрләрнең сайлап алынуы кечкенәләргә үз тормышларын якыннанрак танып белергә ярдәм итә. А. Алишның «Утлы йомырка» хикәясендә, мәсәлән, әбисе алдында үз гаебен үзе ачып салган малайның кичерешләре бирелә. Хикәядә алынган вакыйганың беренче заттан сөйләнүе аның тәэсир көчен тагын да арттыра. Хикәянең чишелешен тынын кысып көткән бала аның соңгы юлларын тыңлаганда иркен сулап куя:

«Әби көлә-көлә чәй ясый: — Әй, җүләр, җүләр, йомырканың утлы булганын кайчан күргәнең бар? Тик, зурлардан сорамыйча, әйберга тияргә ярамый,— ди.

Ә мин тагын кып-кызыл булам. Нигә

сөйли торгандыр бу әби? Әйтерсең, инде аны мин хәзер белмим».

Балаларның яраткан язучысы Б. Рәхмәтнең «Сара-врач», Ә. Бикчәнтәеваның «Дәү әнием» шигырьләре кечкенәләрдә хезмәткә мәхәббәт тәрбияли. А. Әхмәтнең «Бәһау белән бозау» хикәясендә һәм Ш. Галиевнең «Камырша» шигырендә исә шуклыкның, урынсыз шаяруның, мактанчыклыкның яхшылыкка илтмәве ышандырырлык итеп тасвирлана. З. Нуриның «Без инде хәзер зурлар» шигыре, кулларына әлифба тотып, беренче тапкыр мәктәп ишеген ачып керүче балаларның шатлык хисләрен чагылдыруга багышланган.

Уйныйлар битте нурлар:
Әлифба алды куллар!
Мәктәпкә илтә юллар.
Без инде хәзер зурлар.

Сүз ахырында әлеге китапчыклар җыелмасының исеменә дә тукталып үтәсе килә. Кәгазь тартма эченә тупланып чыгарылса да, ул ни өчендер «Тылсымлы тырыс» дип аталган. Безнеңчә, аны «Тылсымлы тартма» дип атаганда уңышлырак чыгар иде, ул чагында аның исеме дә җисеменә туры килгән булыр иде. Мондый җыелмаларны бастырып чыгару киләчәктә дә күздә тотылса, бәлки аның исемен үзгәртү турында да уйлап карарга кирәктер.

**Саҗидә Сөләйманова. ЯШӘҮ ХАКЫ. Шигырьләр. Татарстан китап нәшрияты. 1970**

Саҗидә Сөләйманова — безнең шагыйрәләребез арасында иң актив иҗат итүчеләрнең берсе. Аның хисләргә бай, тирән мәгънәле шигырьләре вакытлы матбугат битләрендә дә, аерым җыентыкларга тупланып та соңгы елларда әледән-әле басылып тора. Быел укучыларга ул «Яшәү хакы» исемле яңа җыентыгын тәкъдим итте. Бу китапка кергән шигырьләрнең күбесендә лирик герой ил-җир язмышы, кешенең тормыштагы урыны, аның тынгысыз күңелен билән алган бик күп нәрсәләр турында уйлана. Шагыйрә исә, аның уйлануларына йомгак ясагандай, һәркемнең күңеленә кереп калырлык нинди дә булса бер поэтик фикер әйтүне үзенең бурычы итеп саный:

Тормыш булмый көю-сөенүсез,
Яшәү авыр сөелү-сөюсез.
Караңгыда якты караш кирәк,
Өшегәндә кирәк җылы сүз.

«Тормыш булмый көю-сөенүсез...» дип башланган шигырьдәге әлеге фикер «Ел әйләнә...», «Туган җирем, әчкән суым!», «Чуерташ», «Мәкер», «Язгы күкнең йөзә көяшлы» шигырьләрендә тагын да көчәя, үстерелә төшә.

Саҗидә Сөләйманова үзенең шигырьләрендә бүгенге көнгә кагылышлы төрле темаларга мөрәҗәгать итә. Тегеләй яки бу шигырендә алынган һәр теманы ул үзенчә чишәргә, укучыга аны үзенә генә хас булган поэтик алымнар, башкалар тарафыннан кабатланмаган поэтик образлар аша җиткерергә омтыла. «Әй, солдатлар тигез, кыю басып...» шигырендә иңбашларына мылтык асып, аякларына кирза итеп киеп үткән солдатлар артыннан ияргән сабыйларны карап калган ананың кичерешләре бирелә. «Утлы еллар җырын» җырлап узган солдатларны күргән саен аның җаны борчыла, аларга карап ул бер үк сүзләрне кабатлый:

Яңартмагыз утлы еллар җырын,
Улым үсеп килә, улым.

Ләкин шагыйрә заман шау-шуын ишетмәмешкә салышырга, җирдә барган аяусыз көрәшкә күз йомып карарга өндәми. «Горур җырлар читлекләрне вата» шигырендә ул ата-бабаларыбыз тапшырган эстафетаны күтәреп баручыларны көрәшчеләрнең алгы сафында атларга, аларның исеменә тугрылыклы булып калырга чакыра:

Мылтык көпшәсенә чәчкә кадап,
Яңа сафлар җырлап узалар.
Байракларга йөрәк каны тамган,
Онытмагыз!
Онытырга кушмый Мусалар!

Моңарчы басылып чыккан китапларда гы кебек үк, шагыйрәнең бу җыентыгында да яшьлек, мәхәббәт, кавышу һәм аерылышу турында язылган шигырьләргә дә шактый киң урын бирелгән. Ләкин, ачыктан-ачык әйтергә кирәк, ул шигырьләрендә Саҗидә үз-үзен кабатлый, тематик яктан артык вакланa, бертөрлелектән котылып бетә алмый. Күрәсең, бергә тупланып басылып чыгачак шигырьләрне сайлаганда җыентыкның редакторы да бераз талымсызлык күрсәткән. Безнең карашыбызча, Саҗидә Сөләйманова андый ташламаларга һич тә мохтаҗ түгел. Җыентыктагы күпчелек шигырьләрнең тормышны, вакыйгаларны яхшы белеп, укучы күңелен дулкынландырырлык итеп язылулары әнә шул хакта — шагыйрәнең үз иҗатындагы вак-төяк кимчелекләрдән бик җиңел арына алырлык мөмкинлеккә ия булуы хакында сөйли.

## *ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ...*

**Радик Исаев**

# АЛМА БАБАЙ



Җәйге матур иртә. Өстенә алма чәчкәседәй ап-ак күлмәк кигән, җиңнәрен терсәгенә кадәр сызганып җибәргән Шәйдулла бабай алма бакчасында утыра.

Менә тиздән шау-гөр килеп бакчага балалар җыелыр. Алар, Шәйдулла бабайга сәламне алданрак бирим, дип, берсен-берсе бүлдерә-бүлдерә: «Исәнме, Алма бабай?» — диярләр.

— Их, балачак! Нинди гүзәл, бәхетле чак! — диде ул, кояш нурларына күзләрен кыса төшеп.

Авырткан билен кузгатмас өчен, тамырлары кабарып торган куллары белән тезләренә таянып, аягына басты. Күзләренә килгән яшь бөртекләрен тыя алмыйча, балалардан көнләшү кыяфәтендә, «Мин сездән аз гына калкурак чагымда сабан сөрергә йөрдем. Җитмәсә, төннәрен ат сакларга җибәрәләр иде»,— дип үзалдына сөйләнеп куйды.

Картның уйларын Гарифә әбинең чәй эчәргә чакыруы бүлде.

Гарифә әби чәйне ясап, авыр гәүдәсе белән мендәргә утыргач, гадәтенчә, авыл яңалыкларын сөйләргә кереште.

— Сепаратта халык шау-гөр килә. Барысы да Якуп малае турында сөйлиләр,— диде ул ачу белән.

— Нәрсә, карчык, кемне тиргисең? — дип сорады Шәйдулла бабай берни аңламыйча.

— Якуп малаен әйтәм. Әтисен алачыкта тимер басып үтерде бит. Шуның малае колхозга акча биргән, ди. Имеш, ясле салдыра, ди. Ул йортны безнең тирәгә салмакчы булалар икән.

— Шофер Хәнифне әйтәсеңме? — диде карт.— Булыр, ул бик уңган егет.

— Һи, аның уңганлыгына... Беркөн мине базарга утыртып алып барды. Кайтканда да утыртырсың дип, акча, алма биреп карадым. Алмады. Менә шул кеше хәзер әнә ни эшли. Алтын заемга акча чыккан диме шунда?

Бу хәбәрне ишеткәч, Шәйдулла бабай, ясаган чәен дә эчеп бетермичә, урыныннан кузгалды һәм:

— Бик шәп булган, менә ичмасам егетлек! Әгәр чын була калса, мин дә алма бакчамны бирәм,— дип әйтеп салды.

Бу сүздән соң Гарифә әби кулындагы чынаягын чак төшереп җибәрмәде. Тәүбә әстәгъфирулла, алла сакласын дип, керпе өстенә утыргандай, сикереп торды. Шәйдулла бабайның иңбашына авыр, симез кулларын салып:

— Юләрләнмә, карткаем, юләрләнмә, бер үк кеше алдында әйтә күрмә, аннан башка да бөтенесенең күзе безнең бакчада,— дип ялвара башлады.

Шәйдулла бабай Гарифә әбинең риза булмаячагын алдан ук белә иде. Шуңа күрә ул эшне үзем исән чакта хәл итим, дип күптәннән уйланып йөрде. Сигез дистәне куып баргач, гомер дә әллә ни калмагандыр. Ашыгырга, тизрәк Сәвит белән киңәшергә кирәк, дигән уйга килде.

Авыл Советы председателе янында Хәниф тә бар иде. Шәйдулла бабайга йомшак диваннан урын тәкъдим иттеләр. Ул, утыргач, таягын тоткан кулына күкрәген куйды да Хәнифкә карады.

— Дөресме, балам, сине балалар бакчасы салдырырга акча биргән дип сөйлиләр,— диде.

Хәниф, көлемсерәп:

— Исәп шулайрак, бабакай. Менә шул бакчаны кая салу хакында киңәшләшә идек.

Шәйдулла бабай, утырган урыныннан шуышып, өстәлгә якынрак килде.

— Дөрес, дисең инде, алайса. Бик зур эш эшлисең, улым, зур эш,— диде ул, яшәреп киткәндәй көләч йөз белән.— Кая салырга уйлыйсыз соң?

Бүлмәдәгеләр тынып калды. Аның нидер әйтүен көттеләрме, әллә бабайга шулай тоелдымы?

— Урын ягына килсәк, балалар, мин аны сезгә табышуда ярдәм итәм. Минем алма бакчасы кемгә ярамаслык? Әнә шул бакчаның аргы башына салырга кирәк аны. Мин инде алма бакчамны күптәннән колхоз файдасына бирергә ниятләп йөри идем. Сабыйларга да булгач...

Гарифә әби Шәйдулла бабайны ачулы каршылады.

— Олыгая килә кеше акылсызлана дип әйтәләр, растыр, ахры. Күрәм, бакчаң белән хушлашкансыңдыр. Тегеләрен әйтәм, нигез ташыңны бирәм дисәң дә, каршы килмәсләр. Тәки гөрләп торган бакчабыздан яздырдылар. И ходаем, картайган көнемдә бар икән күрәселәрем! — дип үксеп еларга ук керешә. Бу көннәрне ул картына чәй дә эчермәде дисәк тә була. Каз-үрдәк итләре салып пешергән аш та, алма бәлешләре дә әзерләнмәде. Кичләрен урын да Шәйдулла бабайга мич казнасы буена, идәнгә генә түшәлде.

Көннәрдән бер көнне, Шәйдулла бабайны тагын да куркыту нияте белән, Гарифә әби аерылышу турында сүз кузгатты. Өйгә зур чаршау корып, картын олы якка чыгудан мәхрүм итте. Бабай ярты гасыр бергә гомер иткән карчыгыннан моны һич тә көтмәгән иде. Ул, тырпаеп торган мыекларын тешсез уртына кысып:

— Вон, зобаный, үзең чыгып кит, күземә күренәсе булма. Монда барысы да мин казынып тапкан мал,— дип тузына башлады.

Бергә гомер иткән картының холкын белгән Гарифә әби:

— Шаяртып кына, сине сынап кына, юләрләнмә, карткаем,— дип ялагайланып сырышырга теләде.

— Юк инде, син бер тапкыр шаяртып, «Казан Шәйдулла» дигән исем бирдерден миңа! — диде бабай, карчыгының авыр кулларын үзенең иңбашыннан алып.— Русча «котел» диделәр, хәтерендәме?!

«Казан Шәйдулла» дигән кушаматны ул колхоз төзелгән елларны алды. Яңа оешкан артельнең чәчү орлыгы житешми иде. Урта хәлле крестьяннарга идарәдән мөрәҗәгать итеп, чәчүлек орлык сорадылар. Ни барын кереп алудан куркып, Гарифә әби төн чыкканчы кырык потлап ашлыгын яшерде. Тик бер казанга тутырылган чүп-чар гына чоланда торып калды. Менә шул казанны күтәреп, мескен бүрек киеп, Шәйдулла бабай чәчү мәйданына килде.

— Нинди оятсызлык эшләдем мин ул елларны син комсыз аркасында! Юк инде, бакча белән андый хәл булмас!

Эшнең кая таба барганын сизгәч, карчык бабайны яхшылык белән җинәргә уйлады. Ул самовар утыртты. Өстәлгә тәм-төмнәр китереп куйды. Аннан ягымлы тавыш белән:

— Бигрәк үз сүзле, үгез күзле син, картым. Бакча турында әйтәм, алма сатып кына да ел саен мең сумлап дахут алабыз. Ә син аны бер тиенсезгә бирмәкче буласың.

Шәйдулла бабай чынаягын каплап куйды да тәрәзә буендагы кызыл сандыктан саклык кенәгәләрен алды. Үзе җай гына өстәл башындагы урындыкка утыргач, карчыгына пружиналы караваттан урын күрсәтте.

— Безнең бит үз гомеребезгә җитәрлек акчабыз, кием-салымыбыз, икмәгебез бар. Җитмәсә утар тутырып мал асрыйбыз. Ул кош-кортның күплеген әйтеп тә торасы юк. Ә соң кемебез бар безнең? Берәр балабыз гына да юк бит ичмасам. Нигә безгә шул кадәр мал-дәүләт?!

Бабай, аскы күз кабагын тавык сыман кыса төшеп, Гарифә әбигә карап алды да сүзен дәвам итте.

— Балалар бакчасын монда төзесәләр, үзебез дөнья куйганнан соң да урыныбыз истәлекле булып калачак. Аннан сине бөркем дә зобаный карчык димәс, депутатларныкы кебек итеп, кәнсәләргә кәртечкеңне дә куярлар,— диде.

Гарифә әби йомшый төште.

— Тукта әле, карт, азрак уйлашыйк, киңәш итешик. Уен түгел бит, бакча тикле бакча бирәбез. Бәлки, колхоз бәрәңге җиребезне арттырыр.

Шәйдулла бабай, кулын селтәп, урыныннан кузгалды. Ул, үзенең уйларын ныгыту өченме, койма буендагы эскәмиягә чыгып утырды. Әле генә яңгыр явып үтүгә карамастан, көн кичкә авышса да, кояш кыздыра. Кояш нурлары күңелгә рәхәтлек бирә, яңа хисләр уята иде.

Көтмәгәндә Шәйдулла бабайның каршына бер төркем балалар килеп чыкты. Алар, «Алма бабай, Алма бабай!» дип бал кортларыдай гөжләп, Шәйдулла картны уратып алдылар.

Бу хәлне күргәч, Гарифә әби аягына да киеп тормыйча урамга чыкты. Башлап ул, капкасын танымаган сарык бәрәне шикелле, уңгасулга карап куйды. Аннан бер адым алга, икене артка чикте. Каршыдагы балалар аңа зур бәйләм чәчәкне хәтерләттеләр.

Карчык колачын җәйде. Аннан, җим савыты күргән үрдәктәй, алга омтылды.

— Кызларым, улларым!..

— Алма әби!

— Алма әби!..

Гомере буе бала дип хыялланган карчыкның уйлары тормышка ашты. Ул балаларны ияртеп алма бакчасына таба атлады.

# ҮЗ БАШЫНА ТӨШСӘ

Берчак Мөхәммәтгали бабай үзенең авырып торуыннан зарланып алды.

— Алла әше, Мөхәммәтгали,— диде хәзрәтебез.— Аллаһе тәгалә яраткан кешесенә чир бирермен дигән. Сабыр ит, үтеп китәр әле. Өшкертеп алсаң да зыян итмәс.

Нурисафа әби белән дә аларның сүзе шул чамалы булды. Карчык сүз уңаенда бозауларының зыянлавын әйткәч:

— Нишлисең, җиңги, алла казасыннан котылып булмый инде,— диде ул.

— Шулай шул,— диде карчык йөзләрен сытып.— Алласын да әйтер идем инде. Бер ятим карчыкка каныкмаса. Үткән ел җәй уртасында кәҗәмнең аягы сынган иде. Бәйләм белән үзенә печән ташып ашаттым...

— Борчылма, җиңги,— диде хәзрәт чак кына да төсен үзгәртмичә. Аллаһе тәгалә бер җирдән алса, икенче җирдән китереп тә бирә ул.

— Соң, анысы шулай инде,— дигән булды Нурисафа әби.— Ләтәрәйгә кер юу машинасы чыккан иде... Бозавым башына булган икән. Бу алла дигәненә дә аптырарсың инде. Әзрәк чут-чамасың белсен иде. Бозавым бит ике йөз таңкәлек, ә кер юу машинасы?..

Барын да сөйләсәм, олы кешенең хәтере калыр. Сүзне озакка суздымыйча, үзем белән булган бер хәлне генә әйтәсем килә.

Бер көнне Гомәр хәзрәт безгә килеп керде. Исәнлек-саулык алганнан соң, җай гына сүз башлады.

— Сәлих энем, бер-ике чүмәләдәй печән бар иде. Шуны алып кайтыйк әле,— диде.

Мин дә олы кешенең үтенечен екмадым. Эштән соң печәнне төядек тә кайтырга чыктык. Авылга җитәрәк биек тау төшәргә туры килә иде. Шунда җиткәч:

— Мулла абзый, тотыныбрак утыр, машинаның тормозлары начар эшли, алла сакласын,— дидем.

— Син, Сәлих энем, аллага гына ышанып бетмә, үзең дә рульне нык тот,— диде бу.

Мин, мулланың башка вакытта бөтен бәла-казаны аллага сылтавын хәтергә алып, көлеп җибәрдем. Ә ул көлми, симез куллары белән чытырдап машинага ябышкан иде.

## Идрис Туктар

### Җөмләләр

Сөй дә, өйлән genәme? Өйлән дә, сөймә genәme?

Сөйми кавышуга караганда, сөеп аерылышу дөресрәк.

Начарлык артыннан кумасаң, яхшылык артыңнан калмас.

Күп булганга форсаты

Үсте аның корсагы.

Хакыйкатьне яшерү — ялганны яклау белән бер.

Дус-ишләргә таянуын таяныйк, әмма үз-үзебезне дә аямыйк.

Игелек күрсәтмәгән — игелек күрмәс.

Сүнә яшен «Әнә яшен!» дигәнче, үтә гомер «Менә яшим!» дигәнче.

Җырның җыртыгы юк, җыртыкның җыры юк.

Кашык күтәрергә ашыкма — төелерсең; эшләргә ашык — сөенерсең.

Кешеләр өчен бер дә борчылмаган кеше — кешеләрне иң борчыган кеше.

Шигырең проза булмасачы, прозаң проза булсачы; укучың риза булсачы.

Кайберәүләр кешедән күп игелек күрсәләр дә — аз күргән кебек, бик аз игелек күрсәтсәләр дә — күп күрсәткән кебекләр.

## СОВЕТ ТЮРКОЛОГЛАРЫНЫҢ IV БӨТЕНСОЮЗ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

Ленинградта Совет тюркологларының IV Бөтенсоюз конференциясе булып узды. Ул төрки халыклар әдәбияты үсешендә зур урын тоткан борынгы уйгур поэзиясенең күренекле әсәрләреннән «Котадгу Белек» («Бәхетле итүче белем») поэмасының язылуына 900 ел тулуга багышланган иде.

Конференция СССР Фәннәр Академиясенең член-корреспонденты Андрей Николаевич Кононовның кереш доклады белән ачылды. Өч көн буена барган бу зур фәнни мәҗлестә 60 тан артык доклад тыңланды. Докладчылар «Котадгу Белек» әсәренең күп төрки халыклар әдәбияты культурасы үсешенә һәм әдәби телләренең формалашуына зур йогынты ясаганлыгы турында сөйләделәр.

Конференциядә Казан галимнәре дә катнашты. Алар арасында Х. Госман, Л. Мәхмүтова, Х. Курбатов, Ш. Абилов һәм Я. Әхмәтгәрәевалар бар иде. В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты профессоры Хатип Госман «Йосыф Хас-Хаҗибның «Котадгу Белек» әсәренә кадәр булган борынгы поэзия үрнәкләре», СССР Фәннәр Академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Казан тел, әдәбият һәм тарих институтының өлкән гыйльми хезмәткәре Шакир Абилов «Урта гасыр болгар-татар әдәбиятында «Котадгу «Белек»нең урыны» дигән темалар буенча докладлар белән чыктылар. Казан галимнәренең бай фактик материалларга нигезләнгән тирән эчтәлекле докладлары конференциядә катнашучыларда зур кызыксыну тудырды һәм югары бәяләнде.

Конференциядә тыңланган һәм анда каралган мәсьәләләрдән чыгып, профессор А. Н. Кононов үзенең йомгаклау сүзендә союздаш һәм автономияле республикаларда тюркология фәненең нык адымнар белән үсә барганлыгын билгеләп үтте. Ул тюркология белгечләренең мондый вәкаләтле очрашуларын ел саен үткәрүне булдырып, тюркология фәнендәге зур проблемаларны хәл итә бару өчен көчләрне бергә туплап, кыюрак эшләргә чакырды.

Катнашучылар тюркологларның нәүбәттәге V Бөтенсоюз конференциясен Ленинградта үткәрергә дигән карар кабул иттеләр. Ул конференция угыз телләре мәсьәләләренә багышланачак.

## ӘДИП ИСТӘЛЕГЕНӘ

Шушы елның июль аенда Татарстан культура министрлыгы һәм Татарстан язучылар союзы идарәсе инициативалары белән әдәбиятыбызның мәшһүр классигы Галимҗан Ибраһимовның каберенә һәйкәл куелды. Һәйкәлне скульптор Рычков Ю. Л. ясаган. Түбәндә без шул һәйкәлнең рәсемен урнаштырабыз.




## ӨЧ ЭКСПЕДИЦИЯ

Шушы елның җәендә ТАССР сынлы сәнгать музее Оренбург өлкәсендәге татар районнарына фәнни-тикшеренү экспедициясе оештырды. Тарих фәннәре кандидаты Фуат Валиев җитәкчелегендәге ул экспедициянең максаты Оренбург өлкәсендә яшәүче татарлар арасындагы халык архитектурасы һәм халык сәнгате материалларын җыеп кайту иде. Нәтиҗә көтелгәннән дә әйбәтрәк бул-

ды: экспедиция членнары бик күп халык архитектурасы һәм сәнгате материаллары туплап кайттылар.



*Оренбург татарларының чигүле итекләре (XIX гасыр ахыры).*



*Касыйм шәһәрендәге 1467 елда корылган манара. Алгы планда XVIII гасыр уртасында салынган ике катлы мәчет.*

Музей хезмәткәрләре белән бергә, ул экспедициягә шагыйрь Рөстәм Кутуй да барган иде. Экспедиция членнары кичләрен җирле халык белән очрашулар үткәрделәр. Ф. Вәлиев татар халык архитектурасы һәм сәнгате буенча лекцияләр укыды, ә Р. Кутуй халыкка әдәбиятыбыз ирешкән уңышлар турында сөйләде, үзенең әсәрләрен укыды.

* * *

Шул ук музей РСФСР художниклары (Мәскәү) катнашы белән Татарстан районнарында да экспедиция үткәрде. Тарих фәннәре кандидаты Ф. Вәлиев җитәкчелек иткән ул экспедиция вакытында күп кенә халык сәнгате материаллары җыйнап кайтылды. Аннары ул материаллар Мәскәүгә СССР халыклары сәнгатенең зональ күргәзмәсенә озатылды. Күргәзмәгә җибәрелгән экспонатлар арасында татар ювелирлары (Балтач районы, Тәнәки авылы) ясаган әйберләр һәм Арча районы осталары тукыган һәм чиккән әйберләр дә бар.

* * *

Август аенда тарих фәннәре кандидаты Фуат Вәлиев җитәкчелегендәге экспедиция Рязань өлкәсендәге Касыйм татарлары яшәгән районнарда булып, шактый күп һәм кызыклы халык сәнгате һәм архитектурасы материаллары җыйнап кайтты. Хәзер Ф. Вәлиев шул экспедиция материаллары нигезендә «Казан утлары» журналы өчен мәкалә яза.

## КОНКУРС ЙОМГАКЛАРЫ

1969—1970 елларда басылган 70 мең исемдәге китапларның кайсысы художество оформлениесе һәм полиграфик башкарылуы ягыннан иң әйбәте булыр? Менә шул сорауга җавап бирер өчен, узган ел конкурс игълан ителгән иде. В. И. Ленинның тууына 100 ел тулуга багышлап үткәрелгән ул конкурста илебездәге барлык нәшриятлар һәм типографияләр дә катнашты. СССР Министрлар Советы каршындагы матбугат Комитеты шушы елның 29 июлендә үткәрелгән утырышында әлеге конкурска йомгак ясады. Нәтиҗәдә биш басма әйбәтләрнең дә әйбәте дип табылып, югары дәрәҗәле дипломга лаек булдылар. Алар: В. И. Ленинның 10 томлык сайланма әсәрләре китапханәчеге, «Ленин тарафыннан эшләнгән», «Синең исемең таңнар тудыра», «В. И. Ленин. Фотографияләр һәм кинокадрлар җыйналмасы» (Беренче том — «Фотографияләр») һәм «Тайга хөрмәте» исемле китаплар. Ул китаплар Политнәшрият, «Карта молдовеняскэ», «Сәнгать» нәшриятлары һәм Хабаровск китап нәшрияты тарафыннан әзерләнгәннәр һәм бастырып чыгарылганнар.

Унбер басмага һәм «Декоратив сәнгать», «Полиграфия» журналларына Иван Федоров исемендәге дипломнар бирелде. Шулардан тыш, тагын 275 китапка һәм 26 журналга да дипломнар бирелде. Бүләкләнүчеләр арасында Татарстан китап нәшрияты тарафыннан бастырып чыгарылган сигез китап та бар. Атап әйтсәк, ша-

гыйрь Сибгат Хәкимнең татар һәм рус телләрендә чыгарылган «Күнелем Ленин белән сөйләшә» исемле сувенир китабына (художнигы Т. Хажиәхмәтов), беренче класслар өчен «Татар теле» дәреслегенә (художниклары М. Григорьев, А. Садыйков, Э. Зарипов) икенче дәрәҗә дипломнар; Р. Нәфиковның «Революциягә беренче адым»ына (рус телендә, художнигы М. Семенов), «Казан татарлары орнаменты»на (художнигы И. Субаев) һәм «Татарстан» фотоальбомына (художнигы И. Әхмәдиев) кызыксындыру дипломнары бирелде. Г. Тукайның «Эш беткәч уйнарга ярый», Г. Мөхәммәтшиннның «Ак песи» исемле китапларына да полиграфия ягыннан яхшы эшләнгәннәре өчен икенче дәрәҗә дипломнар тапшырылды. Э. Миндубаевның «Транспорт һәм төягбушату эшләрен механизацияләү» (рус телендә) исемле китабы исә өченче дәрәҗә дипломга лаек булды.

## КҮРГӘЗМӘ УҢЫШЛЫ ҮТТЕ

Мәскәүдәге художниклар йортында «Сатира ут сызыгында» дип аталган күргәзмә үткәрелде. Индокитайдагы Америка агрессорларыннан һәм Якын Көнчыгыштагы Израил басып алучыларыннан бик ачы итеп көлгән карикатура һәм сатирик плакатлардан торган ул күргәзмәгә илебезнең егерме алты шәһәрендә яшәүче иң яхшы карикатурачыларның хезмәтләре куелган иде. Күргәзмәдә Казан художниклары эшләренә дә зур урын бирелде. Тугыз авторның (С. Әбдрәшитова, Л. Бочкова, Л. Ельковнч, Л. Насыйров, Б. Старчиков, И. Хантимиров, И. Әхмәдиев, Б. Бунь һәм Э. Гельмс) унбер хезмәте күрсәтелде. Күргәзмәгә куелган рәсемнәренең саны буенча шәһәребез художниклары Мәскәү һәм Ленинград художникларыннан кала өченче урында иделәр. Бу — куанычлы хәл. Димәк, безнең художникларыбыз политик карикатура һәм сатира өлкәсендә актив эшлиләр икән.

Шунысын да әйтергә кирәк, безнең художникларыбызның күргәзмәгә куелган хезмәтләре сыйфатлары ягыннан да йөз кызартырлык булмады. Аларны тамашачылар яратып карадылар һәм кайбер художникларның рәсемнәре «Крокодил» журналында бастыру өчен сайлап алынды.

## ЭЛЕМТӘ НЫГЫЙ

Монгол композиторларының чакыруы буенча, М. Җәлил исемендәге премия лауреаты, композитор Мирсәет Яруллин Монголиягә барып кайтты. Ул анда монгол композиторларының иҗаты белән танышты һәм монгол дусларга татар композиторларының иҗатлары турында сөйләде, үзенең кайбер әсәрләрен башкарып күрсәтте. Иҗади элемтәне тагын да ныгытуны күздә тотып, монгол һәм татар композиторлары киләчәктә үзара җырлар алмашып торырга булдылар.

## МАТБУГАТ ЙОРТЫНДА ОЧРАШУ

Германия Демократик Республикасыннан кунакка килгән җәмәгать эшлеклесе Винтерер Георг 14 августта Матбугат йортында татар язучылары һәм журналистлары белән очрашты һәм аларны үзенең фашизмга каршы көрәшеп үткән тормыш юлы белән таныштырды. Үз чыгышларында, язучылар да аңа бүгенге татар әдәбияты турында мәгълүматлар бирделәр һәм, шулай итеп, әңгәмә бик җанлы үтте.

В. Георг белән очрашуда язучылардан Г. Ахунов, З. Нури, Л. Ихсанова, Я. Винецкий, Р. Мостафин һәм В. Нуруллин катнашты.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ КОНСУЛЬТАЦИЯ БҮЛЕГЕНДӘ

20 августта язучылардан Ләбибә Ихсанова, Шәүкәт Галиев һәм Илдар Юзеев Азнакай районы редакциясе каршындагы әдәбият түгәрәге утырышында катнаштылар. Анда алар Марсель Галиев, Ирек Бәдертдинов, Нур Әхмәдиев хикәяләре, Нәфис Гәрәйшин һәм Фәһим Шәймәрданов шигырьләрен тикшереп, аларга карата үз фикерләрен әйттеләр, яшь авторларга эшләкле киңәшләр бирделәр.

## ШАГЫЙРЬ АВЫЛДАШЛАРЫ ЯНЫНДА

Күренекле өлкән шагыйребез Хәсән ага Туфан республикабызның Аксубай районындагы Иске Кармәт авылына барып кайтты. Иске Кармәт — шагыйрьнең туган авылы. Ул шунда унбиш яшенә чаклы яшәгән һәм укыган. Ә аннары, канатлары ныгыгач туган оясыннан очкан яшь бөркеттәй, читкә чыгып киткән һәм зур тормышка аяк баскан.

Бу хәл моннан илле биш ел элек булган һәм ул шуннан соң бер тапкыр да туган авылына кайта алмаган. Ничектер җае туры килмәгән. Әле менә та чыкмаган килеш китеп барган Хәсән Туфан илле биш елдан соң, чәч агартып, зур шагыйрь булып, житмеш яше тулган көннәрдә, ниһаять, сагынган туган авылына кайтты һәм авылдашлары белән очрашып, аларның хәзерге матур тормышлары белән танышты.

Шагыйрьне авылдашлары да сагынып көтеп торганнар икән: очрашу кичәсенә җыелгач, әдипнең чыгышын тын да алмыйча тыңладылар. Аннары үзләре трибунага күтәрелеп, шагыйрьнең әсәрләрен укыдылар, иҗатына югары бәя бирделәр һәм киләчәктә еш-рак кайтып йөрүен үтенделәр.

* * *

Түбән Кама әдәби берләшмәсенең җаваплы секретаре Әхмәт Гаязовның шигырьләре, консультация бүлегендә бернчә тап-

кыр тикшерелгәннән соң, ТАССР Язучылар союзы идарәсе тарафыннан М. Горький исемендәге әдәбият институтына иҗади конкурска тәкъдим ителгән иде. Ә. Гаязов әсәрләре конкурсларны уңышлы үтте һәм ул институтка студент булып кабул ителде.

## КОЛХОЗ ҖЫРЫ

Республикабызның Зеленодольск районында Вахитов исемендәге колхоз (председателе Фәһим Хәйдәров) алдынгы хуҗалыкларның берсе санала. Бөртекле ашлыкларны ул узган ел гектарыннан уртача 19 центнер чамасы алган булса, быел 20 центнердан артыграк җыеп алды. Хуҗалыкның кыяр үстерә торган бик шәп теплицасы, 33 гектар алма бакчасы бар. Шуның өстенә анда бик күп чөгендер, кәбестә үстерелә һәм колхоз ел саен дәүләткә күпләп бал сатып килә. Күгеш, Тугай һәм Айдар исемле авылларны берләштергән әлеге Вахитов исемендәге колхоз кешеләре әнә шулай әйбәт эшләү белән бергә, үз хезмәтләренең нәтиҗәсен күреп, горурлана да беләләр. Һәм алар ул горурлык хисен җыр аша әйтергә теләгәннәр иде. Хәзер аларның теләкләре тормышка ашты: шагыйрь Зәки Нури «бер булып типкән өч йөрәк»нең — Күгеш, Тугай һәм Айдар авылларының җыр текстын язды, ә якташлары композитор Арслан Батыршин аңа көй иҗат итте. «Алланә безнең алмалар» исемле ул җырны колхоз хоры башкара.

*Хөрмәтле иптәшләр!*

«Казан утлары» журналына язылу дәвам итә. Һәр айның 20 сенә кадәр сез алдагы айлар өчен журналга языла аласыз.

Безнең журналга бернинди чикләүсез һәм илебездәге теләсә кайсы элемтә бүлегендә язылырга мөмкин. Аңа язылу шартлары «Союзпечать»ләрдәге газета-журналлар каталогында күрсәтелгән. «Казан утлары» ул каталогка 73210 номерлы индекс белән теркәлгән.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ